# казан утлары

8
АВГУСТ-1974

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**8**

АВГУСТ
1974

## Бу санда

Ш. ГАЛИЕВ. Сигезьюллыклар . . . . . . . . . 3
А. ГЫЙЛӘҖЕВ. Язгы кәрваннар. Повесть . . . . . 8
Р. ХАРИС. Мәхәббәт сукмагы. Шигырьләр . . . 41
Ф. МОСТАФИН. Кенәриле Галимҗан. Хикәя . . 45
М. ЮНЫС. Тозлы җил. Повесть . . . . . . . . 49

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . . 109
Т. МИҢНУЛЛИН. Тау башында бардыр бер район. 110
М. ХӨСНИМӘРДӘНОВ. Сиңа тартыла күңел . . 115
М. ХАННАНОВ. Син кем, Саматов!.. . . . . . 123

СӘНГАТЬ

М. ЗАРИПОВ. Биеклекләр . . . . . . . . . 134

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

И. ИЛЯЛОВА. Академия театры сәхнәсендә — татар классикасы . . . . . . . . . . . . . 146

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Ә. МӘХМҮДОВ. Муса Җәлилнең тәнкыйть эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . 155
Р. МОСТАФИН. Үсештәге, хәрәкәттәге тәгълимат. 160

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

М. МӨЛЕКОВ. «Галиябану» ничек язылган... . . 167

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. УРМАНЧЕЕВ. Фикер гармониясе . . . . . 172**
**Ф. ХАТИПОВ. «Канатланыр чак»ның яңа варианты. 176**

БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

**Р. ГАЛӘВИН. Олылар да яратып укырлык . . . 180**

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

**«Яшь ленинчы» бездә кунакта.** Шигырьләр . . . 182

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . . 188

*Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 12.*

Баш редактор: **Гариф Ахунов.**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина.*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 30/IV-1974 ел. Басарга кул куелды 17/VI-1974 ел. ПФ 13095. Кәгазь форматы 70×108[1]/[16]. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 87700 экз. Заказ Ю-105, Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 12.

© «Казан утлары», 1974.

## Шәүкәт Галиев

# СИГЕЗЬЮЛЛЫКЛАР

●

Яшисең ил гамен кайгыртып —
Үткәнен, бүгенен, килерен.
Чиләнеп бетәсең чишкәндә
Мең төрле чуалчык төенен.

Гомернең буеннан буена
Гел шундый борчылу озатты.
Шул минем гомерне кыскартты,
Шул минем гомерне озайтты.

●

Тыныч яшәр идем, әгәр дә
Бер битараф булып яшәсәм —
Хаксызлыкка әгәр күз йомсам,
Чәчрәп чыгар чакта дәшмәсәм.

Тыныч яшәр идем, әгәр дә
Бар нәрсәгә кулны селтәсәм.
...Бик борчулы булыр идем лә,
Әгәр болай тыныч яшәсәм!

●

Күңелемдә күп кешеләр төре,
Ни кылсам да читтә калмыйлар,
Сугыш ялкыннары арасыннан
Мөлдерәтеп күзгә карыйлар.

Сүзсез-өнсез димә син аларны,
Күңелеңә кагып дәшәрләр!
Алар хыялынча яшәсәң син,
Синең белән мәңге яшәрләр!

●

Шома юллар яңалыкка илтми,
Үз юлыңны кирәк салырга,
Каршылыклар, кыенлыклар үтеп
Егыла-тора алга барырга.

Бер йодрыктай йомарлану кирәк,
Ихтыярны төпгә җигәргә.
Иң кыены шулдыр — бертуктаусыз
Үз-үзеңне кирәк җиңәргә...

●

Үз-үземә артык бәйләнчекмен —
Ул битәрләү, каты хөкемнәр!
Юкка чыгарулар... Мондый хәлгә
Чыдап тормас иде беркем дә.

Бүтән әйтсә, мин дә карышыр идем,
Каныга ул диеп, үч белән.
Үзем булгач — түзәм. Үземне мин
Колагымнан тартып үстерәм!

●

Тынгысызлык тәмам туйдыргачтын
Баш ташларга күпме тырыштым.
Һәм, ниһаять, менә, кача алдым
Ыгы-зыгысыннан тормышның.

Ялгыз калдым. Гамьсез берничә көн...
Уй-борчуга тагын күмелдем —
Тынгысызлык, ыгы-зыгысыннан
Качып буламыни күңелнең?

●

«Яшь чагыңда,— диде өлкән абзый,—
Шыпырт, тыйнак идең син бик тә.
Без сөйләгән чакта, кыймый гына,
Тора идең тыңлап бер читтә».

Күп сыйфатлар, әйе, үзгәргәндер,
Кайберләре тәмам беткәндер.
Абзый кеше, сезне тыңлап торып,
Безнең сөйләр чак та җиткәндер?

•

Табигатьтән ераклаша кеше,
Үзе һаман аңа омтыла —
Читлекләргә ябып кошлар асрый,
Аквариум тота йортында.

Читлек, аквариум белән алдап
Үзен-үзе, имеш, юата.
Офыклар бит сыймый читлекләргә...
Офыкларны, күңел, югалтма!

•

Дулкыннар ник ярга ашкыналар,
Диңгез иркенлеге тар мәллә?
Бу ярларның үзенә тарта торган
Без белмәгән сере бар мәллә?

Биек дулкыннар тиз тыналмыйча
Бәргәләнеп озак сүнәләр.
Вак дулкыннар бик тиз тынгы таба,
Башны комга куеп сеңәләр...

•

Эскәмиядән карны төшердек тә
Утырдык без төнге бакчада.
Иреннәргә генә сыенып та
Җылынып була икән, баксана!

Ул чактан соң бик күп җәйләр килде,
Яшисеңме икән онытып?
Кышкы бакча, көртле аллеялар
Күңелемне тора җылытып...

•

Беренче кат күргәч сәерсендем,
Кызлар шундый кырыс буламы?! —
Ялганмыйча сүзләр, аңлашмыйча
Урадык без күпме урамны...

Хәзер белдем, ялгышканмын икән
Синең холкыңа тел тидереп —
Һәркемгә дә күңлең ачык булса,
Миңа килеп җитмәс идең бит!

●

Үтте гомернең
Кайнар чаклары,
Хистән исереп
Сайрар чаклары.

Җитте әйләнеп
Карар чаклары —
Яшьлек нилекне
Аңлар чаклары...

●

Нур эченнән килгән яшьлек ул яз,
Ак канатлы наян күбәләк.
Җилкендереп, очындырып йөртә
Чәчәк шатлыгына күмгәләп.

...Моңсу яфракларны җилләр коя,
Юаткандай бизәп, алтынлап.
Хәзер миңа җимеш горурлыгын
Алып килгән көзләр якынрак...

●

Әйе, дуслар кирәк. Кемгә нинди —
Һәр очракта яклар өченме?
Юк, туры сүз, кырыс таләп белән
Сыный барыр өчен көчеңне.

Сыный барыр, ныгый барыр өчен,
Шунсыз лаек тиңнәр булмый ла —
«Дустым миннән шәбрәк булсын» дисәң,
Дустың да нәкъ шулай уйлый ла!

●

Сыналалар дуслар, сайланалар...
Ир уртасы булып җиткәндә
Тәмам төшенәсең — санда түгел,
Бөтен хикмәт җанда икән лә!

Көрәштәшләр, көндәшләр белән
Бер бөтен мин кеше күзендә.
Дусларымны әгәр бер югалтсам,
Югалырмын кебек үзем дә!

•

Тәүге җырларымның туган җире
Басу юлы, арыш арасы.
Кайбер елның хәзер игенен дә,
Тургаен да күрми каласың...

Күп кешеле юлга кушылдым мин,
Җырлар машинага утырды.
Туктап уйланырга вакыт та юк —
Мин оттыммы, җырмы оттырды?

•

Бер җыр язган зур шагыйрьләр булган,
«Карурман»нар туган, «Сарман»нар —
Бар моңнарын шуңа салганнар да
Халык күңелендә калганнар.

Йөз җыр язган вак шагыйрьләр йөри,
Ничек кулай — шулай сайрарлар!
Киң күңелле халык, тик ашыкмый
Йөз җырыннан берне сайларга.

•

Зур төзелеш, авыр эш барганда
Була бит ул чәчрәп чыгучы,
Җиңел генә чүкеч эләктереп
Көннең кадагына сугучы.

Еллар йөген алар тота алмый,
Азмы шулай сафтан чыкканнар?
Безнең көнгә лаек булыр бары
Гасыр кадагына сукканнар!

**Аяз Гыйләҗев**

# ЯЗГЫ КӘРВАННАР

ПОВЕСТЬ



Жанны өшетә торган салкын коры кич килде.

Көндез алдаучан җылы булып торды да, төш авышуга, мә сиңа, зират тавыннан өзлексез җил исә башлады. Зират тавыннан, кояш баешыннан искән җил, гадәттә, үзәнлектә ышыкланып утырган безнең бәләкәй авыл өстенә язын-көзен яңгыр, кышын исә кар-буран алып килә торган иде. Бүген битләрне аяусыз чәнчеп, кием-салымнарны әрсез йолыккалап туктаусыз коры салкын җил исте, суытты, көн ямьсезләнде. Карт-корылар мич янакларын сыйпаштырып чамалап тордылар да тиз үк мичләргә ягып җибәрделәр, ишегалларында, җил үтәрдәй араннарда калган мал-туарны җылы абзарларга куып керттеләр.

Көне буе ачык һавада уралганга, без көннең аз гына үзгәрүен дә сизеп-искәреп торабыз. Кичкә таба җиле бераз тынды, әмма салкыны кимемәде. Җил азаюына игътибар иттек, чын күңелдән сөенештек, ындырдан җиде олау солы төяп төнгә каршы Чаллы элеваторына юлга чыгасыбыз бар иде.

Кабан авылы аша барсак, юл шактый кыскара кыскаруын, әмма ике авыл уртасында җиде чакрымлы кара урман ята, кичә-бүген аязып торса да, урман юлларына тоташ яңгырлардан соң баш тыгарлык түгел. Шул сәбәпле әйләнечтән — Түбән авыл аша барабыз. Анда да шул ук кара урманның дәвамы, әмма андагы юл өстендә такта яру заводы бар. Завод дип, хәзер аның исеме генә калган. Сугышка хәтле анда чыннан да такта яралар иде, җидеме-сигезме түгәрәк пычкылары да бар иде, безнең тып-тын урманнарны ярып аваз салырлык бердәнбер гудок та шушы заводныкы иде. «Ду-у-у!» дип безнең яшь йөрәкләрне җилкетеп, күңелне кузгатып кычкыртып җибәрә торган иде, искиткеч! Бишавыл базарына кыяр сатарга барганда урманда гудок тавышыннан сискәнеп калтырансам да, авылга кайткач малайлар алдында атна буе үземнең дә мактанганым бар. Завод янында узу үзе бер рәхәт иде. Түгәрәк пычкылар күз иярмәс тизлек белән чож да чож әйләнәләр... Бөтен җиргә сап-сары нарат такталарны сыртлап өйгәннәр. Ап-ак юкә тактасы өемнәре дә бар. Бер кырыйдарак пычкы чүбе таулары тары көшеле сыман кояшта ялтырап яталар. Малайларның шау-гөр килеп шул

таудан шуып уйнауларына карап без үлеп көнләшә идек! Бөтен җирдә борынны кытыклый торган әчкелтем-татлы агач исе...

Хәзер завод үзе юк, озынча мунсу баракларның төбәләре арык ат сырты төсле бөгелеп җиргә иңгән... Аркылы-торкылы такталар белән ярым томаланган тәрәзәле бер-ике бүлмәсендә ялгыз карчыклар, тол хатыннар һәм житү чәчле, житкән тырнаклы балалар яшәп ята... Үткән-сүткәндә коеларыннан су эчеп китәбез, гаҗәп, кое суларыннан да нарат сагызы тәме килә аларның, ат сугарабыз, кышкы буранннарда, күзгә карангы төннәрдә барак тәрәзәләрендәге тычкан уты кебек кенә җемелдәшкән сүрән утларны күргәч эчкә җылы йөгерә!..

Авыр, мәшәкатьле юлларда һәр җан иясенә куанасың, ут яктысы ялгыз түгеллегеңне искәртә, терелтеп, көч бирен җибәрә!..

Шакмаклап-матурлап өелгән такталарны ташып бетерделәр, түгәрәк пычкыларның күгәреп тешләре коелды, пычкы чүбе көшелләре череп муртайды, аларны юан нык сабаклы алабуталар, сажин-сажин кычыткannар күмеп китте...

Урман юлын сугыш алдыннан гына вак таш җәеп, тракторлар белән таптатып нығытканнар иде, хәзер аның да күп җирен яңгыр-кар суы юып бетерде, юл кылдый-былдыйга әйләнде, шулай да ул кыргый, тар Кабан юлына караганда корырак, өметлерәк. Җиде чакрым әйләнеч безнең өчен бик күп, бик артык, югыйсә, әмма нишлисең, телне тешләп булса да йомышка-юлга, Чаллының атаклы икмәк складларына Түбән авыл аша йөрибез...

На, бахбай!..

Шулай дәрт иттек, Түбән авыл аша барабыз! Җил тына төшү дә безнең файдага, югыйсә, җилгә каршы бару атларга да хәлгә килә, безнең дә ачуны чыгара. Имән урамын чыккач та Түбән авылга таба тоташ үр төшә, арада каһәрле генә ике чокыр бар. Берсе Сай чокыр, икенчесе Тирән чокыр... Гел безне сагалап торган шул каһәр суккан тәбеләр дә булмаса... җил дә унайдан иссә... әйләнечтән юл турырак!

Иөк өстенә ике солы көлтәсе бәйләп куйган идем, арка терәп утырырга бик җайлы, фил колагы тикле якалы толып-чикмәнгә төренәсең дә һәйбәтләп менеп кунаклыйсың.

Күз тимәсен, юл да болай коры гына, соңгы атналарда солы тирәсендә бераз тугайган атлар да күндәм генә баралар, майламаган тәгәрмәчләр генә ризасызлык белдереп шыгырдыйлар...

Имән урамын чыгып бер җир буе киттекме икән, уң яктан, Олы су дип йөртелгән үзебезнең инеш буеннан, үзәнлектән җыр тавышы ишетелде. Бер кыз җырлый иде. Башта, бу суыкта, күз бәйләнгәндә кайсы исәре шырылдап йөри икән дип, мәзәк итеп кенә тыңлаган идем, кинәт калкынып турайдым, чикмән якамны кайтардым. Кызның тавышы аермачык ишетелә, кызның тавышы йөрәкне өзәрлек моңлы, ягымлы иде.

Җил басылды, бөтенләй тынды-сүнде, атлар адымнарын акрынайттылар, сагайдылар, тәгәрмәчләр генә әрсезләнеп шыгырдый, тын тартырга куркып колакларымны үрә торгыздым. Кыз юлга таба чыга иде, ахрысы, чөнки аның тавышы яңгырабрак, моңы үтемлерәк, сүзләре ачыграк ишетелә башлады. Ни тырышсам да, кызны аермачык таный алмадым, җыры исә бөтен барлыгымны, арба-атымны, юлымны, барымны һәм кайтырымны, каралып-куерып килгән офыкларны күмеп китте, онытылдым! Ташкын иде аның тавышы, моң дәрьясы иде!

Үз ирекләренә куелган атлар тагын да акрынрак атлыйлар, кызның сүзләре ап-ачык ишетелә башлады. Кыз кабат-кабат бер үк сүзләрне кабатлый икән.

Алтын булып агаем ла...
Көмеш булып тамаем!..

Аның да күңелендә иләс-миләслек, ярларына сыешмаслык яшьлеге тулышып ага иде бугай, чөнки ул шушы сүзләре белән сихерләнгән, тылсымланган иде. Бары үзе өчен генә, үзенең моңлы күңеле өчен генә, үзенең татлы рәхәте өчен генә яшертен җырлавы, шуннан тәм табып бәхет эчендә йөзгәне аңлашылып тора, ул инеш үзәнлегендә, Олы су иңкүлегендә, алай гына да түгел, җир йөзендә, чиксез-үлчәүсез галәмдә бары тик үзе генә дип уйлый иде. Түбән авыл юлында җиде атлы аны тыңлап барадыр дип, уена да кертмәгәндер.

Без — җиде кеше. Җиде төрле ата баласы. Толлар да бар арабызда, буй җиткән ятим кызлар да, безнең сыман егет-җилән дә бар. Кем елагандыр, кем сөенгәндер, бу җырны берәвебез дә ишетми калмагандыр...

Атлар Тирән чокырның караңгы авызына барып туктагач, сискәнеп киттем: кем мин, кая барам болай?!

Иң арттагы аттан төшкән Дамир кыскарак кәкре аякларын яза-яза миңа якынлашты:

— Ибраһим, әй, ишеттеңме? — дип сорады.

— Саңгырау түгел лә,— дидем мин, атымның аркалыгын тикшереп.

— Син дә инде,— диде Дамир, кинәт үпкәләп,

Уңайсызланып киттем, һич уйламаганда, иптәшемне үртәп маташам икән ич! Сугыш безнең елгыларга да якыная башлагач, хәрби комиссариаттан кайтканда Дамир: «Колак сызлый, малайлар, минем, ишетүем хөрти», дип сөйләнгән иде. Андыйга сизгер егетләр шундук эләктереп алдылар: «Колакай да колакай! Саңгырау да миңгерәү! Армиягә барырга дигәч, Дамирның колагына гөмбә үскән!»

Солдатка каралучылар теленә эләкмә, ник әйткәненә үкенгәндер Дамир... Яшьтән үк кушаматларга бай булды ул, әтисе дә тапкан исем, тьфү... «Тамыр» да диделәр аны, «Камыр»да, Дамир дип әле ничә ел гына эндәшә башлаганнар иде, хәзер «Колакай!»..

Аны-моны абайламыйча мин дә шуңа ишарәләгән булып чыктым...

Чокыр тирәсендә бөялешеп торганда, җыр тоныкк кына булып тагын яңгырап китте, хәзер инде ул шактый еракта, сүзләрен дә, моңын да тәгаен аерып булмый, җыр авыл ягыннан минем йөрәккә тоташ моң булып кына сызылды, язын килгән тургайлар, былбыллар барысы бергә җыйналып, китәр алдыннан безнең яклар белән хушлашып, суык шәфәкъка карап күмәк иңриләр төсле тоелды.

Каян килгәндер минем иләс-миләс күңелгә мондый чагыштыру, валлаһи, ул мизгелдә шулай уйладым!

Тирән чокырда мондый караңгы кичләрдә аерата сак булырга кирәк, аның җәенке төбенә ел саен яңа эз салабыз, ел саен аны язгы ташкыннар тирәнәйтә, киңәйтә, авызыңны ачыбрак барсаң, атың-арбаң белән берәр яры тәкмәрләвең бар! Барыбыз да арбалардан төшәбез, алга чыгып, дилбегә башын тартып тотып, атлар белән янәшә атлап, аларны тыеп, алдагы олауның тәгәрмәчләренә генә карап барабыз. Иң алга яшен утыдай үткен күзле, йокы белмәс Сабираттәй чыга, аның хәтере искиткеч шәп, Чаллы юлындагы бөтен чокыр-чакырларны үзләренең мич төбен белгән кебек белә ул.

Хәвеф-хәтәрсез генә бу шомлы урынны да уздык.

Хәзер атларны йолыккалау юк, аларны үз җаена куеп, җәяү генә барабыз. Дамир тагын минем яныма килде, камчы сабы белән юантык муенын кашып:

— Кем икәнен белдеңме? — диде.

Төпченеп баруына ачуым чыкты, искәрмәстән яңгыраган моңны үземнеке генә итәргә теләдем, шуңа күрә баягыдан да кырысрак итеп җавап бирдем:

— Йөри шунда тилереп!

— Югары очның Әдилә тутаң булыр ул!

Сискәнүемне белдермәс өчен йөткерендем, үзем дә Әдиләдер дип уйлаган идем аны! Шул икән, үзе икән...

Әдиләнең жырлаганын байтактан ишеткән юк иде. Былтыр яз, кар астында кышлаган башак ашап, Сарсаз авылында кияүләге апасы үлде Әдиләнең, дүрт баласы тезелешеп калды. Әдилә шул ятимнәрне карарга Сарсазга жизнәләренә китте дә инде ике жәйне, бер кышны шунда уздырды. Жырны шунда өйрәнеп кайткан дисәм, ай-һай, дүрт сабый янында жырларга вакыты калды микән? Хатыны үлгәннән бирле, жизнәсе дә бик рәтсезләнгән, бик эчә дип сөйләгәннәр иде. Бөтенләйгә кайтты микән Әдилә, әллә сагынып, кунакка гынамы?

Жизнәсе Сталинград янында кулын гарипләтеп, кырык икенең азагында ук сугыштан кайткан иде аның, кулын асып безнең авылда өйдән-өйгә ашка йөргәне дә хәтердә. Гармунчы кеше иде ул, тирә-якта бер иде, хәзер гармун уйный алмагач бара-бара да туктап әче итеп сызгыра... Сыңар кулы белән хатынын кысып коча да тагын сызгырып жибәрә иде... Гомердә дә андый зәһәр сызгырган кешене күргәнем юк иде. «Халык саны ишәйсен!» дигән аның жизнәсе, һәм алар ел саен бәбәй алып кайттылар...

Көтмәгәндә хатыны үлеп киткәч, Әдиләгә өйләнергә ниятли икән дигән сүзләр дә йөрде, балалар чит кулга калмасыннар, синең үз каның бит, дип жизнәсе бик ялына икән, диделәр... Инде өйләнешкән дигән хәбәр дә тараттылар.

Сугыш елларында чыбыксыз телефон бик шәп эшләде, кем турында ни генә сөйләмәделәр, һәр ялтыраганның алтын түгеллегенә без күнеккән идек инде, соңгы имеш-мимешләргә ышанмадык. Дамир «Әдилә тутан» дисә дә, бездән ике-өч яшькә кече бит әле ул, гәүдәгә түгәрәк кенә булса да, без жиденчедә йөргәндә билсез сары бишмәт киеп, киндер букчасын асып дүртенче класста укыды. Дүрт балалы иргә чыгамы соң Әдилә?!. Шулаен шулай да, сугыштан соң ир-атның базары күтәрелде, торна баласы төсле озын торыклы алты-биш Ширияз Фәрите дә өч-дүрт хатын алып аерды инде!..

Әдилә... Әдилә... Бер-ике тапкыр чәчен тартып елатканым да бар... Ул үзгәргәндер, без дә үстек... Сылу гына кызлар Дамир белән безгә дә каш сикерткәлиләр хәзер, аулак өйгә чакыралар, чиккән кулъяулыгы берәләр, ап-ак өч пар пирчәткәм агач чемодан төбендә ята...

Юк, Әдилә акылсыз бала түгел, Югары оч кызы булса да, мин аны әйбәт беләм, Сабирҗан абзый кызы, дүртенче-бишенчеләрдә укыганда ук «Мирсәет бәете»н жырлап карчык-корчыклардан балавыз сыктыра торган хисле, моңлы бала иде бит ул.

Дамир ничек танып алган диген, менә сиңа колакай!

Үзгәргәндер Әдилә, күрмәгәнгә ике жәй, бер кыш узды лабаса! «Көмеш булып тамаем» диме? Зарлану, кайгыру түгел ич монысы, кешегә, дөньяга, жиргә яхшылык теләү! Изгелеккә, юмартлыкка омтылып жирсенә бит кыз күңеле! Кияүгә китсә жырлап йөрмәс иде, жырласа да сүзе, моңы бүтән булыр иде, чыкмагандыр, юктыр, юктыр, юктыр...

Арба тәгәрмәчләрем күңелле генә шыгырдыйлар...

Көмешне күргән бар анысы! Әллә нинди ят ил императорларының олысымак сурәтләре сугылган көмеш талирлар әбинең чулпысында чыңчың итеп китә торган иде.

Әдиләне элекке кебек итеп сәхнәгә чыгарасы иде бер, тамсын иде, чәчелсен иде көмеш булып!

Юк, Әдилә алай ансат кына билен бирмәс, усаллыгы да, чаялыгы да житәрлек кызыйның. Бер заман, ул бишенчедә чакта, артык иртә калкынган күкрәкләренә уйнап кына кагылып киткән идем, сул ягагыма шундый чәпәде, искә төшкәндә хәзер дә кызарам...

Арба тәгәрмәчләрем шаярышып жырлашалар!..

Кайчан кайтты икән, кайчан?

Кайчан китә икән?

Китәме?

Борылып иптәшемә кычкырдым:

— Дамир!

— Нәрсә бар? — диде ул, иренеп кенә.

— Бер нәрсә дә юк!..

— Юкка мин үзем дә тук.

Без ел әйләнәсендә диярлек Чаллыдан кайтмыйбыз. Көзен икмәк илтәбез, язын симәнәгә элеваторга барабыз, сельпога товарларны Чаллыдан алып кайтабыз, Казан-Мәскәүләргә дә юл Чаллы аша, пристаньнан районга тозны да шуннан ташыйбыз. Кайчан кушсалар да, вакыт дип, читен дип тормыйбыз, берсүзсез чыгабыз да китәбез. Күнегелгән эш, таңда да кузгалган бар, ярты төндә дә, атлар гына хәлле булсын, алар чыдасын, без карышмыйбыз, безнең эшебез шул, яшәвебез шул. Тик бүгенге сәфәр минем өчен аерым бер мәгънә алды, шушы мәшәкатьле дөньяга кирәгемне мин шушы кичтә ачыграк тойдым, үзебезгә йөкләнгән гап-гади эшләр олы да, кирәк тә булып киттеләр... Моңарчы карышусыз гына, баш иеп кенә атлы эштә йөрүебездә безнең җитлегүебез, өлгерүебез дә күренә икән!

Юлыбыз да унды: яңгыр яумады, атлар талчыкмады, икенче көнне төшкә келтерәтеп элеваторга ук барып кердек. Чират та тиз узды, йөкләр дә яхшы чыкты, Гыймай Фатихының йөгеннән генә ике пот солысы җитмәде. Төп-төгәл утыз ике килограмм. Җитмәүчелекнең болай төп-төгәл булуы безне бераз шиккә төшерсә дә (Фатихның чак кына шаярганын белеп йөрибез, артка да калгалый, күздән югалып йөргән чаклары да була. «Эч авыртты, парин, рәт югалып тора әле... Фатирга төшкәч, шомырт суы кайнатып эчми ярамас!»), җиде олауга утыз ике кило күпмени ул, үлчәгәндә ялгышканнардыр, дигән фикергә килдек. Фатих үзе кояшта уңган солдат фуражкасын салып селкә-селкә айкояшлар белән карганды, элеваторга икмәк кабул итүчеләрне мутлыкта гаепләде.

Кызыкканнар ди анда синең ике пот солыңа! Фатихның каргануы безнең шикне арттырса да, дәшмәдек...

Кәгазьләргә кул куярга кергәндә, син урысча әйбәт беләсең, дип, олау башлыгыбыз Сабираттәй кантурга мине дә алып кергәли. Бүген дә чакырды, утыз ике кило җитмәгәч, бер-бер сүз купмагае дип уйлагандыр инде. Накладнойларга кул куючы юантык кына, алтын тешле түтенкә:

— Ничек әле анда, китерәсе икмәк күп калдымы калхузыгызда? — дип сорап куйды. Моңарчы чеп-чи марҗа дип йөргән түтенкәбез чыкылдаган татар апасы икән!

— Күбе каян килсен,— диде Сабираттәй өзелеп.

— Симәнә калдыра алдыгызмы соң? — дип кызыксынды апа.

— Бар булганын кырып-себереп алып килдек,— диде кистереп Сабираттәй. — Быелгы иген дә келәт күрмәде, бурага төшмәде, амбарлар җылашып утыра, ындырдан туп-туры монда ташыдык, хөкүмәт үзебезнеке әле, язын орлыксыз калдырмас. Монда ышанычлырак саклаңыр.

Апа артык тирәнгә кермәде, маңгаен җыерып, безгә бик мәзәк тоелган кызыл иренен бөреп торды да чуар тышлы шәмәхә карандаш белән безнең кәгазьләргә кул куйды. Йөкләр янына чыккач карасак, теге җитмәгән ашлыкны безнең өстән чигергән икән.

Сабираттәйне бу яхшылык куандырмады, аның Фатих мутлыгына үз хөкеме булгандыр, ахрысы, кәгазьләрне аннан-моннан гына төрде дә түш кесәсенә салды. Аның болай да калкып торган түше тагын да зуррак булып бүлтәйде.

Әйе, Сабираттәй теге апага ачы хакыйкатьне әйтеп бирде: ындыр тирәсенә ашык-пошык куелган соңгы эскертләр дә язгы кар көртләре кебек эреп бетте, сушилка калайлары ялтырап калды, келәтләр буп-буш, хуҗалыклардагы бураларда да тычкан куанырлык та бөртек юк иде. Барын ташып бетердек. Алда авыр, озын кыш. Председатель «фуражга-нужага» дип аз-маз чүпле солы белән, печән өстенә, халык бик киселгәндә тотылыр дип чак кына бодай калдырырга чамалаган икән дә, районнан боерык биреп үзен нык кына пешерделәр. Калганын да тиз үк илтеп тапшырдык...

Икмәк бетте, эш кенә бетмәде. Атка да, безгә дә тынгы юк. Мәктәп утынсыз утыра. Авыл советына, идарәгә, клубка да кыш ягарлык әзерләргә кирәк. Үзебезне дә онытып бетереп булмый, төннәрен председательгә әйтмичә генә Кабан урманыннан йөге-йөге белән өрәңге әрдәнәләр чәлдереп кайтабыз. Туган-тумача да сорый, карчык-корчык, ятим-ялпы да ялына, ташымасаң читен, үпкәлиләр. Утын чыгару солы ташу түгел, икмәк тирәсендә акмаса да тама шунда, кыска җәйдә болай да ыгып житмәгән бахбайлар утынга йөри башлагач, тагын йөгәнеп калдылар. Бер атлыйлар да ике ял итәләр, әле бит бу көз, язга таба ни булыр?..

Буш вакыт, сирәк эләккәнгә, безнең өчен бик кадерле.

Бүген шундый кичләрнең берсе. Герәнә бәләкәй йозак тагылган күгәргән калайлы стена сәгатебез кичке сигезне күрсәтә. Урамда дөм караңгы. Өйгә тәмле ис таралган, казанда бокыр-бокыр тары боткасы пешә. Тәрәзәләр тирләгән, шабыр суда. Чөелдерек бавы эзләргә дип кичкырын келәткә кергән идем, киштә түреннән жиденчедә укып йөргән китапларны табып чыктым. Киселев «Алгебра»сы. «Ана теле». Саргайганнар. Тышлары купшакланган, бит почмаклары кителгән...

Шул китапларга карап ятам. Тамыр алу да онытылган, кушма җөмләләр турында әллә ни белмим... Икс, игрекларның барысы да «икс» миңа хәзер.

Ишек шапылдады, әнкәй керде дип калкынсам, ят тавыш тамак кырды, кәнсәләрдән дежур килгән икән.

— Ай-яй, тәмле ис тараткансыз,— диде ул, шадра танавының киң тишекләрен киереп иснәп.— Каз итеме әллә?

— Утыр, Бәдәр җиңги,— дидем мин,— сыйланырсың. Сөтле ботка пешә.

— Вакыты бармы соң аның? — диде Бәдәр җиңги, чабата башына ябышып каткан карын кага-кага.— Көн йөгертәләр, төн йөгертәләр. Әллә сабан туена чабышка әзерлиләр инде?

Ул үз сүзенә үзе рәхәтләнеп кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Тагын нәрсә булды? — дидем мин, нидер сизенеп.

— Ни дип, сине чакыралар. Әйдә, киен.

Әнкәй күршеләргә көнбагыш мае сорарга кергән иде, ул чыкканны көтеп кенә тордым да идарәгә киттем.

Кәнсәләрдә шул ук күренеш. Шәп-шәрә өстәл артында председатель Хәкимҗан абзый утыра, өстәрәк, калын, саллы рамы белән түшәмне терәп, Сталин портреты эленгән. Сугыш беткәнгә байтак вакыт узса да, председателебез һаман медальләрен тагып йөри. Сул почмакта өстәл лампасы янында хисапчы утыра, ул үзенең калын кенәгәсенә кадалган.

— Җә, ускәнем,— диде Хәкимҗан абзый, медальләрен чыңлатып.— Ни хәлләрең бар? Иминлекме?

Берәүнең дә миннән «хәлең ничек?» дип сораганын хәтерләмим, уңайсыз булып китте, аптырап иңбашларымны боргаладым. Председательнең минем хәлне белешәсе килүе сүзгә җилем булсын өчен генә икән, җавап көтеп тә тормады, сүзгә күчте.

— Менә ни иде бит әле, ускәнем, сиңа пачутлы гына бер эш табылып тора әле монда. Әкәләле имән ауган дип әйтимме, тавыгыгыз

алтын күкәй салган дип үк җибәримме, мәгәр үзең дә чамаларсың, тәтенең йөрми түгел, йөри, җиде тулы класс белемең бар, ТБУМ бетердең, без менә дүрт класс белән җитәкчелек итеп киләбез, күреп торасың, урамга куып чыгарган кеше юк. Аннары ки шул, тормыш көйләнебрәк бара. Көйле тормышка яңачарак кешеләр кирәк.

— Кая барырга? Кайчан? Бүгенме? — дидем мин түземсезләнеп.

Хәкимҗан абый эре төкле очлы ияген бик тәмләп кашый-кашый күзләрен челт-челт йомып куйды:

— Кабаланма син, үскәнем, ни сөйлидер идем әле? Ә-ә, менә шул булыр сиңа, гәҗитләр караштырасыңдыр, ягъни Казаннан да язалар, Мәскәүдән иптәш Сталин үзе күрсәтмәләрнең иң кирәген биреп тора, авыл хуҗалыгы бүгенгесе көннән башлап шундыен чәчәк атачак ки, үскәнем, шаклар каткыч булыр. Менә шул ие минем сиңа әйтер сүзем. Әйе. Мытыестан кәгазь килде, ике пичәт басылган, районн начальствосы да кул куйган, трактористлар курсы ачалар, бездән өч кеше сорыйлар.

Нигәдер көләсем килеп китте.

— Юк сүздер ул, Хәкимҗан абзый. Юк тракторга нинди курс ачсыннар? Безнең авылдагыларына эш юк.

— Син алай сөйләп, үскәнем, нитмә, беләсең... Тракторлар кайтып төшкәч кенә соңга калу булыр ул. Үрдәк кенә астына су кергәнен көтеп бакылдап утыра, әйе, без хәзерге моментның вәжнилеген бер минут та истән чыгармаенча яшиек, шул. Димәк ки, болай итик, үскәнем. Гәүдән шәп, җегәрең бар, тракторга аңа көч тә кирәк. Тракторчылар бар дисең икән, кемне әйтәсең алай? Сабира апаңнымы? Искерделәр инде алар, туздылар. Карап торырга гына яңа... Син, пример әйткәндә, яшь кеше, сиңа укуы да кирәк. Өч айда әллә ни тиклем гыйлем алырга була, дәрт иткән кешегә ел кирәкми. Чут-чут кенә калхуздан да ярдәм оештырырбыз, мытыес үзе дә гел үк буш итмәс, байлыклары бар, җыен, өч айга Чаллыга барырсыз. Тик, матри, адәм көлдереп йөрмә, тиешлетиешсез кеше белән, бигрәк тә азгын хатын-кыз белән чуалма. Югары авыллар сыната торганнардан түгел, сугышта да үзләрен күрсәттеләр.

Ул тагын рәхәтләнеп сакалын кашыды, медальләре кул хәрәкәте җаена челтер-челтер чылтырадылар, хисапчы кенәгәдән башын калкытты да лампаның филтәсен күтәрде.

Кәефем килгәнне сиздерми генә, ярар, дип башымны иеп чыгып киттем.

Тракторчы!..

Безнең Югары авыл керәшен белән кара-катыш булып, авылыбызның беренче тракторчысы Будрин Борис иде. Авылда кушаматсыз кеше юк, Бүрис дәдәйгә дә яңа һөнәре кушамат булып ябышты. «Будрин Бүрис — тракторист!» дип такмаклый иде малай-шалай... Әллә кызыгып, әллә көнләшеп гел аның артыннан ияреп йөри торган идек...

Бөдрә чәчле, кара тутлы чибәр йөзле Гөргери дәдәй колхоз машинасы белән сугышка чыгып китте дә машинасыз кайтып керде. Исән кайтуына сөендек, аның да кушаматы «шофер Гөргери» булып беректе. Машинасы булмаса да — «шофер». Чөнки ул беренче! Хәзер безнең авылда бензин исе районнан югары начальство килгәндә генә аңкып кала, кыйбатлы хушбуй исе белән бер безгә бензин исе! Мытыес тракторлары безнең бәләкәй колхоз кырларына килеп тә карамыйлар, чират җитми.

Кайтыр тракторлар, ансыз булмас, хәлле-хәлсез унҗиде ат белән әрем-билчән баскан кырларны үңдырышлы итәрмен димә, тракторсыз һич ярамый безгә! Шәп төрәнле сабан тагып ургылып кереп китәсе иде дә офыктан-офыкка сөреп ташлыйсы иде!..

Сабира апа хәтергә төшеп, аны җәлләдем. Тузгандыр да шул, бар иде аның мактаулы чаклары, башта плугарь булып йөрде дә, Чат Нурлыгаян малаен сабанга утыртып, үзе трактор йөртә башлады.

Нурлыгаян малаен егет итте, ир итте, алак-шалак йөргән кешедән ударник ясады, Казанга механизаторлар конференциясенә бергәләп бардылар, Мәскәүдә Калинин белән рәттән утырып карточкага төшеп кайттылар. Сабира апага медаль дә биргәннәр иде... Сугыш башлангач ире танкист булып китте. Сабира апаны алмадылар, йөрәгендә бар икән, диделәр... Булса да булгандыр, ире Орел каласы янында танкта янып һәлак булгач, идарә баскычы төбендә егылып чак дөнья куймады... Тузарсың да!..

Мытыестан ашыктырдылар, атна да узмагандыр, җәй буе йөрткән сбруйларымны Дамирга илттем, нык арыгайган, зур күзле юлдашым Озынъял белән саубуллаштым.

Такта чемоданга чабата киндерәсе белән киндер тышлы колак мендәрен бәйләдем дә Чаллыга юлга чыктым. Бу юлдан байтак кешеләрне әле сугышка, әле бәхет эзләргә Пермь, Ярослау якларына озатканым бар, хәзер үзем китеп барам, хәерлегәме? Дөнья безнең кулга күчеп бара торгандыр шул...

Имән авылын чыгуга, әллә нишләп күңелем тулды. Юк, авылдан китү, әнкәйдән аерылу сагышы түгел иде минем күңелдә. Чаллы ерак түгел, бик сагынсаң җәяүләп кайтып килергә дә була! Минем күңелне моңарчы тоелмаган, моңарчы бар икәнлеге дә беленмәгән ят сагыш, ят моң биләгән иде. Имән урамының ава-түнә утырган иске-москы текмә читәннәренә тикле моңлы, сагышлы иде бүген... Колак төбемдә тургай җыры кебек булып сихри өн чыңлый иде.

«Алтын булып агаем ла!..»
Әлә-лә-ләү!
«Көмеш булып тамаем!..»
Әлә-лә-ләү!..

Көн суык. Көн шыксыз. Юл кантарлары бозланып каткан. Ак чебеннәр оча, чокыр-чакырлы юлдан арба дырык-дырык бара. Дамир — олаучы, ул безне Чаллыга хәтле илтергә тиеш.

Дамир белән безнең аралар кызык кына була башлады. Ни атна, ни шимбә дигәндәй, тиктомалдан Әдилә турында сүз башлый да минем күңел кылларын тарткалап карый. Я булмаса бер дә юкка Әдиләне яманларга тотына. Чигү-тегү эшен дә белми, имеш. Фәлән дә төгән, имеш. Аның кызыксынуын сизеп мин дә сер бирмәскә булдым. Ак димим, күк димим, белми торсын әле!.. Малай җүләр түгел, сизенде, сизенгәч, үчегешергә кереште. Юлга чыксак, атын иң алга куа. Кичке уенга җыелсак, минем сүзләрне очсызга чыгарырга тырыша. Гомергә уртага чыкканы юк иде, гармунчы чакырып мунчаларында биергә өйрәнә башлаган! Күрегенең җиде җиреннән тын өреп торган җиде бакалы тальянын кардыга, ат караучылар йортына илтеп куйды, буш вакыты булдымы — шуны шырылдата, өйрәнә, янәсе! Гел алга чыгарга, гел узарга тели Дамир.

Минем курска барасын ишеткәч, шартлый язды малаең! Бусында үзем дә аны җәлләдем, өйләренә бардым.

— Әйдә, мин әйтәм, Хәкимҗан абзыйны кодалыйк, бергәләп укырбыз.

«Юк» дип кул гына селкеде бу. Мин үгетләргә тотынгач, серен сөйләп бирде. Теге вакытта военкоматтан «колагым каты» дип юрамалый әйтеп кайткан икән ул! Төс аермый икән егет, дальтоник икән! Кызылы белән яшеле бер икән тегенең. Военкоматта караган күз врачы аңа кистереп әйткән: «Армиягә дә алынмыйсың, машинага да утырмыйсың, үзеңә кулай бер һөнәр тап», дигән...

Тез астына суктылар егетнең! Без Чаллыга укырга китәбез, тирәюньдә дан таралды, ә ул монда җимерек кардыда атлар янында кала...

Телгә алмыйм дип тырышсам да, Дамирга карауга шул искә төшә: кызыктыр инде ул, ә? Болыннар кызыл булып күренәме аңа? Ә шәфәкъ ямь-яшелме? Менә сул кул яктагы Сарсаз авылына хәтле сузылган уҗымнар аңа кып-кызыл булып күренәдер? Ә кызларның бит очлары ямь-яшел... Яшел някле Әдилә!

Чыдый алмыйча шаркылдап куйдым, Дамир сизенә, төс аермый торган күзләрен акайтып миңа карады:

— Шүрәле кытыклыймы әллә сине?

— Юк ла, бер кызның няге искә төште.

— Кутырлаганмы?

Дамир һич кенә дә тик утыра алмый, боргалана, терсәге белән минем касыкка килеп орына, авырттыра, артка да карый, як-якка да, тегенең нидер әйтәсе киләме шунда, кысталган кеше күк бара да бара. Ахырда чыдамады егет, күзләрен читкә борып:

— Тегене күрмәденме? — дип сорады.

— Кемне?

— Кыланып барма инде, белмиләр ди! Әдиләне инде... Җырлап узган иде бит.

Ул да нәкъ шуларны уйлап бара икән! Юк шул, күреп булмады Әдиләне, өйләрендә җан әсәре сизелмәде. Күрше-күләннән сорашырга читенсендем...

Теге чакта, җыры белән безне озатып калганда, Әдилә ике-өч көнгә кунакка гына кайткан булып чыкты...

Бу араларда клуб ачылмады; каз өмәләре башланмаган; аулак өйләр дә тынып тора. Ни арба, ни чана дигәндәй, тегермәнгә баручылар да юк, вак-төяк йомыш белән Чаллыга, я башка олырак урыннарга чыгып китүче дә күренмәде. Менә без генә өчәүләшеп китеп барабыз...

Кар сизелерлек оча башлады, вак кына үткер кырлы ярма кисәкләре бит очын чеметтереп-чеметтереп коелалар. Дамирга аркамны терәп барам, болай җылырак та, сөйләшмәскә дә җайлы...

Тик аның белән сөйләшергә туры киләчәк, бик нык сөйләшергә туры килер, күңелгә шулай тоела...

Күңелгә килгән — алга килә, диләр, рас икән, безне ашыгычрак озатканнар булып чыкты. Курслар менә-менә оешып кына килә икән, бинасы да юньләп каралмаган, уку әсбаплары да юк, тегесе житешми, монысы әзерләнмәгән. Безгә, иртәрәк килгән бәхетле кулларга, байтак вак-төяк эш белән маташырга туры килде. Ишек-тәрәзәләрне ныгыттык, пилорамнан пычкы чүбе ташып нигезне җылыттык. Кыскасы, без килеп ике атна узгач кына барысы оешты. Һич көтмәгәндә, эшләгән өчен безгә бераз акча да биреп куйдылар, күңел күтәрелде, курсантлар да җыелып бетте, уку башланды. Бик дәртсенеп тотынган идек, өч айда гына программаны уза алмадык. Трактористка ни кирәге бардыр, безне капиталистик илләрнең географиясен дә, тарих укытып та җәфаладылар.

Үз бусагаңнан чыгып киттеңме, туган җиреңне аңлый башлыйсың, ныграк сагынасың, диләр. Рас икән, Әдилә матур турында торган саен ешрак уйлый башладым. Ятсам төштә, торсам истә дип бик белеп җырлыйлар икән безнең Югары авылда!

Кызның хәлен кем аша белергә дип озак баш ваттым. Үзенә атап хат язар идең, уңайсыз. Төрле-төрле гайбәтләр йөрде, дөресме алар, түгелме — кем җеп очын эзләгән? Әнидән сорап язар идем, өйдән чыкмый яткан кеше яшьләр арасындагы хәлләрне каян белсен?

Тоттым да Дамирга хат яздым. Бик озак көттереп, Яңа ел бәйрәмнәре узгач кына авылдаштан җавап килде. Кич иде, зәңгәр эңгердә, тәрәзә бозына иңемне терәп, авыл хәбәрләрен укыдым.

«...Куып кайтармасалар, ят рәхәтләнеп, озак тоттылар дигәнне теленә дә алма... Клуб үз урынында. Якмыйбыз. Утын бетте. Яңа ел вече-

рына дип ике чәнәшкә белән утын алып кайткан идек, вечерның да рәте булмады... Үлем-житем юк. Өйләнүче юк. Үзем атлар арасында — генерал! Старший конюх иттеләр дәдәнне. Гармунда «Сирбиянка»ны сиптерә башладым... Печән бетте, рига түбәсеннән салам ташыйбыз. Теге, известь базлары янындагы чокырларга тутырган айбагыр силосы чергән булып чыкты, су үткән. Ярамады. Аулак өйләр буламы дигәнсен, монда безнең уен кайгысы түгел, сезнең сымак казна ипиендә симерешеп ятмыйбыз. Әдиләне сорагансың, кайтканы да, күренгәне дә юк. Кияүдә дә диләр, юк та дип әйтәләр. Жизнәсе куены татлыдыр шул ана! Кайткач үзең сорашып белерсең, миңа кирәге шул тиклем генә, үпкәләмәссең. Чәчүгә кайтып житә аласызмы? Тракторны шуннан ук бирeп жибәрәләрме?»

Кызарындым, бүртендем, нишләргә белмәдем. Иртәгесен зачет иде, белгән сорауга җавап бирә алмыйча «начар» эләктердем...

Каян тешләргә белгән бит малаен! «Жизнәсе куены» дигән... «Трактор биреп җибәрәләрме?» дигән! Көнендә очраса салма савытының читен китә идем китүен...

Сүз тынлый торган гадәтем бар, шуңамы, яратып, тырышып укыдым. Тракторны гына түгел, башка машиналар тирәсендә дә «ипилектозлык» беләсем килде. Мастерскойдагы кыру станогын бик яраттым... Тик һаман да тәмам онытылып китеп булмый, яз якынлашкан саен күңелдәге пошаман үзен ныграк сиздерә иде. Дамирның тетмәсен тетеп тә, юмалап та хатлар язып карадым, күңелдәгедәй итеп җавап язмады егет, Әдиләне кабат телгә дә алмады.

Имтиханнардан котылдык, кулга «тракторист» дигән документ тоттырдылар. Иптәшләр, укытучылар белән саубуллаштык та фатирларга таралыштык. Олау көтәбез. Алдан хәбәрләшкән буенча безне алырга ат җигеп Дамир үзе килергә тиеш. Председатель айгырын җигеп килер микән, әллә үзе җигеп йөри торган берәр җегәрле атта гына килерме?

Минем дә, авылдашым Торна Хәмитнең дә тракторист булып авылга шәбрәк атта юрттырып кайтып керәсе килә! Председатель айгырында выжлап авылга барып керәсе иде дә бит!..

Хәмит дигәннән, өч-дүрт ай бергә аралашсак та якынаеп китә алмадык без аның белән. Өйдән күчтәнәч-мазар килсә почмакка кереп, юрган астына посып кына сохари кимереп йөри торган бу ач янаклы, аксыл чырайлы егет үтә дә аз сүзле иде. Мыдыр-мыдыр китап ятлап утыруыннан башка аның тавышын ишеткән дә юк. Дөнья турында, кызлар турында аның белән бер сүз алышып булмый иде, әллә нинди төнлә туган нәмәрсә! Кайтырга җыена башлагач кына малайның чырае актырып китте, кайтасы килүен дә, тракторчы булуыннан канәгать икәнен дә беренче тапкыр шул көнне ишеттем.

Бишенче мартта килергә тиешле Дамир күренмәде, бәйләштереп куйган урын-җирләребезне сүтеп төн кундык, күз текәп торсак та, председатель айгыры икенче көнне дә күренмәде. Мур кырмагандыр бит Югары авылны диештек. Инде тәмам аптырашып, өметсезләнеп торганда, кич кырын, күз бәйләнгәндә безнең фатирга Дамир килеп керде. Ул урәчәле, дәү генә чана тарткан иде.

— Кайда атың?

— Сатып эчтеңме әллә? — диештек без Хәмит белән бер авыздан.

Дамир, кыска муеннын бүрек колакчыны белән сөртә-сөртә, чанасын мөгезеннән тотып болдырга ук тартып китерде.

— Менә сезгә ат. Менә олау. Сыясызмы? Бик симермәдегезме? — диде ул.

Хәмит белән икәүләп Хәкимҗан абзыйны сүгә башладык. Без кызган саен Дамир сүзсезрәк була бара. Бүген юлга чыгу турында уйлыйсы да юк иде, Дамир бөтенләй хәлдән тайган, өшәнгән. Тагын куна калдык.

Юл буе әрләсәк тә, Дамир ак димәде, кара димәде.

— Үзең конюх! — дидек без алмаш-тилмәш.— Җитмәсә, старший. Иң шәп атны тотарга да җигәргә иде! Эх, син, бәрәңге боламыгы!

Чаллыда ятып шәпләнгәч, тракторчы исемен алгач, борын күктә иде, авылга чана тартып кайтып керергә бик хурланган идек, ярый әле, караңгы төште, авылдашлар безне күрми калды.

Дамирның көнләшүдән бавыры кабарган, белеп торам, ул минем таныклыкны ике тапкыр сорап алды, кат-кат укып, пичәтен иснәп карады. Әчемнән генә тантана иттем: менә җиңешеп маташкан идең, карама мөгезле чана сөйрәп калдыңмы, абзаң һөнәр ияse булды!

Курсларда укыганда күңелләр күтәренке иде. Барыбыз да яшьләр, төрле районнардан җыелган булсак та, бик тиз дуслашып өлгердек. Чак кына дөнья мәшәкатьләреннән аерылып, дәресләкләрдә сөйләнгән, китапларда язылган тормыш беләнрәк яши башлаган идек без. Мин үземнең авылга кайтып керүемне дә шулайрак итеп, шәп итеп, һич югында, тантаналы итеп күз алдыма китергән идем. Менә мин кайтып төшәм, янәсе... Председатель дә куана, гомергә елмаймаган хисапчы да көлә, әнкәй дә шатлана, агай-энеләрне әйткән дә юк!.. МТС директоры безне җыеп ала да әле яңа гына Бөгелмә станцасыннан кайтып төшкән, буяу исе килеп торган тракторларга утырта... Музыка, байраклар, котлаулар...

Шушы тантананың бер читендә мин һәр вакыт Әдиләне дә күрә торган идем! Мондый күңелле киләчәктә Дамирга бик бәләкәй, бик кысан урын калдырган идем мин: танавыңны чөеп, хат язарга иренеп йөргән идеңме, мә сиңа!

Әнкәй куанды, сүз дә юк, мыштым гына елап та җибәрде. Бәрәңге дурычмагы белән сыйлады. Мунча якты. Әнкәй юып үтүкләгән күлмәк-штанны киеп, әнкәй җәйгән җылы урында яту нинди рәхәт!..

Уяндым да аннан-моннан капкалап идарәгә чаптым. Озаграк йоклаганмын, Хәмит әллә кайчан килеп тә җиткәндер, йокыга сак егет... Нинди яңа хәбәрләр бар икән, дим...

Кояш шактый күтәрелсә дә, идарәдә беркем юк иде. Җыештыручы Бәдәр җиңгинең борынына корым кунган, ул соңгарып кына мич томалап маташа, бүлмәгә зәһәр күмер исе чыккан иде. Борынымны җыерып беравык көтеп утыргач, түзмәдем:

— Болар кайда соң? — дип сорадым. Бәдәр җиңги дә, беренче күргәндәй, урындыкларга, таплы-таплы эскәмияләргә күз ташлады, төтен кызарткан сирәк керфекле күзләрен челт-челт йомгалап:

— Кайсысы кирәк ие соң сиңа? — диде.

— Соң, Хәкимҗан абзый кайда? Башкалар?

— Аларның ни, белмисеңме әллә?..

— Белмим бит. Мин кичә генә Чаллыдан кайтып төштем.

Чаллы сүзенә дә исе китмәде Бәдәр җиңгинең.

— Кардыда алар,— диде күзләрен сөртеп.

— Нишлиләр анда?

— Төшеп кара. Үзең күрерсең.

Төшәсе дә килә, килми дә. Монда, идарәдә, халык арасында очрашасы килә иде Хәкимҗан абзый белән! Баскыч төбендә таптанып торган арада карды ягыннан бер төркем кеше менеп килүе күренде. Бригадирларны ияртеп Хәкимҗан абзый кайтып килә иде, эчемә җылы керде, ирәеп кенә ак пирчәткәмне киеп куйдым. Председатель яңа сырма өстеннән иске, кыршылган кожан кигән, кожан җиңнәре пычранган, бригадирлар да таш чапкан төсле мышлап төшкәннәр иде. Саргайган бармаклары арасына юан-юан тәмәке кыстырганнар, пыш-пыш суыралар. «Берәр бия колынлый алмый интегәдер», дип уйладым. Килүчеләр минем шактый кычкырып әйткән сәламемә баш кактылар да идарәгә кереп киттеләр. Хурланып, гарьләнеп мин дә аларга иярдем. Хәкимҗан

абзый кэрә-керешкә кожаны белән сырмасын бергә салып мич арасына урындыкка ыргытты. Күкрәгенең медальләрдән буш икәнлеген абайладым, гажәпләнүем тагын да арта төште.

Бригадирлар, аларга ияреп кергән кешеләр, бер сүз дә дәшмичә, кайсы кая таралып чүмәштеләр, кысылган иреннәрдә чытыр-чытыр тәмәке янды, идарә эче яна ягылган мунча кук зәңгәр төтен белән тулды. Тәрәзәдән карап көлеп торган март кояшы төтен арасыннан үтеп кереп кешеләрнең сүрән йөзләрен яктырта, аларга караган саен мин шомлана бара идем.

Телефонны шактый боргаласа да, теге башта алмадылар, ахры, председатель эче итеп сүгенеп җибәрде:

— Утыралар шунда аналары яламаган нәрсәләр, сагыз чәйнәп!

Мин кып-кызыл булдым. Хәкимҗан абзыйның сүгенгәнен беренче ишетүем иде. Аны юаш, тәмле телле булуы өчен председатель итеп сайладылар да. Хәтеремдә, кырык бишнең башында, Хәкимҗан абзый фронттан кайтып төшкәч тә, гомуми җыелыш җыелган иде. Шунда Сабира апа чыгыш ясап:

— Без, Хәкимҗан абзый,— дигән иде,— барыннан да бигрәк тәмле телне сагындык. Тәмам аптыраш бит хәзер: үзебез дә сүгәбез, безне дә сүгәләр! Нәсел-нәсәбегез белән тәмле телле булдыгыз, кулыгыздан эш тә килде, әйдә, дилбегәне кулыңа тот әле! Безгә камчы кирәкми, дилбегә каксаң да эшлибез без!

Ә бүген тәмле тел сүгенә... Ниһаять, дежур кызлар аңа район җир бүлеген тоташтырдылар, байтак әрепләшкәч, МТС директорын эзләп таптылар. Кәнсәләрдә халык ишәйде, Хәкимҗан абзый аларның керүенә, сәлам бирүләренә дикъкать тә итмичә, һаман сөйләшә иде. Райкомны да алды, райбашкарманы да. Симәнәләр, чәчкечләр, культиваторлар турында сүз куерды, председатель соңгы сүзе итеп һәркемгә: «Азрак фураж табышмассызмы?» — дип әйтеп карады. Ара-тирә кычкырып та алды, песи кебек булып та карады, тик бер кайда да аңа өметле җавап бирмәделәр бугай, калын, аксыл кашлары тагын да кырысрак җыерылды.

Берәү бер сүз дәшмәгәндә мин дә шым гына утыра бирдем.

Менә председатель телефон трубкасын шап иттереп рычагка куйды да тирләгән кул сырты белән иреннәрен сөртте, аннары бүлмәдәгеләргә карап кулларын җәйде:

— Фураж сорыйм, фураж! Ярдәм кирәк! Чүп-чар, солы... Ни булса да ризамын дим, юк! Телефоннан акрынып эш чыкмас, су язып май төшми! Берәр атнага чыгып китми ярамас!..

Ферма мөдире, бригадирлар, аларга ияргән кешеләр капылт кына урыннарыннан куптылар да бер сүз дә әйтмичә, тешләрен кысып урамга чыгып киттеләр. Хисапчы, борыны белән калын гроссбухларга төртелеп, чырт та чырт чутын сала башлады. Мич арасыннан борыны җепшек Бәдәр җиңги килеп чыкты.

— Өй борынча чыгарга кирәк, кем, Хәкимҗан,— диде ул.

— Шулай туры килә.

— Бер ун пот бәрәңге мин бирермен. Соңгысы. Атларга җәл түгел. Атлар да үлеп бетсә кая барырбыз? Ун пот бирәм.

Хәкимҗан абзый аны ишетмәгән кебек ияген уч̌лап утыра бирде. Мин Бәдәр җиңгидән шыпырт кына:

— Кая киттеләр алар? — дип сорап, ишеккә ымладым.

— Кардыга,— диде ул.

— Нигә?

— Аңышмадыңмыни, бахыр, бүген тагын ике ат җан биргән.

Сикереп тордым да кардыга чаптым. Ике ат! Минем Озынъялым да шулар арасында түгел микән?.. Трактор белән җенләнеп йөреп мин үземнең канатымны, аерылмас тугры дустымны, шушы еллар эчендә

ничәмә-ничә йөз чакрымнар бергә узган Озынъялымны бөтенләй хәтеремнән чыгара язганмын! Йөз-мең чакрымнар узылган. Ә аның бер чакрымы да җәһәннәм баскычларын үтү белән бер иде ич!

Карды янына төшмәгән булсамчы!..

Безнең кардылар Олы суның аръягында, калку урында. Мин кардыга житәрәк атларны күмеп кайтып киләләр иде инде. Каршыма килүчеләрнең мал зиратыннан кайтып килүләрен авыр адымнарыннан ук абайладым. Абзыйларга:

— Исәннәрме сез,— дип сәлам бирдем. Икесе эндәшмәде, берсе, безгә кода тиешле Галимҗан абый:

— Сорама инде, туган,— дип узып китте.

Озынъялым үлмәгән икән үлүен...

Дүрт җиреннән юан арканнар белән өрлеккә асылынган ат мине танымады, мин аны... Дамир күрсәткәч кенә янына бардым хайванның... Ул зур күзләрен тутырып миңа карады, таныды, дымлы борын тишекләрен кыймылдатып куйды, нәзек тавыш белән ыңгырашып сәлам бирде. Юк шул, янымда синә дигән күчтәнәчем юк шул, акыллым... Кесәмдә икмәк кыерчыгы түгел, таныклык ул... Мин тракторчы дигән язу... Моннан соң синең янына буш кул белән төшмәм, бәрәңге кабыгы белән булса да сыйлармын үзеңне!..

Дамирга вак-төяк өчен үчегешеп маташуларым шундук онытылды, кичкә хәтле кардыдан чыкмадым, атларның асларын тазартыштым, кыргыч белән ябагаларын кырдым, түбәдән су тама башлаган урыннарын ямадык...

Фураж да, солы да юк иде атларга, күгәрә башлаган салам белән җан саклап торалар икән бичаралар.

Кичке чәйдән соң мин тагын кәнсәләргә атладым. Бу юлы Хәкимҗан абзый бер үзе генә утыра иде. Күрештек.

— Тракторчы дип кәгазь бирделәр,— дидем мин юаш кына.

— Анысын булдыргансың,— диде ул, кәгазьгә кырын күзе белән генә карап.

Белдермәскә теләгән идем, үзеннән-үзе үпкәмне әйтеп салдым:

— Сөендереп булмады сине, Хәкимҗан абзый,— дидем.

— Сөенәм, үскәнем, бик шатланам.

— Кул кысып котламадың. Кәгазьдәге билгеләргә күз салмадың.

— Күңелем белән бик котладым, үскәнем... Тик күңел бит, әллә ничегрәк дип әйтимме... икегә бүленгән! Яртысы, олы яртысы җылый аның, үскәнем, синнән яшерене юк. Менә мартка кердек. Калхуз келәтендә бөртек симәнә юк. Күзгә кырып салырга бер бөртек җурна юк! Атлар барысы өрлектә... МТС машиналарына өмет бар, мәгәр чират кайчан җитә?..

— Трактор бирәчәкләрме соң?

— Аннан ни файда? Инеш буеннан вак таш җыеп чәчәрсеңме? Менә бүген нәрәт килде. Сарман ягыннан, Кәсле дигән глубинкадан өч йөз центнер солы симәнәсе язганнар. Иртәгәдән шуны ташый башларга кирәк. Кәслегә иртәгәдән калмый, ишетәсеңме, иртәгәдән калмыйча, житмеш биш чана чыгарырга кирәк. Ә ул житмеш бишне әфсен укып җыясыңмы? Шүтке түгел, алтмыш биш чакрым диләр аны Кәслене! Ә җибәрмәсәң — бәла! Атна-ун көннән юл өзеләчәк. Өзеләчәк, көт тә тор, син ашыкканда гел шулай була ул, үскәнем. Ярты авыл — карт-коры. Яртысы — аксак та туксак. Менә син чана тартып Кәслегә барасыңмы? Кесәңдә дукамент, син дә трактор дауларга килгән!

— Дауламыйм, Хәкимҗан абзый,— дидем мин тыйнак кына.

— Даула син, үскәнем. Әгәренки, даулашмасак эшебез җайга китәчәк түгел безнең. Дауларга кирәк. Тракторын да, машинасын да, барын да даула! Булачак ул трактор, бирәчәкләр аны. Тик менә бүгенгесе кыен, җурна дигәне чәчне агарта! Солы Кәследә. Алтмыш биш чак-

рым!.. Бодайны Чаллыдан чыгарачакбыз, анысын мытыес ташып бирәм, ди. Солыны атна арасында ташып бетерергә кирәк, пример әйтик, житмеш биш чана чыгарсак... Чана саен өчәр пот салсак...

— Ир-ат дүрт потны тарта.

— Ашыкмыйк, үскәнем, өчәрдән чамалап карыйк...

Ул чут төймәләрен ике куллап тартты да уфылдап куйды:

— Ике йөз дә егерме биш пот була. Ярыйсы икән, үскәнем. Тик менә житмеш биш чананы каян табарга? Олы мәшәкать бу, олы...

Шул чак ишек ачылды, ап-ак мамык шәлгә уранган, ак пирчәткә кигән түгәрәк кенә кыз килеп керде. Карадым да каттым: Әдилә ич бу!

Председательгә әллә ни әйтмәк булам, телем тотлыга. Әдилә Хәкимжан абзый белән оялып кына исәнләште дә миңа кулын сузды:

— Ибраһим да кайткан икән, исәнме.

— Мин кайтырга киткән... Менә син ничегрәк? — дидем мин туптуры.

Ул шәл почмагына авызын яшереп көлемсерәде.

— Мин дә менә... жизнине өйләндереп кайттым.

— Ниндирәк кеше алды инде? — диде кызыксынып председатель.

— Анысын кем белсен инде, Хәкимжан абзый! — диде Әдилә житди генә.— Күршеләрендә кодача тиешле бер апа бар иде. Ире сугыштан кайтмаган, бер малае белән тора. Шул ике тол бергәләп оя кордылар.

— Гомерле булсын,— диде председатель, ияген кашып.

— Бөтенләйгә, алайса? — дидем мин, шатлыгымны яшермичә.

— Бөтенләйгәдер инде,— диде ул, нигәдер миңа түгел, Хәкимжан абзыйга карап.

— Кайтуың яраган,— диде ул.— Менә солы симәнәсе ташырга керешәбез. Син дә барырсың.

— Кая?

— Кәслегә.

— Бик якын икән! — дип көлде кыз.— Күрше-тирәдән, әйтик, шул ук Сарсаз глубинкасыннан симәнә алып булмыймы? Анда да бардыр ич солы? Әллә Кәсләдә мөгезлесеме?

Хәкимжан абзый төксә генә елмайгандай итте:

— Ә-ә, үскәнем! Кыз бала шул син, жиңел уйлыйсын. Һе, хатынкызның шул... Кайсы глубинкада нәрсә бары анысы инде аның дәүләт сере. Сугыш сере белән бер анысы! Безнең катнаш юк анда. Менә Чаллыдан килгән нәрәт. Пичәт басылган, кулы куелган. Кәследән диелгән и бетте-китте. Барасыңмы?

— Ярар, барырмын,— диде Әдилә жәберсенмичә генә.

— Мин дә барам,— дидем кинәт кенә.

Хәкимжан абзыйның чырае яктырып китте, ул ике куллап чутка ябышты һәм чырт-чырт итеп төймәләрне авыштырды.

Кәнсәләрдән без икәү чыктык. Язгы төн. Төн айлы, анда-санда гына болытлар ага. Урам яп-якты, инә эзләп табарлык. Урам буп-буш. Андасанда гына тәрәзәләрдә зәгыйфь утлар җемелди, кеше күләгәләре уйный.

— Кайтыр юлың ерак, усал маһмайлар күп, озата барыйммы? — дидем мин кыюланып.

— Эшең булмаса, бар,— диде ул.

Барабыз. Әлек урам уртасыннан киң, төз ат юлы була торган иде, хәзер тар сукмак, атлаганда бер-беребезгә тиеп-тиеп китәбез.

— Иркен яшәдегез, ахры, Чаллыда,— диде Әдилә кинәт.

— Нигә?

— Бер матур белән танышкансың икән.

Эсселе-суыклы булып киттем.

— Каян белдең?

— Дамир сөйләде.
— Ә, Татлы тамыр! — дигән булдым мин.— Сөйләр ул!
— Бер дә ояты юк,— диде Әдилә олыларча,— Әйбәт кыздыр бит!
— Беркем белән дә танышканым юк,— дип мыгырдандым мин.— Кирәге-кирәкләре бер тиен.
— Арзан бәяләдең син кызларны.
— Мин укырга бардым ич анда, Әдилә.
Юк, Әдиләгә ачуым килеп түгел, Дамирның сүзләренә каным кыза башлады! Каян уйлап чыгарган диген, белә малаең кайсы почмакта сагалап салып егарга кирәклеген! Сүзне тиз-тиз икенчегә бордым, югыйсә, кызып ук китүем бар иде.
— Тутаңның балалары җылашып калдымы?
— Җыламый нишләсеннәр? Миңа иягәнделәр. Олы кызын алып кайттым әле, бездә торып торыр.
— Җизнәң ни хәлдә?
— Җизнигә нәрсә? Куенында яшь кәләш, авыз ерык...
— Өмете синдә икән дип сөйләделәр.
— Аның өмете булгандыр да, минем өмет башкада шул!
Әдиләнең шулай олыларча, кыю итеп, ачыктан-ачык сөйләшүенә исем китте.
— Кемдә инде ул синең өметең? — дидем мин, йөрәгем дөпелдәгәнен ишеттермәскә тырышып.
Әдилә көлеп җибәрде:
— Бик тиз белер идең бугай.
Сүзсез калдырды бу кызый мине, тәмам зиһенемне бутады. Беравык дәшмичә бардык.
— Әллә оныттыңмы? — дип сорады ул кинәт.
— Нәрсәне, Әдилә?
— Оныткан, икмәктер, оныткан!
— Әйт инде!
— Минем чәчне тартып китүеңне! Яңагыңа чалтыратуым хәтереңдәме?.. Әллә син башка кызларның да чәчен тарта идеңме?
— Онытмадым, Әдилә! Башкаларныкын тарткан булмады, кояштыр!
— Сөям дигән ымың түгел идемени ул, Ибраһим!
— Ай-һай, каты чәпәгән идең яңакка!
— Онытырлык булмасын дидем, Ибраһим... Егетләрнең хәтер кыска бит аларның... Яшене нинди, күкрәве шундый булсын дидем!.. Син дә чәчне каты тарткан идең бит... Яңагың шешмәгән идеме, кая, карыймчы, эзе калмаганмы?
Ул ак пирчәткәсен салып минем яңакны сөйде.
— Кытыршы,— диде ул.
Аның бармаклары йомшак, кайнар һәм хуш исле иде. Мин ихтыярсыздан аның кулын эләктереп алдым, икебез дә оялып читкә тайпылдык.
Аларның йорт турындагы карт тирәкләр тонык кына гөжлиләр.
— Иртәгә иртә торасы бар, Ибраһим,— диде ул.
Мин аның йомшак бармакларын учымда иркәләдем.
— Хушлашабызмыни, Әдилә?
— Иртәгә күрешәбез бит.
Аны-моны уйлап тормастан, аңа тартылдым, ул бер генә секундка минем кочагыма керде дә житез жәнлек кебек йомылып чыгып та китте, борын төбемдә генә капка ябылды. Аяк тавышы ишетелеп торды, менә ул тукран төсле генә тукылдатып ишек шакыды, этисенең: «Кем йөри анда, кызым, синме?» дигән карлыккан тавышы ишетелде...
Мин, Түбән оч бозавы, хат язарга куркып йөргән булдым! Үскән Әдилә, үзгәргән... Ике кыш, бер җәй дүрт баланы карап, гаилә башы булып яшәгән кеше шул!..

Күз алдым яктырып киткән кебек булды, күтәрелеп карасам, тулган ай болыт астыннан чыгып килә...

Бүгенге көн өчен вакыйгалар артык күп булса да, бер җепкә тезгәч, алар бары тик бер мәгънә алалар иде: әйе, яшәү җиңел булмаячак! Әмма яшәргә, тырышырга кирәк! Әйе, авыр, җәфалы, бөлдергеч сугыш беткәнгә кайчан гына бит әле! Күкрәкләр тыныч сулый башлаганга күпме вакыт узды... Әйе, безнең буын бәхетлерәк... без күкрәкләргә салкын мылтык түтәсе түгел, кызлар кыса алабыз...

Әдиләне озаткан кичтә мин, эссе көндә чишмә суын туйганчы эчкән кеше төсле, сафланып, тынычланып кайттым...

Кайтышлый Дамирларга кагылдым. Дамирның әнисе сорамыйнитми генә ишек ачты, кече якта сукыр лампа яктысында җеп эрли икән. Дамир, җылы ятратканга, мич башына менеп утырган.

— Кем бар? — дип кычкырды ул, муенын сузарга тырышып.

Сырма төймәләремне чишеп җибәрдем дә аның янына мендем. Менгәч, сырманы салып ук куйдым. Мич түбе кап-кайнар, һава бөркү иде. Икебез дә аякларны асылындырып утырдык.

— Кайтып кына егылган идем,— диде Дамир акланып.

— Чанагызны сорап торырга кердем. Бер көн Чаллыдан бик җилле алып кайткан иде.

— Кәслегә барасыңмы? — диде Дамир, бераз көттереп.— Мин дә барам.

— Сине дә җибәрәләрме?

— Үзем барам. Мужыт атларга бераз өлеш чыгарырлар. Чәчү алдыннан аларны азрак сыйламыйча ярамас. Барам! Мин алып кайтканын, мужыт, кардыга төшерерләр... Улаклар күгәрә башлады бит... Ята алмыйм тик кенә карды өендә, йокыга китә алмыйм!.. Алар бит төне буе ыңгырашалар!..

Өйгә кабаланып кайтып, иң әүвәл лапаска кагылдым, караңгы почмакларда кармалана торгач чананы эзләп таптым. Тавык тизәгеннән арындырдым, чистарттым. Таза гына күренә болай, бер як табаны гына чалшайган. Бау белән мөгезенә тарттырып бәйләсәң, ул ягы да турыланыр. Өйгә чана күтәреп керүемнән әнкәй барын аңлады.

— Барасыңмы?

— Исәп шулай, әнкәй.

— Хәкимҗан абыеңны күрә алдыңмы соң?

— Күрмичә...

— Ни диде?

— Ни дисен?! Әйтмәде.

Балалар йоклый. Без әнкәй белән икебез ике якта көрсенешеп ятабыз... Ул ни уйлыйдыр, утыз биштә тол калган хатынның төннәрен ниләр уйлаганын әле мин белмим, ә минем уйларым гел Кәсле юлына барып тоташа. Чак таңны аттырдык...

Җитмеш биш чана дигәч, бер дә исем китмәгән иде, бик күп була икән ул! Көн артык җылы да, салкын да түгел, сирәк кар ява. Кешеләр җиңелдән киенсәләр дә, җылы киенгәннәр, билләрдә каеш, аллы-кызыллы сөлгеләр, төрле төстәге билбаулар. Муеннарда җылы шарф. Яз ае булса да, март тотрыксыз ул, кәефе кырылып буранлаган чагы да еш була. Арада өлкән апалар, җиңгиләр дә, егет-җилән дә бар. Егетләр хатын-кыз арасына катнашырга читенсенеп идарә болдыры тирәсенә бөялеп тәмәке көйрәтәләр. Хатын-кызларның байтагысы соңгы вакытларда эшкә чыкмаган. Югары очлар Түбән очларны, Түбән очлар Югары очларны танып алып, ерактан ук бер-берсен сәламлиләр, кочаклашалар, бер-берсен күрми торган арада гәүдәләренә сарган хәсрәтне коярга теләгәндәй җилтерәтешеп тә алалар, бер-ике минут сүз әйтә алмыйча елмаешып торалар да китә сүз чишмәсе челтерәп!.. Кем өйләнгән дә кем аерылган, кемнең сыеры бозаулаган да

кемнең сарыгы кысыр калган! Тавыклар күкәй саламы, казлар утырамы, курмы-утын запаслары бетмәгәнме, басуларда кар ятамы, кышкы чир-чорлар кимегәнме?.. Бетәмени дөнья сүзе хатын-кыз бер-берсен зарыгып очратканда?!

Арыш арасындагы бодай кебек бер-ике ир-ат та бар. Болары — кичәге фронтовиклар. Алар житди, кырыс, шушы гайре табигый җанланышның бар хикмәтен алар гына белгән кебек, фронтовиклар председательгә тартылганнар. Куллар шинель кесәсендә. Һәр шинельдә кесә бар, һәр кесәдә кул гына юк... Хәкимҗан абзый үзе дә юлга чыгарга җыенган төсле, кыска тунының билен зәңгәрсу пута белән кысып буган. Речь сөйләргә җыена, ахры, йөткеренә, тамагын кыра...

Ниһаять, Әдилә дә килеп кушылды...

Шуны көтәм икән, шуны эзлим! Башкалар күземә күренмәс булды, ярминкә гөжләгәндәй тавышлар тынды, берәү дә сизмәслек итеп кенә сәлам алыштык, рәхәт булып китте.

Карасам, дәү, биек мөгезле чанасын сөйрәп Дамир Әдилә янына барып та җиткән, җим тырмаган тавык кебек, аягы белән кар тырмаган була, нидер сөйли. Тик кыз егетнең үзенә түгел, чанасына карады.

— Чана дисәң дә чана бу! — диде ул.— Үзең ясадыңмы?

— Ясамыйча? Арсаң-нитсәң, чанаң-нисң белән утыртам да кайтам,— диде Дамир, авызын ат дагасы хәтле ерып.

— Әйем,— диде Әдилә иркәләнеп.— Куркам.

— Нигә?

— Кем чанасына утырсаң... ни диләр әле?

— Үзенә Әдилә чанасына кунакларга туры килмәгәе,— дидем мин, Дамирның Чаллыга килеп кергәндә алҗыган кыяфәтен хәтерләп.— Конюхларның аяк йомшак аларның, төшке ашка да айгыр җигеп кенә кайталар.

Бусы үчекләшү иде. Әдилә көлде, Дамир усалланып:

— Ә син шөшлесез чабатачы! — диде...

Ул арада Хәкимҗан абый өскәрәк, такталары кылдый-былдый торган болдырга менеп басты.

— Туганнар,— диде ул.— Исән-аман йөрергә тырышыгыз. Бер-берегезне юлда ташламагыз. Инде быелгы читен яз соңгысы булсын! Тезләнсәк тә, егылыр өчен түгел, сикереп торып, йөгереп китәр өчен тезләнербез. Быелгысы елда без тәмам ныгып, көчәеп, йөгереп китәргә тиешлебез ки, и анысы шулай күренеп тә тора! Ягез, туганнар, иплəп кенә кузгалыгыз...

— Атлылар очраганда таптап китмәгез! — дип кычкырды кемдер. Кемнәрдер күңелле генә көлеп куйдылар. Хәкимҗан абзый бу ялгыз тавышны ошатып бетермәде бугай, шул якка карап әйтә куйды:

— Быел яз бирешмәскә кирәк, туганнар! Быел яз!..

Алдан хатын-кыз кузгалды.

— Яшь кәҗә тәкәләрен алга чыгарыйк! — дип чәрелдәде арадан берсе.

— Карт сыерлар артка калсын өченме? — диде егет-җиләннәрдән берәү.

Сабираттәй дә монда икән, моңарчы аны күрми торганмын, борылып карап бер генә сүз әйтте:

— Яшь тәкәләр такыр юлны чамалыйлар әле, артка калалар! — диде. Туктап мине көтеп алды, кулымны кысты. Башка вакыт булса, мин аның кытыршы, бирчәйгән бармакларының нигә калтыравын аңламас идем, бүген барын төшенеп алдым. «Менә, Ибраһим нәнәм, көзен интегеп бер якка ташыган идек, хәзер икенче яктан алып кайтасы була», дигән кебек иде аның калтыравыклы кул кысуы...

Бер уйласаң шулай... Икенче уйласаң, әгәр солы безнең амбарларда калган булса, язга чыгып җитәр идеме икән?..

Кар төшә. Эре-эре ак күбәләкләр иркәләнә-иркәләнә тирбәлеп юлга төшәләр дә безнең чабата астында шадраланып сытылалар. Юл тар, юл бәләкәй, без тар күпер аша чыгучы сарык көтүе кебек кысылышып барабыз. Зәй белән Сарман арасындагы олы юлга чыккач кына бераз иркенәйдек. Бу юлдан аракы заводына Сарсаз сазлыгыннан торф, безнең урманнардан утын ташыйлар, атлылар көн саен диярлек узып тора, уптылар инде безнең якның йөзәр яшьлек имәннәрен, карасаң картузың очып төшәрлек юкәләрен!.. Завод атлары икмәктә, әнә тизәкләрендә чәчрәп-чәчрәп солы бөртекләре ята, жегәрле атлар! Без шул атлар такырайткан юлдан озын бау булып сузылдык. Хәзер янәшәдә ике дә, өч кеше дә атлап була, төрле озынлыктагы бауларга бәйләнгән чаналар гына бер-берсенә дык та дык бәреләләр, мөгезләре белән сөзешәләр.

Авылда чактагы ыгы-зыгы күзгә күренеп кимеде, һәркем җанына якын юлдаш, күңеленә унай сердәш сайлап алып, шуның белән гәп куертып бара. Сүз юлны кыскарта, юлдагы сүз — чыннан да җан азыгы, сүз озын-авыр чакрымнарны санатмый. Юлда иң куркынычлысы уй һәм ялгызлык...

Без өчәү атлыйбыз. Өчәү булгач адымнарыбыз эре, җиңел, күңелләр көр. Дамирның уены-чыны бергә, мине тешләргә тырыша, сүзләре белән чәнчеп-чәнчеп куя, мәгәр мин тыныч. Безнең Әдилә белән икәү генә белгән серебез бар, безнең икәү генә узган юлыбыз бар. Җитмеш биш җан арасында барсак та, без икәү! Икәү генә, икебез генә! Бу кышкы юл, бүгенге юл, иртәгәге юл ничаклы озын булмасын, ул барыбер кичә без икәү үткән юлның дәвамы гына...

Иөзе белән борылып ул миңа чана бавын сузды:

— Җәле, Ибраһим, шәлемне генә рәтлимче.

Миңа сузды бит, Дамирга түгел! Дамир сыртына камчы төшкән чыгымчы ат кебек алга ыргылды, без янәшәдә икәү генә калдык. Минем кулда ике чана бавы. Юк, мин ике чана тартып бармыйм хәзер, мин ике бәхет тартып барам, ике куаныч минем кулымда! Юл буенда гына учма-учма саламнар кадалган — маяклар. Күземә алар парлы-парлы булып күренәләр... Мин сабан туенда чаптар атта бараммыни!.. Сары маяклар — тирә-яктагы кызларның сары яулыклары, сары кәләпүшләр, сары тасмалар... Рәхәт!..

Әдилә туктап ак шәлен рәтләде, сырма кесәсеннән чите китек көзге чыгарып купшыланган булды.

— Матур син, бик матур,— дидем, үз-үземне белештермичә.

Ул ялт кына як-ягыбызга карап алды.

— Миңа матур булмыйча ярамый.

— Әйе шул.

— Бик тиз ризалашасың әле син! Шундый көндәм кешеме дисәм...

— Тиз түгел, Әдилә. Мин күптән шулай уйлап йөрим.

— Ни дип уйлыйсың?

— Син җырчы кыз. Җырчы кыз матур булырга тиеш. Җырчы кыз — үреп салган такыя төсле, аны бөтен кеше күрә.

— Остарган син... Чаллыда...— диде ул, күзләре белән мине иркәләп.

Шәл читеннән дулкындай чыгып торган чәчләрен аз-маз җыештыргач та, ул бияләен киярга ашыкмады, ялан кул гына чана бавына үрелде, мин аның үтә йомшак бармакларын тотып алдым, сөйдем.

— Эссе,— дидем мин туп-туры алга карап, Әдиләгә карарга да кирәкми иде хәзер, безнең куллар бер-берсенә нидер әйтәләр, сөйләшәләр. Аларның сүзен-ымын, сихри өнен без икәү генә аңлап барабыз.

— Синең кулларың ныгыган,— диде ул.

— Тимерне нык бордырдылар тегендә.

— Чаллы матурдыр?

— Әллә ни күреп тә булмады. Кыш бит, кар ерып кая барасың? Җәен матур гына була. Кама буйлары, аргы якта зәп-зәңгәр урманнар, анда, Тарловкада, санаторий диләр, чирлеләр ята икән. Ап-ак пароходлар йөзә. Ә Чаллы үзе сары ком. Элеватор тавы биек-биек, текә яр, әллә кай төшләр күренеп тора.

— Тауны яратам мин... Сарсазда чакта түтинең олы кызы белән Кашка тауга әллә ничә барганым бар.

Сарсаздан Кашка тауга дүрт-биш чакрым, бала җитәкләп әнә кая барып йөргән икән Әдилә!

— Таудан мин сине күрдем!

— Ничек?

— Югары авыл урамыннан атка утырып чыгып килә идең!

Көлештек. Кар мулрак төшә башлады, җил дә исеп куя, кар бөртекләре шомырт чәчәкләре күк коелып безнең юлга түшәләләр, безнең сырма сырларына килеп кұналар, Әдиләнең сызылып торган кара кашларын агарталар... Без барабыз. Без хәзер бер сүз дә сөйләшмибез. Куллар кулда, сизәм: уйлар да тоташкан...

Бераздан көн җепшетте, юл авырайды, алдагы рәтләр буталышып тукталдылар. Без әлегә арттан барабыз, ерак-еракка сузылган кәрван күз алдыбызда. Без дә тукталдык. Куллар теләр-теләмәс кенә бер-берсеннән аерылдылар.

Алдагылар:

— Яшьрәкләр алга чыксын,— дип шауладылар.

— Майлары эресен бераз.

— Такыр юлдан парлашып кына теркелдәрләр иде бугай...

Бусы безнең капканы кагулары булды. Мин алга ыргылдым, Дамир миңа иярде, Әдилә дә бездән калмады. Кыз-кыркын, егет-җилән чыр-чу килеп безнең эзгә төште, базар ясады. Өлкәнрәкләр юл сабып:

— Юртакларга урын бирегез!

— Сабан туе чабышкылары килә,— дип кычкырып, сызгырып, тел шартлатып, көлешеп безне озатты.

Әдилә белән икәү иң алга чыктык. Элек, без арттан барганда, бөтен кеше күз алдыбызда иде, хәзер без аларның күзе алдында. Безнең янәшә барган җилкәләр аларга серне ачып ташламаса ярар иде! Бая тотаклашкан җылы куллар шул тиклем шаһитләр алдында бер-берсеннән ерагайсалар да, без бик якын, ым-ишарәләр аңлашырлык дәрәҗәдә якын идек...

Уйлыйм-уйлыйм да ышанырга да, ышанмаска да белмим: каян килде миңа шушы хәтле бәхет?! Сугышның беренче аенда ук ятим калып, тол ананың сыңар канаты астында, туйганчы аш ашамыйча, күнел юанырлык кием кимичә, кайчагында кимсенеп тә, кай чагында чамасыз гарьләнеп тә яшәп килгән сынык күңелне нишләттең, Әдилә?! Гомер онытырлык итмәдең...

Ләке урманына җитәрәк борылып карасак, авылдашларны бер-ике җир буе артта калдырганбыз икән. Безнең арттан ук диярлек мышный-мышный Дамир килә. Кар тагын да ныграк ява башлады, җитмәсә, үзе дымлы, җепшек кар, авыр кар. Бусы бик начар иде, өсне чылата, юлны авырайта торган март кары. Урман юлның бер ягында, сулда гына, уңда — япан кыр, чүп-чуар чигешле куян эзләре тирәнәеп, күмелеп баралар.

Урман ышыгында рәтләр тыгызланды, уртак сүзләр купты. Бөтен кеше тизрәк заводка барып җиту турында хыяллана иде. Анда аз-маз хәл алып тамак ялгарга исәп. Ләке урманын узгач та түбәнгә озын, сөзәк үр башлана, юл бераз җиңеләергә тиеш. Офыкларны иңләп, күңелләрне басып, җылымса, авыр болытлар шуышты. Сабираттәй:

— Буран-кыян чыкмагае, сул кулымны күтәрә алмыйм, сызлый,— диебрәк торды. Һәркем үз тәнендә, үз күңелендә булган үзгәрешләрне

көн бозылуга юрады. Берәүләрнең колагы кычыткан, эт аунаган, каргалар түбәнтен очкан...

Барыбызның да курыкканы буран иде. Бик мәкерле, бик алжыткыч, бик дәһшәтле була җепшек, кара март бураннары! Кешенең адымын салмакландыра, акылын җуя, изрәтә, зиһенне томалый, авыр кар дөньяны да, күкне-җирне, нужалы юллардагы адәм балаларын да күмепкаплап китә... Әдилә белән башта һәр кар бөртегенә куанышып барсак та, безнең иреннәр дә кысылды, илдә хәсрәт барда тыйнак булуың әйбәтрәк! Барабыз, барабыз да иреннәргә кунган карны ымсынып күккә күтәрелеп карыйбыз. Күк шундый түбән, салынкы, үрелсәң болытларны сөзеп алып булыр төсле. Ява, туктарга һич исәбе күренми. Кәрваннын ахырын, азактагы кешеләрне түгел, бездән ун-егерме сажинда баручыларны да аерып танып булмый. Бер якка янтаебрак, нелеп атлап барганга кешеләрнең ярты якларын ак кар сарып киткән...

Зарыгып көтелгән завод үрен төшә башладык, хәзер бераз гына унайрак булачак. Буш чана да килә-килә кулны талдыра икән, уң кулымның беләзеге сулык-сулык сызлап куя.

Үр уртасына җитәрәк, безгә каршы менеп килүче атлар очрады. Биекбиек чаналарга юл биреп төрле якка сибелештек. Борыннарга ат исе, авыл кешесе өчен гаҗәеп якын, кадерле терлек исе килеп бәрелде. Дамирга карадым, аның соры күзләре зур булып ачылган, шаккатудан иреннәре дә ачык, үзе әкиятләрдәге шүрәлене күргәндәй хәйран калып торараш каткан иде.

— Икмәк ашыйлар шул, таза икмәк! — Дамирның күзләренә моң чыкты, тавышы калтыранды.

Әдилә, шукланып:

— Дамир, бу атларның берәрсен сиңа бирсәләр, нишләр идең? — дип сорады.

Дамир телсез калды, Әдиләнең соравын ишеткәннәр көлешә башладылар.

— Дамирга бирсәң, күрсәтә ул.

— Киптереп өрләккә элә.

— Казылыкчы Дамир!..

Атлылар узып бетте, сүз җебе шуларга ялганды. Кемнәр кайсы сабан туенда нинди атта чабышканнар, кайсы авыл атлары фәлән елларда беренче килгән, кем малае егылып ничә кабыргасын сындырган... Сабираттәй: «Мин килен булып төшкән елны уникe ат җигеп килгәннәр иде»,— дип куйды. «Керәшен очында Май чапканда [1] өчәр ат җигеп чыгар идек, унар-унбишәр кеше тәялсә дә, атлар йөрәк кагып кына барырлар иде»,— диештеләр Түбән очлар... Бер генә тантана да, бер генә бәйрәм дә ир канаты — аттан башка узмаган. Һәркемнең атка бәйләнешле бик кадерле истәлеге бар икән, колыннар, байталлар, чабышкылар, юртаклар, йөк батырлары барысы да хәтердә сакланган, заводның шома сыртлы, кыска койрыклы тук атлары шул истәлекләрне кузгатты, барыбыз да күңел сандыкларыбызны ачып, хатирәләрне уртак итәргә тырыштык. Сүзләр буранны онытырды, хатирәләр эч пошыргыч җепшек бураннан көчлерәк булып чыкты...

Хәзер исә атлар өрләктә, кешеләр ятим...

Атларга да кешеләрсез читендер, хәрәкәтсез тору бик кыендыр. Төннәрен ыңгырашалар, ди ич Дамир! Аларның төшләренә дә чуклы чәчәкле, аллы-гөлле сабан туйлары, колын койрыгы төсле йомшак-ефәк уҗымнар, бәйгеләр, ярминкәләр, Май чабулар, яшел аланнарда керт-керт итеп туранбаш кыркып йөргән чаклары керә торгандыр... Алар да карды ярыкларыннан сызгырып кергән тыгыз, март җилен

[1] Керәшен татарларында масленица бәйрәме.

тоялардыр, аларның да каннары кайнарланып китәдер... Бик тирәндә, зәңгәр томанлы ат хыялында айгыр кешнәгән тавышлар яңгырыйдыр...

Без, алдагылар, хәзер тубыктан диярлек кар ерып барабыз, әлерәк кенә узып киткән ат-чана эзләре чак-чак шәйләнәләр. Бездән арттарак килүче Дамир кинәт кычкырып җибәрде:

— Бүреләр!

Шып туктадык. Тыгыз ак пәрдә аша алда, юлдамы, кырыйдаракмы, ниндидер кара төрткеләр кыймыл-кыймыл килгән кук булды.

— Нәрсә бар? Нигә туктадыгыз? — диделәр арттагылар, безне тыгызлап.

— Бүре күргәннәр.

— Йөри ди сиңа, көпә-көндез!

— Бүре дигәч бүре инде! — дип әтәчләнде Дамир.— Ләке урманында мыж алар, чокыр-чакырлы урман бит, бүре оясы. Шуны белмисезме әллә?

— Белми идек, шулай да шиккә төштек.

— Шушы хәтле халыкны ашап бетермәсләр әле,— диде Әдилә.

— Чукмарны аласы калган,— диде үкенеп Дамир.— Бабайдан калган чукмар бар безнең. Келәттә ята.

Акрынлап атлыйбыз, кара күләгәләр дә якынлаша. Ат дисәң, атлы түгел, кеше дисәң, кешегә дә охшамаган. Нәрсә булыр бу?

— Йөктән төшеп калган нәрсәдер, селкенми,— диде кемдер.

Янына килеп җитәрәк кенә безне өркеткән кара нәрсәнең юл уртасында туктап, яртылаш карга күмелгән «ХТЗ» тракторы икәнен белдек. Атлар үткәндә Дамирны кәмит иткән идек, хәзер чыбык очы мина чаҗлап килеп тиде.

— Тракторчы чана тарта, тракторы юлда ята! — дип такмаклады Дамир.

— Ибраһимны көткән бу нәмәрсә!

— Трактор ятмый,— дидем мин җәберсенеп. Күңелдә: «Ничек итеп бу тракторны авылга алып кайтырга?» дигән сорау туды. Җилдән ышыкланып трактор тирәсенә сырышкан хатыннарны аралап әле уңга, әле сул якка чыктым. Ягулыгы бетеп туктаганмы, әллә берәр урыны ватылганмы, белмәдем, трактор байтактан монда тора, ахрысы, тәгәрмәчләрен кар күмә язган.

— Эх,— дидем мин.

Сабираттәй минем ни уйлавымны төшенде, ул да килеп җитеп, күзләрен тутырып тракторга карап тора иде.

— Келтерәтеп кенә авылга алып кайтыр идеңме?

— Эх, Сабираттәй!

— Әллә кайчан талап бетергәннәр инде моны! — диде Дамир.— Юньле часте калмагандыр.

Мин тәмам кызып киттем:

— Кем талаган? Магнетосы монда! Алсалар аны алырлар иде. Свечалар да урынында... Радиаторы төзек күренә. Карбюратор ике шөреп белән генә беркетелгән. Алыйм дигән кешегә момент! Аны да алмаганнар.

— Ә утыргычы? Утыргычын каерып алып киткәннәрме?

— Утыргычнымы? Анысын аның тракторчы урламаган. Анысын инде кулы кычыткан комсыз бәндә чәлдергән.

— Сцеплениенең татарчасын беләсеңме? — дип сорады Сабираттәй.

— Белмим.

— Фирәзә булыр аның исеме, Ибраһим. Нинди матур исем кушканнар.

Тракторның исән, бөтен булуы, детальләренең таланмавы минем дәрәҗәне күтәреп җибәрсә дә, корыч айгырның карга чумып мескенәеп

юлда утыруы күңелемә бик авыр тоелды. Кем кузгатып чыгарган аны юлга? Нигә ташлап киткән?..

Петровка аракы заводына килеп життек. Игәнә суы аркылы салынган күпергә кергәндә борылып карадым, трактор күренми иде инде...

Ах-ух килеп, йортлар арасына ышыккарак барып кердек. Кәннең кайсы вакыты икәнен дә аермачык белмибез. «Минем корсакның торышына караганда, төш авышкан булырга тиеш»,— ди берсе. «Минем корсакка төш Ләке урманында ук житкән иде»,— дип жорлана икенчесе. Ял итеп, тамак ялгап алырга берәүнең дә каршылыгы юк иде. Теге яктан озын үрне төшсәк, монда каршыбызда бик биек тау бар, ял итмичә, ашап алмыйча без бу тауга менә алачак түгел.

Беркадәр өскәрәк менгәч, аркылы урам уза. Аркылы урамның ике ягына агач кибетләр, ашханәләр, учреждениеләр урнашкан, почта да шунда. Телефон чыбыклары яман усал үкерәләр. Жил арасыннан завод гудогы да юаш кына, тук песи мырлаган кебек кенә ишетелеп китте. Чаналарны кибет ишеге төбенә тартып китердек тә төркем-төркем булып эчкә кердек. Тик без кызыгырлык берни дә юк иде кибеттә. Балта сабы, көрәк сабы, агач көрәкләр, жилпуч... Кәнфит-прәннекләр күзне кыздырса да, алары карточкага гына бирелә икән.

Чабата кары эрегәнче тизрәк урамга чыктык. Урамда калган иптәшләр арасында ниндидер жанлылык сизелде.

— Ичмасам, без эш майтарып йөрибез,— диде кибеткә каршы бинадан чыгып килүче Сабираттәй.— Ашханә икән анда!

— Югары авыллар килә дип майлы бутка пешереп куйганнармы?

— Белен дә, майлы бутка да юк, иллә мәгәр чәйләре бар!

Бу хәбәр үтә сөенечле иде, каты-коты белән салкын жилдә тамак ялгауга караганда, жылыга кереп бер-ике стакан кайнар чәй эчеп жибәрсәң, бу инде юлга көч дигән сүз. Ә безгә көч бик кирәк иде әле... Бик кирәк!

Бәләкәй ашханә барыбызны да сыйдырмады, өлкәнрәкләр эчкә узды, яшь-жилкенчәк аптырап тормады, «Насыйп түгел икән, бигрәк әйбәт!» дип гөрелдәшеп тышта калды. Берничә чананы уртага куеп, үзебез шулар тирәсенә утырыштык. Байтак кеше калай кружкадыр, котелоктыр тыккан икән; ашханәдән уттай кайнар ике чиләк кайнар су алып чыктылар, кем кишер чәе, кем жиләк чәе йөздереп, шуңа әйбәт төс керттек. Дамир да, мин дә кружка тыкмаганбыз икән, Әдиләнең бизәкле ак чәшкәсенә чират алдык.

Өйдән чыккан ризыкларны уртак табынга куярга кирәк иде.

Иң кыен вакыт иде бу. Берәүләр кыенсынып тынып калды, күзләр жиргә тәгәрәделәр... Кысыр сыер жилене тиклем генә ризык капчыкларыннан нәрсә-кара чыга башлады. Алабута кушып пешерелгән, кайрактай кара катламалар, бәрәңге кырып шуңа сыңар уч кына әремле арыш оны кушып пешерелгән ләчтә ипиләр, тәгәрәткән бәрәңгеләр... Таза ипиләр дә солы, ясмык, борчак оны кушып пешергәнгә вакланып, уылып торалар.

Болар барысы да уртага чыгып тезелделәр. Уртадагы чана өстендә чиста ашъяулыкта урын калмады диярлек. Каян башына килгән диген, ашъяулыкны Әдилә тыккан икән!

Гыймай Фатихының яссы күкрәкле, бөкрерәк кызы Гөлбәдәр генә, «күрәләрме-күрмиләрме» дигән сыман аска карап, табынга бер кыерчык бодай ипие куйды. Аның кыерчыгы яңа туган ай күк балкыса да, табын уртасында ахыргача утырып калды...

Куллар табынга үрелде...

Юлда, ындырда, жилдә киселеп, яргаланып беткән, бирчәйгән бармаклы, эре, калын тырнаклы куллар... Тупырдатып бала сөясе урында жыерчыклы күз тирәләреннән күз яше сөртеп өйрәнгән куллар...

Гомер-гомергә иннек-май күрмәгән иреннәр шау кайнар чәйле круж-

каларга тиде, кояш нурларында тәссезләнгән сирәк керфекле күзләр рәхәтлектән кысылды, тартылган янак сөякләре шытырдап китте...

Табын янында гына була торган тантаналы тынлык урнашты. Алабута катнашкан булса да, алда — ризык. Аны олыларга кирәк!.. Кешеләрнең сулыгып-сулыгып ризык сораган ашказаннарына рәхәт җылылык йөгерде, йөзләргә кызыллык белән елмаю чыкты, төс кунды, беренче рәхәттән соң телләргә татлы сүз килде, туганлашу, татулашу килде. Берәүләр: «Бик күңелле башланды бу сәфәр, ахыры да шулай хәерле тәмамлансын»,— диделәр. Очрашуларына, бергә сәфәр чыгуларына куанышкан хатын-кыз тук казлар кебек каңгылдаштылар. Сугышка хәтле баеп, ныгып калган авылларны телгә алдылар, икмәкне кызыл олаулар белән йөге-йөге китереп аудара торган, һәр елда җитәрлек кадәрле балын, яшелчәсен, йонын булә торган үзебезнең «Ленин юлы» колхозының элеккеге чакларын сагыныштылар...

Әзерлексез чыккан без агач авызларга да чәй чираты җитте, без дә теләгәнчә кинәндек. Борын өстенә борчак-борчак тир бөртекләре чыкканчы эчтек. Мондый да тәмле чәйне, ай-һай, моңарчы эчкәнем бар идеме икән?!.

Завод урамында чәй эчеп утыру бик тансык булса да, безгә ашыгырга кирәк иде. Әбәт иткәндә чак кына тыелып торган буран тагын кар өерә-өерә уйнаклый башлады. Аяклар кызганда хәрәкәт итәргә кирәк иде. Барасы җир байтак, бүген барып җитеп, Кәследә кунабыз да иртәгә таңнан кире борылабыз...

Үрне шәп кенә, күмәк кенә төшсәк тә, тау менә башлагач сынаттык. Моңарчы язгы су кебек тоташ бара идек, хәзер исә юл чуарланды: берәүләр өстә үк, икенчеләр мыш-мыш менеп килә, шактый халык әле тау итәгендә диярлек, завод урамын яңа чыгып киләләр.

Сабираттәй дә шулар арасында икән, ул да тауга иң соңгыларның берсе булып менде. Бите тимгел-тимгел кызарган, утлы күзләре чокыраеп тирәнгә баткан, Әдилә дә шуңа игътибар иткән икән:

— Сабираттәйнең чанасын үзеңә ал, Ибраһим,— диде ул.

Сабираттәйнекен дә алдым, тагын бер-ике алҗыган апаның чанасын үземнекенә бәйләдем, миннән күрмәкче Дамир да өч-дүрт чананы бергә төйнәде, без аның белән лилипутларның корабларын сөйрәп баручы Гулливерга охшап киттек...

— Булмас бу,— диде Дамир өметсезләнеп.— Бүген шулай җөгәнгән хатыннар иртәгә ни кырырлар?

— Иртәгә мондый алҗыткыч тау юк инде,— диде Әдилә.— Кайту ягына юл җиңелрәк тә була.

Заводтан соң алты чакрымда Тарлау авылы. Тарлауга кергәндә кара буран чыкты. Моңарчы яннан искән җил әле каршыдан бәрде, әле артка төште, эре-эре кар кисәкләре өерелеп очып килеп яңакларга, керфекләргә сыланды, болай да салынган башлар тагын да түбәнрәк иелде.

— Булмый,— диештеләр берәүләр.

— Шушында куна калыйк.

Азчылык шулай дигәч, күпчелек икеләнде.

Әдилә болай диде:

— Бүген ничек булса да барып җитәргә кирәк.

— Нигә кунып чыкмаска? — дидем мин дә азчылыкны уйлап.

— Бүген куна калсак, иртәгә барып кына җитәбез. Тагын көн ярым кайтырга... Ә нәрсә ашарбыз? — диде Әдилә.

Сабираттәй буылып-буылып йөткеренсә дә аны яклады:

— Барыйк без... Кәслегә барып җитү кирәк. Әйдәгез, тагын бер нык кына талпыныйк.

Ишле халыкка кара буран да куркыныч түгел алай, йөрәксенеп, Тарлау урамын да чыгып киттек. Авыллар ешайды... Әхмәт, аннары Әлмәт... Бәләкәй Әлмәт... Бөгелмә ягындагы Әлмәтнең адашы...

Авылда чакта юлның ничек узасын, көчебезнен купмегә җитәсен берәү дә күз алдына китерә алмый иде. Анда барысы да сер иде. Хәзер исә юлның без уйлаганга караганда күп авыр, алҗыткыч булуы күренде. Шушы таркаулык мизгелендә, гомуми аптырашта Әдиләнең тапкырлыгына, кыюланып сүз әйтә алуына, Сабираттәй кебек авылның авторитетлы хатыннарының аңа ияреп китүенә мин хәйран калдым.

Каян килгән аңа шундый сизгерлек? Каян килгән төпле итеп сөйли алу?

Егет-җиләнгә эш артты, без әле артка калабыз, әле юл таптарга алга чабабыз. Олы гына апалар бакча балалары кук тотаклашып атлыйлар, чөнки җил, гәүдәләрне сындырырдай җил, һаман тукталмаган җил! Телефон чыбыклары безгә хәбәр китергән кебек ачыргаланып, өзгәләнеп сызгыра...

Теләк уртак карарга әверелде: тырмашып булса да Кәслегә барып кунарга! Иртә таңнан исән-аман солыны төяп чыга алсак, үз авылыбызга соңгарып та кайтып керә алырбыз. Иртәгә ашыкмасак та булыр, бүген бирешмәскә кирәк. Бүген, бүген, бүген!..

Күңелгә күптән ишеткән бер кызык килде, үзалдыма көлеп куйдым.

— Сөйлә, сөйлә,— диде Әдилә,— башкалар да белсен!

— Белмиләр ди аны...

— Белмәгәне дә бардыр...

— Әлмәтләрне «әметиләр» дип йөрткәнне беләсезме? — дип сорадым мин якындагы кешеләрдән. Беләбез дигәнне ишетмәдем.

— Аларны азрак кына хурлау сүзе булыр бу... Тарихы болай булган. Әлмәт авылы коры җирдә утыра, инеше-елгасы да, чишмәсе дә юк авылның. Шуңа күрә әлмәтләр йөзә белмиләр. Бер заман шулай, ярминкәләр әле бик шәп чакта, әлмәтле унөч кеше Нөркәйдән кайтып киләләр икән. Төнтә калганнар, җәяүлегә юл ерак шул! Азрак кына төшергәннәр ди болар, кәефләнеп җыр суза-суза кайталар, имеш. Бер заман, Әхмәт авылын үткәч, карабодай басуына барып чыкканнар болар. Ярминкәгә киткәндә генә ямь-яшел булып калган басу дулкын-дулкын ап-ак чәчәккә күмелгән икән. «Бәй,— дигән өлкән бер агай,— харап булдык бит, егетләр, Агыйдел монда күчкән бит! Нишлибез?!»

Утырып озак кына уйлашканнар болар, шешә төбендәге калдыкларны капкалагач, Агыйделне йөзеп чыгарга карар биргәннәр... Кочаклашып бәхилләшкәннәр, чишенеп ташлап күлмәк-ыштаннарын, күчтәнәчләрен бәйләп кул очына күтәргәннәр дә ап-ак чәчәктә утырган карабодай диңгезенә чумып йөзә башлаганнар. Байтак бырдаганнар болар, азаплана торгач, теге як ярга йөзеп чыкканнар. Теге акыллы агай: «Ходаның рәхмәте белән йөзеп чыктык, инде санап карыйк, берәребез батып үлмәдеме икән?» — дигән. Шешәдәге калдык белән бераз җылынгач, болар саныйлар, саныйлар икән, бер кешегә ким чыга икән. Үкерешеп җылашалар икән әлмәтләр! Кем батып үлгән дә, кем харап булган! Әле ярый, Әхмәт авылының бер егет кунактан кайтып килә икән, Әлмәт йөзәрләрен тезеп куеп санап биргән бу. Барысы да исән-сау икән, хикмәт шунда, әлмәтләрнең санаганы бере үзен исәпкә кертми калдыра килгән... Шуннан бирле Әлмәт авылы кешеләрен «әметиләр, карабодай басуында йөзүчеләр» дип шаярталар... Бу хикмәтне авылның даны китсен өчен әлмәтләр үзләре уйлап чыгарган дип тә сөйлиләр...

Минем мәзәк рәтләр буйлап китте, Әлмәт авылына барып кергәнче, авылны узганчы шуны тугылладык...

Әлмәтләр кичерсеннәр, шушы гөнаһсыз мәзәк безгә көч кертте.

Кәслегә җитәрәк Әдилә җинелрәк сөякле өч-дүрт кызны ияртеп алга китте, алар, без тупланып барып кергәнче, идарәдә фатирлар белешеп, кешеләрне җидешәр-сигезәрләп кайсын кемгә бүлеп тә куйганнар иде. Без исә Кәслегә кеше аягы басылгач кына барып әлгәштек.

Бер заман Кәсле урамнарына бөтен Югары авыл күченгән кебек булды, анда да, монда да җилдә карлыккан тамаклар кычкырып бер-берсен, иптәшләрен эзлиләр, фатирга эндәшәләр, кар сарган капкаларны көч-хәл белән ачалар. Иңнәренә бишмәтләр, туннар салган хуҗалар кулларын төкереклэп капка алларын көриләр, юлчыларны чакыралар. Тавыш, шау-шу.

— Гафифәти, безнең белән керәсеңме?

— Нурия, гырламасаң безгә ияр!

— Үлҗәнәне күрмәдегезме, кадалгыры!

— Без монда-ау!

Капкалар ябылды, тавышлар тынды. Иң аргы фатирга иптәш кызлары белән Әдилә төшкән икән, Дамир белән мине шунда чакырдылар.

Без кергән өйдә ишле генә гаилә яши икән. Хуҗабыз Габбас абый сугышта булган, ахры, өстендә искерә төшкән юка гимнастерка. Ул без тезелешеп кергән чакта ишек яңагына таянып баскан иде, чишенеп, өс-башларыбызны таратып ташлаганчы шуннан кузгалмады. Аның яңаклары эчкә суырылган, йөзе кырыс, сирәк сакалының бөртекләре эре-эре булып төрле якка чәбәләнгәннәр. Пошынып та куйдым, идарәдән керткәннәрдер кертүен, хуҗага безнең ябырылу бер дә ошамады, ахрысы! Аның каравы, хатыны Сәрвәр апаның теле-телгә йокмый, орчык күк тирәбездә бөтерелеп йөри, анысын-монысын сораша, тула оекларны кибәргә үзе элде, киемнәрне җылыга мич буена таратты.

Алардан тыш өйдә тагын бер өлкән кеше бар иде. Сөннәтчә кырма сакаллы, ап-ак чәчле бер карт без кергәндә түр сәкедә намаз укып утыра иде, менә ул алла белән әңгәмәсен тәмамлап, тезләрен бөкләп намазлык өстендә утырып калды, берәм-берәм барып аның җылы, сөякчел кулын кыстык.

Мич арасында юан сүс муенчак белән бәйләп куелган кызыл бозау күренде, мич башында өч-дүрт бала мыштым гына әүмәкләшәләр. Йоклаган булгандыр инде алар, без гөжләгәнгә уянганнардыр.

— Комачау ясадык сезгә,— дидем мин Габбас абыйга карабрак.— Балаларны да кузгаттык.

Хуҗа һаман эндәшмәде.

Сәрвәр апа бәрәңге әрчегән җиреннән бүленеп:

— Куйсана,— диде,— без күнегеп беттек инде, әле өченче көн дә унике кеше кунып чыкты. Сез дистәгә дә тулмаган!

— Унике? — дип ах иттеләр кызлар.

Әдилә барып бәрәңге әрчешмәкче дә булган иде, Сәрвәр апа: «Ял ит, хәлдән тайгансыз ич»,— дип, тегенең кулыннан пычакны тартып алды.

— Глубинкабыз зур шул безнең,— дип аңлатты Сәрвәр апа.— Үзебездә үскән игенне дә читкә ташымыйбыз, сортовой орлык кына чәчәбез. Казаннан килеп тикшереп кенә торалар безнең басуларны!

Сорт участогы икән бу Кәсле! Аерым хисапта яшәүче бәхетле колхоз!

— Сарсазлар да ярты басуларына сортлы орлык чәчәләр,— дип сүзгә катышты Әдилә.

— Габбас абый гына безне өнәмәде шикелле,— дидем мин, һаман ишек катында басып торган сүзсез хуҗага карап.

— Сөйләшми ул,— диде офтанып Сәрвәр апа,— сугыштан шулай кайтты. Инде кырык дүртнең кышында, немецның койрыгына каты кыл бәйләгәндә, яннарында гына мина шартлап телсез калган... Болай ачылыр әле диләр, ничек булыр инде, ходай ни язган. Балалар бәхетеннән ачылып китсә кана да бит...

Бабай бездән: «Кайсы авыллар сез, озак килдегезме, юллар ничек?» — дип сорашып алды...

Дәү казанда түгәрәк капкачны биетеп бәрәңге бытырдый башлады. Сәрвәр апа казан астына коры йомычкаларны өстәп кенә тора. «Көзен мунча күтәргән идек, шуның йомычкасына рәхәтләндек». Без һаман да юл хатирәләре белән уртаклашабыз, трактор турында, завод турында сөйләшеп алдык. Сәрвәр апа башкаларның кемгә фатир төшүләре белән дә кызыксынды. Алты-җиде кешенең моннан өч өй аркылы гына туктауларын белгәч, башын кагып иренә ымлады. Габбас агай бик житдиләнеп, җыерчыклы киң маңгаен тагын да җыера төшеп аңа текәлде, аннан ризалыгын белдереп башын какты, беренче тапкыр йөзендә елмаюга охшаган яктылык чагылды. Намазлык өстендә утырган бабай да аларның ымнарын аңлап:

— Җайсызрак булган икән шул,— дип өстәде.

Сәрвәр апа бабайның сүзен ачыклагач кына без эшнең нәрсәдә икәнлеген аңладык.

— Ни инде, Мәҗит хатынына, Минниса җиңгиләргә кергәннәр, алайса, сезнекеләр,— диде ул.— Күңелләре тар түгел аларның, юк, бик тә әйбәт кешеләр, фатирына да кертәләр, йомышка-юлга йөрергә дә ипле күршеләр, мәгәр, тамак яклары кысанрак быел... Өй эчләре тулы хатынкыз, Мәҗит үзе Сталинградта калды, Миннисa үзе саулыкка мохтаҗ... Бил белән интегә. Җитмәсә, былтыр бик казаландылар, ходай күрсәтмәсен! Сыерлары уҗым ашап күбенде, чак чалып калдылар... Бәрәңге базларына су кереп әллә нихәтле бәрәңге кисәүгә әйләнде... Сезнең андагыларны бәрәңге белән сыйланырга монда дәшәрбез. Калган ашым да бар, кысыр умач булса да, сөт белән агарткач ару гына булыр әле. Ипиемне дә угыз белән изгән идем...

— Алай икән, алай,— диешеп тыңладык.

Сәрвәр апа тагын җиде кешене ияртеп кайткач, болай да кысан өй эчендә инә төртерлек тә урын калмады. Габбас абзый һаман урынга утырмады, аяк өсте тегеләрне каршылады, чишендереште, олы табак белән бәрәңгене дә табынга үзе китереп утыртты.

Ян сәкегә яр карлыгачлары күк тезелешеп утырышсак та, һәр урындыкка икешәр кеше калды, чоланнан буш тәпәннәрне керттеләр, әйләндереп каплагач, алар да эшкә ярады. Алай да Дамир белән миңа урын житмәде, бәрәңге тутырган калай табакны минем тез өстенә куеп, икебез җылы мич янына чүгәләдек.

Ир кешеле өй... Хуҗасы бар өй! Әтиле өй!.. Дамир да, мин дә ятимнәр... Ә монда әтиле балалар... малайлар... Кергәч тә мин аларга көнләшебрәк караган идем, хәзер әллә ничегрәк...

Өстәл янындагылар да һаман-һаман шул сүзгә әйләнеп кайтабыз. Элек матур гына сөйләшкән кешенең авыр контузиядән соң тынсызөнсез калуына барыбызның да күңел сызлый, бу хәл белән бер ничек тә килешәсе килми иде. Сәрвәр апа да ике сүзенең берендә ирен телгә ала:

— Ял итсен, диләр... Диңгез буена барсын, диләр. Нинди диңгез ди әле монда! Нинди ял! Карап торган ирләребез биш-алты бөртек булгач, ел әйләнәсендә көне-төне эшлиләр. Сезгә дигән симәнәләрне хәстәрләп куючылар да шулар! Менә тормышлар аруланыр, җайланыр, аннан дәваланырга да өлгерер, теле дә кайтыр. Менә сез дә яхшы теләктә торыгыз!..

Ул ак яулыгының очы белән күз яшьләрен сөртте.

Зиһенем ачылып, күз алларым яктырып китте. Бу мәшәкатьләр, кадерле кунакны каршылаган кебек каршылау, егермегә якын кешегә әзерләгән сыйлы табын, өченче көн генә кунып чыккан уникe кеше — болар барысы да аның өчен — Габбас абый өчен эшләнә! Аның исән кайту куанычы шул тиклем зур, сөенече шул кадәр мул — Сәрвәр апа бу сөенечне тел белән генә гомердә дә әйтеп бетерәчәк түгел!.. Шуның

өстенә якын кешесен — балаларының газиз әткәсен телле итәсе килү теләге шундый көчле ки, ул һәр кичне утыз-кырык кешене фатирга кертергә риза, базында бәрәңге барында, чоланында он барында ул барысын туганнарча бүлешәчәк, кергән мөсафирлар аларны онытмасын гына, Габбас абыйлары өчен теләктә генә торсыннар!

«Кешеләрне Габбас абыегыз гозерен үтәп кертәм»,— диде ул соңыннан... Мөгаен, анысы да хактыр. Юк, бу теләкләре уртак аларның, алар өй эчләре белән чиксез бәхет тоеп, сөенешеп, сөешеп яшиләр, үз бәхетләре белән кешеләрне дә шатландырырга телиләр.

Яшәүнең иң бөек максаты, кешенең иң гади сыйфаты шул түгелмени?

Алтын булып агаем ла...
Көмеш булып тамаем!..

Шушы җырдагы кебек ич аларның тормышлары... Әдиләне бер җырлатасы иде...

Аркада җылы мич, тездә бушап бара торган кайнар табак... Өй эчендә әйтеп, сөйләп бетерә алмаслык рәхәтлек. Һәркем үз күршесенә бәрәңгенең тәмлерәген куярга тырыша, күңелне күтәрә торган татлы сүзләр әйтелә... Бәрәңгене ялт иттердек. Аннан чәй килде. Чын чәй, куе итеп ясалган такта чәй. Сәрвәр апа чоланнан бал керткәч, барыбыз да ах иттек. Бал, бердән, бик кадерле кунакка гына куела торган нәрсә, зур сый, икенчедән, март ае булса да аларның баллары шикәрләнмәгән, ягъни утырмаган, кичә генә суыртып куйган төсле сап-сары, сәмих сагыз диярсең! Чак кына куерган балны, ояла-ояла, калак очларыбызга эләктереп кенә бер-ике каптык...

Күршедә тукталган юлдашларыбызны андагы хуҗалары, Миннисa апалар, безнең янга бәрәңге ашарга бик авырыксынып кына җибәргәннәр икән. «Юлга алган ризыкларыбыз бер капчыкта иде» дигәч кенә ризалашканнар, «Озак юанмагыз, чәй куеп көтәрбез!» дип кычкырып калганнар. Чәйдән соң без Әдилә белән аларны озата чыктык. Чыннан да, Миннисa апаларның бәләкәй тәрәзәләрендә ут җемелди, безнең иптәшләрне анда да йокламыйча хуҗалары көтә иде...

Ниһаять, Әдилә белән икәү генә калдык... Күршеләрне озатмаганда да була иде, әмма мин шушы минутны уйлап, шушы минутны көтеп чыккан идем...

— Кайтыйк, Ибраһим, син бик аргансыңдыр? — диде ул.

— Ә үзең?

— Мин бит биш-алты чана сөйрәмәдем. Кәрванның бер очыннан икенче очына чабып та йөрмәдем.

Калдырган эзләребезгә баса-баса кайтып барабыз. Төнге буран урамның ике ягына тыгыз тезелгән йортларны күздән яшереп безнең ялгызлыкны тагын да көчәйтте, ник бер җан иясе булсын! Этләр дә өрми, ичмасам, шомландырып җил генә сызгыра.

Әдилә кинәт миңа таба тартылды:

— Тукта әле,— диде ул, пышылдап.

Икебез дә тын тартмыйча тыңланып торабыз.

Йорт араларында җил йолкына, безгә үче бар сыман колак төбендә сызгыра.

— Бүреләр! — диде Әдилә.— Чукмар менә кайчан кирәк булган икән!

Мин дә ишеттем, бүреләр улый. Берәү генә түгел, икәү, өчәү, шактый зур өер, ахрысы, берсе сузып-сузып җибәрә дә, икенчеләр кыска-кыска көчле тавыш белән аны күтәреп алалар. Алар әллә кайда, без әллә кайда йортлар арасында булсак та, бер өер бүре улаганда тән чымыр-чымыр итеп куя, кот бот тирәсенә төшә...

— Этләр шуңа тынган,— дидем мин.— Бүредән шүрли алар.

— Керик,— диде Әдилә калтыранып.
— Ерак ич алар,— дидем мин, батыр күренергә тырышып.
Габбас абыйларның өй турына гына житкән идек, безне тәмам куркытып, гөрс итеп өй кыегыннан зур кар кисәге ишелеп төште...
— Әдилә! — дидем мин, кызның күзләрен күрергә тырышып.
— Куркыныч монда, Ибраһим.
— Күптән синең жырлаганыңны ишеткән юк.
— Әллә шушында жырлатыр идеңме?
— Түгел дә...
— Күптән жырлаган да юк инде...
— Нигә?
— Жыр бит ул язгы су кебек... Үз вакытын белеп кенә кузгала...
Март башы — яз башы. Мин март башын бик яратам... Кешеләр уйлап чыгарган бәйрәм түгел ич бу, табигать биргән бәйрәм... Яз житте, жырларга урыны туры килми, вакыты туры килми.
— Кояш житми сиңа, алайса, жылылык житми.
— Алай да димәс идем. Бүген миңа озын юл үтсәк тә кәефем шәп...
— Син жырлап жибәрсәң, жил дә тынар, бүреләр дә туктар.
— Каян беләсең?
— Былтыр көз, Чаллыга барганда синең жырыңны ишеттем мин, Әдилә.
— Кайчан иде икән? — диде ул нигәдер оялып.
— Кич иде. Матур кич иде! Син жырлый-жырлый, бер башың Олы су ягыннан юлга таба миңа идең...
Әдиләнең калку күкрәкләре, нидер сөйли-сөйли, минем күкрәгемне иркәлиләр, назлыйлар, көне буе жил-буран гына кагылган иреннәремне аның иреннәренә якын китерәм, аның май жиледәй тәмле-татлы сулышын тоям, ул күзләрен йоммый, тагын да зуррак ачып миңа карый, елмая, мин аның ап-ак матур тешләрен күрәм, тагын да якынрак тартылам, Әдилә көлә, башын артка ташлый, аннары мине суырып үбә...
Иптәшләр йоклаган. Сеңгәннәр. Сәрвәр апа утны кысып бәләкәй якка күчергән, өйдә ярым караңгы.
— Гаепләштән булмасын, сезнең икегезгә урын мич арасында калды,— диде ул. Кәнфитләнеп торыр чак түгел, без, аны-моны уйлап тормастан, тиз-тиз чишенеп ыргыттык. Әдилә минем йон аякчуларымны, чабатаны мичнең буш калган урынына жәйләп урнаштырды, мин лампаны күтәреп аңа яктыртып тордым. Ул көлә, мин дә аңа карап көлми түзә алмыйм.
— Тс-с,— ди ул, миңа бармак янап.
Мич арасына юка гына кыршылган палас жәелгән иде, баш астыбызда әллә чалбар, әллә пинжәк төймәләре калкып-калкып тора. Өстебезгә үзебезнең дымлы киемнәр... Баш очыбызда бозау, сарык бәрәннәре. Без кыштырдагач, алар да уянды, бәрәннәр тып-тып өскә үк менеп киттеләр. Мин түзмәдем, көлеп жибәрдем, Әдилә йомшак учлары белән минем авызны эзләп табып томалады...
Аяклар арган... Аяк табаннары гүләп тора... Ничә чакрым жир узган аяклар... Ничә кешенең эзенә басып үткән аяклар... Жирнең моңын, жирнең кодрәтен татый торган крестьян аяклары... Мин үз аякларым янында Әдиләнең аякларын тоям, арганлык та, юлда, тау башында улап утырган ач бүреләр дә онытыла... Бозау әнкәсен сагынып мөгри, бәрәннәр кычкырып мәэлдәп куя, Әдилә миңа таба тартылып, кочагыма керә... Без бер-беребезгә сарылабыз, саф иреннәребез әле кадере югалмаган, бер генә тапкыр әйтелә торган сүзләрне әйтәләр:
— Яратам мин сине, Әдилә!..
— Мин дә, Ибраһим...
Быелгы язны, быелгы жәйне күз алдыма китереп карыйм... Ни генә булмасын, безне алда ниләр генә көтмәсен, тыныч яз ич бу! Тыныч

дөнья!.. Хат ташучы үткәнен куркып һәм өметләнеп көтәсе юк... Безнең егыларны әле армиягә алмый торалар. Сугыш безнең яшьтәшләргә килде дә терәлде. «Немецның койрыгын бәйләделәр»,— ди әнә Сәрвәр апа... Әдилә хәзер гел-гел авылда булачак... Әдилә... Аны олылыйлар... Иптәш кызлары да, башкалар да... Ни дисәң дә тормыш чынлыгы белән күбрәк очрашкан шул ул, ачысын-төчесен иртәрәк татыган. Апасын күмгән... Дүрт баланы карап гомер иткән... Күңеле һәм тәне гарип җизнәсен караган...

Куенымда минем бар байлыгым, өметем, киләчәгем... Куенымда Әдилә... Ул миңа шул кадәр якын, үз булса да, әле мин өйләнү турында уйлый алмыйм... Анысы миңа тиңдәшсез хыял, гомергә эшкә ашмаслык хыял булып тоела әлегә...

Өйдә тагын кемдер йокламый иде. Йомшак кына шыгырдап чыпталы ишек ачыла да, берничә секундтан безнең борыннарга салкынча, рәхәт һава килеп бәрелә. Сәрвәр апа бераздан безнең янга килде.

— Йокламыйсызмы, балалар? — Аның тавышында шатлык ишетеп икебез дә калкындык.— Абзагыз тикшереп тора, буран басылган, суыта!

Чыгып йөрүче Габбас абый икән. Кочагымны тытырып Әдиләне күкрәгемә кыстым.

— Суыта, Әдилә...

— Суыта сиңа, мин янып төштем...

— Миңа да бик эссе!..

Төн уздымы, әллә төштә генә күренеп киткән сихри бер мизгел идеме бу, әйтә алмыйм. Кәсле авылына, Сәрвәр апаларга рәхмәтләр әйтеп сикерешеп тордык... Хуҗалар безне: «Юл төшсә, туп-туры үзебезгә керегез», дип озатып калды...

Иртәнге кояш! Рәхмәт сиңа. Күңелләрдә өмет, тәндә көч. Аяклар ял иткән. Өс-баш, чабаталар коп-коры, җиңел. Билләр кысып буылган. Моңа синең якты нурларыңның шифасын өстәргә кирәк, иртәнге кояш. Авылыбыздан киткәндәге җанлылык кабатланмаса да, иптәшләр күңелле генә сөйләшәләр, шырык-шырык көләләр. Иртән кояш күренмәсә, кешеләр сирәк көләләр...

Тиз үк юлга чыктык, кәсләләрнең тәҗрибә зур икән, эшне печеп башкардылар. Җитмеш биш чана. Җитмеш биш капчык солы. Һәркем, хәлле хәленчә, кем чанасында өч пот, дүртне алучылар да бар, ике белән калучылар да булды. Бер кәгазь, бер үлчәү...

Буш чана сөйрәү җиңелрәк булса да, солылы капчыкларны тарту күңеллерәк икән! Юлыбызның бер максатына ирешелгән. Чәчүлек орлык тутырылган. Эре, сортлы солы! Чәчүлек кайта Югары авылга, тереклек кайта.

Дамир чанасында төгәл алты пот... Иртә таңнан Кәсле кардысына төшеп менәргә дә өлгергән ул, авызы ерык:

— Колын күрдем бүген, малайлар...

Колын... Дамирның иң зур хыялы. Монысын мин беләм. Икенче зур хыялы аның Әдилә! Монысын Әдилә белән икебез дә беләбез.

Нишлисең, барлык хыяллар да тормышка ашмый шул...

Алты пот солысын атларга калдыру турында уйлый Дамир...

Колын!.. Тиз генә күреп булмас әле колыннарны Югары авылда!

Әтисе дә конюх иде Дамирның. Биш яшеннән атка менеп чапкан, җиде яшеннән ызанга тырмага төшкән, ун яшьтән чытыр арба белән көлтәгә чыккан иптәшемнең хәлен Кәсле юлында аңладым. Сөйгән ярсыз да, атсыз да калган егетнең хәле яман, бик яман иде...

Әлмәткә кайтып җиттек. Кичә кич авыл урамнарын узганда, күз ачкысыз буранда Әлмәттә тереклек иясе юк сыман тоелган иде. Бүген анда да, монда да кыска бишмәтләрен җилбәгәй җибәргән, бүрек

колакчыннарын күтәргән карт-коры күзгә чалынды, малае-шалае шунда урала, капка төпләрен көриләр, урамны — без узасы юлларны — ялт итеп арулап куйганнар. Кара кашлы, шалкан төсле ак йөзле апалар, кулларын каш өстенә куеп, безне каршыладылар:

— Исән-саулармысыз?

— Чәчелмичә барып җитә алдыгызмы?

— Чәй эчеп чыгыгыз!

Чәй эчеп тормадык, урамны көрәп куюлары өчен рәхмәтләр укып юлда булдык. Әлмәтләр авыл белән безнең кәрванны озатып калды.

Завод тавына тиклем шәп кенә бардык дияргә ярый. Берничә кеше шома юлда тәгәрәп китте дә, бер чана ватылды, Зарифа апаның капчыгы ертылып солысы юлга ага башлады, аны берәмтекләп чүпләп тутырдык, тегәрҗеп белән шытырдатып капчыгын ямадык... Үкчә кырылганын, чабата башларына үсеп чыккан әрсез мыекларны санап тормадык...

Заводка җитеп тын алабыз дип куанышканда гына кәрван уртасында нидер буталды, алдагылар чаналарын ташлап артка борылдылар, арттагылар бер урында бөялделәр. Әдилә белән без дә шулар янына ашыктык.

Сабираттәйнең йөрәк өянәге кузгалган иде.

Торымнан-торымга йөрәге кузгала икән аның, дип сөйлиләр иде, бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, шул яман хәл завод тавы өстендә башланган икән...

Без барып арага кысылышканда, Сабираттәй капчык өстендә кырын ятып бияләеннән кар ялый иде.

— Хәлең ничек? — дип сорыйбыз аннан. Сабираттәй эндәшми, башын гына чайкый...

Нишләргә? Кеше йөрәге тишек капчык яки ватылган чана түгел, түгәрәк ясап уралган кешеләр бер-икешәр адым чигенеп, хафада калдылар.

Хатыннар Сабираттәй чанасы тирәсенә җыйналгач, мин үзебезнең өс-башыбызның нинди таланган, йолкынган иске-москы булуына игътибар иттем. Ябык идек без, ямьсез идек... Кояшлы март көнендә, тау өстендәге ак-ак кар арасында барысы аермачык күренде, йончыган идек без, арган идек... Башкалар шулай йончылганда йөрәк авырулы хатын ничек түзә алсын? Хәкимҗан абзыйның «тузган ул!» дигән хөкеме исемә төште.

Дамирның бөтен авылга атаклы чанасына яңа эш табылды. Аның авыр капчыгын минем чанага салдык, Сабираттәйне, үрәчә арасына аякларын суздырып, Дамир чанасына утырттык.

— Түзми әмәлең юк, Сабира апа,— диде Әдилә.— Завод күренеп кенә тора әнә. Анда инде врач бардыр, каралып чыгарсың.

Хатыннар үз чаналары тирәсенә таралышканда да сүз гел шул турыда барды:

— Кем белән кунды ул?

— Тамагына каптымы икән?

— Йоклый алдымы?..

Чанамда саллы гына ике капчык. Әдилә чанасын Югары очның бер егеткә тактык. Сабираттәй янында Дамир белән Әдилә. Тау төшкәндә чана салулап китү куркынычы бар, Әдилә чытырдап үрәчәгә ябышкан, карап-чамалап кына төшәбез. Аяклар тая, авыр чанам дык итеп тез астыма килеп бәрелә, мин егылып та киткәлим. Сабира апа, мәрткә киткән кебек, сүз дә дәшми, күзен дә ачмый... Ә кояш җете, ак кар күз кабакларын сызлата!..

Бригадир «барма» дигән икән аңа, бөтен авыл кузгалганда ничек түзеп ятмак кирәк, дип, дәртсенеп үзе юлга чыккан. Солыны өч пот салдырган...

Тау төшү ифрат авыр булды. Моңарчы чыдап килгән баулар, арканнар өзелгәләде, бер чана хуҗасын бәреп китте дә телефон баганасына барып сыланды, капчык ярылды, солы акты... Егылган кешеләргә карата такмак чыкмый инде хәзер, кешеләр тын, борчулы һәм үтә житди иделәр. Аяк таймасын өчен бер-берсенә тотынышып, кочаклашып төшәләр...

Бара-бара завод урамына төшеп життек. Сабираттәй дә тынычланып күзләрен ачты...

Хәзер эшләр җайлана!

Тик заводта врач юк икән, сугышка чаклы бар иде, хәзер тиенә алганыбыз юк шул, диештеләр кешеләр. Фельдшер бар икән, медпункт якында гына, без өчәүләшеп — Әдилә, Дамир һәм мин — Сабираттәйне шунда алып киттек. Башкаларга: «Калып торыгыз, тамак ялгагыз», — дисәк тә, байтак кеше безнең белән барды.

Сабираттәйне чаршау артындагы ап-ак җәймә җәелгән агач караватка кертеп салдык. Хәзер безгә аның юеш чабаталары белән идәнгә үк салынып төшкән сырма җиңе генә күренеп тора.

Фельдшер апа берездан безнең янга чыкты. Озын гына, эре сөякле, бераз шадрарак апа. Калын кофтасының түшендә орден ленталары. Сугыштан кайткан, күренеп тора.

— Каян кайтып киләсез? — диде ул каты «къ» белән.

— Кәследән иде лә, солы симәнәсе алып кайтып барабыз.

— Атларыгыз калмадымыни соң?..

— Атлар ни, бары белән югы бергә...

— Кайсы авыллар?

— Югары авыллар идек.

— Ничек соң, апа? — диде Әдилә.— Ни хәлләр бар?

Фельдшер җавап бирергә ашыкмады, тәрәзә каршысына басып урамга карады.

— Ничек дип әйтим икән? Фельдшер гына мин... Ә йөрәк...

Моңарчы абайламаган идек, ишек яңагы янында стенада телефон бар икән, фельдшер апа шалтырата башлады. Сарман больницасын сорады. Аннан завод идарәсенә шалтыратты. Аның шөбһәле сүзләрен ишетеп без бик каты шүрләдек... Сабираттәйнең хәле әйбәттән түгел икән!

Кем белән сөйләшүен аңламадык, мәгәр сүз гел безнең турыда барды. Трубкасын куйгач, ул безне ашыктыра башлады:

— Хәзер заводтан уникe ат торфка китә икән. Югары авыл шундадыр бит? Сез күпер төбенә җыйналып аларны көтеп торыгыз. Өлкәнрәкләр утырып та кайтыр, ә капчыкларның бар булганын шуларга төягез.

Өчебез беравыздан:

— Ә Сабираттәй? — дидек.

— Иптәшегезне алып калам. Больница белән киңәшәм дә үзем ат белән Сарманга озатып куярмын,— диде фельдшер.

Иптәшләр янына чыктык, атлар турындагы хәбәргә сөенешсәләр дә, Сабира апа турындагы хәбәрне ишеткәч, аларның да борын салынды... Аптырашып Игәнә күперенә төштек, монда озак юансак, завод атларының китеп баруы мөмкин, йөкчеләре дә кырысрак аларның, үткәнсүткәнне утыртырга бигүк яратмыйлар. Шулай булып чыкты да, олаучылар:

— Йөк төяп нишләп йөрик, ди? Бүген әйләнеп кайтасы бар. Атлар көне-төне юлда,— дип карышып маташтылар. Без боек кына таралыша башлагач, кул селкеп чаналарыннан сикерешеп төштеләр һәм безнең капчыкларны чаналарга төяргә булыштылар. Арганракларга, өлкәннәргә урын да табылды.

Атларга төялешеп тә, җәяүләп тә иптәшләр кайтып китте, без Әдилә белән монда калдык. Медпунктка борылып менгәндә фельдшер апа телефоннан сөйләшә иде. Байтак кына көтеп утырдык. Менә теге яктан Сабираттәйнең:

— Косасы килә,— дип әйткәне ишетелде.

Әдилә белән мин белештермичә аның янына атылып кердек. Чалкан яткан Сабираттәйнең иягe очлайган, күзләре төпкә чумган, чырае танымаслык булып үзгәргән иде.

Фельдшер:

— Чыгып торыгыз моннан,— дисә дә, без кузгалмадык.

Сабираттәй:

— Косасы килә,— дип пышылдады. Аннан күзләрен йомды, хырылдый башлады, юка гәүдәсе буйлап дулкын йөгереп узды. Аннары кинәт тынды.

— Үлде бичара,— диде фельдшер.— Нишли генә алам соң мин? Таланган ич аның йөрәге, ватык сәгать күк келтерәп тора!

Әдилә иреннәрен тешләп минә таба тартылды, йөзен иңбашына яшереп капланып төште...

Фельдшер безне: «Үземдә кунарсыз, ялгыз торам мин, иртәгә иртән ат белән китәрсез»,— дип үгетләсә дә, кунарга заводта каласы килмәде. «Иртән килеп җитәрбез»,— дип, без кайтырга чыктык. Нindидер көч безне өйгә, юлга өндәде...

Трактор яныннан бу юлы сүзсез генә узып киттек...

Безнекеләр авылга кайтып та җиткәндер инде... Юл озын булса да, без бер җирдә дә тукталып тормадык, кайттык та кайттык.

— Иртәгә үк Хәкимҗан абзыйны күреп сөйләшергә кирәк,— диде Әдилә.— Моның башка берәр җае юкмы икән?

— Иртәгә түгел, бүген үк күрербез.

— Кайтып җитәсе бар шул әле.

Мин каралҗым-зәңгәр урман өстенә тәгәрәгән кояшка карадым.

— Җитәрбез...

Аяклар талды, аны сизмәдек. Тамак ачты, тукталырга вакыт кызгандык. Барган шәпкә генә икмәк сыныкларыбызны кимердек. Ни турында сөйләшсәк тә, сүзнең очына Сабираттәй килеп ялгана иде.

— Балаларын кая куярлар инде?

— Ничәү әле аның?

— Өчәү.

— Өчәү үк икән шул.

Үзебезнең урманны чыкканда күз бәйләнә башлады. Урман юлы туп-туры, урман юлы тулы кеше! Кемнәр болар? Кая баралар? Ашыгыбрак атлый башладык, ара якынайды, алдагылар, бәләкәй чаналар тарткан кешеләр килеп җиткәч, читкәрәк чыкты. Каршыбызга безнең Югары авыл кәрваны чамасы ук озынга сузылган ишле чаначылар килә иде. Иң алдагы чаналы, сыңар куллы ирдән:

— Кайсы авыллар?— дип сорадык. Ул теләр-теләмәс кенә:

— Ераклар,— диде.

— Шулай да?

— Чокырлыдан без,— дип, сүзгә катышты аның артыннан килүче хатын.— Ишеткәнегез бармы?

— Юк.

— Кәслене беләсездер, алайса?

— Беләбез. Бик беләбез.

— Шуннан биш кенә чакрым безнең авыл.

— Ничек? Ничек? Ә симәнәне каян алып кайтасыз?

— Солы симәнәсе бу,— дип ачыклады хатын.— Сарсаз глүбинкәсеннән чыгардык менә...

Без аптырап сүзсез-рухсыз катып калдык...

Урманнан үзебезнең авылга йөгереп дигәндәй кайттык. Туп-туры идарәгә барып кердек. Хәкимҗан абый шунда утыра иде.

— Кайтып җиттегезме, үскәннәрем? — диде ул юаш кына.

— Без кайттык... Сабираттәй генә...

— Үлеп калды,— дидем мин.

Председатель дәшми. Без дә эндәшмибез...

— Чокырлылар очрадымы? — дип сорады ул кинәт.

— Очраттык шул менә...

— Сез, үскәннәрем, болай итегез инде... Чокырлы кешеләрен очратуыгызны башкаларга тишмәгез... Ишеттем мин аны! Көне буе районнан шуны даулап кайттым!.. Менә генә телефонограмма алдык, симәнәне безгә Сарсаздан, ягъни якын глубинкадан бирә башлыйлар... Чаба-чаба үзем дә койрыксыз маэмай булып кайттым менә... Тик бу юләрлекне башкаларга әйтмәгез, эх, Сабира кызганыч!..

Иреннәребезне кысып, йодрыкларны йомарлап, идарәдән чыгып киттек, әйтмәдек ул хәлне, берәүгә дә сөйләмәдек...

*

* *

Икенче көнне Сабираттәйне алып кайтып җирләдек. Өченче көнне Сарсаз глубинкасына элеккедән дә ишлерәк булып, озын кәрванга тезелеп юлга чыктык. Ара якын булгач, малай-шалай да безгә иярде. Дамир гына өйдә калды, аның атларына да солыдан өлеш чыгардылар. Дамир атлар яныннан кайтып безне озатып калды.

Әдилә белән иң актыккы кешеләр булып барабыз. Көн матур. Чалт аяз. Кар өстенә карасаң күз чагыла. Авылны чыккач та зират тавы аермачык күренеп тора. Зиратта яңа кабер. Кызыл балчыктан өелгән бәләкәй генә таучык ак карда уйнаган кызыл төлке кебек кенә күренеп тора...

Май-июнь, 1972 ел.

## Ренат Харис

# МӘХӘББӘТ СУКМАГЫ

### Таң суы

Ун ел инде таң күргән юк,
Әйдә, бер күрик әле,
Чыклардан чирканчык алып,
Урманда йөрик әле.

Йөрәкнең жу иткәне юк,
Юк шашынып типкәне —
Күңелемдә гыйшык дигән
Чишмә әллә кипкәнме?

Таңны күргәч, дулкынланмый,
Чылтырамый калмас ул.
Ыргып чыгар, бөркеп чыгар,
Җырлап чыгар изге су,
Ырымлы су, дәвалы су...
Тоям, сау бит чишмәсе.
Иңнәреңә чәчрәтермен —
Изүеңне чишәрсең...
Сиңа — рәхәт...
Мин аңладым —
Миннән нәрсәдер үткән.

Иртәләр генә калган ич,
Ә таңнар инде беткән.

### Килешми, ярамый

Диңгезгә дулкынсыз килешми дә, ярамый да —
күлгә охшап кала.

Чүлгә эссесез килешми дә, ярамый да —
Даны-шаны югала.

Урманга җилсез килешми дә, ярамый да —
Сурәт кыяфәтен ала...

Кешегә мәхәббәтсез килешми дә, ярамый да —
Кайгыдан да, шатлыктан да уала.

●

Язгы бөреләр күңелгә
Китә дә тиеп-тиеп,
Сорамагач та әйтәбез:
Яратам сине,
диеп.

Сары яфраклар күңелгә
Китә дә тиеп-тиеп,
Сорагач та әйтмибез без:
Яратмыйм сине,
диеп.

## Кар рәсем

Шыгырдап, шыгырдап,
Кар керде шигырьгә.

Сызылып, сызылып,
Юл китте сузылып...

Без бу юлда синең белән икәү генә.
Тик бу ак юл кая илтә икән менә?
Нигә соң син дәшмисең, әйт, нигә, нигә? —
Без бу юлда синең белән икәү генә.
Йөгереп китсәк менә шушы ак юл буйлап,
Каршы алыр кебек безне безнең туйлар.
Ап-ак өйгә ап-ак баскыч өйдерермен,
Ак парчадан ап-ак күлмәк кидерермен.
Нигә соң син дәшмисең, әйт, нигә, нигә? —
Без бу юлда синең белән икәү генә?..

Кар рәсем, кар хыял
Эреде, таралды.

Каралды ап-ак юл,
Каралды, каралды.

## Озаклады

Киттең инде,
Күзләремнән күптән киттең инде.
Кычкырып әйткән сүзләремнән
Киттең инде.

Йөрәгемне эчтән бикле, тыштан бикле,
Мәңге бикле буш бер зиндан иттең инде.
Кем коткарыр,
Синнән көчле кем табылыр,
Кем соң ватар йөрәгемнең йозакларын?
Үтә көннәр йозакларга тутык өстәп...
Озаклады коткаручым,
Озаклады.

●

Егет диңгездән йөгереп чыкты.
Ай яктысы чәченнән тама.
Караңгыда кыз тавышы:
Кочагың юеш —
Кочаклама.
Караңгыда кыз тавышы:
Кочагың салкын —
Кочаклама...

Шулай диеп бер-берсенә
Кеше ничек әйтә ала?!
Кара, нинди шыксыз сүзләр:
Кочагың салкын —
Кочаклама...

## Зәңгәр чатыр

«Укып кара әле,
Зинһар, укып кара!
Булмаганга башка чара, калмаганга тәкать
Язган җырларым бу фәкать.
Син үзең дә, шагыйрь, мөгаен,
Мәхәббәткә сабышкач кына
Шигырьгә ябышкансыңдыр...

Болай булды бу:
Командировкада кинода
Табыштык та таныштык үзе бәлән.
Унынчыда гына укый иде әле.
Имтиханнары алдыннан
Толымбай урманнарыннан
Җыеп кайттык ап-ак сирень.

Биш таҗлысын эзли-эзли ул сөйләде:
Унынчы А классыннан
Аңа бер егет гашыйк икән.
Багышлап шигырьләр яза икән.
Ә ул аны малайсына...
Әйтәм бит: гашыйк булдымы кеше —
Күккә аша башлый,
Чүп кенә сүзе дә
Шигырь булып таша башлый.

Мине армиягә алдылар,
Шул көзне ул Казанда техникумга керде.
Ике ел ике арада хат йөрде.
Шушы җырлар минә дәфтәремнән чыгып качып
Аңа таба очты, аңа таба йөгерде.
Ни генә юк җырларымда минем!
Бу җырларда минем тилелегем,
Бу җырларда күпме хыялый сурәт,
Хыялый урман, хыялый күл,
Хыялый төн уртасында зәңгәр чатыр,
Кайчакларда хәтта сабый тавышы...

Армиядән туп-туры мин Казанга кайттым,
Иске өйләр арасыннан фатирын эзләп таптым,
Ишек кактым.
Ярым караңгыда бер ханым ишек ачты
Һәм, мине танып, чаршау эченә качты.
Ә чаршауда йөкле шәүлә калды.
Кермә диде ул,
Күрмә диде ул сыктап...

Менә ничә ел узгач,
Җырларымны укып карадым.
Ихлас күңелдән язганмын бит,
Ихлас күңелдән бу җырларым кәгазьгә түгелгән.

Кайдалыгын белмим. Казанда юк.
Эзлисе дә килә. Табасым да килми.
Үзем түгел, бәлки җырым эзләп табар.
Бәхетсездер кебек,
Менә күзләренә кара».

Егет миңа рәсем сузды.
Әйе, әйе. Ул — шул,
Кайчандыр мине хисләр давылына ташлап киткән,
Ташлап китеп мине шагыйрь иткән
Беренче мәхәббәтем.

Башка кеше күңелендә ул тудырган хисләр
Менә шигырь булып өелеп ята минем алдымда.
Минем алдымда
Минем беренче мәхәббәтем хакында
Саф күңелдән язылган
Ят шигырьләр...

## Фазыл Мостафин

# КЕНӘРИЛЕ ГАЛИМҖАН

хикәя

Иртән сәгать нәкъ алты тулуы булыр, Галимҗан абзый шактый көмешләнгән чәчләрен артка сыйпаштырып үз «резиденциясе»ндә утырыр. Куе ябалдашлы тополь төбендәге ике тәрәзәле кечкенә будканы, уенын-чынын бергә кушып, шулай дия торган булды ул. Труба-турбина хуҗалыгына начальник булып килгәч, язганда-сызганда урын, дус-иш килгәндә куыш булыр дип, үзе ясады ул аны. Буровойлардан калдык-постык такта кайтартты, балта, пычкы алып килде. Атна-ун көн дигәндә будка әзер иде. Үзе киеп йөри торган комбинезон төсенә буяп та җибәргәч, труба-турбина әрдәнәләре арасында әллә каян күренеп тора башлады әлеге будка.

Ишекне сак кына ачып керер Галимҗан абзый, керү белән ян тәрәзә өстендәге челтәрле читлеккә күз салыр. Шуны гына көткән пар кенәри пыр тузар, әрле-бирле сикерешеп, талпына-талпына канат кагар, өзеп-өзеп дәртле сызгырыр.

Галимҗан абзый аяк очларына гына басып читлек янына килә, ягымлы тавыш белән кошларга сүз куша: «Ай, рәхмәт төшкерләре, бүген дә сагынып көттегезме мин картлачны? Ашыйсыгыз да килгәндер инде, сыйлыйм үзегезне, хәзер сыйлыйм».

Кошлар аның саен талпына төшәләр, сызгырулары аның саен дәртләрәк, түземсезрәк. «Ярар инде, ярар, бераз гына сабыр итегез, башта плащны салырга кирәктер, элеп тә куярга кирәктер».

Карт мастер өстәл янына килә, тартмасын ачып кәгазь пакет чыгара. Учына киндер орлыгы салып, читлек эчендәге савытка коя, савытның икенчесенә графиннан су агыза.

Кенәриләр тек-тек җим чүпләгәндә, Галимҗан абзый өстәл артына кереп утыра, уң кулы белән яңагына таяна, күзләрен йомар-йоммас бер мәлгә тынып кала. Тамаклары туйган кенәриләр, шуны гына көткән кебек, янәшә кунача-га куналар, канат кага-кага сайрарга тотыналар.

Галимҗан абзыйның көн дә тыңлый торган иртәнге серенадасы бу. Үзе яшьлек дөньясында, бормалы су буенда, кызыл маңгайлы текә тау итәгенә сыенган Куштирәгендә. Бала чактан ук яратты ул сандугач сайрауларын. Урманга барса да, әрәмәгә төшсә дә, яшел үлән өстендә сузылып ятар иде, дөньясын онытып кош сайравын тыңлар иде. Әнкәй назын да, әткәй иркәсен дә алмаштырды моң.

Беркөнне Куштирәген ташлап китте ул. Авыл каршысындагы кызыл маңгайлы текә тау да калды, бормалы су буйларындагы әрәмәләр дә, сандугачлы тирәкләр дә. Кинәт булды аның китеп баруы, таң атканда станциягә барып житәргә, Баку якларына юл тоткан поездларның берсенә утырып китәргә кирәк иде.

Очраткан саен «көтүче калдыгы, авызыңнан үпкәң күренә» дип, бик тә теңкәсенә тигән зәһәр телле карт остабикәдән үч алырга булды Галимжан. Көтү кергәнче кеше-карага күренмичә авылга кайтты, бакча артыннан ишегалдына узды, кача-поса чоланга керде, остабикәнең тәһарәт өчен генә тоткан жиз комганына муеннан тутырып керосин салды. Остабикәнең ишегалдындагы кое тирәсендә «шул көтүче калдыгыдыр, шул гынадыр» дия-дия, жан-фәрманга чабып йөрүен кет-кет көлә-көлә койма ярыгыннан озак карап торды ул.

Шул китүдән әйләнеп кайтмады туган авылына Галимжан, башы да күзе, нужасы да үзе дигәндәй, илне күп гиздe, ул чаклардагы нефтьле төбәкләрне барысын да йөреп чыкты. Кемнәрне генә күрмәде, кемнәр белән генә очрашмады — әммә шунысын белде: яхшы кешеләр күп булып чыкты дөньяда.

Яшьлек гадәтен үзгәртә алмады, кая гына барып чыкмасын, бераз акча юнәтеп аякка басуы була, кенәриле читлек сатып ала. Аның турында сүз чыктымы: «Ә, теге, кенәриле Галимжанмы?» — дия торган булдылар.

Яраткан жыры да «кенәриле» иде аның. Яшьрәк чакларында өзелеп-өзелеп Куштирәген сагынганда тирәкле су буйларына, чәчәкле тау араларына китәр иде һәм бер ялгызы калып кенәриле жырын сузар иде. Эх, тавыш иде үзендә, моң иде! Чәчләр агара башлагач, мәжлес-мазарларда аерылмас дусты Юрий Юрич олы куллары белән аркасына шап та шоп суга-суга кыстарга тотынып иде: «Галим-ка, друг, давай канарейку». Һәм Галимжан абзый күзләрен йома төшеп, әле дә моңын жуймаган күкрәк тавышы белән сузып жибәрер иде:

Асылъяр, кенәри, бергә булырбыз әле.

Галимжан абзый өстәлгә счет куеп, төймәләрен шалт итеп бер тартуга кенәриләр сайраудан шып туктыйлар: «Агаебыз эшкә кереште, комачауламыйк», — диләр бугай.

Ашыкмый гына кәгазен кәгазьгә куеп, кичә кайсы буровойга күпме турбина, борау жибәрелгәнен исәпләгәч, техснабтан кайтартылган трубаларны санап карагач, саннарның йомгагына күз салгач, кат-кат баш кагып куя: «Ай азагы житә, тагын трубаларга кытлык туа. Азрак кайтаралар, азрак...»

Труба-турбиналарның иртәгә кирәклесенә заявка язу өчен ун минут вакыт житә. Кәгазь-дәфтәрләрне пөхтәләп кенә бер читкә жыеп куйгач, кесәсеннән Юрий Юрич бүләге көмеш портсигар чыгарып папирос ала. Әле дә шул зимагур гадәтен ташлый алмавына көнеленнән сыкранып шырпы сыза. «Юрий Юрич күптән ташлагандыр инде, ә мин, картлач, ташлый алмыйм, һаман да шул тәмәке колы».

Сәгать сигезенче ярты, күптәнге гадәт белән күзләр тәрәзәгә төбәлә: хәзер тәрәзә төбеннән мастерлар узарга тиеш. Иртәнге планеркадан чыгып мастерской каршына килеп туктаган вахта автобусларына утыру өчен алар сукмактан килеп кечкенә капкадан керәләр һәм әлеге карт мастер резиденциясенең тәрәзә төбеннән үк узып китәләр. Ярата Галимжан абзый аларның ничек узганын тәрәзә аша күзәтеп торырга. Атлауларыннан, килеш-килбәтләреннән планеркадагы сүзнең кайсы тирәдә бөтерелгәнен чамаларга ярата.

Әнә сукмак очында беренче булып Гайнанов күренде. Ата каз кебек муенын сузган, озын кулларын тегермән канатлары кебек, шыксыз селтәп бер йөгерә, бер атлый. Кечкенә капканы да аягы белән генә тибеп ачты. Әһә, егетем, планеркада сүз син дигәнчә булмадымыни. Чыбыркылап куган кебек шуның өчен чабасың. Арттарак биш-алты мастер бергә килә-ләр, араларында Шәрипов, әле уңга, әле сулга карап, төкерекләрен чәчә. Директорның күзенә кереп һәр әйткәненә баш кага-кага куштанланып утырган да, хәзер иптәшләре алдында боргалана, акланырга тырыша. Арзан мәзәкләреннән үзе хихылдап, койрык болгый.

Тәүфыйк бүген дә артка калган, берүзе ашыкмый гына атлый. Әллә инде барыбер тәрәлеп тормый дип, дөньясына кул селтәгән. Юк, менә ул башың күтәрә төште, күкрәгеп киереп әче итеп сызгырды. Үзе инженер, бригада житәкли, үзе һаман малай-шалай шуклыгын ташламаган. Алдагы төркемдәгеләр берьюлы аңа таба борылдылар, һәм кайсы кул изәп, кайсы баш кагып күңелле шаулашып алдылар.

Нәрсәсе белән күңеленә хуш килгәндер, Галимҗан абзый үз итә бит шул егетне. Институттан килгән көнне үк яратты үзен. Яшь инженерны аның бригадасына җибәрделәр, теләр-теләмәс кенә алган иде, борын чөймәде, мин кем димәде, уен-көлке белән ярты ел помбурлыкта йөрде, бер ел чамасы тормоз сабы шомартты. Башы йомры егетнең, скважина бораулау мәсьәләләренә аек карап инженерларча фикер йөртә белә. Мастерга, бригадага төпле киңәшләре белән күп ярдәм итте, бөтен трестны шаккаттырып бер-бер артлы рекорд куйдылар. Бик үсеп китә торган, үсеп тә китәр иде дә, телгә зәһәр, кемлегенә карамый туры әйтә торганнардан.

Тәүфыйк капкадан керүгә, яшел будкага күз салды, аны көтеп ишек төбенә чыккан карт мастерны күрүгә йөзе-күзе белән елмаеп, уң кулын күтәреп, ерактан ук:

— Галимҗан абзыйга иртәнге сәламнәр! — дип кычкырды.

Алар, кулларын кыса-кыса күрешкәч, Галимҗан абзый бер мизгел Тәүфыйкка текәлеп карап торды.

— Кәефең ярыйсы күренә, энекәш, әллә бүген эләкмәдеме?

Тәүфыйк баягыдан да җәелә төшеп елмая; бер күзен кыса төшеп:

— Ничек эләкмәсен инде, обязательно, эләкте,— ди.

— Тагын партизанмы?

— Кызык кеше икәнсез, Галимҗан абзый. Тормыш үзгәреп тора бит.

— Соң?

— Анархист мин бүген, абзый кеше.

Карт мастер, кашларын җыерып, кырысрак булырга тырышкандай итеп әйтә:

— Кешегә дигән буровойны басып алгач, шулай диярләр, егетем.

— Гайнановның бик кудырасы килгән иде, китмәдем. Егетләр яклады. Шәрипов да яклап сүз әйтте.

Галимҗан абзый бер генә мизгел уйланып ала һәм кинәт:

— Шәп иткәнсең, молодец! — ди. — Бөтен конторны бер Гайнановка эшләтәләр, атна-ун көн көтсен әле, башкалар көтәләр бит.

Тәүфыйк, вахтага соңга калам дип, борылмакчы иде, Галимҗан абзый аның җиңенә үрелде.

— Туктале, бер нәрсә күрсәтәсе бар, әйдәле минем белән.

Икәүләп бер читтәрәк урнашкан складка керделәр. Галимҗан абзый үрелеп ут кабызды. Аслы-өсле өелгән ящиклар арасыннан узып бер почмакка җиткәч, тагын үрелеп ут кабызды. Бер әрдәнә кечкенәрәк, нибары егерме ящик, шуның янына туктадылар.

— Кара әле.

Тәүфыйк, кулындагы сумкасын читкә ыргытып, тиз генә өстәге ящикны алып. идәнгә куйды, тактасын каерып, бер борауны тартып чыгарды. Икәүләп бик озак карадылар борауны, шарошкаларын селкеттеләр,

тешләрен капшадылар. Башкалардан аермасы юк. Ә стаканындагы бу кызыл тамга?

— Болар, энекәш, сынарга җибәрелгән бораулар булырга тиеш,— диде ахырда карт мастер,— тик документлары килеп җитмәгән...

— Бораулап карыйм әле,— диде Тәуфыйк, аягүрә торып,— икесен генә алып китим.

— Нинди тирәнлектә бораулыйсың?

— Иртә белән верей горизонтына кергәннәрдер, сигез йөз метр чамасы булырга тиеш.

— Ал! Ләкин кара, тирәнлекне төгәл үлчәп төшер, икесенең дә купме, ничек бораулаганына, зинһар, акт яз. Вахта кул куйсын. Заводтан вәкил килеп җитәр.

Төш вакытында буровойга су ташучы машина белән Тәуфыйк кайтып төште, атылып будкага килеп керү белән баш бармагын сузып күрсәтте.

— Нәрсә, Тәуфыйк, әллә кош тоттыңмы?

— Галимҗан абзый, калганнарын тизрәк бир.

Карт мастер сабырлыгын җуймаска тырышып сорады:

— Ни булды?

Бораулар менә дигән, проходкалары бермә-бер артык.

— Ни кыларга икән синең белән?

— Ничек инде, ни кыларга? Икенчесе забойда, күтәргәнче барып җитәргә кирәк.

Галимҗан абзыйның кашлары җыерылды, йөзе кырысланды, ике-өч кенә минут уйлап торгач, кинәт кулын селтәде:

— Беткән баш бетсен инде. Кичен безгә керергә онытма.

— Буровойдан кайта алсам керермен. Обязательно, керермен.

...Нәкъ бер атна узды. Кичтән яңгыр сибәләп китте, Галимҗан абзыйның тез буыннары сызлап тора иде. Иртән уянып китсә, сәгать алты тулган. Унбиш-егерме минутка соңга калсам, кенәриләр әллә ни үпкәләмәсләр әле дип, үрелеп радиоалгычның төймәсен борды. Соңгы хәбәрләр тапшыралар, Мәскәүдән... Төньяк-көнбатыш районнар өчен яңа рекорд. «Әлмәтбурнефть» трестының мастер Тәуфыйк Зиннуров җитәкчелегендәге бораулау бригадасы 1822 номерлы скважинаны девонга бораулаганда яңа рекорд куйды, файдалы тизлек станок-айга...

Галимҗан абзый үзе дә сизмәстән сикереп торды, күз аллары карангыланып киткәндәй булды, ни өчендер тамак төбен капшап алды. «Әйтәм атна буе күренмәде, тишек борын, әйтәм...» дип сөйләнә-сөйләнә, ни әләкте шуны киеп бораулау конторасына чыгып чапты.

Миргазиян Юныс

# ТОЗЛЫ ҖИЛ

ПОВЕСТЬ

## 30



„Биш минуттан Мәскәү поезды кузгалып китәчәк. Озатучыларның вагоннан чыгуын үтенәбез. Билетларыгызны озатучылар алып китә күрмәсен».

Янымда бер чегән хатыны бала имезеп утыра. Аяк очымда ике солдат башларын бер-берсенең җилкәсенә салып йоклыйлар.

Бу — минем хәтеремдә калган төннәрнең иң озыны иде.

Поезд китү турындагы белдерүдән соң зал бушап кала да, бераздан тагын халык җыела. Халык күп чакта урын эзләп йөрүчеләр йокларга ирек бирмиләр. Халык әзәйгәч, йокыга китә башлау белән, милиционер килеп уята:

— Гражданин, бу утыргыч ятар өчен ясалмаган. Әнә, ничә пассажир урын тапмыйча басып тора,— ди.— Мин, читкәрәк шуышып, басып торган кешеләргә урын бирәм. Урын бушау белән, тагын йокыга китәм.

Минем инде кабыргаларым сызлый, чигәләрем кысып башым авырта. Шулпа ашыйсым, чәй эчәсем килә.

Кесәмдәге акчаны учыма бушатып, тагын санап карадым. Кая инде билетка җитү. Акчам чемоданымны посылка итеп салырга җитсә, билетсыз да китеп булыр иде. Рөхсәтсез генә вагонга кереп утырырга тәвәккәллек җитмәде. Шулай икеләнеп торган арада Мәскәүгә ике поезд китеп барды.

*

* *

Бушлай бирелә торган хәрби литерны билетка алыштырып, офицерлар вагонына гына утырып йөргән чаклар искә төште. Ул вакытларда поезд кузгалганда ресторанга гына кереп, кыйммәтле ашамлыклар белән тукланып чыга идек.

Беренче мәртәбә очучы киеме киеп авылга кунакка кайткач, гомуми җыелышта партия оешмасы секретаре безнең буынның никадәр алга

---

Ахыры. Башы 7 нче санда.

китүен күрсәтү өчен авыл халкына болай дип сөйләгән иде: «Бакир агай, мәрхүм, гомер буе иген игеп яшәгән гади бер крестьян иде. Аның улына карагыз, безнең Габдрахман — летчик, офицер».— Залда утыручылар дәррәү миңа таба борылып караганнар иде.

Ул чакта мин дә секретарьның сүзенә ышанган идем. Горурланудан клуб түбәсенә менеп этәч булып кычкырыр дәрәҗәгә җиткән идем. Җыелыш беткәнче укалы погоннарымны ялтыратып, кәпрәеп утырдым. Бүген исә күңелемне бер шөбһәле сорау тырный: «Дөресме секретарьның фикере? Дөресме? Дөресме?»

Шушы сорауга җавап эзләгәндә гаҗәеп бер хакыйкать барлыгын аңладым: игенчегә дә чин тага торган булсалар, минем этинең дәрәҗәсе генералныкыннан бер дә ким булмас иде. Ул чыннан да игенчелек генералы иде. Генерал буларак, эти, мәрхүм, ел саен бер дивизия туйдырырлык икмәк үстерде. Ә мин, юеш борынлы лейтенант, шушы хакыйкатьне белмичә, этиемнән югарырак үрләдем дип кәпрәеп йөрдем...

Өлкән буын безгә дәрәҗәне кызганмыйча, зур юмартлык белән мул итеп бирде. Үзләре патша заманында наданлыкта, хокуксыз яшәгәч, алар безне кеше итәргә тырыштылар. Безнең белем алуыбызга сабыйларча куандылар. Белем безгә акыл, тәүфыйк алып килер дип өметләнәләр иде алар. Без инде әкренләп белем алуны диплом алуга әйләндереп киләбез. Диплом синең белемеңне, дәрәҗәңне күрсәтә. Диплом алу белем алудан җиңелрәк тә, файдалырак та. Диплом кәгазен кешегә күрсәтеп мактанып йөрергә була...

Чемоданымны саклау камерасына илтеп тапшыргач, туалетка кереп салкын су белән битемне юдым. Кечке поездга кадәр унике сәгать вакыт бар иде әле. Тагын бер мәртәбә шәһәр карарга, кадрлар бүлегенә кереп, яңадан эшкә урнашу мөмкинлеген тикшереп чыгарга кирәк иде. Мин бит эшкә урнашу турында кайгыртмадым әле. Тәҗрибәле кешеләр белән киңәшергә, дингезчеләр белән сөйләшеп карарга кирәк. Болай беренче уңышсызлыктан куркып артка чигенү дөрес булмас.

Шәһәр йокыдан уянып, көндәлек эшенә керешә башлаган иде. Урам себерүчеләр төнлә коелган яфракларны җыеп, чүп савытларына тутыралар. Урамдагы кешеләрнең күбесе хатын-кыз. Алар җилкәләренә элеп чыккан киемнәрен төзәтә-төзәтә базарга ашыгалар.

Мин, кайсы якка баруыма әһәмият итмичә, яңа йокыдан уянган шәһәр эченә кереп киттем.

Бу тирәдәге йортлар үзәктәгеләргә охшамаган иде. Аларның күбесе ике-өч катлы итеп диңгез туфыннан салынган. Бу урамнарда көньяктагы тузан, кояштан каралган җылы таш коймалар, аулак, күләгә урыннар ешрак очрый иде. Шәһәр читендәге бер катлы йортларның төзелешендә төрки халыклар йогынтысы сизелә. Украиналылар йортларын башкачарак итеп салалар.

Башымны күтәреп, йорт номеры астына язылган урам исемен укыдым: «Дала урамы». Урам һавасында әз булса да дала исе сакланып калган әле. Мондагы тормышта Бабель хикәяләрендә очрый торган буяулар бар.

Урам почмагында биш-алты хатын пычак чарлатырга чират тора. Пычак кайраучы аларга ниндидер көлке сүз сөйли. Хатыннар дәррәү көлеп җибәрәләр дә, карт сөйли башлагач, көлүләреннән туктап, тагын тыңларга тотыналар. Шул хатыннар янына җиткәч, туктап, бераз карап тордым да:

— Диңгез буе бульварына ничек барасы? — дип сорадым.

— Менә бу урам белән бераз баргач, Преображенскийга чыгарсыз. Шуннан бара торгач, Дерибас урамына җитәрсез. Дерибас урамы сезне Бульварга алып төшәр,— диде бөдрә чәчле кара бер хатын. Блондинка-

лар йомшаграк күңелле булалар. Сары чәчле хатынның мине җәяү йөртеп интектерәсе килмәде, ахры:

— Трамвай барында нигә җәяү йөрергә? Әнә теге тукталышта егерме сигезенче трамвайга утырыгыз да үзәккә җиткәнче барыгыз. Дерибас урамыннан Бульвар күренеп кенә тора,— диде анысы.

Пычак кайраучы янына җыелган хатыннарның миңа тагын берничә юл өйрәтәчәген сизеп, мин кара чәчле хатын өйрәткән юл белән тизрәк китеп бардым.

Кадрлар бүлеге ачылырга ике сәгатьтән артык вакыт бар иде әле. Мин башта Преображенский урамын эзләп таптым. Язуда бу урам Совет Армиясе урамы атала икән. Одесса урамнарын күбрәк иске исем белән атап йөртәләр. Икешәр исем буталыш кертә, эзләгән йортны табу читенләшә.

Урамнарны иске исемнәре белән атау үзенә күрә кала тарихын белгәнлекне, шәһәрдә күптән яшәгәнлекне күрсәтә. Шунлыктан искечә атап йөртүне бетерүе кыен. Дерибас урамына берничә мәртәбә яңа исем кушып караганнар. Ләкин беркем дә аны яңача атамаган. Исем яңарту белән мавыгучылар граф де Рибас исемен калдырырга мәҗбүр булганнар.

Дерибас урамына җиткәндә ашханәләр ачыла башлаган иде инде. Зур универмагка янәшә бер ашханәгә чәй эчәргә кердем. Минем бәхеткә каршы, ашханәләрдә ипине бушка бирү модага кереп килә иде. Бушлай ипи студент халкы өчен зур куаныч булды. Торап куелган ак икмәк өстәлләрдә өелеп ята. Бер-ике стакан чәй сатып ал да туйганчы ашап чык. Стипендия акчасы кесәдән саркып чыгып беткәч, шул түләүсез икмәк безне еш кына ач йөрүдән коткара иде.

Сәгать сигезләр тирәсендә кадрлар бүлеге янына диңгезчеләр җыела башлады. Сүз һаман резервтан котылып, тизрәк еракка йөзә торган пароходка эләгү турында бара. Ишеткән сүзләрне бергә җыеп нәтиҗә ясаганда, диңгезчеләрнең һәммәсенең яхшырак пароходка, акыллырак капитан кулы астына, тату яшәүче бердәм коллективка эләгәсе килә иде. Тыңлап йөри торгач аңлашылды: диңгезчеләр начар пароходтагы әйбәт капитанга эләгүне яхшы пароходтагы начар капитан белән эшләүдән артыграк күрәләр икән. Аларның һәр экипажны дөрес бәяләүләре, пароходчылыкта эшләүче капитаннарның, помполитларның холыкларын, уңай һәм кире якларын белүләре тәмам хәйран калдырды. Кадрлар бүлегендәге характеристикаларны диңгезчеләр биргән бәя белән чагыштырып карыйсым килеп китте. Телгә алынган кешеләр турында андагы кәгазьләргә дә диңгезчеләр сөйләгәнчә язылганмы икән?

Минем төркемнән төркемгә күчеп, сүз тыңлап йөргәнемне күргәч, мондагы кешеләр шикләнә башладылар. Кайберләре мине күрү белән сөйләшүдән туктап кала иде. «Болар мине әллә шымчыга саный инде», дип уйлап алдым да диңгезчеләр яныннан читкәрәк китеп, чинар агачына барып сөялдем. Агачның салкынча кайрысына аркамны терәвем булды — кемдер арттан килеп ике беләгемнән эләктереп алды. Мине тоткан куллар шуышып аскарак төште. Менә кулларымны каерып артка таба борды. Мин агачка берегеп калдым.

— Җаныңмы, малыңмы?

— Җибәрегез, кулны сындырасыз бит!

— Кара, валлаһи син бит бу! Әллә күземә күренәме дип торам! — Кулымны каерган кеше агач артыннан чыгып җилкәмнән кочаклап алды.

— Эдик дус! Ни эшләп йөрисең монда?

— Үзең ни эшләп йөрисең, старик?

— Мин монда эш эзләп килдем. Син ялдамыни? — Бер кызып киткәч, сорау бирүдән тыелып булмый иде.

— Минем әниләр монда бит. Кайтуыма егерме көн инде.

— Хәтерләдем, син Одесса кешесе бит әле. Одесса турында сөйләгәннәрең әле дә исемдә. Ялга кайтуыңмыни?

— Юк, бөтенләй кайттым.

— Хәрби хезмәт сиңа ошый иде. Куып җибәрмәгәннәрдер бит? Әллә берәр хәл булдымы?

— Синең шикелле авариягә очрап, геройларча кайтып китү безгә эләкмәде. Хәзер ракета чоры башланды, дустым. Бомбардировщикларны свалкага озаталар. Безнең полкны кыскарттылар. Синең дусларыңның күбесе гражданкага кайтып китте.

Эдикны үз күзем белән күреп, аның белән үзебезнең полк хәлләре турында сораштырып торсам да, бу очрашуның өнемдәме, төшемдәме икәнлегенә әле төшенеп җитмәгән идем.

Эдуард Гончаров белән без ике ел бер эскадрильяда хезмәт иттек. Рәдиф Агишев белән очрашканчы ул минем иң якын дустым иде. Кичләрен офицерлар йортына танцыга йөри идек. Мине армиядән озатканда Эдик Хәрби академиягә керергә хәзерләнеп калган иде.

Мин тагын полкташларым турында сораштыра башладым:

— Безнең эскадрильяны да тараттылармы?

— Таратмый ни эшләсеннәр? Әйттем бит ракета чоры башланды дип.

— Агишевның кая киткәнлеген беләсеңме? Эскадрилья командиры майор Алмазов кайда хәзер? Безнең укчы-радистыбыз Осташко үзенең Херсонына кайтып киттеме?

Эдик тәмәке кабызды. Бергә хезмәт иткән кешеләр турында сөйләгәндә ул да минем шикелле үк дулкынлана иде:

— Осташконың маҗаралары турында сөйли башласам ышанмассың да. Син киткәч, Осташконы капитан Булгаркин экипажына күчергәннәр иде. Володя Лагутин син барында ук аның белән оча башлаган иде бит инде. Син киткәч, Булгаркинның звеносын Котып шартларында очуны үзләштерергә билгеләделәр. Ай ярымнан звеноның ике экипажы кире әйләнеп кайтты. Булгаркин экипажын озак көттеләр, аларның кая булулары турында хәбәр-хәтер юк иде. Вертолет җибәреп тә эзләтеп карадылар. Поляр станцияләреннән соратып та тикшерделәр, ләкин аларның эзләре югалган иде. Алты айдан Булгаркинның семьясына пенсия билгеләделәр. Лагутинның хатыны күрше полкның бер техник-лейтенантына кияүгә чыкты. Тугыз ай дигәндә Булгаркин, Лагутин, Осташко полкка кайтып төшмәсеннәрме!

Самолетлары ватылгач, алар кеше аягы басмаган тундрага сикергәннәр икән. Ике атна адашып йөргәннәр. Шуннан соң аучы чукчаларга юлыкканнар. Аучылар кышлагына елына бер генә мәртәбә вертолет килеп ашамлык калдырып китә икән дә шуның белән ел буена бәйләнеш өзелә икән. Вертолет килгәнче, безнең очучыларыбыз аучылар арасында яшәгәннәр.— Эдик, сөйләвеннән туктап, миңа карады.— Тукта әле, Габдрахман, эш эзлим дип шаяртмыйсыңдыр бит? Сине Мәскәү университетына укырга кергән дип сөйләгәннәр иде бит. Без инде синнән күренекле галим чыгар дип көтә идек. Теория ягына бик әвәс кеше идең бит син.

Бу турыда мин Өметгали белән Багратка сөйләгән идем инде. Ләкин ул чакта серләремне тулысынча ачып сала алмаган идем. Сөйләсәм дә, алар мине аңламаслар иде.

— Минем университеттан китүемне беркем дә хупламады. Башлаган эшне тәмамлау кирәк иде. Бераз дуамаллык эшләп ташладым шикелле.

— Диплом алырга ничә ел калган иде соң?

— Ике ел.

— Алай булгач, бетерергә кирәк иде шул. Югары белем югары

белем инде ул. Армиядә дә хәзер югары белемсез бернәрсә эшләп булмый. Урта белем белән анда да ерак китәрлек түгел. Югары белемле офицерлар кыскартуга эләкмәделәр.

— Син дә дипломга шулай карыйсың икән,— дидем мин Эдикка.

— Югары белем дәрәҗә түгел бит ул. Институт дипломын погонга таккан йолдыз шикелле итеп кешегә күрсәтеп йөрү дәүләткә никадәр зыян китерә. Чын, реаль белемне һөнәргә әйләндереп, эштә кулланып була. Тормышта кулланырга ярамаган белем нигә кирәк? — Мин, Эдик белән очрашуга ышанмыйча бер тын карап тордым да сүземдә дәвам иттем:— Укыганда әдәбият фәне миңа бик ошый иде. Педагог булу көн тәртибенә баскач, бу фәннең кирәк түгеллеген аңладым. Шуңа күрә укуны ташларга туры килде.

— Университетка керер алдыннан бу турыда уйламаган идеңмени?

— Уйлаган идем. Ул чакта, үзең беләсең, диңгезчеләр хәзерли торган училищега керү өчен медицина комиссиясен үтәргә кирәк иде. Сәламәтлегең начар дип, геология факультетына да алмадылар. Әдәбият яраткач, филфакны сайлаган идем, инде хәзер аңладым — мин филолог була алмаячакмын.

Эдик кулын минем җилкәмә салды:

— Ярый әле, син бу хакыйкатьне аңлый алгансың. Дипломына, я булмаса акчасына кызыгып, гомер буе күңеленә ошамаган эш эшләүчеләр дә бар бит.

— Үзең күңелең тарткан эшкә урнашырга йөрисеңме соң? — Мин Эдикның нинди эш белән мавыкканлыгын белә идем.— Бәлки сиңа радиотехниканы ташламаска кирәктер?

— Мин белештем. Һәр пароходта радиостанция бар. Морзе әлифбасын ныклап үзләштерсәм, радист булып эшли алачакмын. Авиациядә чакта ук мин радистлыкка кучмәкче булып йөри идем бит. Хәзер инде ничек булса да теләгемә ирешергә иде исәп.

— Башка җирдә дә пароходчылык юкмы икән? Син бу турыда белешеп карамадыңмы? — дидем мин Эдикка.

— Белешеп карадым. Одессада кит аулау экспедициясе бар — анда да урын юк. Ждановта пароходчылык бар — андагы пароходлар чит илгә йөрми. Баку шәһәрендәге пароходчылыкта да шул ук хәл. Владивостокта эшкә урнашу җиңел дип сөйлиләр — Сахалиннан соң минем бер дә консерва белән тукланып яшисем килми. Туклану дигәннән, кайтып тамак ялгап алуга син ничек карыйсың?

— Кайткан чак булыр әле. Башта кунар урын табарга кирәк.— Көннең кичкә авыша башлавы мине борчый иде инде.

— Әйдә, безгә кайтыйк,— дип, Эдик мине култыклап троллейбус тукталышына алып китте.— Ял сезонының кызган чагы. Хәзер бер җирдә дә урын табып булмый.

Тәкъдимнән баш тарткан булып, кыстатып тору бер дә табигый чыкмас иде, шуңа күрә мин Эдикка иярдем.

Вокзалга кереп минем чемоданны алып чыктык та Куликов кыры дигән мәйдан аша унсигезенче трамвай тукталышына юнәлдек.

## 31

Трамвай көтүчеләрнең күбесе — Олы фонтанда дача биләүчеләр һәм «кыргыйларча» ял итәргә килгән турист халкы. Тукталышта Одесса карчыклары тозлы суда пешерелгән чәкәнле кукуруз — «пшонка», стаканлап вак креветка саталар. Трамвай көтүчеләр шул креветканы сатып алалар да эч пошканнан, көнбагыш ярган шикелле, кабыгын җиргә төкерә-төкерә ашыйлар.

Бала җитәкләгән бер чегән хатыны, трамвай көтүчеләрнең борыннарына төртә-төртә, кара борыч тәкъдим итеп карады да безнең янга килде:

— Хуш исле кара борыч. Алып җибәр, чибәр егет! Пакеты өч сум гына!

Эдик бер пакет борычка акча түләде. Бу аның ялгышуы иде. Эдикны җиңеп булганлыкны аңлагач, ике чегән хатыны безне кысрыклап скверга алып керделәр дә ялтыравыклы тукымадан ясалган галстук алырга кыстый башладылар.

Мондый галстукларны мин Мәскәүгә командировкага килгән кайбер кешеләр муенында күргәли идем. Ялтырарга яратучылар зәвыгына туры китереп эшләнгән бу товарны кайдан табалар икән дип баш вата торган идем. Бу искиткеч галстукның чыганагын белгәч, ачыш ясаган галим шикелле шатланып куйдым.

Тукталыштан читтәрәк, ак чәчәкле сәрби агачы төбендә, бер яһүд малае трамвай көтүчеләрне «кәртечкәгә» төшерә. Мондагы кешеләрнең экзотика яратканлыгын бу малай аңлап алган булса кирәк: аның кулында — гади кайчы. Фотопленка хезмәтен кара картон үти. Клиент бишкә кадәр санап өлгергәнче, яшь рәссам аның профилен кайчы белән уеп та ташлый. Билгеле, кәгазьдәге профиль «кәртечкәгә» төшүченекеннән матуррак чыга. Яхшылыкның кадерен белүчеләрдән яуган өч сумлыкларны әлеге уңган малай кесәсенә салып кына тора.

Бу кадәр озак көтүгә мәскәүлеләр түзмәс иде. Мондагы халык кабаланмый, трамвай көтүдән дә файда ясап, тукталышта тамаша карый.

Аяксыз бер инвалид карлыккан тавыш белән «Раскинулось море»ны җырлап алды да, кулына бескозыркасын тотып, халыкка мөрәҗәгать итте:

— Братишкалар, чибәр туташлар, геройлар, Одессага килгән кунаклар! Мин ирләренә тугры булган хатыннардан һәм хыянәтсез, намуслы, батыр ирләрдән генә алам. Ирләренә хыянәт иткән хатыннар, җәмгыять милкенә кул тидергән ирләр мең сум бирсәләр дә, мин аны кире битләренә ыргытам.

Трамвай көтүчеләр арасында ирләренә хыянәт иткән хатыннар, җәмгыять милкенә кул сузган ирләр, билгеле, юк иде. Шунлыктан, аяксызның бескозыркасына шыбырдап вак акча ява. Инвалид, халыкның юмартлыгын мактап, җыйган акчасын кесәсенә тутыра гына башлаган иде, кинәт милиционер пәйда булды.

— Нишлисез сез, гражданнар, туктагыз! Сез бит кешене туры юлдан яздырып, паразит булып яшәргә өйрәтәсез. Шушы инвалидка хөкүмәт яшәргә җитәрлек итеп пенсия түли. Эшлисе килсә, аңа уйнап кына эшләрлек эш тә бирәләр. Бу кешенең тамагы тук, өсте бөтен. Ул бит эчәр өчен акча җыя. Аңа акча биреп җинаять эш эшлисез, гражданнар.

Инвалид, ашыкмыйча гына, җыйган акчасын кесәсенә салды да, милиционерга кушылып, халыкны үгетләргә тотынды:

— Милиционер дөрес әйтә, братишкалар. Бирмәгез миңа, чибәр туташлар, геройлар. Мин аны барыбер эчеп бетерәм. Одессага килгән кунаклар! Акча кирәктән җырламыйм мин. Сезне яратуыма түзә алмыйча, йөрәгем җилкенеп, күңелем моңланганга җырлыйм. Сезнең шушылай матур, бәхетле яшәвегезне күрү шатлыгыннан җырлыйм.

Трамвай көтүчеләр рәхәтләнеп көләләр. Аларга кушылып аяксыз инвалид та көлә. Милиционер ни эшләргә белмичә бер тын халыкка карап торды да кулын селтәп китеп барды. Култык таякларына таянып, инвалид җирдән күтәрелде. Ашыкмыйча гына бескозыркасының тузанын кагып киде дә горур гына кыяфәттә вокзал буфетына таба юл тотты.

Еракта тимер тәгәрмәчләрнең рельска ышкылып чыңгылдаганы ишетелде. Тавыш якыная бара. Трамвай көтүчеләр сөйләшүдән тукта-

дылар. Хәрби округ штабы каршысындагы тирәкләр артыннан трамвай килеп чыкты.

Мондый трамвай Одессадан башка шәһәрләрдә дә булдымы икән? Трамвай юлы гадәттәгедән таррак. Үзе җәен яшелчә сатар өчен вакытлыча әмәлләнгән ларек шикелле тар такталардан гына оештырылган иде. Түбәсе япон фанзасыныкына охшашлы, стена урынына, пассажирлар коелып калмасын өчен, тәбәнәк рәшәткәләр генә беркетелгән.

Одессада яши башлагач, мин бу техниканың революциягә кадәр Бельгия акционерлары төзегәнлеген белдем. Кыңгырау шикелле тормышны яңгыратып яшәргә яраткан Одесса халкына мондый трамвай бик кулай килгән, ахры. Башка маршрут трамвайларын күптән яңага алыштырсалар да, Унсигезенче трамвайны һаман саклый килгәннәр.

Тәгәрмәчле беседкалар тукталышка килеп җитү белән халык дулкыны ишекләргә ташланды. Бер минуттан трамвай күч аерып азапланган умартаны хәтерләтә иде инде.

Интеллигент кыяфәтле агайлар, матур, әдәпле апалар трамвай көтүчеләрне сабыр булырга, тәртип бозмаска өндиләр, ә үзләре тәртип бозучыларны этә-төртә ишеккә таба үрмәлиләр. Ниндидер бер сихерле көч, әдәпле белән әдәпсез арасындагы аерманы җимереп, кешеләрне трамвай эченә сөйри иде.

Трамвайның рәшәткәләре шытырдап куба башлаганчы тулдылар. Малайлар кишәнке-кишәнке булып тышкы якка асылындылар.

Җимеш агачлары эчендә утырган чүлмәк түбәле ак йортлар, виноград сабаклары чорналган беседкалар әкрен генә артка таба йөгерә. Бер яктан мине Куприн әсәрендәге Яшка-музыкантка охшашлы кеше кыса, икенче яктан ачык изүле, чәче маңгаена бөселеп төшкән яшь бер ир кабыргамны бораулый. Каршымдагы урында чүлмәкле гөл кочаклаган бер карчык буылып-буылып ютәлли. Трамвай дөбердәвенә кушылып, вагон эчендә өзек-өзек сүзләр ишетелә:

— «Слава» флотилиясе Гибралтарга кергән, диләр...

— Алар узган айны ике бүлмәле квартирага күчтеләр. Газлы, туалеты ваннасыннан аерым, балконына раскладушка сыя...

— Тапкан кемгә чыгарга! Ул бит Привозда хамса белән сату итә...

Шушы сүзләрне ишеткәндә, трамвай уңга таба борылыш ясады да, мин янымдагы кешенең җилкәсе аша күкселләнеп яткан илаһи бер киңлекне күреп алдым.

Бу зәңгәрсу сәхрә еракларга, офык артларына китеп югала. Шушы мәңгелекне хәтерләткән чиксезлек алдында дөньяның ыбырчыбырларын беләсе дә, ишетәсе дә килми иде. Әңгәмә кинәт өзелде. Трамвай эчендә тантаналы тынлык урнашты. Мин моңа кадәр татымаган эчке бер дулкынлану аша күңелдә рәхәтлек туа башлаганын сиздем. Көләч зәңгәр күк, саф диңгез һавасы чыннан да тынгысызлыктан арыган күңелгә шифалы ял биреп, йөрәк җилкенүен басарлык иде.

## 32

Эдик ишектән керү белән үк минем турыда сөйли дә башлады:

— Армиядәге дустым Габдрахман бу, кичә вокзалда кунган...

— Менә юләр. Ирекле көннән вокзалда куньп йөриләрмени? Нигә соң безгә генә килмәдегез? — диде Эдикның әнисе.

Эдикның әбисе, җиңел сөякле, какча тәнле, чибәр бер карчык, хафалана үк башлады:

— Кура җиләге кайнатып эчерим әле. Ул вокзалда әллә нинди куркыныч чир йоктыруың бар, алла сакласын.

Озын чәчле, уйчан кара күзле үсмер кыз гына сүзгә катнашмыйча

безгә карап тора иде. Эдик аны биленнән кочаклап минем янга алып килде:

— Галя, сиңа кияү алып кайттым, таныш булыгыз.

Берничә минуттан соң инде мин үземне күптәнге танышларым арасына эләккән шикелле сизә идем.

— Алай булгач, без дә танышыйк инде,— диде Эдикның әнисе, миңа кулын тузып.— Паспорттагы исемем Талия булса да, мине Татьяна Константиновна дип йөртәләр. Әбиебезнең исеме Фатыйма. Ул исемен русчага әйләндергәнне яратмый. Без аны «әби» дип кенә йөртәбез. Ярар, калганын өстәл янына утыргач сөйләрбез. Галя, өстәлне беседкага әзерлә, яме!

Татьяна апа чия агачлары арасындагы җәйге кухняга кереп югалгач, Галя абыйсының колагына нәрсәдер әйтте дә тиз-тиз атлап виноград белән чорналган беседкага кереп китте.

Аяк атлаганда Галяның биле сизелер-сизелмәс кенә сыгылып китә, авыр толымнары салмак кына чайкалып куя.

«Менә шушындый толымнарга таккан талир тәңкәләр тавышы бабаларыбыз заманында егетләрнең үзәкләрен өзгәндер инде», дип уйлап алдым. Мин Галя шикелле чибәрлекләре күзгә ташланып торган кызлардан бераз курка идем. Атлаган саен сокланучыларны очратып тору андый кызларның күбесенең мин-минлеген үстерә, акылларын тирәнәйтергә ирек бирми. Уйлап карасаң, матурлыкның куркыныч ягы да бар бит. Матурлык алдында егетнең зирәге дә миңгерәүләнеп киткәндәй була. Әгәр чибәрлекне өләшә торган булсалар, мин аны бик ышанычлы, матур булуның җаваплылыгын аңлый алырлык кешеләргә генә тапшырыр идем. Табигать матурлык биргәндә моны уйламый шул.

Без юынган арада беседкадагы өстәлгә кухнядан ашамлык ташырга керешкәннәр иде. Анда кыздырылган скумбрия, томалап пешергән зәңгәрсу бадымҗан, помидор, тозлы яшь кыяр да куелган.

Галя беседка түбәсеннән асылынып торган йөзем тәлгәшләрен кайчы белән кисеп алып, тәлинкәгә сала иде. Ашамлыклардан чыккан хуш ис тирә-якка таралды. Менә шушылай тату гаиләдә әниләр кулы белән хәзерләгән татлы ризыкларны соңгы мәртәбә моннан ике ел элек җәйге каникул вакытында авылда ашаган идем.

Мин, тәмле ашау — буржуйлар гадәте, ашау өчен генә яшәү — оят дигән фикердә. Шуңа карамастан, әниләр пешергән майлы кыстыбый, тары тәбикмәге шикелле тәмле ризыклардан баш тартырлык көч юк иде миндә.

Табын әзерләнеп бетүгә, бер учлам хуш исле яшел үлән тотып, беседкага Эдикның әбисе килеп керде.

— Гомерендә үләнсез аш ашаганы юк аның,— диде Эдик минем колакка.— Син аның йөзенә кара. Сиксән яшендә дә аның битендәге алсулык кыз чагындагы кебек.

— Эдик, сез бу егет белән бергә хезмәт иттегезмени? — диде Фатыйма әби.

— Әйе, бер эскадрильяда. Диңгезчелеккә дә бергә керергә йөрибез,— диде Эдик.

Фатыйма әби бер тын уйланып торды да башын чайкап куйды:

— Нилектән яшьләр генә хәтәр эш эзлиләр икән? Берәр тыныч кына җиргә урнашып, ипләп кенә эшләп йөрсәләр, ни булган инде! — Әби, яныма утырып, мине аркамнан сөйде.

— Безнең заманда эшнең тынычы юк. Тынычланып яши торган чор түгел,— диде Эдик, әбисенең колагына иелеп.

Татьяна апа сүзне башка темагарак борып җибәрде:

— Эдик мине аңламый. Бәлки син аңларсың. Ир-егеткә һөнәр диңгезчелек белән генә чикләнмәгән бит. Одессада егермегә якын югары уку йорты бар. Шуларның берсенә укырга керергә ярамаганмыни?

Эдик тәмам әсәрләнеп беткән, башка эш турында ишетергә дә теләми. Шуны аңлатып кара әле, акыллым.

— Әни, Габдрахман үзе йөзү эшенә керергә дип башкаладан килгән.

— Шулай ерактанмыни? Башкаладан килгән кеше икәнсең,— диде Татьяна апа.— Анда нәрсә эшли идең?

— Укый идем.

Бу сүзне ишеткәч, Галя җанланып китте:

— Кайда укый идегез?

— Университетта.

— Кайсы университетта, МГУдамыни?

— Әйе.

— Юләр икәнсез. Студентлыкны мин диңгезчелеккә алыштырыр идемме. Ул университеттан нинди генә атаклы кешеләр чыкмаган. Моряклар чит илдән алып кайткан тәти кием киеп кәпрәеп йөрүдән башка берни белмиләр.

— Галка, син үзең кеше тәнкыйтьләүдән башка бернәрсә белмисең. Синнән бер тапкыр да юньле сүз ишеткәнем булмады,— диде Эдик.

— Ишеткәнең булды. Студентлар турында мин гел әйбәт сөйлим.

— Каршыңда МГУ студенты утыра. Шулай булгач, юньләп сөйлә.

— Ул бит хәзер студент түгел инде.

— Студентлыгым бераз калды әле. Читтән торып укуга күчтем,— дидем мин.

— Андый укуны стационар белән чагыштырып булмый шул. Ничек инде читтән торып дәрес үзләштереп булсын, эшкә урнашу белән укуызны ташлаячаксыз.

— Галя, нигә аңа каныгасың әле? Син кеше белән гел рәтләп сөйләшә белмисең,— диде Татьяна апа.

Сүзгә Эдикның әбисе дә кушылды:

— Мин яшь чакта мәдрәсә бетерүчеләр Истамбулга укырга китә торганнар иде. Минем ике абыем шунда укып гимназия бетерделәр. Без пароход белән ел саен алар янына кунакка бара идек.

— Нигә болай диңгез тарта икән дип уйлыйм. Безнең әбиебез диңгезче булган икән,— диде Эдик.

— Кыз чагымда бер төрек капитаны мине бик озак сорап йөрде. Туганнарым да риза иде, үземнең генә чыгасым килмәде,— диде Фатыйма әби.

— Ялгышкансың, әбекәй. Шул ярпач есаулга чыкканчы, төрек капитанына чыккан булсаң, без хәзер Стамбул мәчетендә яшәгән булыр идек,— диде Галя.

— Тәүбә диген, ахмак кыз. Кем әйтте сиңа мәчеттә яшиләр дип? Мәчет гыйбадәт йорты бит ул.

— Син аларны сөйләшү белән мавыктырма әле,— диде Татьяна апа.— Габдрахман да бер дә ашамый, әллә ашыбызны яратмый инде.

Аштан соң җимешләргә житешеп кенә утыра идек, капкадан бер ир килеп керде.

— Әтием,— диде Эдик минем колакка.— Зур житәкче. Завод директоры.

## 33

Безнең семьяда әти кайтканчы ашарга утыру гадәте юк иде. Исемдә, яртылаш басып куелган самовар мыштым гына пышылдап утыра. Әни бәрәңге савытын сөлгегә төреп, ике мендәр арасына яшереп куя. Без, урамга чыгып, түземсезлек белән әтинең бригада йорты янындагы борылмадан килеп чыкканын көтеп торабыз... Әтине күрү белән атылып кереп әнигә әйтәбез. Әни ашъяулык җәя башлый.

Ашарга утырмыйча, семья башлыгының кайтканын көтү, белмим, кирәкме икән? Бәлки эти кешенең кайтканын көтеп тормыйча, вакытында ашату хәерледер. Әмма йорт башлыгын көтеп тору эти кешене зурларга, ихтирам итәргә кирәклекне аңлата иде. Бу кагыйдә этине аш вакыты җиткәч тизрәк өйгә кайтырга, балаларын ялыктырмаска өйрәтә иде. Бәлки тәрбия бирү шундый гадәтләрне гадел үтәүдән башланып китә торгандыр.

Эдикның этисе өстәл янындагылар белән исәнләште дә кулын юып, табынга утырды. Татьяна апа аңа чиста тәлинкә белән чәнечке куйды.

Эдикның этисе, алдындагы ашамлыкларны чокыштырып карагач:

— Танюша, теге яшь виноград суы әчеп җитмәдеме икән? — дип сорады.

— Әчәрлек бугай инде. Китеримме соң?

Фатыйма әбинең төсе үзгәреп китте:

— Ансыз ярамыймыни?

— Юк, әни, ансыз ярамый. Армиядән кайткан улым белән тагын кайчан бергә утырырга туры килер. Кунак егетенең дә яңа уңыштан берәр стакан җимеш суы татып карыйсы килә торгандыр.

Татьяна апа өстәлгә графин белән алсу эчемлек китереп утыртты.

— Танечка, мин монда килсәм, атна буе ач йөрерлек итеп туенып китәм. Син, Танюша, тәмле итеп аш әзерли, ләззәтле итеп сыйлый беләсең,— диде Эдикның этисе.

— Ә син табын хәзерләгән кешеләргә яманлык күрсәтә беләсең,— диде Эдикның әбисе.

Кинәт авыр тынлык урнашты. Эдикның этисе, уңайсызлыктан котылу теләге белән, стаканнарга шәраб агызырга тотынды:

— Фатыйма әби шикелле туры әйтергә батырлыклары җиткән кешеләр хөрмәтенә. Мондый кешеләр әзәя бара,— диде дә стаканын күтәреп эчеп җибәрде, аннары:— Эдуард, син эшкә урнашкансыңдыр бит? — дип сорады.

— Юк, урнаша алмадым әле. Пароходчылыкта кыскарту бара, алмыйлар.

— Нигә соң башка эшкә кермисең? Кил, мин сине үземнең заводыма урнаштырам. Һөнәрең әйбәт синең. Менә дигән урын табарбыз үзеңә.

— Йөзү эшенә керәсем килә.

— Алай булгач, Алексей Сергеевичка әйтим әле. Без аның белән өлкә комитеты пленумында еш очрашабыз,— диде Эдикның этисе.

— Кем ул Алексей Сергеевич? — дидем мин Эдикка.

— Пароходчылык начальнигы. Бик зур фигура. Син этинең сүзенә ышана күрмә. Ул гомергә дә бу турыда сөйләшмәячәк. Аның принцибы: һәр кеше үз теләген үзе тормышка ашырырга, тормыш юлын күкрәге белән ерып салырга тиеш,— диде Эдик пышылдап.

— Ә син, Галя, кайсы институтка керәсең? — диде Эдикның этисе.

— Политехническийга.

— Берта апаң эшли торган институтка керәсең икән. Ул сиңа ярдәм итәр әле.— Эдикның этисе сөйләшергә сусаган кеше шикелле ашыга, кабаланып ашый иде.

— Рәхмәт. Миңа ярдәм кирәкми. Мин сезнең ярдәмегездән башка да керә алам,— диде Галя.

Ашап туйгач, Эдикның этисе Татьяна апаның кулын үпте, Галяны башыннан сыйпады. Безнең белән капыл гына саубуллашкач, капкадан чыгып китте.

Эти кешенең төнгә каршы каудар чыгып китүе миңа сәер тоелды:

— Аңламыйм. Нишләп ул чит кеше шикелле кылана?

— Ул безнең белән тормый бит. Аның башка семьясы бар. Әйтте бит «Берта апаң» дип, ул аның яшь хатыны инде.

— Гаҗәп, үзләре әниең белән тату яшәгән шикелле ләр. Синең әниең урынында булсам, мин аны өемә дә кертмәс идем,— дидем мин.

— Син әниенең холкын белмисең әле. Ул теге Тәүраттагы бер яңагына сукканда икенче яңагын да куеп тора торган кеше. Әнием әтине бик кызгана. Әтинең яңа семьясындагы тормышы таркау, балалары юк, хатыны йорт эшен яратмый. Кая туры килсә, шунда тукланып, керләрен кешегә юдыртып яшиләр. Ул еш кына монда килеп зарланып китә. Әни белән без икебез аны кызганабыз. Әби белән Галя әтине яратмыйлар. Әби аны әнинең тормышын җимереп киткән өчен тирги...

Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң катлаулысы — семья тормышында бугай. Аны читтән генә күзәтсәң, бервакытта да төшенә алмыйсың. Үзең шундый хәлгә төшсәң дә, аңлавы кыендыр ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтне. Аңлашылмас гаҗәп бер хәл икән ул.

## 34

Эдиклар гаиләсе бакча эчендә утырган таш йортның кечкенә бер бүлмәсендә яши иде. Бүлмә эчендә зур ятак белән кәнәфидән башка мебель сыярлык урын юк. Бу хәл мине уңайсызлый башлады. Икәү генә калгач, Эдикка әйттем:

— Монда сезнең үзегезгә дә урын бик тыгыз икән бит. Өстәвенә, тагын мине чакырдың.

— Көнеле киң кешегә урын житәрлек. Без синең белән беседкада йоклarбыз. Җәй көне кем өйдә тончыгып ята?

Беседкага ятак әмәлләдек. Галя безгә урын җәеп бирде. Узган төнне йокламаганлыктан, минем күптән ятасым килә иде.

Урын җәелеп бетү белән тизрәк чишенә башладым. Эдик беседкага керде:

— Юләр, су коенмыйча йокларга яталармыни? Галка, безнең белән су коенырга барасыңмы?

— Юк, бармыйм.

— Үкенәсе булма. Су яңа сауган сөт кебек.

Бакчалар аша диңгез ярына чыктык. Ярга сырышып үскән артыш куакларына тотынып, аска, вак ташлыкка төштек.

— Бөтенләй чишен,— диде Эдик.— Бу — аулак җир. Төнге коенуның бар рәхәте дә шунда.

Без әкрен генә суга кереп киттек. Диңгез сөзәкләнеп тирәнәя бара иде. Җылы диңгез суы тәнне чорнап алды. Рәхәтлек тәндәге һәр күзәнәкне иркәли, ләззәтләндерә. Дөньяда нинди генә рәхәтлекләр юк!

Су билгә җиткәч, сузылып ятып, йөзеп киттем. Диңгез тәнне назландырып сыйпый. Әйтерсең мин кире сабый балага әйләнеп, ана куенындагы бер рәхәтлеккә килеп кердем. Күңел тән сизәрлек мул бәхет тойгысы белән тулды. Эдик авызына кергән суны пошкырып түкте дә:

— Әйдә тирәнгәрәк керәбез! — диде.

Мин аңа таба борылып карадым. Дустым ай нурларыннан тукылган ялтыравыклы көмеш сукмак уртасыннан колачлап йөзеп бара иде. Мин дә шунда таба йөзеп киттем.

Арыгач, чалкан ятып, озаклап ял иттек.

Күңелдә ниндидер сизелер-сизелмәс кенә бер курку тойгысы посып ята иде. Тирәнлектән әллә нинди куркыныч бер су җәнлеге күтәрелер дә салкын, лайлалы тәне белән синең аркаңа ышкылып китәр кебек. Шөлләү нервларны кытыклап, күңелдә ниндидер сизгерлек уята, шушы тойгы тәннең ләззәтләнүен тагын да көчәйтә иде.

Янәшә йөзеп, яр буена әйләнеп кайттык.

— Хәзер тәнне корытып сөртик тә кайтып ятыйк,— диде Эдик.— Күрерсең, башың мендәргә тигәнче үк эреп китәрсең.
Эдик иелеп бер тын ташлык өстендә кармаланып йөрде дә тынгысызланып сорады:
— Габдрахман, без монда чишенгән идекме?
— Әйе, шушында. Мин киемнәрне әнә теге таш ягында калдырган идем.
— Ташы бар, ә киемнәребез юк. Шайтан алгыры, әллә чәлдереп киткәннәр инде?
Коенудан алган рәхәтлек кинәт шундук коелып төште. Кузгалган ачу күңел тынычлыгын агулап ташлады.
— Башка җирдән эзлисеңме әллә? Таш яныннан кара, шунда чишенгән идек бит.— Мин судан чыгып, киемнәр калган җирне эзләп таптым.
— Менә без чишенгән җир. Киемнәр юк. Гад, кемгә кирәк булды икән безнең чүпрәкләр?! — дип сүгенеп алды Эдик.
— Әллә син мине куркытыр өчен яшерденме? — дидем мин Эдикка.— Шаярма. Соңгы чалбарымнан колак кагу минем өчен бер дә көлке түгел. Иртәгә кадрлар бүлегенә чалбарсыз барып булмас бит. Табарга кирәк.
— Ахмак син, Габдрахман. Шулай шаяралар димени!
Киемнәр калган җирне берничә тапкыр урап чыктым. Таш өсте буш иде. Тирә-якта бернәрсә дә күренми. Тагын бер тын эзләнеп йөрдем. Үләнлекләрне, куак эчләрен актарып бетердек. Киемнәребездән җилләр искән иде.
— Кайгырма, Габдрахман. Минем ике алмаш чалбарым бар. Күлмәк дигән нәрсә миндә өчме-дүртме.
— Ничек шәрә килеш өйгә кайтасың ди. Сволочьлар, тапканнар урлар нәрсә! Синең чалбарың миңа ярамас та әле. Мин бит илле икенче размерның бишлесен киям.
— Бакчалар аша кайтырбыз. Кеше очраса, куаклыкка посарбыз. Киеме кызганыч түгел, шушы хәлдә калуга ачуым килә. Әйдә, киттек. Куаклыктан чыккач, кеше очраса, кыймылдама. Таш һәйкәл дип уйласыннар. Монда андый һәйкәлләр күп.
Без кача-поса гына яр өстенә мендек. Караклар шикелле ялт-йолт каранып, койма тишегеннән бакча эченә кердек.
Кинәт койма буенда пырхылдап көлгән тавыш ишетелде:
— Эдик, син түгелме соң бу? Син бит тәрбияле егет. Ни эшләп, әдәм көлдереп, шәрә йөрисең? Киенеп чык, яме. Мин сине көтәм.
Без койма буендагы үләнлеккә постык та кире атылып чыктык. Коймага сырышып куе кычытканлык үскән иде. Әрнүгә түзә алмыйча, сукмак янында угаланып утырганда, Эдик пышылдап әйтте:
— Минем белән бер класста укыган күрше кызы. Шул яшергән икән, идиотка! — Эдик муенын сузып, тавыш килгән якка кычкырды:— Лариса, синме бу? Оятсыз, шаталак җан, мисез баш, тапкансың шаярыр нәрсә? — Эдик урыныннан торып, тавыш килгән якка бара башлады.
— Ой, Эдик, яныма килә күрмә! Мин бер дә болай хәтерең калыр дип уйламаган идем. Исендәме, сигезенче класста укыганда минем күлмәгемә тере бака бәйләп киткән идең. Ул чакта мин караңгы төшкәнче диңгез буенда елап утырган идем. Синең белән сөйләшеп торырга минем вакытым юк. Киттем, хәерле төн!
— Лариса, җен кызы, киемнәр кайда? Диңгезгә батырып тончыктырганчы, китер киемнәрне! — диде дустым чынлап ялварган тавыш белән.
— Мин синең суга батыруыннан курыкмыйм. Син сүзенне тотмый торган егет. Кичә кич миңа нинди вәгъдә биргән идең, ә?

— Китер киемнәрне, ишетәсеңме? Килә алмавымның сәбәбе бар. Бергә хезмәт иткән дустымны каршыладым. Син бит аның киемен дә яшергәнсең.

— Эдик, бүген нинди көн икәнлеген оныттыңмыни? — диде егет кеше тавышы. Койма артында гөж килеп шаулашкан, көлешкән тавышлар ишетелеп китте.— Тизрәк киен, рыцарь! Ыштаннарыгыз коймага эленгән. Белеп тор, антын оныткан кешене муенына таш тагып диңгезгә салабыз.

— Билләһи, хәтеремнән чыккан. Бүген классташларның җыела торган көне бит. Без ел саен җыелып, унынчы классны бетергәндә биргән антыбызның үтәлүен тикшерәбез. Әйдә, бергәләп барабызмы?

— Юк. Минем йокым килә,— дидем мин, кычыткан чаккан җирләрем әле һаман әрни иде.

Эдик тиз генә киемнәребезне алып килде дә, киенеп, классташларына иярде.

— Антын бозган өчен аңа нинди җәза бирәбез? — диде теге башлап дәшкән кыз тавышы. Эдик нәрсәдер әйтте. Классташлары кычкырып көлделәр. Аларның тавышлары әкренләп ерагая башлады.

Мин Эдикларның ишегалдына кайтып, беседкага кердем. Помшак юрган астына кереп яту белән бөтенләй эреп киткәндәй булдым. Уйларым, тойгыларым сүнеп юкка чыктылар.

*

*   *

Кояш инде агач биеклеге күтәрелгән. Бөтен җир йөзе нурга чумган. Ял итүчеләр диңгез буена төшеп киткәннәр. Уналтынчы станция белән вокзал арасында йөрүче трамвай дөбердәп урамнан узып китте.

Таң атканда мин бер мәртәбә уянган идем инде. Хуҗа йоклаганда торып йөрүне яхшысынмыйча, ята бирдем.

Эдик төш җиткәндә генә күзен ачты. Яктыра башлагач кына кайтып яткан булган ул.

— Габдрахман, сизәсеңме? Картаябыз бит, малай,— дип, Эдик торып утырды.— Классташларымнан кияүгә чыкмаган биш кыз, өйләнмәгән өч егет калган. Лева Засурскийның ике баласы бар. Ира Левчукның ире — подполковник. Егерме ике гаврикның бишесе вузда укый, өчесе инде югары белемле. Калганнарының һөнәрләре, эшләре бар. Егерме ике кешедән бер мин генә американский безработный. «Курыкма, Эдик, егерме бер кеше бер эшсезне туйдыра алырбыз әле»,— диләр.

— Теге безнең киемнәрне яшергән кыз кайда эшли?

— Пароходта буфетчы булып. Ул әйтә: «Эдик, өйлән миңа, ди. Рейстан кайтканда мине каршы алырга килерсең,— ди.— Моряк хатыннары шулай яшиләр бит. Нигә сиңа да шулай морячка ире булып яшәмәскә»,— ди.

— Кайгырма,— дидем мин Эдикны юатып,— Экономикабыз елдан-ел ныгый. Экономика ныгыган саен, чит илләр белән мөнәсәбәт үсәчәк, сәүдә көчәячәк. Газеталарга бу турыда яза башладылар. Сәүдә итү көчәйгәндә диңгез флотын үстерми булмаячак. Аңладыңмы? Мин политэкономия фәнен өйрәнгән кеше, ышан, без эшсез утырмаячакбыз.

— Алай булгач, ашыгырга кирәк,— диде Эдик.— Әйдә, капкалап алыйк та, кадрлар бүлегенә барып, әйбәтрәк пароходны сайлап алыйк...

35

Кадрлар бүлеге начальнигының кабинет ишегенә эре хәрефләр белән мондый белдерү элгәннәр:

«Эшкә урнашу мәсьәләсе белән килгән кешеләр кабул ителми».

Коридордагы кешеләрнең сөйләшкәннәрен тыңлап йөргәннән соң, Бульварга чыгып, кадрлар бүлеге каршысындагы эскәмиягә барып утырдык.

Эскәмияләрдә утыручылар да әйбәт пароходка урнашып, әйбәт рейска киту турында гәпләшәләр иде. Яннарына килеп утыргач, безнең кырыйдагы бакенбардлы бер егет бездән сораштыра башлады:

— Эшләр ничек, мариманнар?

— Әйбәт. Зарланырлык түгел,— диде Эдик.

— Судно кәтәсезме?

— Әйе, көтәбез. Шушы урыннан кузгалмыйча җитмеш ел утырсак, бик әйбәт пароходка билгеләрбез дип вәгъдә иттеләр,— дидем мин.

— Вот дает! Син, кореш, травило икәнсең. Ничек дидең әле? Җитмеш ел дидеңме?

— Диңгезче башта рәхәтләнеп көлде. Аннары гына үз хәлен әйтте:

— Мине дә көлкегә калдырдылар. Ленинградта төзелгән яңа танкерга утырырга тиеш идем, медкомиссияне үтә алмадым.

Карап торуга егет үзе таза күренә иде.

— Нинди авыру таптылар соң? — диде Эдик.

— Әнә тегенди,— дип, диңгезче бармагы белән һавада нииндидер катлаулы сызым сызып күрсәтте.— Так что, егетләр, сакланыгыз андый авырудан.

Нәрсәдән сакланырга кирәклеген ул безгә аңлатып өлгерә алмады. Кадрлар бүлеге ишегеннән чыгып килүче дустын күрү белән, урыныннан торып, шуның каршына китте.

— Бу бераз «тегендирәк» түгелме икән?

— Булуы мөмкин,— диде Эдик,— безнең өчен башкасы бик әһәмиятле. Ишеттеңме, яңа танкер алырга баралар, ди. Төзиләр булып чыга яңа пароходларны. Алар төзелеп торганда безгә дә урын табылырга тиеш. Көтәргә кирәк. Озакламый безгә дигән көмеш кораб әнә теге причалга килеп туктаячак,— дип, Эдик бармагы белән пассажир пароходлары туктый торган пирска таба төртеп күрсәтте.

## 36

Белмим, хәзер ничектер, ул елларда Диңгез буе бульварындагы Пушкин һәйкәле янына майның унсигезләрендә имтихан билетларының серен белергә теләүче унынчы класс укучылары җыела иде.

Төн уртасына кадәр һәйкәл янына, уйсу җиргә аккан яңгыр суы шикелле, имтихан белән кызыксынучы укучылар агылып тора. Мәсьәлә чишүдә дан казанган нечкә муенлы даһи математиклар иртәгә сынауда туры киләчәк мәсьәләләрнең җавабын тикшереп утыралар.

Мәсьәләләр дистәдән артык, ә сынау билетында бары тик бер генә булырга тиеш. Аларның кайсысы билетка керәчәге турында кайнар бәхәс бара. Һәрхәлдә, имтихан билетына бу мәсьәләләрнең берсе дә кермәячәк. Шуңа карамастан, ел саен сынау башланыр алдыннан унынчы класс укучылары Пушкин һәйкәле янына җыелып киңәшмә уздыралар.

Таң атканда имтиханга хәзерләнүчеләр арып-алҗып өйләренә таралалар. Имтиханда, билгеле, аларга башка мәсьәлә чишәргә туры киләчәк. Шуңа карамастан, җаваплы сыналу алдыннан җыелып киңәшү укучыларга рухи бер көч бирә, сынауның җитдилеген аңларга ярдәм итә.

Бераздан бу шәһәрнең мавыгучылары җыела торган урыннар ачыла башлады. Кит тоту промыслосы идарәсе каршына диңгездә йөзүдәге яңалыкларны белергә теләүчеләр җыела. Собор мәйданында һәр кичне футбол сөючеләр җыены була. Тынычлык проспектына квартир алыш-

тырырга теләүчеләр киләләр. Ял көнне Дзержинский клубы бакчасында филателистлар, нумизматлар коллекция алышу бәйрәме үткәрәләр. Одесса гөжләп, мавыгып яши. Мавыгу кешеләрне якынайта, тормышларын бизи. Алар беренче очрашуда ук уртак тел табалар, берберсенә серләрен сөйлиләр.

Без дә Эдик белән Пушкин һәйкәле янына җыелган абитуриентларның сынауга кирәчәк сораулар турында сөйләшүләрен тыңлап утырдык. Аларның дулкынланулары күңелдә ямансулык уята. Без дә әле күптән түгел генә карасы кибеп бетмәгән аттестат белән киләчәкне яуларга хәзерләнеп йөрүчеләр идек. Сынау еллары артта калды, ә сыналу һаман бара әле. Аяк атлаган саен миңа сынаучылар очрап тора. Һәр адымда синең ныклыгың, ир-егетлегең тикшерелә. Адым саен юлыңда очраган киртәләрне атлап үтәрлек көч, гайрәт сорала.

Ниһаять, без Галяны көтеп алдык. Янбызга килеп житү белән ул безне, ашыктырып, иптәш кызы яшәгән урамга алып китте.

*

* *

Авыр имән ишекне ачып вестибюльгә кергәч, киң мәрмәр баскычтан өскә күтәрелә башладык. Баскычның як-ягында канатлы фәрештәләр кулларына электр шәме тотып безгә карап торалар иде.

— Нинди сарайда яшиләр болар, ә? — Эдик түшәмгә ясаган аллегорик рәсемнәрне күрсәтте.

Йортның классик ысулда салынган мәрмәр баскычлары миңа да тәэсир итте.

— Иптәшең граф кызы түгелдер бит?

— Юк, ул инспектор кызы. Одессаның үзәгендә мондый йортлар еш очрый.

Без икенче катка күтәрелеп, бизәкле ишек каршысына килеп туктадык. Ишек янагына алты данә электр кыңгыравы төймәсе беркетелгән. Һәр төймә астына квартирада торучының фамилиясе язып куелган.

— Боларның туалетларында да алты лампочкамы икән? Анда керер алдыннан һәр хуҗа бүлмәсеннән үз лампочкасын яндырып чыга торгандыр,— диде Эдик.

— Автоматика,— дип, Галя «дүрт мәртәбә» дигән төймәгә басты.— Элек кешеләрнең хосусый лампочкага көчләре житмәгән. Хәзер, аллага шөкер, житә. Безнең класстагы бер малай ташландык детальләрдән җыеп автомашина ясаган.

Түгәрәк битле, җыйнак гәүдәле, матур бер кыз безгә ишек ачты:

— Нигә алдан кисәтеп куймадың? Син бит кунаклар алып киләсеңне әйтмәдең!

Кунаклар булса, әйткән булыр идем. Болар синең әтиең белән танышырга килүче кешеләр генә.

Галя безне эчкә уздырып җибәрде.

Ишек ачучыга ияреп, зур иркен бер бүлмәгә килеп кердек. Бүлмә артык биек булганлыктан, андагы мебельләр ничектер бәләкәй күренә иде.

— Әтиең өйдә юкмыни? — диде Галя.

— Кухняда варенье кайната.

Безнең артык текәлеп каравыбыз кызны уңайсызландырды булса кирәк, ул, урындыкларын рәтләп утырткан булып, читкә борылды.

— Нина, бу егетләрнең эшкә урнашасылары килә,— диде Галя.

— Хәзер әтине чакырам,— дип, Нина ишеккә таба юнәлде.

— Чакырмагыз,— диде Эдик.— Сезне күргәч, әтиегез белән сөйләшәсе килүем сүрелде инде. Ул кергәнче, сезнең белән туйганчы сөйләшеп каласым килә.

Нина бер тын уңайсызланып торды да Эдик башлаган шаяру тонын дәвам иттерде:

— Минем дә сезнең белән сөйләшәсем килә. Моңа кадәр шигырьләрегезне генә укыганым бар иде. Минем шагыйрь кеше белән беренче мәртәбә очрашуым әле.

— Әллә Эдик сезгә багышлап шигырь яздымы? — дидем мин.

— Юк, кая ул! Эдуард Сергеевичның шигырьләре фәрештәләр, очучыларны әсәрләндерүче хур кызлары турында гына...

— Нина тишек авыз. Мин бит сиңа аларны яшереп кенә күрсәткән идем,— диде Галя, үпкәләгән булып.

Шигырьләре турында сөйләшү Эдикны бераз оялтты булса кирәк, ул шаярту сәләтен югалтты.

— Хәзер инде Эдик гел шушы очрашу турында гына язачак,— дидем мин.— Шушы юл белән сез дә әдәбият тарихына кереп калырсыз бәлки?

— Нина, Габдрахманның Одессага нигә килгәнлеген беләсезме? — диде Эдик, бераз иләшә төшкәч.

— Юк, белмим шул.

— Вокзалда йөргәндә бер кызга күзе төшкән дә, аерыла алмыйча, шуның артыннан монда килгән.

— Дөрес эшләгән. Егет кеше нәкъ шундый булырга тиеш.— Нина радиола кабызып, уйнатырга пластинка куйды.

— Сезне күргәч, ул кызны онытттым инде,— дидем мин.— Эдик шикелле шагыйрь булмасам да, тәмле итеп бәрәңге пешерә беләм. Тормышта бәрәңге пешерә белү шигырь язудан ким түгел бит, әйеме?

— Минем егетем шигырь дә яза, бәрәңге дә пешерә белергә тиеш,— диде Галя.

Зур җиз таз күтәреп бүлмәгә Нинаның әтисе килеп керде. Яңа гына уттан алынган кара җимеш вареньесе парланып тора иде.

— Тырышсам, мин дә бәрәңге пешерә алыр идем, ләкин варенье кайнату һич кулымнан килми,— диде Эдик.

— Әти, мин сиңа әйткән идем бит. Эшкә керергә теләүче егетләр менә шушылар инде. Син аларга ярдәм итә алмассыңмы икән?

— Мин аларны үзем кайнаткан варенье белән чәй эчерә алам. Аннан соң, риза булсалар, аларның берсенә сине кияүгә бирә алам,— диде Нинаның әтисе.

Беренче күрүдә үк бу кеше миңа ошады.

— Кызыгызга өйләнгәч,— дидем мин,— сез мине эшкә урнаштырмый калмассыз бит, әйеме?

— Нина, башына бәла алырга теләүче табылып торганда, тизрәк туй ясыйк. Мондый кешенең башкача очрамавы да мөмкин,— дип, хуҗа шкафтан шешә чыгарып өстәлгә утыртты.

— Син ашыкма әле, Габдрахман. Нинаның үзеннән сорарга кирәк, ул кайсыбызны сайлар бит,— диде Эдик, сүзгә кушылып.

— Ашаганыгызны күргәч әйтермен. Элекке заманда кешенең булдыклылыгын ашавына карап чамалаганнар,— диде Нина.

Шушылай җиңелчә шаярып сөйләшү арабызда уртаклык барлыгын, безнең бер-беребезгә ошаганлыгыбызны күрсәтә иде. Гәпләшкән арада өстәлгә ашамлыклар да килде. Берничә минуттан инде без, нинди йомыш белән килгәнлегебезне онытып, хуҗа сөйләгән мәзәкләрне тыңлый идек.

Сөйләшә торгач, сүз диңгезчеләр тормышына, аннан соң диңгездә йөзү маҗараларына, пароходчылык тарихына кереп китте.

Нинаның әтисе, Борис Григорьевич, революциягә кадәр Одессада РОПИТ һәм Добрфлот исемле пароходчылык компанияләре булуы, патша карары буенча пароходчылыкның кораблары туксан тугыз

данәгә җиткәч, йөзенче итеп мәҗбүри рәвештә хөкүмәткә хәрби крейсер төзеп бирергә тиеш булганлыклары турында сөйләде. Шунлыктан Добрфлотның суднолары бервакытта да туксан тугыздан артмаган. Аның каравы, компаниянең һәр вакыт зур тоннажлы пароходлары булган.

Революциягә кадәр Одессада хосусый рәвештә пароход тотучылар да булган. Борис Григорьевич шуларның берсе Шайя Кропотницкий турында сөйли башлады:

— Шайяның өч зур, ике кечкенә пароходы булган. Берсенә хатыны хөрмәтенә «Сара», икенчесенә кызы хөрмәтенә «Роза» исеме кушылган булган. Өченчесенә үзенең патриотлыгын күрсәтү өчен «Николай патша» исеме куштырмакчы булган икән дә, ул чакта патша исемен хәрби корабларның иң зурларына, иң яңаларына гына бирергә рөхсәт ителә торган булган. Шуңа күрә Шайя өченче пароходына «Рус патриоты» дигән исем биргән.

Кропотницкий үзе диңгезче булмаган. Шушы хәлдән файдаланып, өлкән механик «Сара» пароходын ремонтларга дип хуҗадан бүрәнә алдырткан да үзенә дача салган. Икенче механик өлкән механикның хыянәте турында хуҗага әләкләгән. Кропотницкий аңа әйткән: «Ул минем бүрәнәләремнән йорт салдырткан икән, инде тора бирсен. Аны эшеннән чыгарып, сине өлкән механик итеп куйсам, син дә шул юл белән йорт салдыртачаксың», дигән.

Төн урталары җиткәч кенә кайтырга җыена башладык.

— Әти, син бу егетләргә эшкә урнашу турында әйтмәдең бит әле,— диде Нина.

— Бүгенге көндә пароходчылыкка эшкә урнашу мөмкин түгел. Озакламый Франциядән, Польшадан пароходлар алырга тиешбез. Бәлки шул чакта диңгезчеләр кирәк була башлар. Әлегә резервны кая урнаштырып бетерергә белгән юк. Борис Григорьевич әйтте дип кешегә сөйләп йөрмәгез. Мин сезгә бер акыллы киңәш бирә алам. Мореходкада читтән торып укучыларны эшкә урнаштырырга дигән күрсәтмә бар. Әгәр укырга керә алсагыз, сезне урнаштырып булыр иде. Башкача эш пешмәячәк...

Хуҗалар белән саубуллашып урамга чыктык.

— Менә, ишеттеңме? Юкка вакыт уздырып йөрисез. Армиядән кайту белән документларыңны тапшырган булсаң, хәзер институтта булыр идең инде,— диде Галя абыйсына.

— Мин бит кая керергә белмичә, җиңел конкурс эзләп йөрмим. Биш ел көтәргә туры килсә дә, диңгез эшенә генә урнашам,— диде Эдик.

— Кара әле, Эдик, бу кеше күрсәткән юлны тикшереп карыйк әле. Минемчә, ул бик әйбәт киңәш бирде,— дидем мин.

— Чамалап карарга була. Мин артык ышанып бетмим,— диде Эдик.

## 37

Икенче көнне сәгать иртәнге сигездә без диңгезчеләр хәзерли торган училищеның ишеге ачылганын көтеп утыра идек инде.

— Габдрахман, синең диңгезчеләр турындагы инглиз анекдоты ишеткәнең бармы? — диде Эдик.

— Юк, ничегрәк ул?

— Диңгез яры буенда җир сөрүче бер крестьян ерак сәфәрдән кайтасы корабын көтеп торучы диңгезчедән сорый икән: «Ничек шундый хәтәр эш ошый икән сиңа?» — ди. «Ул эш миңа бер дә хәтәр күренми»,— ди диңгезче. Крестьян сорый: «Синең әтиең кайда үлде?» — ди. «Диңгездә»,— ди тегесе. «Бабаң?» «Диңгездә». «Ә бабаңның бабасы?»

«Ул да диңгездә». Шуннан соң крестьян әйтә: «Синең урынында мин гомергә шундый хәтәр корабка утырмас идем»,— ди. Диңгезче сорый: «Ә синең әтиең кайда үлде?» «Түшәгенә ятып»,— ди крестьян. «Бабаң?» «Ул да үз түшәгендә үлде». «Бабаңның бабасы?» «Ул да шунда». «Синең урыныңда булсам, мин беркайчан да шул хәтәр түшәккә ятмас идем»,— дигән диңгезче игенчегә...

Бераздан училищега курсантлар җыела башлады. Строй баскыч каршысына килеп туктады. Егетләр берәмләп баскычтан күтәрелә башладылар.

Курсантларга ияреп без дә эчкә кердек.

Вестибюльдә постта торучы моряк янына штурвал һәм магнит компасы куелган иде. Стенага кораб йөртүдә кулланыла торган әсбаплар эленгән.

Коридор буйлап бераз баргач, «Кабул итү комиссиясе» дигән белдерү эленгән ишекне ачып кердек.

Өстәл артында кызгылт чәчле секретарь утыра иде. Кызның иреннәре бака кабырчыгы эче сыман перламутр төсенә буялган.

— Габдрахман, кара әле, керфекләре зәңгәр түгелме соң моның? — диде Эдик пышылдап.

Кыз безгә күтәрелеп карамыйча гына тырнакларын чистартуында булды.

Эдик тамак кырып куйды:

— Без документ тапшырырга килгән идек.

Секретарь кыз безгә күз сирпеп алды да түшәмгә карап:

— Стационарга документларны җыеп бетердек. Заочныйга пароходчылык биргән справка белән генә алабыз,— диде.

Мондый җавапка мин әллә ни аптырамадым. Соңгы елларда читтән торып укырга үз һөнәреңбуенча гына ала башлаганнар иде.

— Киттекме? — дидем мин, ишеккә таба борылып.

Эдикның тиз генә чыгып китәргә исәбе юк иде. Ул өстәл каршысындагы урындыкка барып утырды да сокланган кыяфәттә кызның косметикасын тикшерергә кереште:

— Без бит, чибәр туташ, армиядән кайткан кешеләр. Демобилизация безне һөнәрсезгә әйләндерде. Безнең теләсә нинди уку йортына керергә дә хокуклы икәнебезне белмисезмени?

Кыз, сөйләшүнең тәмамланганын белгертеп, юка игәү белән тырнакларын матурларга кереште.

Эдик кабат сорады:

— Ул указ, сылукай, бу училищега кагылмыймыни?

— Мин сезгә русча әйттем: читтән торып укырга без пароходчылыкта эшләүче диңгезчеләрне генә алабыз.— Секретарь кыз өстәл тартмасыннан конфет алып авызына капты.

— Әйдә, начальникның үзенә керәбез. Бу курчак белән сөйләшүдән мәгънә чыкмас,— дидем мин.

Без училище начальнигының кабинетын эзләп таптык. Начальникның секретаре, урта яшьләрдәге хатын, безгә әйбәтләп аңлатты:

— Бүген аның белән очраша алырсызмы икән? Югары училищеда экзамен бара. Ул шунда. Сәгать бишләр тирәсендә кайтырмын дип әйткән иде. Шул вакытта килеп карасагыз, бәлки кабул итәр.

Сәгать биштә без начальникны кабинеты каршысында көтеп утыра идек инде. Алты тулып килгәндә беренче ранг капитаны кара дерматин белән тышлаган ишекне ачып кабинетына узды. Аңа ияреп без дә эчкә кердек.

— Нинди йомыш? — диде начальник.

— Укырга керү мәсьәләсе,— дидем мин.

— Документларыгызны приемный комиссиягә тапшырыгыз, карарбыз.

— Алмыйлар шул. Пароходчылыкта эшләүчеләрне генә алабыз, диләр.— Эдик документларын начальник алдына илтеп салды. Начальник кәгазьләрне актарып чыкты да гаризаның сулъяк почмагына кыйтачлап нәрсәдер язды.

— Комиссиягә тапшырыгыз.

Мин дә кәгазьләремне начальник алдына илтеп салдым. Ул, гаризага тукталып тормыйча, аттестатны карарга кереште:

— «Алтын медаль»гә бетердегезмени?

— Әйе.

— Бу бит күчермә генә. Төп нөсхәсе кайда?

— Шушы көннәрдә килеп житәргә тиеш,— дидем мин, дөресен әйтмичә.

Анкетамны караганнан соң начальникның кашы жимерелде:

— Демобилизациядән соң өч ел узган. Университеттан ни өчен чыгардылар?

— Үзем теләп киттем.

Начальник минем сүземә ышанып бетмәде булса кирәк — кырт кисеп:

— Сезне ала алмыйбыз,— диде.

Эдик өстәлгә якынрак килде:

— Иптәш беренче ранг капитаны, Габдрахманның этисе Ватан сугышында һәлак булган. Ул этиемнең эшен дәвам иттерәчәкмен дип ант иткән кеше. Зинһар алыгыз.

— Әтиең нинди корабта иде? — дип, начальник ягымлы итеп миңа карап куйды.

Минем әтием диңгезче түгел иде. Ул сугыш бетәргә бер ай кала Германиядә һәлак булды.

«Әтиемнең эшен дәвам иттерүне» начальник үзенчә аңлады:

— Бик дөрес эшлисең, иптәш Рахманкулов, бик дөрес эшлисең. Диңгезчелек һөнәренең буыннан-буынга килүе бик әйбәт. Мин ике улымны да матрослыкка урнаштырдым. Диңгезнең тозлы жилен палубадан торып иснәсеннәр. Чыныксыннар, авырлыкларны жиңәргә өйрәнсеннәр. Әгәр шушы сынауга чыдый алсалар, мин аларны училищега бирәчәкмен. Минем әтием дә, бабам да диңгезче булганнар. Дөрес, дөрес эшлисез, иптәш Рахманкулов.

«Минем әтием диңгезче түгел иде» дип әйтергә авызымны ачкан идем, Эдик терсәге белән кабыргама төртте:

— Мин дә шул ук фикердә, иптәш беренче ранг капитаны. Әтиеннең һөнәрен бала чакта ук үзләштереп бетерәсең бит. Мин дә малаемны диңгезче итәчәкмен.

— Малаегызга ничә яшь?

— Әле бер яшь тә юк. Мин буйдак әле,— диде Эдик уңайсызланып.

Начальник минем гаризамның почмагына нәрсәдер язды:

— Не подкачай. Отличнога бетерә алсагыз, иң яхшы пароходка урнаштырырбыз. Училищеның традициясе шундый.

Начальник безнең кулларыбызны кысып, укуыбызда уңышлар теләде.

*

* *

— Кайчан болай шомарып өлгердең син, Эдик? — дидем мин, урамга чыккач.

— Авиациядә чакта син мондый түгел идең. Кара, нинди итеп буяп куйдың. Барыбер жаным тыныч түгел. Әтиемнең исеменә тап төшердем кебек. Әллә әтием диңгезче түгел иде дип кереп әйтимме икән?

— Кыланма. Башта минем үземнең дә аны төзәтәсем килгән иде. Чамалап карагач, үз фикереңдә калдырырга исәпләдем. Мәсьәлә —

синең этиеңнең сугышта һәлак булуында. Диңгездәме, окоптамы — моның аермасы юк. Морякларны әйтәм, традициягә нинди ихтирам белән карыйлар. Авиациядә бу хәл юк иде бит. Эшли башлагач, без дә шулай булырбызмы икән? Әлегә мин үземнең авиаторлыгымнан арына алмыйм. Үзем диңгезче булырга хыялланам, күңелем белән үзем әле һаман авиатор.

— Мин дә еш кына шул хакта баш ватам.

— Медалең барын миңа әйтмәгән идең бит. Урта мәктәпне медаль белән бетергәнсең икән.

— Аның әллә ни аермасы юк инде.

— Минем өчен аның аермасы зур. Мин бергә әзерләнеп, сынауны бергә тапшырырбыз дип өметләнгән идем. Дөресен әйткәндә, минем урта белем күптән очып чыгып бетте инде,— дип, Эдик маңгаена төртеп күрсәтте.— Котелок буш!..

— Кабатлый башлагач, хәтерләрсең әле. Минем хәл синекеннән катлаулырак. Аттестатның төп нөсхәсен кулга бирмәячәкләр. Мин аны бер мәртәбә алырга тырышып караган идем инде.

— Вакытлыча сора. Безгә укуыбыз турында справка алу кыйммәт. Эшкә урнашкач, аттестатыңны кире җибәрерсең.

Икенче курста укыганда университет каршында Шәрык институты ачтылар. Без Баграт белән гарәп теле өйрәнмәкче булдык. Аттестатның төп нөсхәсен алып булмаганлыктан гына теләгебезне эшкә ашыра алмый калдык.

Баграт, китмәгән булса, аттестатны алу юлын табар иде. Ул хәзер каникулга кайтып киткән булырга тиеш. Бүген үк сөйләшеп калмасаң, Өметгали дә тиздән өенә кайтып китәчәк.

Телефоннан шалтыратып сөйләшергә акчам юк иде. Эдикның да кесәсе буш. Бу турыда сүз кузгатсаң, ул энисеннән акча сораячак. Без болай да ат чаклы ике егет Эдикның энисе җилкәсендә яшибез.

Исәпли торгач, телефонга түләрлек акча табу юлын таптым. Хәзер берәр хәйлә корып Эдиктан аерылырга кирәк иде.

— Бүген үк сынауга хәзерләнә башларга кирәк. Мин Мәскәү белән сөйләшкән арада син кирәкле китапларны җыеп куй,— дидем мин аңа.

— Галканың китаплары бар. Мин синең сөйләшкәнеңне көтеп тора алам.

Эдик минем берүзем генә калырга теләгәнемне аңламый иде. Аңардан ялварып сорадым:

— Сынау башланырга нибары бер атна вакыт калды. Син хәзер үк кабатлый башларга тиешсең. Башкача без өлгерә алмаячакбыз.

Эдик теләр-теләмәс кенә трамвай тукталышына таба китте. Мин Дерибас урамыннан Собор мәйданына кадәр күтәрелдем дә, трамвайга утырып, Одесса-товарная станциясенә киттем.

## 38

Мәскәүнең товар станциясенә илнең төрле почмакларыннан туктаусыз эшелоннар килеп тора. Йөк бушатырга кеше җитмәгән чакта монда студентларны да чакыралар иде.

Студентлар эшләгән җир әллә кайдан күзгә ташлана. Анда — көлке сүз, җыр, кызу бәхәс. Университет бинасында чакта хәтергә килмәгән әллә нинди катлаулы мәсьәләләр, кызыклы фикерләр туып тора монда.

«Физиклар һәм лириклар» арасындагы бәхәс газета-журнал битләренә чыкканчы вагон бушаткан җирләрдә туды. Төгәл фән студентлары белән гуманитарлар очрашкач, бер фәнне яклап, икенчене тәнкыйтьли башлау белән фикер әллә нинди катлаулы мәсьәләләр эченә кереп китә-

иде. Сокланырлык матур дәлилләр табыла, искереп беткән аксиома җимерелеп челпәрәмә килә.

Мәскәү товар станциясендәге бу очрашуларда студентның эрудициясе үсә, мөстәкыйль фикер йөртү сәләте арта иде.

Ул чорда вагон бушату эшенә без еш йөри идек. Ә хәзер, әллә йөк бушату эше механизацияләнгәнлектән, әллә материаль яктан студентлар өчен төзү отрядлары файдалырак булганга, Мәскәү станцияләрендә студент халкы бик сирәк күзгә чалына башлады.

Одесса станциясендә хәл икенчерәк иде. Йөкчеләр ашыкмыйча гына складка кер юу машиналары ташыйлар. Өч кеше складтан йөк автомобиленә бер подполковникның Германиядән кайткан багажын төяп азапланалар. Мин машина янына барып туктадым:

— Ярдәм кирәкмиме сезгә?

Озын куллы, кәкре аяклы бер йөк ташучы шикләнеп миңа маңгай астыннан гына карап алды да кул селтәп каршыма килә башлады:

— Ычкын, ычкын моннан! Комачаулап йөрмә! Теләсә кемгә уралып йөрергә рөхсәт ителми монда!..

Бәхәсләшеп торуның файдасы булмаячак. Йөк төяүчеләрнең эшне чит кеше белән бүлешәселәре килми иде. Мин вагон бушатучылар янына юнәлдем. Бригадирга охшашлы бер кешенең складтан чыкканын көтеп торып:

— Абый, мин эш эзләп килгән идем. Сезнең бригадага кеше кирәк түгелме? — дидем.

— Эш кайда да җитәрлек. Син конторга кереп, отдел кадр белән сөйләшеп кара.

Мин конторга киттем.

Кадрлар бүлеге башлыгы, минем үтенечне тыңлагач, тикшеренергә тотынды:

— Паспортың бармы соң?

— Бар.

— Күрсәт.

Паспортны кесәмнән чыгарып, начальникка суздым.

Ул паспорттагы рәсемне минем белән чагыштырып карады. Паспортка язылган сүзләрне җентекләп тикшереп чыкты.

— Пропискаң кайда? Без пропискасы булмаган кешене эшкә алмыйбыз. Пропискасы булмаган кешене милициягә тапшырырга гына ярый ул.

— Тапшырыгыз,— дидем мин, курыкмаганлыгымны күрсәтер өчен.— Сезнең эшләрне дә милициядән тикшертү зыян итмәс иде.— Мин юри «эшләрне» дигән сүзне басым ясап әйттем.

Начальник паспортны өстәл аша миңа ташлады:

— Һәр йолкыш сукбайга безнең эшне тикшерергә хокук бирелмәгән шул. Акчаларын эчеп бетерәләр дә монда эш сорап киләләр. Беләм мин синең ишеләрне! Хәзер туп-туры кесә чистартырга китәчәксең. Шпана!..

Үземнең шпана түгеллегемне аңлатып вакыт әрәм итеп тормастан, туры вокзалга киттем. Кичке поездны каршылап, берәр пассажирның чемоданнарын илтергә булышсаң, бәлки Мәскәүгә шалтыратырлык акча табып булыр.

Шушы көнгә кадәр эшсезлек михнәте акча булмау белән генә чикләнә торгандыр дип уйлый идем мин. Эшсезлек сине коллективтан аерылып яшәргә мәҗбүр итә, эш кешеләре каршысында үзеңне түбәнәйтеп, кимсетеп күрсәтә икән. Эшсез йөрүченең эче поша. Андый кеше үзен кая куярга белми интегә.

Хемингуэй: «Кош очар өчен, адәм баласы бәхетле булыр өчен яралган»,— дигән. Үзеңә ошаган эш эшләп, шуннан ләззәт таба алмасаң, син берничек тә бәхетле була алмыйсың. Кеше хезмәт белән генә бәхетле була ала.

Бәлки бу яңа фикер түгелдер. Ләкин кешедән ишетеп кенә белгән фикер белән үз тәҗрибәңнән туган фикер арасында бик зур аерма бар.

Мин перрондагы дүрт тәгәрмәчле тәбәнәк бер тимер арбага барып утырдым да поезд көтү ыгы-зыгысын күзәтә башладым.

Вокзал ишеге янында носильщиклар тәмәке тартып торалар. Озын буйлы, чандыр гына бер носильщик иптәшләренә ниндидер көлке сүз сөйли. Калганнары, һавага төтен балдаклары җибәреп, кәефләнеп тыңлыйлар. Мәзәгрәк урыннарда барысы берьюлы башларын артка каерып көлеп алалар.

Кулына ак чәчәк тоткан яшь бер кыз арлы-бирле перронда йөри. Ул сәгатенә күз салып ала да поезд киләсе якка карап тора, аннары, зарын тыңларлык кеше эзләгәндәй, як-ягына карана.

Кыз баганадагы сәгатькә карап вакытны дөресләде дә вокзалга кереп китте. Вокзал эчендә поезд килгәнен күрә алмый калырмын дип курыкты булса кирәк — аннан да чыкты, тагын арлы-бирле йөрергә кереште.

Кыз минем яннан узып китте. Беренче тапкыр мәхәббәткә юлыгып күңеле кузгалган, сабыйлыктан чыгып, яңа үсмерлеккә керә башлаган бер кыз иде бу.

«Моның көткән кешесе ышанычлы бәндә булса гына ярар иде», дип эчемнән тынгысызланып куйдым.

Мин утырган арба янында кемнеңдер кулыннан төшеп калган ялгыз чәчәк ята. Мин аны юлдан читкәрәк, багана төбенәрәк этеп куйдым. Чәчәкне этәргә иелгәндә күзем чалбарыма төште. Тез турылары тәмам юкарган. Чалбар тишелеп чыгарга тора иде. Тизрәк эшкә урнашып булмаса, озакламый кеше күзенә күренергә дә оят булачак.

Перронга әкренләп халык җыела башлады. Арбаларын тартып носильщиклар үтеп китте. Алар, ара калдырып, перрон буена тезеләләр. Мин дә уңайлырак урын сайлап, носильщиклар арасына барып бастым.

Борылма артыннан паровоз күренде. Паровоз пошкырып минем яннан узып китте. Бер-бер артлы вагоннар уза башлады. Аларның баруы әкренәйгәч, каршымдагы вагонның ишеге яныма килеп җиткәнен көтеп тордым да тимер тоткага ябышып баскычка күтәрелдем:

— Кемгә носильщик кирәк? Кемнең чемоданын илтергә? — Тавышым җинаять эшләгән кешенеке шикелле куркып, калтыранып чыга иде. Коридор эченә кергәч, тагын бер мәртәбә кычкырдым:

— Носильщик кемгә?

Якындагы купеның ишеге шуышып ачылды. Рам эчендәге рәсем шикелле, ишек яктылыгында тәненә сыланып торган зәңгәр спорт костюмы кигән бер кыз елмаеп карап тора иде:

— Алик, син мине каршыларга килдеңме әллә?

Валериянең теле «Габдрахман» шикелле тупас исемнәрне әйтергә көйләнмәгән иде. Минем исемем матуррак яңгырасын өчен ул аны «Алик»ка әйләндергән иде.

Сабакташым коридорга чыгып, миңа сырышты:

— Алик, нигә дәшмисең? Минем бу поездда икәнлегемне каян белдең? Башта мин ышанмадым. Әллә күземә күренәсеңме дип торам. Бүген иртән генә синең хакта этигә дә сөйләп утырган идем әле.

Мин тишелә башлаган чалбарым турында уйлый идем. Тез турым күренмәсен өчен Валериягә якынрак килдем:

— Телепатия белгертте. Безнең арада әлек тә ерактан сизү феномены бар иде бит. Бүген синең шушы поезд белән шушы вагонда киләчәгеңне сизенеп белдем...— Мин таркаулыктан бераз айный башлагандай булдым.

— Бик шәп! Алик, чыннан да телепатия аша белдеңме? Бәлки мин

дә сине иртән шул феномен аркасында искә алганмындыр, ә? Беләсеңме, без монда вакытны ничек үткәрәчәкбез?

— Белмим, булырмы икән? Мин бит монда бик житди йомыш белән килгән кеше. Инспектор Мегрэ[1] — яшерен миссия! — Ниһаять, мин үз-үземне кулга алып, шаярып сөйләшерлек хәлгә килдем.

— Валерия, каршы алучылар күренмиме? — диде урта яшьләрдәге чал чәчле матур бер кеше.

Купедан чыккан бу кешенең өстендә Кузнецкий мост ательесында тегелгән затлы соры костюм иде. Петлицасындагы йолдызлар бу кешенең дипломатия генералы икәнлеген күрсәтә иде. «Валерия ялганламаган икән», дип уйлап алдым мин.

— Әти, бүген иртән бер курсташым турында сөйләгән идем бит. Ул мине каршы алырга килгән.

Дипломатның карашы минем тишелә башлаган чалбарымнан, төсен югалткан яшькелт күлмәгемнән шуышып узды. Бу караш шундый игътибарлы һәм сизгер иде. Аңа минем ашказанымдагы студентлык чоры бүләге — гастритка кадәр күренгәндер кебек тоелды миңа. Ләкин бу кеше кимчелекләр күргәнлеген белгертмәде. Дипломат кызы белән бергә укучы студентка елмаерга тиешле чамада елмаеп, лаванда исе аңкып торган зур йомшак кулын миңа сузды:

— Валентин Владимирович Трифонов. Танышуыбызга шатмын.

Бу кешенең кыйммәтле киемнәре, салмак хәрәкәтләре, мәгънәле һәм матур итеп елмаюы — тәненең һәр күзәнәге «мин шат, мин канәгать, мин ихтирамлы, дәрәҗәле кеше. Бу сыйфатларның барысы да минем тырышуымның нәтиҗәсе» дип кычкырып торгандай тоела иде.

— Габдрахман Бакирович Рахманкулов,— дидем мин Валериянең этисе шикелле өч катлы итеп. Ләкин минем бу сүзләрнең тәэсир итү көче бик чамалы иде.

Бу вагондагы пассажирлар чыгарга ашыгып кабаланмыйлар, чемодан, капчык күтәреп көчәнмиләр иде. Чемоданнарын килеп алганны сабыр гына көтеп торалар да носильщиклар артыннан ашыкмыйча, гәүдәләрен һәйкәл сыман тотып салмак кына атлап чыгып китәләр.

Валентин Владимирович Трифонов яныбыздан узып барган проводникны туктатты:

— Иптәш проводник, ни өчендер безне каршыламадылар. Носильщик күренсә, рәхим итеп, чакырыгыз әле.

Проводник вагоннан чыгып китте дә берничә минуттан әйләнеп тә керде:

— Менә сезне каршы алырга килүчеләр, иптәш пассажир,— диде ул.

Валериянең әтисенә охшашлы таза матур бер кеше вагонга килеп керде:

— Дүртенче вагонны мин баштан көтәм, ә сезне койрыкка таккаңнар икән.— Алар кочаклашып үбештеләр.— Валерия нинди үскән, просто гранд-дама булган! — дип, каршылаучы кеше Валерияне дә кочаклап үпте.

Каршы алырга ияреп килгән ирләр йомшак сары күннән ясаган зур чемоданнарны купе эченнән алып чыктылар. Каршы алучы белән Трифонов, бер-берсенә юл биреп, перронга төштеләр. Без Валерия белән тамбурда калдык.

— Алик, без Аркадиядәге санатория тибындагы дачага туктаячакбыз. Иртәгә үк кил, яме. Синең белән Кафка турында сөйләшәсем килә. Өченче көн банкетта бер кеше Кафка иҗаты турында сүз кузгаткан иде. Ул язучы хәзер модада икән. Бервакыт син аның «Үрмәкүч»е турында нәрсәдер сөйләгән идең. Хәтеремдә калмаган.

---

[1] Инспектор Мегрэ — Жорж Семенон әсәрләре герое.

Мин, кулымны биреп, Валерияне баскычтан төшердем. Күн чемоданнар зур кара «ЗИМ»га төялгән. Машинадагылар Валерияне көтеп торалар иде. Вокзал янындагы капкага җиткәч, без саубуллаштык. Курсташым кереп утыру белән кара машина тавышсыз гына кузгалып китте. Борыныма бензин исе килеп бәрелде. Урам чатына кереп югалган машина артыннан бераз карап тордым да вокзалга таба киттем. Сәгать ярымнан Одессага Киев поезды килергә тиеш иде.

Микрофоннан Киев поездының ярты сәгатькә соңга калып килүе турында әйттеләр. Мин вокзал эченә кереп буш урын эзләп таптым. Валерия турында уйламаска тырыштым. Салкынча стенага терәлеп, поезд көтә башладым.

## 39

Училище начальнигы гаризама кул куйганнан соң күңелем күтәрелеп киткән иде. Хәзер күңелдә ниндидер авыр тынгысызлык уянды, йөрәктәге төзәлә башлаган әрнү яңарып киткәндәй булды. Мин бит бу кызны оныттым дип ышанып йөри идем инде. Аның нилектән шулай озак истән чыкмыйча күңелдә яшәвен берничек тә аңлый алмадым.

Валерияне озатканнан соң нигәдер дөньядагы башка нәрсәләрнең кызыгы калмады. Хәзер инде очсыз-кырыйсыз океан, ерак атауларда үсеп утырган пальма яфракларының дымлы җил белән сөйләшеп кыштырдаулары турындагы хыялларым да юата алмый иде мине.

Шул кыз килеп күземә күренү белән бөтен теләкләремне сүндереп ташлады. Нәрсә булды соң әле миңа? Нилектән дөньяның асты өскә килгән кебек булды?

Башкалада калган тормышның бер хатирәсе искә төште.

Мин Пушкин исемендәге музейның француз рәссамнары залында. Пыяла түшәмнән үтеп кергән тигез яктылык тузанлы юлда утырган карт бер хәерче яһүднең ябык гәүдәсенә төшкән. Сукыр хәерчене җитәкләп йөрүче малайның зур, моңсу күзләре миңа текәлгән. Аның күз карашында ярдәм сорап ялвару да, аһ-зар да, кешеләрне рәхимле-шәфкатьле булырга өндәү дә сизелми. Малайның күз карашы: «Исемең кеше булса, син безне дә онытма. Без синең шикелле үк бу дөньяга яшәргә килгән кешеләр. Туйганчы ашаудан, җылы ятактан, ихтирамнан мәхрүмбез. Ләкин безнең дә яшисебез килә», дип әйтеп тора иде.

Пикассо ясаган шушы рәсем каршында күпме вакыт торганмындыр. Сулыш алган тавышка борылып карасам, янымда курсташым Валерия Трифонова басып тора иде.

Импрессионистлар залын карап бетергәч, бергәләп Волхонка урамына чыктык, елга яры буйлап Ленин тавына таба атладык,

Елга буендагы таш парапетта бер карт кармак салып утыра. Янында соры песи, койрыгын күтәреп, хуҗасының балык каптырганын көтә. Бер кыз белән егет, бер-беренә сыенышып, елганың соргылт суына сүзсез генә карап торалар. Елга ага... Тормыш та шулай ага. Яшәеш дигән нәрсә кешеләргә күрсәтмичә генә аларның гомерләрен агызып алып китеп тора. Адәм балаларының бу турыда уйларга вакытлары юк. Алар магазинга кереп икмәк алалар, зур залларга җыелып кино карыйлар. Кайчакта, сүз тыңларга өйрәнсен дип, балаларын да кыйнап ташлыйлар. Ял иткәндә шәһәр эченнән аккан пычрак сулы елганың таш ярына утырып кармак та салалар.

Елга уртасыннан су трамвае узып китте. Фонарьлардан төшкән утлар дулкын өстендә чайкала башлады. Күңелдә яңа гына туып килгән тойгыларны таушалган сүзләрдән саклап, бик озак сүзсез генә елгага карап тордык...

Җир йөзендә көчле машиналар, затлы киемнәр, татлы ризыклар

бар. Алардан тыш шатлык, куаныч, хәсрәт, михнәт шикелле кеше күзенә күренми торган тойгылар да бар.

Без үлгәннән соң җәйге кичләрдә аккан суга карарга яңа кешеләр килер. Алар да күңелләреннән татлы тойгылар кичереп, парапетның салкын ташына күкрәкләрен терәп, киләчәккә планнар корырлар. Безнең эзләребезгә басып, җир йөзеннән меңләгән буыннар узар. Машиналар урынына компьютерлар килер. Кешеләр башка төрле кием киеп, башка ашамлыклар ашап яши башларлар. Ләкин бездән соң яшәгән кешеләрнең йөрәкләрендә дә без кичергән кайгы-куаныч, мәхәббәт-нәфрәт тойгылары булыр. Кешенең кыяфәте, акылы гасыр саен үзгәрә барса да, аның хисләре әз үзгәрә...

Киев поездының килеп җитүен әйттеләр. Мин урынымнан кузгалып, поезд каршыларга перронга чыктым...



## 40

Телефоннан сөйләшү генә ни өчендер мине канәгатьләндерми. Таныш тавышны ишетү белән мин шул кешенең үзен күрәсем килеп интегә башлыйм. Кайчакта кешенең йөзенә карау белән аның нәрсә әйтергә теләгәнлеген сүзсез дә аңлыйсың бит. Шунлыктан телефоннан сөйләшкәндә чыбыкның икенче очындагы кешенең йөзен күрергә тилмереп, газапланып бетәм. Трубкага сөйләгәндә кирәкле сүз исемә төшми. Сөйләшеп беткәч кенә иң кирәкле сүзләремне әйтергә онытканлыгымны хәтерләп, борчыла башлыйм.

Сөйләшү пунктындагы күп кешеләр, фикерләрен телефон аша җиткерә алмыйча, минем шикелле интегәләр иде.

Бер карчык Киевта яшәүче кызына биле авыртуы турында зарлана. Мескен әби ничәмә йөз чакрымдагы кешесенә бик каты кычкырсам гына ишеттерә алырмын дип уйлый иде булса кирәк.

Кычкырып әйткән сүз телефоннан бозылып ишетелә иде. Карчык, әйтәсе килгән сүзен кызына аңлата алмыйча, кабинадан елап чыкты.

Карчыктан соң Орск шәһәреннән Одессага запчасть алырга килгән тәэминат вәкиле сөйләште. Ул, тагын бер атна вакыт кирәклеге турында аңлатып, командировкасын озайттырды.

Сөйләшүчеләрнең күбесе Одессага ял итәргә килгән кешеләр иде. Аларның хәтсезе билет алырга өйдән акча җибәрүне үтенделәр.

Ниһаять, мине дә кабинага чакырдылар.

— Габдрахман, синме бу? — диде Өметгали тавышы.

— Мин бу, исәнме, Өметгали дус!

— Исәнме, йөрәк маем, саумы? Рәхмәт, дустым, онытмыйча шалтыратуыңа. Эшкә урнаштыңмы?

— Юк, урнашмадым әле. Эшкә урнашу өчен аттестат кирәк. Деканаттан аттестатымны алып миңа җибәрә алмассыңмы?

— Нинди аттестат ул?

— Урта мәктәпне бетергәнлеккә бирелгән аттестат.

— Эшкә керү өчен андый аттестат кирәкмени?

— Кирәк, Өметгали. Ансыз эш чыкмый, аңлыйсыңмы? Ничек тә алып, шул аттестатны җибәрергә тырыш әле, ишетәсеңме?

— Ишетәм. Бирсәләр, алып җибәрермен, кайгырма.

— Бирмәсәләр дә алырга тиеш син, Өметгали, аңлыйсыңмы? Минем киләчәгем шул аттестатка бәйле. Бик кирәк. Ансыз булмый...

Трубкада хатын-кыз тавышы ишетелде:

— Бетерегез. Вакытыгыз чыкты.

— Алло, Өметгали! Аттестатны авиапочта белән сал. Мин китәм. Комсомол секретаре Вадим Козырев белән саубуллаша алмадым, аңа сәлам әйт. Салу белән телеграмма...

Кинәт шылт иткән тавыш ишетелде. Сөйләшү өзелде. Телефон трубкасы тынып калды. Ут сүнде. Трубкага өрә-өрә, аттестатны җибәрү белән телеграмма сугарга кирәклекне Өметгалигә кычкырып карадым да — булмады. Трубканы элеп, кабинадан чыктым. Чираттагы яз итүче өеннән акча сорар өчен кабинага кереп китте.

Ике көннән соң Өметгалидән телеграмма килде:

«Габдрахман, аттестатыңны ун көнгә алып торырга рөхсәт иттеләр. Ун көннән кайтарып бирмәсәң, сине университеттан чыгарачаклар. Күчермәсен эшләтеп, кире җибәр. Кулыңны кысып, Өметгали».

Без инде Эдик белән урта мәктәп программасын шактый гына кабатлап өлгергән идек. Физиканы ике көн эчендә караштырып чыктык. Рус теле белән әдәбиятны да бер-ике көндә сукалап чыгарбыз шикелле иде.

Алгебраны кабатларга тотынгач, без бер урында таптанып тора башладык. Эдик алгебраның күп кагыйдәләрен бөтенләй онытакан иде.

Математиканың кагыйдәләре үзара бәйләнешле. Аларның берсен генә белмәсәң дә, мәсьәләне чишә алмыйсың. Кабатларга тотынгач, Эдик үкенә башлады: «Ул кагыйдәләрнең болай кирәк буласын кем белгән бит. Укыган чакта мин аларны икеле куймасыннар өчен генә ятлаштырып барган идем».

Олы фонтаннан үзәк почтамтка барып йөрүе ерак иде. Аттестатны ешрак белешеп тору өчен без сынауга опера театры янындагы Пале-Ройяль бакчасында хәзерләнә башладык.

Чинар агачлары күләгәсендә тыныч, салкынча. Безнең эскәмия тирәсендә бала коляскалары. Янәшәдә бала караучы карчыклар гәпләшә. Без тирләп-пешеп мәсьәлә чишәбез. Мәсьәлә чишелеп бетеп, дөрес җавап табылу белән мин почтамтка йөгерәм.

Университетта сынауга әзерләнгән чакларда тәүлегенә унсигезәр сәгать китаптан башымны күтәрмичә утыра ала идем. Эдик озак утырырга күнекмәгән. Арыды исә, ул мине су коенырга кыстый башлый:

— Барыбер бер атна эчендә өч еллык материалны кабатлап бетереп булмас, әйдә, су коенып килик.

— Җаваплы сынауга хәзерләнгәндә бер минутка да тукталырга ярамый,— дим мин.

Төштән соң әдәбиятны кабатларга керештек. Эдик су коенырга күндерә алмагач, җаен табып, бәхәс кузгатырга исәпләде. Ул хәзер Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә?» дигән әсәренең герое Рахметовны тәнкыйтьләргә тотынды:

— Минемчә, Рахметов бераз психрак кеше. Нигә инде иректе көннән очлы кадак каккан такта өстендә йокларга?

— Ул бит революционерлыкка хәзерләнгән. Шуңа күрә алдан ук төрмә шартларына күнегеп тормакчы булган. Ихтыяр көчен чыныктырган.

— Барыбер ул «тегеләйрәк» кеше! — Эдик бармагы белән чигәсен бораулап күрсәтте.— Төрмәгә керәчәген белгәч, бераз адәм төслерәк яшәп калырга кирәк иде аңа...

Караңгы төшә башлагач, соңгы мәртәбә почтага кереп, хат турында белешеп чыктык та, Олы фонтанга йөри торган катерга утырып, өйгә кайтып киттек.

Порттан чыгу белән катер уңга борылып, Төркия юнәлешенә таба юл тотты.

Кырмыска явы шикелле кайнашкан су коенучылар яныннан уздык. Текә ярлы Отрада пляжлары күренде. Отраданы үтү белән Аркадиядәге ял йортларының утлары җемелди башлады.

Катер яныннан ерак рейстан кайтучы океан пароходы узып китте. Зур пароход кузгаткан дулкын катерны як-якка чайкап алды. Пароходның диңгездә баруы мәһабәт бер күренеш икән. Порт каршысындагы

рейдка җиткәч, пароход йөрешен әкренәйтте, кемнедер чакырып, басынкы тавыш белән гудок бирде. Шул тавыш минем Одессага нинди ният белән килгәнлегемне исемә төшерде. Йөрәгем әрни башлады. Күнелдә өметсезлек тойгысы баш калкытты.

Эдиклар яши торган Унынчы станциягә кайтып җиткәндә караңгы төшкән иде инде.

41

Өметгалинең хаты дүртенче тәүлек дигәндә Одессага килеп җитте.

Хат бирүченең кулыннан алу белән конвертны ачып, аттестатны тикшереп карадым. Зәңгәр кәгазьгә алтын хәрефләр белән басылган аттестат конверт эчендә иде. Мин туры училищега йөгердем.

Кабул итү комиссиясенең таныш ишеген ачып эчкә кердем.

Бүген секретарь кыз чәчен күксел зәңгәр төскә буяп килгән. Әллә шушы хәлдән каушап киткәнмен. Аптырап карап торганымны күргәч, зәңгәр чәч елмаеп сорады:

— Сезгә нәрсә кирәк?

— Менә аттестатны китердем.

Кыз аттестатны алып, минем әлек калдырган кәгазьләремә теркәде. Кәгазьләрне картоннан ясаган тышлык эченә салып, тышлыкка фамилиямне язып куйды:

— Сессия киләсе дүшәмбедә башлана. Сессия вакытында рейста булучыларны соңрак җыячаклар. Зачет кенәгәсен сессиягә килгәч алырсыз,— дигәч, кыз өстәл тартмасыннан бланк алып студентлык билеты язарга тотынды.

Язып бетергәннән соң фоторәсемемне ябыштырды да билетны миңа сузды.

Училищега шушылай ансат кына керә алуыма мин ышанып җитми идем әле.

— Училищеда укуымны раслар өчен шушы язу җитәме?

Кыз миңа төбәлеп карап торды да сорау бирде:

— Сез училищега укыр өчен керәсезме, әллә язу алыр өчен генәме? Уку өчен керсәгез, шушы язу җиткән.

— Укыганлык турында кадрлар бүлегенә белешмә тапшырырга кирәк иде. Сез миңа шуны бирә алмассызмы?

Зәңгәр чәч өстәл тартмасыннан әзер справка алып, фамилиямне язды да кул куеп миңа сузды. Мин рәхмәт әйтеп саубуллаштым. Урамга чыккач кына Өметгалинең хатын укырга онытканлыгым искә төште.

«Габдрахман дус! Закон буенча аттестатны кулга бирергә ярамый икән. Багратка рәхмәт әйт. Секретарь кыз аны ярата. Без Багратның дуслары булганлыктан гына бирде. Күчермәсен төшерү белән аттестатыңны Люсяга кире сал.

Чит илгә чыгып йөри башлагач, Люсяга бирәр матур сувенир алып кайтырсың инде. Ул синең өчен бик тырышты.

Баграт комсомол путевкасы белән чирәм җиргә китте. Мин сынауларымны биреп бетердем. Борынгы рус әдәбиятыннан өчле, тарихи грамматикадан дүртле алдым. Калганнары бишле. Билет кесәмдә — берсекөнгә Бохарага кайтып китәм.

Сез киткәч, бүлмәнең яме югалды. Америка оештырган күргәзмәне ачарга АКШның вице-президенты Мәскәүгә килә дип сөйлиләр. Маштаков, билгеле, Мәскәүдә калачак.

Курсның барлык студентларыннан кайнар сәлам. Кызлар өчен синең Одессага китүең сенсациягә әверелде. «Рахманкулов — герой», диләр. «Егет кеше булсак, без дә тузан эчеп ятмас идек», диләр. Син киткәннән соң Трифонованы күргәнем юк иде. Берничә көн элек университет клубында очраштык. Аның тирәсендә бер демократ бөтерелеп йөри,

чехмы, полякмы. Валерия Багратны чакырып, синең турыда сораштырган. Баграт синең сәяхәткә чыгып китүеңне әйткән. Габдрахман синең аркаңда укуын ташлап китте, дигән. Аның белән дуслашу сиңа гел кирәк түгел иде. Валлаһи, синең михнәт күреп йөрүең шул кыз аркасында гына. Ул бит сиңа пар түгел. Аның кем икәнлеген Баграт уку башланган көнне үк аңлап алды. Козырев сиңа сәлам әйтте. Деканатта синең китүеңне хуплап бетермәгәннәр. Козырев сине Гыйльми совет утырышында яклап чыккан. Ярый, хуш. Безне онытма. Өчарыкка хат яз. Кулыңны кысып, Өметгали».

## 42

Мин кергәндә кадрлар бүлеге начальнигы делоларга теркәләсе характеристикаларга кул куеп утыра иде. Кергәнлегемне сиздерү өчен тамак кырдым. Начальник әһәмият бирмәде. Ул, көйләп җибәргән автомат шикелле, туктамыйча, эшен дәвам иттерде. Тагын бер тын көтеп карагач, училищедан алган справканы өстәлгә китереп салдым. Начальник күз кыры белән генә миңа карап алды да өстәл читендәге кара төймәгә басты:

— Мин сиңа кеше кертмә дип әйттем бит,— диде начальник ишектән кергән хатынга.

— Кертмим, Семен Зиновьевич. Бу иптәш сез кисәткәнче кереп өлгергән иде...

Секретарь хатын чыгып киткәч, начальник янә эшенә кереште. Минем өстәл янында басып торуым аңа бераз комачаулый иде булса кирәк. Ул чираттагы характеристикага фамилиясен селтәп салды да, минем кәгазьне алдына шуыштырып китерде һәм тиз-тиз генә күз йөртеп чыкты:

— Сезне ни өчен заочныйга алдылар?

— Алдылар инде,— дидем мин.

— Училищеда укуыңа карамастан, без сине эшкә урнаштыра алмыйбыз.— Начальник, ярсуын басарга теләгәндәй, ашыгып эшенә тотынды.

Эшнең болай булып бетәсен белгән кебек, Эдик миңа «җебеп торма, каты тор, училищега керүеңне әйбәтләп әйт», дип кисәткән иде.

Читтән торып укучы кешеләрне эшкә урнаштырырга дигән күрсәтмәне начальник үтәргә тиеш булса да, үтәү-үтәмәү аның үз иркендә иде.

Минем язмышым хәл ителгән иде инде. Нәтиҗәдә көч бушка түгелде, вакыт әрәм китте. Тырышулар, теләкләр юкка чыктылар.

Минем кабинеттан чыгып китүемне көткән арада начальник «личное дело»ларны бер урыннан икенче урынга күчереп өйде. Алдындагы чиста кәгазьгә шиндидер дулкынлы сызыклар сызып карады. Мин урынымнан кузгалмыйча тора бирдем. Ниһаять, начальникның түземе бетте.

— Мин сезгә әйттем түгелме соң? Аңлашылмадымыни? — диде ул, кырыс кына итеп.

Үзем дә сизмәстән кинәт ярсып киттем:

— Барыбер алачаксыз! Бүген борып җибәрсәгез, иртәгә килермен, иртәгә алмасагыз, берсекөнгә!.. Эшкә алганчы шушы кабинет ишеге төбеннән китмәячәкмен. Читтән торып укучыларны борып җибәрергә сезнең хакыгыз юк. Нишләсәгез дә, мин эшкә урнашмыйча туктамаячакмын.

Начальник башын күтәреп миңа карады. Ул мине болай сөйләшер дип көтмәгән иде булса кирәк. Берничә минут ул, ачуланыргамы моны, сүзсез генә куып чыгарыргамы дигәндәй, чамалап торды.

— Алмасам, бернәрсә дә эшли алмаячаксың. Гомумән, минем белән мондый тонда сөйләшмиләр. Кая гаризаң? — Начальник гаризамның

сул як почмагына нәрсәдер язды да:— Инспектор Зеленовский оформлять итәр,— диде.

Өстәлдәге кәгазьне үрелеп алдым да, рәхмәт әйтергә дә онытып, тизрәк чыгып киттем. Хәзер мин шатланырга тиеш идем. Моңа кадәр кеше менә алмаган биек тауга күтәрелгән альпинист кебек хис итәргә тиеш идем мин үземне.

Начальник гаризама кул кую белән мин эшсезлектән котылдым. Хәзер мин диңгезчеләр коллективында. Ай саен өйгә акча салып тора алам. Илләр гизәчәкмен, дөнья күрәчәкмен!.. Ләкин күңелдә бушлыктан башка бернәрсә дә юк. Нигәдер мин бу хәлгә куана алмый идем.

## 43

Бу бәхет мине шатландырырга тиеш иде бит! Нигә болай ямансу булып китте соң әле?

Мин үземне тиешлесен алып бетергән бер кеше шикелле сизә идем. Мондый хисне элек тә татып караганым бар минем. Әллә гадәтем шундыймы? Теләгемә ирешүнең нәтиҗәсе мине бер дә куандырмый. Шул минутны якынайту өчен көрәшү генә кадерле миңа.

Һавадагы торна тавышына әсәрләнеп, нужа күреп йөрү минем табигатемдә иде, күрәсең.

Көндәлек тормыш максаты — аз көч түгеп, күбрәк файда табу, һавадагы торна тавышына алданмыйча, кулдагы чыпчыкны кысып тотып, тыныч кына яшәү мине куандырмый иде. Тиле кеше шикелле, шул һавадагы торна авазына ияреп китәсем килә иде.

Төпләнеп яши алмавыма моңа кадәр бик офтана идем. Тыныч тормыш, акча төшерә торган файдалы һөнәр, мал җыю минем гадәтем түгеллеген аңлагач, бераз тынычландым. Хәзер инде мин тизрәк пароходка эләгергә, диңгезчелек һөнәренә өйрәнергә, укуымны уңышлы тәмамларга тиеш идем.

Бурычларымны ачыклагач, гаризамны тотып, Зеленовскийның кабинетын эзләп киттем.

Ике яклап тезелгән ишекләргә инспекторларның фамилияләре язып куелган: «Инспектор группы загрансудов Кримкер Б. Г.» — Бусы Нинаның әтисе Борис Григорьевич булса кирәк... «Инспектор группы пассажирских судов Бычков А. П...»

Коридорның очына барып җиткәч кенә иң соңгы ишеккә эленгән тактада Зеленовскийның фамилиясен күрдем: «Инспектор группы каботажных судов». «Каботаж» дигән сүзне ишеткәнем булса да, мин аның мәгънәсен белми идем. Бу сүздә «абордаж», «пассат», «галс», «бригантина» сүзләрендәге тылсымлы мәгънә — ниндидер романтика бар кебек иде. Шуңа күрә «каботаж» миңа «загранплавание»га караганда күбрәк ошады.

Стена буена тезелгән чиратның койрыгына барып баскач, миннән алдарак торучы җирән чәчле малайдан:

— Каботаж белән чит илгә йөзү арасында нинди аерма бар? — дип сорадым.

Егет әллә ничә мең еллар элек яшәгән казылма бер җәнлек күргән шикелле гаҗәпсенеп елмаеп куйды. Бер тын миңа текәлеп карап торды да чират торучыларга таба борылып әйтте:

— Менә бу чудак каботажның нәрсә икәнен сорый. Минем моңа башым җитми. Ничек аңлатыйм икән, ә?

Чираттагылар көлешә башладылар. Тар маңгайлы, озын, очлы борынлы бер егет яныма ук килеп, миңа баштанаяк карап алды да:

— Кореш[1], синең диңгез җилен иснәп караганың юкмыни әле? — диде.

Мин дәшмәдем. Үземне көлкегә калдырырлык сорау бирүемә үкенеп куйдым.

— Иснәп караганың булмаса, Таможня мәйданына бар да порт капкасыннан чыккан диңгезчеләрне иснәп кара. Загранкадан кайткан диңгезчеләрдән кыйммәтле одеколон исе килә. Каботажның эше дә, тормышы да тозлы. Шунлыктан каботаж матросларыннан тозлы җил исе килә.

Диңгезчеләр тагын бер мәртәбә көлешеп алдылар.

Күлмәген сәдәфләмичә генә итәк очларын төйнәп куйган икенче бер егет:

— Кореш, тозлы гына түгел, борычлы да. Каботаж җиле тәнеңне киптерсә, кесәңә томау төшерә,— диде.

Бу сүзләрдән соң чираттагыларның кәефләре тагын да күтәрелебрәк китте. Алар гөж килеп фикер алышырга тотындылар. Тар маңгай юхаланган сыман сорады:

— Каботажны үзең теләп сайламагансыңдыр бит, кореш, әйеме?

— Юк, каботажга җибәрегез дип аерып сорамадым. Кадрлар начальнигы үзе билгеләде,— дидем мин.

— Кара, ул сиңа нинди зур яхшылык эшләгән, ә? Син аның юмартлыгын онытма инде. Каботажга иң лаеклы, иң уңган кешеләрне генә билгелиләр бит,— диде күлмәк итәген төйнәп бәйләгән егет.

— Төшеп калган кешеләрдән булсак, без әнә теге чудаклар арасында булыр идек,— дип, тар маңгай чит илгә йөзүчеләр чиратына төртеп күрсәтте.

Мин башта әһәмият биреп житкермәгәнмен икән. Чит илгә йөзүчеләр белән чагыштырганда каботаж диңгезчеләренең киемнәре дә башка төрлерәк иде. Каботаж кешеләре тегеләргә караганда ябыграк, үз-үзләрен тотулары да башкачарак.

Чит илгә йөзүчеләр, җаваплы урында эшләүчеләр сыман, эчке бер масаю белән сабыр гына чират көтәләр. Инспектор бүлмәсеннән чыккач та, эре генә атлап китеп баралар.

Зеленовский кабинетыннан чыккан һәр диңгезче инспекторны тәнкыйтьләп ала. Ачусыз гына сүгенә. «Никадәр тырышсагыз да, мине кимсетә алмаячаксыз. Мин андый йомшак кеше түгел» диган сыман, ясалма горурлык белән коридордан чыгып китә.

Беркадәр күзәтеп торганнан соң мин чит илгә йөзүчеләрнең тәҗрибәләре зуррак, һөнәрләре яхшырак икәнлеген дә чамалап алдым. Каботаждагыларның «загранкага» йөрүчеләрне тәнкыйтьләвендә җәяүле солдатның атлы сугышчыга булган мөнәсәбәте сизелә иде.

Зеленовский кадрлар бүлеге башлыгының кечерәйтебрәк ясалган күчермәсен хәтерләтә иде. Аның өстәле начальникыннан кечерәк, арзанлырак агачтан ясалган. Инспекторның үз-үзен тотышы, начальникныкына охшаган булса да, ничектер ясалма кебек тоела, киеме дә арзанлырак сыман иде. Бары тик инспекторның йөзе генә начальникныкыннан итләчрәк һәм зуррак иде.

Мин кәгазьләремне инспектор алдына илтеп салдым да, начальникның мине шушы төркемгә билгеләвен әйттем. Инспектор миңа күтәрелеп карамады. Аның кыяфәте үк: «Әйдә, әйдә, яхшырак күренергә тырыш. Монда керүчеләрнең һәммәсе шулай миңа ошарга тырыша. Ләкин карар чыгаручы — мин, син — шул карарга буйсынучы гына»,—

---

[1] Кореш — (диңгезчеләр жаргоны) дус, иптәш.

дип әйтеп тора кебек иде. Мин сулыш алырга да куркып, инспекторның карарын көтә башладым.

Ниһаять, инспектор башын артка ташлап, аркасын урындык артына терәде:

— Фамилияң?

— Рахманкулов.

— Йомышың?

— Иптәш Курененко мине сезнең группага билгеләде,— дидем мин. Курененко сүзенә басым ясап.

— Аңламыйм. Резервтагы диңгезчеләрне кая куярга белгән юк, ә монда дөм тәҗрибәсез кешене эшкә алып яталар?

Аркам туңып киткәндәй булды. Инспектор бер тын уйланып карап торды да, иелеп, минем анкетамны тикшерергә кереште. Мин үземне сират күпере алдына килеп туктаган гөнаһлы кеше кебек хис итә башладым. Үзем болай җинаять эшләгәнемне хәтерләмим. Нәселемдә кулаклар, төрмәдә утыручылар, чит илгә качып китүчеләр дә юк. Ләкин, йа раббым, анкетамны тикшерә башласалар, тез буыннарым йомшарып китә, күз алларым караңгылана, бизгәк тоткандагы шикелле калтыранам.

— Сине ни өчен университеттан куып чыгардылар? — Зеленовский минем «җинаятемне» ачуына сабыйларча чын күңелдән куана иде.

— Беркем дә кумады. Мин үз иркем белән читтән торып укуга күчтем.

— Так, так...— Ниһаять, ул иркен итеп сулыш алды.— Димәк, сез ике җирдә укыйсыз? Шома егет! Бездә уку бушлай бит. Әйдә, укы. Хөкүмәт акчаны кызганмый, түли. Димәк, хөкүмәтне савым сыер урынына саварга була, ә? Ике җирдә уку әз күренде инде сезгә, әйеме? Эшкә урнашып зарплата алып ятарга да уйладык инде, әйеме? Дәүләт агай юмарт бит, шулаймы? Аның ашын өч кашык белән чөмереп ашарга була, ә?

Зеленовский, зур бер эш башкарган кеше сыман, артлы урындыкка ярым ятып, күзен йомды.

Кинәт мин аның нинди кеше икәнлеген аңлап алдым. Бу, һичшиксез, куркак кеше булырга тиеш. Үзе куркып яшәгән кеше генә башкаларны шушылай куркытырга ярата. Куркак кеше башкаларны куркытудан тәм таба. Ул башкаларны шомландыра алса, үзен батыр итеп сизә башлый.

— Иптәш Курененкога кереп, Зеленовский сезнең боерыгыгызны үзгәртте дип әйтимме соң? — дидем мин, бернәрсәгә дә исем китмәгән кебек.

Инспекторның кыяфәте үзгәреп китте:

— Сезгә алай дип кем әйтте әле? — Хәзер ул өстән килгән карарны берсүзсез үтәүче күндәм бер кеше иде инде.

Зеленовский анкетага карап эш карточкасы төзеде.

— Адресыгыз ничек, иптәш Рахманкулов?

— Татарстан. Баулы районы.

— Юк, Одессадагы адресыгыз.

— Мин вакытлыча иптәшемә тукталдым.

— Алай булгач, мин сине кадрлар бүлегенә пропискага керттем. Одессада ачык прописка юк. Кирәк булса, тулай торакка направление дә бирә алам...— Инспектор миңа кәгазь кисәге сузды.— Котлыйм, Рахманкулов. Сез хәзер резервта. Икенче класс матрос зарплатасының җитмеш биш проценты түләнеп торачак. Көн саен тугызынчы яртыда миңа кереп теркәлергә тиешсез. Зарплаталы курорт, әйеме?

— Курортсыз гына булмыймы соң, иптәш инспектор? Мөмкин булса, мин бүгеннән үк эшкә керешер идем.

— Пока юк. Урын табылу белән урнаштырырмын. Минем группада

дүрт-биш ай эш көтүче диңгезчеләр бар. Башта аларны урнаштырырга кирәк. Ашыкмагыз, сезгә дә чират житәр.

Без күптәнге дуслар кебек кул биреп саубуллаштык.

Бульварга чыккач, диңгез эшендә эшләп картайган морякларга охшарга тырышып, чайкалыбрак атлап киттем. Һәр очраган кешегә: «Күрәсезме, мин диңгезче! Коры жирне яратсам да, сезне ташлап, диңгезгә чыгып китәргә туры килә. Ни эшлисең, вазифабыз шундый!» — дип мактанып аласым килә иде.

## 44

Эдик миңа кадәр торып каядыр киткән иде инде. Битне югач, шәһәргә барырга жыена башладым.

Фатыйма әби минем уянуымны көтеп торган икән. Юыну белән чәйгә чакырды.

Татьяна апа — эштә. Галя белән Нина институтка керергә әзерләнеп йөриләр. Эдикның мине көтмичә берүзе чыгып китүе күңелне борчып, эшкә урнашу шатлыгымны бераз сүрелдерде. Кәефемне Фатыйма әби дә сизеп алды булса кирәк. Чәй ясап алдыма китереп куйды да:

— Эдик белән ачуланышмагансыздыр бит? — дип сорады.

— Юк, ачуланышмадык.

— Нигә ул сине көтмәгән соң?

— Белмим.

— Ул иртән әнисе белән дә сүзгә килеп алды. Укырга кермим, тизрәк эшкә урнашам, ди. Таняның хәтере калды. Ул әйтте: Габдрахман кергән жиргә нишләп керә алмадың? Сынауга әзерләнмичә жил куып йөргәнсеңдер, диде. Безнең Эдик әтисенә охшаган. Эдикның әтисе Таняның тормышын жимереп китте. Үзе дә бәхетле була алмады. Таняны да бәхетсез итте. Эдик та шулай булыр дип куркабыз. Укырга керергә йөри башлагач, бик сөенгән идек. Син аны укы дип үгетләп кара әле.

Мин Фатыйма әбине юата башладым. Аның сөйләр сүзе күп иде. Икебез генә калудан файдаланып, ул тагын туганнары турында сөйләргә тотынды.

Тугызга өлгерергә кирәк булганлыктан, әбинең зарын тыңлап бетермичә, трамвай тукталышына киттем.

Зеленовский янына барып теркәлгәч, паспортымны пропискага алдылар. Пропискага керү өчен өч сум акча түләргә кирәк иде. Мин бик уңайсыз хәлдә калдым.

— Салгалыйсыңмыни? — диде Зеленовский, күз кысып.

— Юк, мин андый кеше түгел.

— Акчаң кая китте соң? Одесса пропискасына керү өчен башкалар мең сум түләргә дә риза булырлар иде дә, күп кешегә бу бәхет тәтеми,— диде Зеленовский елмаеп.— Ярый, акча тапкач кертерсез инде.

Кадрлар бүлегеннән чыккач, мин туры тулай торакка юнәлдем. Ул вакытта пароходчылыкның тулай торагы Потёмкин баскычыннан төшү белән сул яктагы йортка урнашкан иде. Хәзер ул йортта пароходчылыкның кадрлар бүлеге.

Мин администратор хатынга инспектор биргән кәгазьне күрсәттем. Администратор башта телефон шалтыратып, кемгәдер зарланып алды.

— Урын юклыгын белә торып, инспекторларыгыз һаман направление бирәләр. Семен Зиновьевич, кырыктан артык диңгезче идәндә куна. Позор бит бу! Кертмәгез дисез! Урамда кунсыннармыни? Урамда кунып йөрергә милиция рөхсәт итми. Шунлыктан урын булмаса да кертергә

мәҗбүр булабыз инде. Әйе. Әйттем. Хәзер инде өлкә комитетына барып зарланырга гына калды.— Шулай дигәч, администратор трубкасын куйды.— Урын юк, акыллым. Кунар урыныгыз булмаса, сәгать унберенче яртыда килерсез. Урынсызларны без кубовой идәненә яткырабыз. Дөресен әйткәндә, начальство идәндә ятарга рөхсәт итми. Нишлисең бит, минем үземнең ике малаем диңгезче. Мин сезне чиратка куйдым. Атна-ун көннән бәлки урын булыр.

Диңгездә йөзә башлагач, мин яр буе шәһәрләренең күбесен күрдем. Аларның берсендә дә одессалылар шикелле диңгезчеләрне ихтирамлап, чын күңелдән яратучыларны очратканым булмады.

Одессаның һәр гаиләсендә диярлек диңгезче бар. Кайбер семьяларда диңгезчелек һөнәре буыннан-буынга күчеп килә.

Одессаның ирләрен диңгез дөньяның иң ерак җирләренә илтеп ташлый да аларның хатыннарын айлар, еллар буе ялгыз яшәргә мәҗбүр итә. Моряк хатыннары диңгезне яратмыйлар. Алар үзләренең кызларын, киләчәгеңне диңгез белән бәйләмә, дип үгетлиләр. Ләкин Одесса кызлары үсеп җитү белән диңгезчене сөяләр дә әниләре шикелле үзләрен гомерлек ялгызлыкка дучар итәләр. Малайлар тәпи йөрергә өйрәнү белән капитан булып уйный башлыйлар. Мәктәптә укыганда да ир балалар диңгезче булырга хыялланалар.

Одессада диңгез — тормыш үзәгендә. Диңгез аларның тамакларын туйдыра, аларга шатлык һәм хәсрәт китереп тора.

Мин кайтканда Татьяна апа белән Фатыйма әби чия чүпләп утыралар иде. Өйгә керү белән Татьяна апа зарланырга тотынды:

— Эдик иртәгә рейска китә. Сынау тапшырудан баш тарткан. Син аны үгетләп карамадыңмы?

— Эшкә әләккәч, училищега кереп торуның кирәге булмас инде,— дидем мин, Татьяна апаны юатырга тырышып.

— Минем өчен аның эшкә урнашуыннан укырга керүе артык,— диде Татьяна апа.— Хәзер бит, Габдрахман, дипломсыз бернәрсә эшләп булмый. Безнең заманда укымаган кеше гарип кеше кебек. Безнең Эдик кына шуны аңламый.

Таня апа малаеның гамьсез яшәве турында тагы да зарланмакчы иде. Капкадан, әтисен ияртеп, Эдик кайтып керде.

— Таня, малаебызны озату хөрмәтенә бераз бәйрәм ясап алыйк инде,— диде Эдикның әтисе.

— Ат азгыны тайга иярә. Син гел шул якны гына кайгыртып йөрисең,— диде Фатыйма әби.

— Әни, зинһар, тавыш куптарма. Ул сабый түгел. Аның үз акылы үзенә җиткән,— дип, Таня апа ашыгып табын әзерләргә керешә.— Сергей, син Эдикны укырга кер дип үгетләп карамадыңмы соң?

— Мин киләсе елга керәм,— диде Эдик, әнисенең сүзен бүлеп.— Быел мин сынау бирә алмаячакмын.

— Улым, хәзерге заманда белемсез берни эшләп булмый бит. Син инде ул якны тырыштыр,— диде Эдикның әтисе.

— Син үзең менә надан булсаң да гел җитәкчелектә генә утырасың,— диде Фатыйма әби.

— Нишләп мин надан булыйм! — диде Эдикның әтисе.— Мин бит индустриаль техникум бетердем.

— Эдик, капитанлыкка күтәрелә алсаң, укымасаң да ярый. Гомер буе капитан сеңлесе булырга хыялланам.— Безнең сөйләшкәнне Галя тыңлап тора иде.

— Улым, эчүдән, хатын-кызлардан саклан. Әтиеңнең тормышы гыйбрәт сиңа,— диде Фатыйма әби, үгет-нәсихәт бирүләр тәмам кызып җиткәч.

— Әни, балалар алдында юк сүз сөйләп утырма инде,— диде Таня апа.

— Шушы балалар кебек чагымда мин ике бала анасы идем. Безнең заманда баланы утызга җиткәнче чәйнәп ашатмыйлар иде,— диде әби.

Бу гаиләдә Фатыйма әбигә Таня апа гына каршы әйтә ала иде. Хәзер әбинең тәнкыйтен җавапсыз калдырдылар.

Табын хәзерләнеп бетте. Без өстәлгә якынрак килеп утырдык.

— Эдик, син ничек турыдан-туры пароходка эләгә алдың? — дидем мин.

— Тарихта андый хәлләр дә була икән,— диде Эдик елмаеп,— «Россия» дизель-электроходына радиотехник кирәк булган. Штат буенча радиотехник тоту каралмаган. Мине шунда электрик итеп урнаштырдылар да радиотехник эшен эшләргә куштылар.

— Нигә Габдрахманнан яшерәсең, Нинаның әтисе ярдәм итте дип әйт инде,— диде Галя, Эдикның алай тиз эшкә урнаша алуының серен ачып.

— Барыбер башта училищега урнашырга кирәк иде. Дипломың булмаганга электриклыкка гына алганнардыр,— диде Таня апа.

— Элек чыннан да шулай иде. Хәзер һәр дипломлы кешене югарыга күтәрү гадәте бетеп килә. Бүгенге көндә алган белемеңне эштә куллана белү кирәк,— диде Эдикның әтисе.

— Күптән шулай кирәк иде. Соңгы вакытта белеменнән бигрәк дипломы белән мавыга башладылар,— диде Эдик, әтисенең фикеренә кушылып.

— Дөресен әйткәндә, очраштыргалый шул,— диде Эдикның әтисе.

— Университеттан чыккач, синең швабра күтәреп, палуба юып йөргәнеңне күрсәләр, авылдашларың нәрсә әйтерләр иде икән? — диде Эдик миңа.

— Эшнең ниндие дә почетлы. Эшләмичә соры корт булып яшәүдән гарьләнергә кирәк,— диде Таня апа, мине юатырга тырышып.

— Безнең заманда һөнәрнең кадерен беләләр иде. Хәзер кая карама — профессор. Укымышлы кеше күп, эш рәтен белүче юк. Әллә шунлыктан, элек җимешнең поты бер тиен иде, хәзер кадагы ун тәңкә,— диде Фатыйма әби.

— Әни, син кеше сүзеннән гаеп табарга гына торасың. Сезнең заманда җимешне байлар гына ашаган, хәзер һәркем җимешсез өстәл янына утырмый,— диде Таня апа.

— Әби дөрес әйтте,— диде Галя, әбисенең фикеренә кушылып.— Безнең заманда урта белемсез кеше юк диярлек, кием-салым, йорт җиһазлары һаман яхшыра, һаман күбәя. Тормыш яхшырган саен комсызлык арта бара. Элекке заман кешесе болай комсыз булмагандыр. Минем иптәшләрем кигән киемнәр элекке заманда патша хатыннарына да тимәгәндер бәлки. Ә аларга андый киемнәр дә һаман әз күренә. Нигә шулай комсызланалар икән?

— Галина, бу унҗиде яшьлек кызлар чишә торган мәсьәлә түгел.— Эдикның әтисе урыныннан кузгалып, китәргә җыена башлады.

Әтисе чыгып киткәч, Галя өстәлне җыештырып, табак-савыт юарга керешті. Таня апа безгә беседка эченә урын җәйде. Без ятак читенә барып утырдык.

— Уйлый башласаң, катлаулы да инде бу тормыш,— диде Эдик, чишенә башлап.— Тырышып, тырмашып һаман теләгеңне тормышка ашырырга йөрисең. Теләгеңә ирешү белән шатланасы урында үзеңне алданган кеше шикелле тоя башлыйсың. Диңгезчелеккә урнаша алсам, миңа башка бернәрсә дә кирәкмәс дип йөри идем. Бүген инде эшкә урнашкач, кинәт шатлыгымның алай зур булмаганлыгын аңлап алдым. Диңгезчелеккә эләксәм, дөньяда миннән дә бәхетле кеше булмас дип уйлый идем. Хәзер сизенәм: бәхетле булу өчен тагын нәрсәдер җитми икән әле.

Эдикның мондый кичерешләре миңа таныш иде. Ул да, минем

шикелле, тырышуның нәтиҗәсе өчен түгел, өмет белән яши торган кеше иде булса кирәк.

Билгеле, һәркемнең бәхетле буласы килә. Ләкин минем өчен бәхет кесәдәге зәңгәр тышлы диплом да, кыйммәтле костюм да, хосусый «Волга» машинасы да түгел иде. Минем бәхетем эшкә ашырга теләмичә һаман киләчәккә кала торган тылсымлы бер теләктә иде. Ул каяндыр һавадан ишетелгән торна тавышы шикелле моңлы, матур иде. Шул тавыш шикелле күзгә күренми генә уза торган эфемер бер тойгы иде.

Эдикларның бакчасы артындагы тыкрыктан ике кеше сөйләшеп диңгезгә таба төшеп киттеләр. Одессага кайтучы пароход озын итеп гудок бирде. Таң алдыннан да Одессага ерак диңгезләрдән пароходлар кайткандыр — мин аларның гудок тавышларын ишетмәдем.

## 45

«Диңгез вокзалы» тукталышында троллейбустан чыктык та тимер юлы аша вокзал каршысындагы мәйданга үттек. Мәйданда пароходка билет көтүчеләр кайнашып йөри. Билет алырга өлгергәннәре пристань капкасы алдында, дулкынланып, пароходка утырта башлаганны көтәләр.

Юл газабы — гүр газабы, дигәннәр борынгылар.

Давыллар аша үтүне, диңгездә чайкалу газапларын пассажир билет алырга чират торганда ук кичерә башлый. Ул сәяхәтенең хәвеф-хәтәрсез бетәсенә ышана. Шулай булса да диңгез диңгез инде... Аның сине ничек каршылаячагын алдан кем белгән? Менә шушы билгесезлек диңгезгә чыгарга хәзерләнгән кешенең күңелендә әллә нинди шом уята, аны нинди генә сүзгә дә ышанырга мәҗбүр итә.

Порт капкасыннан керү белән причалга терәлеп торган зур ак пароход күренде. Шушы пароход Эдикны диңгезгә алып китәргә тиеш иде.

Корабны юан арканнар белән тарттырып причалдагы тимер пушкаларга бәйләп куйганнар. Аның җыйнак гәүдәсендә кузгалып китәргә җыенган чабыш аты омтылышы сизелә.

«Россия»нең торбасыннан бөҗраланып төтен күтәрелә. Мачтадагы сигнал флаглары корабны тизрәк кузгалып китәргә ашыктыргандай талпынып җилфердиләр.

Дустымны алып китәсе пароходны күргәч, йөрәктәге түземсезлек кабат яңарды. Тулпар ат та ир-егет күңелендә шушындыйрак хис уята торгандыр.

Диңгезчелек эшеннән хәбәрдар булмасам да, «Россия»нең тышкы кыяфәтенә карау белән моның дәһшәтле дулкыннарга каршы торырлык, иң ерак диңгезләрне дә әйләнеп чыгарлык кораб икәнлеген аңлап алдым.

Пароходның гомере кешенекеннән дә кыска. Иске кораб тузып өлгергәнче үк, яңа суднолар белән ярыша алмыйча, аларга урынын бирә. Ул чакта «Россия» дизель-электроходына утыз дүрт яшь иде. Өлкәнлегенә карамастан, бу кораб үзенең беренчелеген яшьләргә бирергә исәпләми иде әле.

Кузгалып китәргә кырык минут чамасы вакыт калган. Матрослар трюм капкачларына брезент каплап, су үтмәслек итеп ныгытып йөриләр. Борттагы ачык ишектән эчкә эчемлекләр, сыер түшкәләре, зур-зур капчыкларга тутырган азык-төлек ташыйлар. Корабның репродукторларыннан музыка агыла. Без судно янына килеп туктадык:

— Күрәсеңме, Эдик, сине музыка белән каршылыйлар.

— Эшемне башкара алмам дип куркам мин, Габдрахман. Бергә әлегә алмадык бит. Бергә булганда бирешмәс идек.

— Киләчәктә бәлки урнашырбыз әле. Хәзергә пароходка эләгүең кыйммәт,— дидем мин, Эдикны юатыр өчен.

— Белмим, булырмы икән? Бергә хезмәт иткән чакны сагынам.— Эдик тирән итеп сулап куйды.— Әниләр юксынырлар инде. Син, вакыт табып, баргалап йөр. Армиядә чакта, кайткач аларга ярдәм итәрмен, йортны, ихаталарны караштырырмын, дигән идем. Эшкә урнашу артыннан йөреп вакыт узды.

Судно янына килеп җиткәч, башыбызны күтәреп бер тын карап тордык та трапка басып өскә күтәрелә башладык.

— Менә, үзе теләп каботажны сайлаган яр диңгезчесе безгә визит ясый.— Трап башында теге Зеленовскийга керергә чират торганда очраган җирән чәчле диңгезче егет басып тора иде. Аны тану белән ниндидер киеренкелек туды. Җирән матрос кадрлар бүлегендәге сөйләшүне исенә төшерде булса кирәк, ул мине тагын үртәргә кереште:— Чит илгә йөзә торган судноga гына урнаш дип, тагын ялынып карамадылармы соң? Әллә монда белешергә генә килдеңме?

Нәкъ шул минутта коридордан җиңенә өч тасмалы шеврон таккан таза гәүдәле бер кеше килеп чыкты да матросны шелтәләргә тотынды:

— Тагын фәлсәфә сатарга керештеңме, вахтенный? Вахтада торганда базар ясама дип мин сине ничә кисәттем инде! Хәзер мин сиңа выговор бирәм дә вахтадан төшерәм.

Матрос акланып маташкан булды:

— Юк, иптәш өлкән штурман, мин сөйләшмим. Мин аларның документларын тикшерә идем. Әй, гражданин, таныклыгың кайда? — дип, вахтенный Эдикка таба кулын сузды.

— Миңа таныклык бирмәделәр әле. Пароходка баргач, менә шушы кәгазьне күрсәтерсең, диделәр.— Эдик кадрлар бүлеге биргән приказ кәгазен матроска сузды.

— Пароход түгел, дизель-электроход,— диде матрос, мактанырга яратучыларга хас ясалма өстенлек белән. Приказ кәгазен карагач, Эдикка кире кайтарып бирде. Уз-уз, монда сөйләшеп торырга ярамый.

— Кая барырга соң? Бу кәгазьне кемгә күрсәтергә?

— Белмим. Комачаулап торма. Атла, кореш, соңгы мәртәбә әйтәм.— Матрос үз эшен җиренә җиткереп эшләргә тырышкан булып маташа иде.

Янибызга машина маена буялып беткән бер кеше килеп туктады. Вахтада торучы аңа таба борылды:

— Пычрак киемнән пассажирлар палубасына чыкмаска дигән приказ сиңа кагылмыймыни? Судно пычратып аяк астында уралып йөрсәң, мин сине бик тиз тәртипкә өйрәтермен! — Баягы матрос өлкән штурманнан алган шелтәне тизрәк кайтарып бетерергә ашыга иде.

— Әй, калай әтәч, вахтага сине куйганнар икән. Мин сине һаман гальюн[1] тазартып йөри дип уйлаган идем,— дип, тегеңә җавап биргәч, майлы киемле диңгезче безгә таба борылды:— Сез кадрлар бүлегеннәнме, егетләр? Мин үземне алыштырырга килүче мотористны көтәм,— диде, Эдикның моторист түгеллеген белгәч, безне алга әйдәде:— Әйдәгез, приказ тапшыра торган җирне күрсәтәм.

Без коридорга керә башлагач, җирән матрос каршы төште:

— Әйттем бит, коридорны пычратып, монда чуалып йөрмә дип! Әй, салака, давай кәгазьләреңне!

Эдик приказ кәгазен матроска сузды. Матрос миңа таба борылды:

— Ә синең приказың кайда?

— Мин дустымны озатырга гына килдем.

— Озатышып йөрергә судно вокзал түгел. Давай, дуй, дуй, ычкын моннан! — Ул күзе белән өлкән штурман киткән якка карап алды да

[1] Гальюн — туалет, бәдрәф.

пышылдап әйтте:— Хәтерең калмасын, кореш, служба! Ишеттең бит — чиф ничек аждаһалана. Монда — тәртип, дисциплина; тәртипләре бугазларына тыгылгыры! Өлкән штурман трап яныннан китсен дә, мин сине кертермен.

— Рәхмәт, дус кеше, болай да минем аркада шелтә алдың. Сине яңадан уңайсыз хәлгә куясым килми. Сау бул, Эдик, хәерле юл. Эшеңдә уңышлар телим! — Без Эдик белән кочаклашып саубуллаштык.

Причалга төшкәч, кораб янына җыелган халыктан читкәрәк китеп, мичкә өстенә менеп утырдым.

Трапта торганда әлеге җирән матроска ачуым килгән иде. Хәзер инде мин аны кызгана башладым. Иптәшләре арасында абруе юклыгы күренеп тора. Аның да чит илгә йөри торган пароходта эшлисе килә торгандыр? Башкача үзенең каботажда эшләве турында болай кимсенеп искә алмас иде. Үзен яратып та бетермиләр булса кирәк. Теге дингезче ничек сөйләште бит үзе белән.

Яңа эштә Эдикны нинди коллектив, нинди мөнәсәбәт көтәдер инде? Ул да җирән чәч шикелле зарланып сөйләшә башламаса ярар иде.

Эдик белән дә аерылышабыз. Шушы чит шәһәрдә хәзер берүзем калам. Уйлап карасаң, яшәү дигәнең кавышу белән аерылышулардан тора бит. Һәр иртәдә көн белән кавышсаң, кичен аерылышасың. Ай белән, ел белән, гомер белән дә шулай...

Теге шевронлы кеше, чыгып, вахтада торучы матроска нәрсәдер әйтте. Матрос «Утырырга рөхсәт ителми» дигән белдерүне чишеп алды да коридорга кертеп яшереп куйды. Радиодан пароходка утырту башланганлыгын әйттеләр.

Причалдагы кешеләр дәррәү трапка омтылдылар. Кысылышып өскә күтәрелә башладылар. Җирән матрос аска төшеп, трапка килгән кешеләрнең билетларын тикшерергә тотынды. Аңа вахтада торучы штурман ярдәмгә килде. Бераздан пирс бөтенләй бушап калды.

Дөнья мәшәкатеннән качып, диңгез буе курортларында үскән пальмалар күләгәсенә ашыгучылар хәзер инде ак пароходның палубасында иделәр.

Палубага күтәрелү белән пассажирларның түземсезлеге басылмады. Атаклы лайнерның тылсымлы каюталарын тизрәк күрергә теләгән кыбырсык халык бер палубадан икенчегә чабып мәш киләләр. Кайберәүләр юлларында очраган һәр нәрсәне тотып капшап карыйлар, сәяхәттән кайткач, сөйләп, пароход күрмәгән кешеләрне шаккаттыру өчен корабның иңен-буен, биеклеген адымлап үлчәргә тырышалар.

Көндәлек тормыш мәшәкатьләреннән котылган һәр пассажир үзен җил-давыл белән көрәшеп, океан гизәргә, кеше аягы тимәгән яңа атаулар ачарга чыккан диңгез флибустьеры[1] итеп сизә иде. Алда — зәңгәр хыял, маҗаралар, яңалыклар...

Диңгез һавасы ургылып үпкәгә керә, җиңеллек, рәхәтлек биреп бөтен тәнгә тарала. Шушы һава һәр тиенен санап яшәгән саранны да иртәгәсе көне турында кайгырта белмәүче бер юмартка әйләндерә. Палубага менгән сәяхәтчеләр озата килүчеләргә кул болгарга да онытып, дизель-электроходның ресторанына юнәлделәр. Стюардессалар, администраторлар ни эшләргә белмичә аптырап беттеләр. Кая карама — кеше. Коридорлар, палуба, каюталар пассажирлар белән шыгрым тулган.

Судно гудок бирде. Бу тылсымлы, куәтле аваз яр буендагы кешеләрнең баш өсләреннән ишелеп узды да шәһәр йортларына бәрелеп портка кире әйләнеп кайтты.

Өченче гудоктан соң корабның трабын алдылар. Күперчектән капитанның боерык биргән тавышы яңгырады. Матрослар корабны пирска

[1] Флибустьер — маҗара эзләүче, пират.

беркеткән юан бауларны бер-бер артлы сөйрәп алып, палубага урнаштырырга тотындылар.

Борт белән пирс арасында тар гына су тасмасы күренде. Корабның борыныннан асылынып төшкән юан чылбырлар хәрәкәткә килде. Якорь судан чыгып, өскә күтәрелде.

Кораб борты белән пирс арасындагы су тасмасы киңәя бара. Кораб торбасы һавада төтен боҗралары бөркелдерә башлады. Койрык астында су кайнарга тотынды. Ак кораб ашыкмыйча гына маяк ягына таба борылды да, салмак кына йөзеп, диңгезгә чыгып китте.

Зәңгәрсу киңлектәге ак нокта һаман кечерәя бара. Бераздан инде ул офык артына китеп югалды.

Аерылу тойгысы йөрәкне әрнетеп алды. Минем бердәнбер танышым, бердәнбер дус кешем корабка утырып каядыр китеп барды. Әйтерсең кораб үзе белән минем өмет-хыялларымны да алып китте. Миңа бик ямансу, күңелсез иде.

## 46

Эдикны озаткач, Таня апа белән Фатыйма әби мине үз улларыы кебек карый башладылар. Аларның шул кадәр кунакчыллыгына уңайсызлана да башладым. Минем аларга бернинди ярдәм күрсәткәнем, файда иткәнем юк. Киләчәктә, белмим, яхшылык эшләп булырмы, юкмы? Алар мине һаман үз балаларыннан артык күреп тәрбияләүләр. Торган саен минем аларга бурычым арта, алган әҗәтем күбәя бара кебек тоела иде. Мин түзмәдем, иртәгә рейска китәм дигән булып, чемоданымны алып, тулай торакка киттем.

Тулай торакта урын юк иде. Ялынып сорагач, администратор сәгать унбердән соң кунарга килергә рөхсәт итте.

Сәгать төнге унбер тулгач, дежур хатын тулай торакның капкасын бикләп керде. Урынсызлар номерлардагы буш ятакларны тикшереп чыктылар. Ятак таба алмый калучылар су кайната торган бүлмәгә юнәлделәр. Тәҗрибәлерәкләр кием үтүкли торган өстәлне, идәннең түр як урыннарын алып өлгергәннәр иде инде. Кайбер егетләр асларына салырга матрас та тапканнар иде.

Башкаларның нәрсә эшләүләрен күзәтеп йөри торгач, мин урынсыз калганмын.

Ишек янындарак бераз буш җир бар иде әле. Мин шул урынга барып утырдым да кесәмнән газета алып, идәнгә җәя башладым.

— Хиба так можно? — диде почмакта яткан бер диңгезче.— Синең аша атлап йөриячәкләр бит. Кил, менә монда ят. Күңелең киң булса, урын тар булмас.— Шулай дип, әлеге диңгезче, иптәше янына кысылып, стена кырыеннан миңа урын бирде.

— Син дә эшкә урнашып кына азапланасыңмы әллә? — дидем мин, башымны егетнең бөкләп салган күн курткасына терәгәч.

— Юк, мин күптән эшлим.

— Ничек монда эләктең соң?

— Ялда идем. Минем танкер ай ярымнан гына Одессага кайтачак. Әле шуны көтәм.

Сөйләшә торгач, без танышып та киттек. Бу егет Сергей исемле иде. Ул пароходчылыкның иң яхшы танкерында донкерман[1] булып эшли икән.

Донкерманның нинди эш башкарганлыгын сорарга кирәк иде дә, үземнең «яр күсесе» икәнлегемне фаш итүдән куркып, тыелып калдым.

Йокы ястык теләми, диләр. Бераздан кубовой идәнендә, үзара ярышкандай, каты-каты гырылдаган тавышлар гына ишетелә иде.

[1] Донкерман — насослар белән идарә итүче моторист.

Беренче мәртәбә күземне ачып җибәргәндә бүлмә эче дөм караңгы иде. Тыгынлыктан һәм һава юклыктан тәмам изрәгән кешеләрнең гәүдәләре арасыннан атлап түргә таба бер шәүлә кыймылдап узды.

Коридордагы дежур хатын кемнедер ялварып үгетли иде:

— Ят инде. Яхшы түгел бит, ят. Хатын кеше шушылай кыланамыни? Малайларны уятасың. Төн уртасында тавышлана дип, Курененкога барып әләкләүләре бар. Зинһар өчен ят!.. Морякларны уятасың. Аларның иртәгә эшкә барасылары бар. Ял итсеннәр, яме.

— Итсеннәр, балакайларым, итсеннәр. Йокласыннар. Курененконы себеркеләп урыныннан куып чыгарсалар, диңгезгә чыгып китәрләр иде алар...

— Әйдә, Лиза апа, әйдә. Мин сине чишендереп яткырыйм. Әйдә, тавышланмыйча гына кереп ят.

Шыгырдап ишек ябылып ачылды. Лиза апаның соңгы мәртәбә кычкырып әйткән тавышы ишетелеп калды. Коридорда тынычлык урнашты.

Сергей да уянып коридордагы тавышны тыңлап ята икән.

— Лиза апа шаулый,— диде ул.

— Кем ул Лиза апа?

— Тулай торакны җыештыручы хатын. Сугыш вакытында аның ирен, өч улын фашистлар тотып асканнар. Шул кайгыдан мескен эчкәли.

— Курененкога тел тидерде. Ул аны яратмыймыни?

— Резервта утыручыларның зарларын ишетеп тора бит ул. Диңгезгә чыга алмауларын алар Курененкодан күрәләр. Лиза апа бик йомшак күңелле хатын...

Бер мәртәбә бичләр [1] Лиза апага: «Курененко Дюк Ришелье һәйкәлен юарга кушты, менә егерме биш сум аванс, калган житмеш биш сумын, юып бетергәч, Курененконың үзеннән алырсың»,— дигәннәр. Алай алдан акча да биреп куйгач, ышанган инде, мескен. Баскычка басып, һәйкәлне әйбәтләп юган. Юып бетергәч, кадрлар бүлегенә аласы акчасын сорарга килгән. Курененко: «Минем андый боерык биргәнем юк. Боерык биргән кеше үзе түләсен»,— дигән.

Лиза апа профсоюзга барып әйткән. Аңа житмеш биш сумны каяндыр табып түләгәннәр. Ә Курененко гомергә аның дошманы булып калган.

Психологик җайланыш — кеше табигатенең бик кызыклы бер үзенчәлеге. Адәм баласы тегe яки бу кешенең яхшымы-яманмы икәнлеген чамаларга тырыша. Аны белү өчен озак кына күзәтергә, ничек эшләвен, башкаларга нинди мөнәсәбәт күрсәтүен якыннанрак күрергә кирәк. Ләкин тормышта бу юл кулланылмый. Кемнең кем икәнлеген беләсе килгән кеше күп вакыт коллектив биргән бәягә карый.

Коллектив сине яман кеше итеп тапса, башкалар да синең яман ягыңны гына күрә башлыйлар. «Яман» кешенең яхшылыгы күренми, күренсә дә исәпкә алынмый.

Киресенчә, җәмәгать фикере сине яхшы дип тапса, синең начарлыкларың кайвакыт күренми дә үтә.

Мин, эшли башлагач, мондый психологик җайланышка бирелмичә, Курененконың кем икәнлеген аңларга тырыштым. Кадрлар бүлеге башлыгы үз эшенең бөтен якларын тигез күреп, төпченеп эшли торган уртача сәләтле, начаррак холыклы бер кеше икән. Әгәр ул шушы урынына диңгезчелектән күтәрелгән булса, аны яманлаучы да булмас иде. Ул моңа кадәр милиция идарәсендә эшләгән булган.

Диңгезчеләрдә профессиональ этика көчле. Коры җир кешесенең моряклар эшенә катнашып, боерык биреп йөрүен яратмыйлар. Шун-

[1] Бич (инглиз сүзе) — коры җирдә яшәүче кеше.

лыктанмы, резервта утыручылар Куренeнко чыгарган карарга ышанмыйлар иде. Ул эшли башлау белән пароходчылыкта резерв барлыкка килгән.

Дингезче халкы шаяртырга ярата. Озак резервта утырып алҗыган бер егет Куренeнконың адресын белеп алган да шәһәрнең берничә җиренә мондый белдерү кәгазьләре элгән:

«Холодильник сатыла. Алырга теләгән кеше кичке сәгать җидедән соң Свердлов урамы, 18 нче йорт, 8 нче квартирга килеп белешә ала».

Ул чорда суыткычлар аз чак иде. Одессалылар сату-алуга ифрат әвәс халык. «Сатыласы» холодильникны белешергә килүчеләр тәмам тенкәсенә тия башлагач, Куренeнко милиционер чакырырга мәҗбүр булган, имеш.

## 47

Кубовой бүлмәсендә кунып яши башлаганга ике атнадан артык вакыт үтте. Бер көнне иртән Сергей белән юыну бүлмәсеннән чыгып килгәндә, безне Лиза апа туктатты:

— Сережа, син һаман кубовойда кунасыңмыни әле?

— Әйе, Лиза апа.

— Алтынчы номерда ике койка бушый. Тизрәк урнашырга тырышыгыз.

Без шундук алтынчы бүлмәгә киттек.

Тәрәзә янындагы караватт өстендә ачык чемодан ята. Чемоданның хуҗасы, ябык йөзле, озын буйлы, чандыр бер дингезче, тумбочкасын, матрас асларын актарып, калган әйберләрен чемоданына тутырып азаплана иде.

Егет караватт белән стена арасына кысылган галстугын алып әйберләре өстенә ташлады да, чемоданының капкачын ябып, безгә таба борылды:

— Финита ля комедия! Дингез чакыра. Иртәгәдән лимонлы-бананлы Сингапурга карап винтка мильләрне урый башлыйбыз! — Шулай дигәч, егет чемоданының авырлыгын чамалап карады.

— Өч ай эшсез утырдым. Җитте! Тәнемә сеңгән дингез тозы бөтенләй чыгып бетте. Җибәрмәсәләр, Куренeнконы чәйнәп йотар хәлгә җиткән идем.

— Нинди судноға билгеләделәр? — диде Сергей.

— «Кремль» танкерына. Бераз картрак. Әмма аның рейслары әйбәт. Тизлеге тугыз узел [1]. Кулай судно. Сингапурга җиткәнче кесә тулы валюта җыела...

— Резервка ничек эләктең? — диде Сергей, дингезчене сүзеннән бүлеп.

— Отпускадан соң. Инспектор урыныма бер «инвалид»ны утырткан.

— Йөзү эшенә инвалидларны да алалармыни? — дидем мин гаҗәпләнеп.

— Алалар шул. Үзе болай үгез кебек таза егет ул. «Кулы» кадрлар бүлегендә утыра. Шул «кул» егетне теләгән пароходына урнаштыра инде.

— Мин отпускада чакта инспектор минем урынга үзенең танышын утырткан дисәң, ни булган соң! — дип, Сергей дингезченең сүзен мин аңларлык итеп әйтте.

Егет җиңе белән битен сөртеп алды да чемоданын күтәреп ишеккә юнәлде:

— Гуд бай, мариманнар. Дингез чакыра! Сезнең дә тизрәк пароходка эләгүегезне телим. Сингапурда очрашырга язсын.

---

[1] Бер узел — сәгатенә бер мильгә (1,856 километрга) тигез.

Диңгезче бүлмә ишегеннән кереп килгән милиционерга бәреләязды.

— Әллә чылбырдан ычкынганмы бу бәндә? — диде милиционер, бусагадан атлап кергәч.

Милиционерга тулай торакның коменданты ияргән иде.

— Алар кешечә йөри беләләрмени,— дип өстәде ансы.

Комендант белән милиционер ишек кырыендагы ятакны тикшерергә тотындылар. Мендәрне, матрасны күтәреп карадылар. Тумбочка эчендәге әйберләрне алып актка теркәделәр. Әйберләр кәгазьдә теркәлеп беткәч, Лиза апаны чакырып, нәрсәдер әйттеләр дә бүлмәдән чыгып киттеләр.

— Диңгезчедән калган мал.— Лиза апа тумбочкадан чыккан сабын савыты, бритва, теш щеткаларын мендәр тышлыгына тутырды.

Милиционер белән комендантның тумбочкадагы әйберләрне карап акт төзүләре мине шикләндергән иде. Милиционер чыгып киткәч, борчылуым тагын да көчәйде:

— Нинди кеше турында сөйлисез сез? — дидем мин Лиза апага.

— Кичә кич машина астына эләккән егет турында,— диде Лиза апа.— Монда урнашканчы ул летчик булган.

Бу хәбәр урын табылу шатлыгын юып төшерде. Сергей да шомлана калды:

— Үзе ташланмагандыр бит?

— Юк, ташланмаган. Исерегрәк булган, диләр. Ниләр генә эшләтми инде бу каһәр төшкән аракы!

Лиза апа чыгып киткәч, Сергей һәлакәткә очраган егетне кызганып куйды:

— Мин аны беләидем. Эчкәне өчен эшеннән чыгарылуы дөрес. Монда да бар тапканын аракыга тотып бетерә иде. Тавышланмыйча йөргән кешенең салуына каршы килмиләр бит бездә. Нәтиҗәсе менә шулай була. Соңгы вакытта аракыга акча таба алмагач, спирт катнаштырып ясаган төрле агу эчә башлаган иде,— диде ул.

Үлгән кеше урынында йоклаячагымны уйлап, мин шикләнә башладым.

Караватхуҗасының мәет булуы һәр әйбергә, хәтта бүлмәнең һавасына кадәр сеңеп калган кебек тоелды. Сиздермәскә тырышсам да, Сергей минем кичерешемне абайлап алды:

— Шикләнсәң, әнә теге караватны ал.

— Юк, шикләнмим,— дидем мин.— Табигый хәл бит.

Лиза апа караватка яңа җәймә җәйде, мендәр тышлыгын алыштырды.

— Одеалны алыштырмыйлармыни монда?

Лиза апа минем нәрсә әйтергә теләгәнемне аңлады булса кирәк.

— Матрасы да бик тузган икән. Тукта әле, мин сиңа яңаны кертим,— диде.

— Әллә күлмәкләребезне дә юып алабызмы? — диде Сергей.— Чиста җәймә өстенә керләнгән киемнән ятасы килми.

— Мин кер юа беләм. Таз табып булса, биш минутта юып алырбыз,— дидем мин.

Сергей таз эзләгән арада, мин шәһәргә чыгып кер сабыны сатып алдым.

Укыганда керләрне мин үзем юа идем. Ир-ат юган кернең хатын-кыз кере белән ярыша алмавын әйтеп торасы юк. Сергейның кер юганын күргәч, бу фикердән ваз кичәргә туры килде. Ул хатын-кызлар шикелле озак ышкып, күбекләндереп уа да борып сыга. Селеккәләп, бөкләнгән җирләрен язгалагач, тагын уарга керешә.

— Әллә син кер юу мәктәбенә кереп укыдыңмы?

— Тормыш мәктәбе өйрәтте. Моряклар белән монахлар гомер буе керләрен үзләре юалар. Кер юа белми торган кыз туры килсә, өйләнгәч, аны да өйрәтермен.

— Юа белә торганы туры килсен инде. Чисталык матурлык белән бер тигез бит ул. Чисталык хатын-кыздан күбрәк сорала.

— Диңгезчедән дә аз соралмый шул. Мин күптән сынап йөрим: ялкаулык белән шапшаклык бергә яшиләр.

Кerләребезне юып, кубовой бүлмәсенә киптерергә элгәч, шәһәргә барып мунча кереп кайттык. Безнең белән бер бүлмәдә яшәүче диңгезчеләр җыела башлаганчы, без эшебезне бетереп, урыннарыбызга менеп ятарга өлгергән идек инде.

## 48

Иң элек түр почмактагы урынны биләүче диңгезче кайтты:

— Бу караватхуҗасының кая киткәнлеген беләсеңме? — диде ул, минем яныма туктап.

— Беләм.

— Белгәч, магазинга барып кайтырга кирәк. Мондый урынга болай гына ятарга ярамый. Мәрхүмгә поминка ясарга кирәк. Бер уңайдан яңа урын мәҗлесе дә булыр.

— Соңга калдың, кореш,— диде Сергей, урыныннан күтәрелеп.— Без мәҗлесне үткәрдек инде.

— Миннән башка уздырылган мәҗлес исәпкә алынмый. Мин бит бу бүлмәнең коменданты. Давай, кореш, көттермә.

Сүзне шаяруга борырга ашыктым:

— Комендант кадәр комендантны гади сый белән генә сыйлап булмас. Бераз көтсәң, закускаларны рестораннан китертербез. Шәрабләрне Франциядән кайтартыйкмы, Испаниядәнме?

«Комендант» җавап бирергә өлгерә алмый калды. Бүлмәгә минем караваткa каршы куелган ятакның хуҗасы кайтып керде:

— Изге урын буш тормый, диләр. Менә очучы урынын да алганнар,— шулай дигәч, әлеге диңгезче Сергейны танып алды.— Син бу бүлмәгә эләккәнсең икән. Боцман Жора бакшиш[1] сорамадымы соң?

— Сорады. Без бирергә риза булдык. Юньле ресторан таба алмаганлыктан гына аның теләге кабул булмый тора. Игорь, син «комендант»ның күңелен күрергә ярдәм итәрсең инде,— диде Сергей.

— Ул якны ачыклагансыз икән. Жора сездән биографиягезне сөйләтә башлаячак,— диде Игорь.— Монда урнашкан кешеләрдән ул ясак җыя, биографиясен сөйләтә. Шуннан соң гына бүлмәдә яшәргә рөхсәт итә.

— Болардан биография сөйләтеп торасы юк. Синең танышларың салакалар,— дип, Жора чишенә башлады.

Жораның аягында хатын-кыз оегы иде. Ул аны салып, караватбашына элеп куйды.

— Хәзер хатын-кыз оегы модага кердемени? — дип, Сергей Жора салган оекны тотып карады.

— Кан тамырлары бүрткәнгә эластик оек урынына кия торгандыр ул аны,— дидем мин.

— Артык күп кызыксына башласагыз, Жора сездән патент хакы да түләтер әле,— диде Сергейның танышы.

Безнең кызыксынуыбыз Жораның базарын күтәреп җибәрде булса кирәк, ул аякларын одеал астына яшерде:

— Яңа квартирантларның салака икәнлекләре әллә каян күренеп тора. Мондый оекның файдасын салакалар аңлыйлармы?!

[1] Бакшиш — (гарәпчә) — бүләк, ришвәт.

— Безнең Жора бик сәләтле рационализатор,— диде Игорь.— Әйт әле, оек киеп йөрүдән син ай саен ничә сумлык файда күрәсең?
— Ярты литр куйсалар сөйлим,— диде Жора елмаеп.
— Жора гел хатын-кыз оегы киеп йөри. Үкчәләре, бармак турылары тишелгәч, тузган җирен кисеп ташлый да, башын бөкләп, тагын кия. Тишелгәч, тагын кисеп ташлый да кунычын баш итеп кия. Ул безнең шикелле оекбаш юып интекми, ямап та азапланмый. Биш кием оекбаш урынына ана бер кием оек җитә.
— Син бу турыда газетага мәкалә яз,— диде Сергей.
— Язмыйм. Серемне башкаларга ачасым килми. Ә сез получкадан миңа бер яртыны куярга тиеш булырсыз.
— Ярый, куярбыз,— дидем мин.— Безнең тизрәк пароходка эләгүебезне генә телә.
— Син, кореш, кайсы пароходта йөздең? — диде бүлмә «комендантын» Сергейга.
— «Апшерон»да.
— Капитаныгыз Бакшеев, өлкән механигыгыз Каратаевмы?
— Син аларны каян беләсең?
— Мин, кореш, пароходчылыктагы бар кешене беләм. Кешеләрне генә түгел, пароходларда тәртип нинди икәнен, нинди җитешсезлекләр барлыгын — барысын да беләм.
— Кара әле, дус кеше, сине начальник итеп куярга кирәк икән. Син начальник булсаң, безне бер көндә пароходка урнаштырып бетерер идең,— диде Сергей.
— Эшли алмас иде дисезмени? Училище бетергән булсам, мин әллә кайчан капитан булыр идем инде.
— Кызлар белән танышканда син болай да мин капитан дип мактанасың,— диде каршы караваттагы егет.
Жора, аны ишетмәмешкә салышып, тагын миңа таба борылды.
— Ә син кайсы суднода эшлисең?
— «Куин Мэри»[1] да,— диде Игорь.— «Нормандия» янганнан соң ул «Куин Мэри»га күчкән. Хәзер аңа ул лайнер да ошамый башлаган, «Франс»ның төзелеп беткәнен көтеп, резервта утыра.
Жора минем урындык артына эленгән чалбарыма, терсәкләре тишелгәч җиңе кыскартылган яшькелт күлмәгемә күз салды:
— Юк, бу егет диңгез җилен исләп карамаган әле. Син кайсы инспектор карамагында, кореш?
— Зеленовскийда.
— Визаң ачык түгелмени?
— Нинди виза ул? — дидем мин аңламыйча.
— Әйттем бит бу егет тозлы җилне исләп карамаган әле дип! — Визаның нәрсә икәнлеген дә белмәгән кеше белән сөйләшеп тә торасы юк дигәндәй, Жора борылып ятты.
Бүлмә эче тынып калды. Сергей белән каршы караваттагы диңгезче бик тиз йокыга киттеләр. Аларның тирән итеп сулыш алганнары ишетелә башлады.
Жора, урыныннан торып, минем яныма килеп утырды:
— Каботажда эшләп әллә ни файда чыгарып булмый. Син, кореш, тизрәк виза оформить итәргә тырыш. Өч партия членыннан рекомендация ал. Эшләгән җиреңнән партия җыелышында расланган характеристика сорап, кадрлар бүлегенә тапшыр. Шуннан соң сиңа махсус анкета бирерләр. Шул анкетаны тутырып, автобиографияңне язып тапшырганнан соң, чит илгә йөзәргә рөхсәт итү мәсьәләсе әкренләп карала башлар. Ялгышкансың син, кореш, эшкә урнашканчы виза алу

[1] Куин Мэри — Британиянең иң зур пассажир лайнеры.

кирәк иде.— Жора нәсихәтен сәер генә итеп тәмамлап куйды:— Тартырга бармы синең?
— Юк, мин тартмыйм.
— Әллә эчмим дип тә әйтергә телисеңме?
— Эчмим дә.
— Кореш, Привоз янында дини семинария бар. Шунда урнаш. Алачаклар...
— Беләсеңме, кореш, әгәр чын диңгезче буласың килсә, аннан ераграк тор,— дип, Жора Сергей ягына ымлап күрсәтте.— Ул миңа ошамады. Ә тегесе,— ул тагын берәүгә таба ымлап алды,— читтән торып училищеда укый. Андыйлардан чын диңгезче чыкмый. Минем йөз мәртәбә сынап караганым бар инде. Андыйлар теориядән ары китә алмыйлар.
Башны йомшак мендәргә салып, чиста җаймә астында ятуы шул кадәр рәхәт иде. Жораның каботаж белән куркытуы да, узган төннәрне шушы урында яткан кеше язмышы да тәннең изрәвенә комачаулый алмады.

## 49

Йокыдан уянуга, күзем урындык артына элеп куелган күлмәккә төште. Сергей, миңа кадәр торып, кичә юган күлмәкне үтүкләп тә өлгергән иде инде.
— Юып үтүкләгән кием кисәм, күңелем күтәрелеп китә,— диде ул.
Мин дә урынымнан торып киенә башладым:
— Бүген дә пароход тутыгын чистартырга җибәрсәләр, тагын пычранабыз инде,— дидем мин.
— Дүрт ай буе бер мәртәбә эшкә бармадым,— диде боцман Жора.— Инспектор янына кереп теркәлеп чыгам да Лонжерон пляжына кызынырга китәм.
— Резервта торучы капитаннарны да эшкә кушмыйлар бит. Сине дә шуларга тиңли торганнардыр бәлки,— диде Сергей.
— Резервка куйганнан бирле көн саен эшкә җибәрәләр. Мин бер мәртәбә дә эштән кала алмадым,— дидем мин.
— Җибәрми нишләсеннәр, сукыр чебен шикелле әрсезләнеп, эшкә билгеләнгән вакытка туры китереп йөргәч,— диде Жора мактанып.— Мин бригадалар җыелып бетмичә кермим.
Без урамга чыктык. Потемкин баскычыннан күтәрелгәндә боцман Жора безне куып җитте:
— Ашыкмагыз, миңа ияреп керсәгез, сез дә бүген ял итәрсез.
Баскычтан менгәч, уңга борылып бераз бардык та кадрлар бүлеге каршысындагы эскәмиягә утырдык.
Диңгезчеләр ишектән кереп китәләр дә бик озак чыкмый торалар. Сәгать тугызлар тирәсендә эшкә билгеләнгән бригадалар бульварга чыктылар.
Сергей урыныннан торды:
— Әйдә, керик, соңга калмаска кирәк.
— Ашыкма,— диде Жора,— тагын бер бригада чыгарга тиеш. Шулар чыкмыйча керергә ярамый.
Бераздан кадрлар бүлеге ишегеннән тагын бер төркем диңгезче чыкты. Алар без утырган эскәмия яныннан шаулашып узып киттеләр.
— Хәзер керергә була,— дип, Жора урыныннан кузгалды.— Соңга калып килгән өчен шелтәли башласалар, каршы әйтмәгез. Башыгызны иеп тик торыгыз. Кадрлар бүлегендә эшләүчеләр шундый кешеләрне яраталар.
— Кеше алдында баш иеп, кимсенеп торудан көне буе палуба чис-

тартуың йөз мәртәбә артык,— диде Сергей. Мин дә Жораның сүзен тыңлап, вакытында керми калуыма үкенә башлаган идем.

Коридорга кергәч, өчебез өч ишек янына чиратка бастык. Кеше әз иде. Озак көтәргә туры килмәде. Ярты сәгатьтән мин инспектор Зеленовский кабинетында идем инде:

— Нигә соңга калып килдең?

— Бүген беренче мәртәбә мендәргә ятып йокладым. Вакытында уяна алмаганмын,— дидем мин, башка сәбәп таба алмагач.

— Тагын бер мәртәбә соңга калып килсәң, мин сине резервтан төшерәм.— Шелтәсенең миңа ярыйсы гына тәэсир иткәнлеген күргәч, инспектор болай дип өстәде:— Иди, гуляй. Болай соңга калып килергә иртә әле сиңа.

Сергей белән Жора мине урамда көтеп торалар иде.

— Күрдеңме? Акыллы кеше һәр вакыт шулай эшли. Бүгенге көн безнең карамакта,— диде Жора.

— Соңгы мәртәбә...— дидем мин.— Синең соңга калып килүеңә бәлки күнеккәннәрдер. Мине резервтан чыгарып ташлый яздылар.

— Курыкканга куш күренә. Резервтан чыгарсалар, алар йөзәргә җибәрергә тиешләр, чыгарып карасыннар, икенче көнне үк профсоюз кире урнаштырачак. Чыгармыйлар алар. Куркытыр өчен генә әйтәләр...

Без Диңгез буе бульварының каштаннары арасыннан ашыкмыйча гына Пушкин һәйкәленә таба юл тоттык. Һәйкәлне узып, опера театрына кадәр күтәрелдек тә Дерибас урамын аркылы чыгып, дәүләт банкы каршысына туктадык. Монда илле тиенлек пирожки саталар иде.

— Мариманнар[1], дары савытларыгызны тикшереп карагыз әле. Кемнең күпме сармагы[2] калган икән.

Мин кесә төбендәге берничә бакыр акчамны Жораның учына салдым. Сергей сузган вак акчалар арасында көмеше дә бар иде. Жора учындагы акчаны берничә мәртәбә санап карады:

— Җиде тиен җитми. Дары савытларыгызны тагын бер мәртәбә тикшерегез.

— Син үзеңнекен тикшермәдең бит әле,— диде Сергей.

— Минем дары савытындагы соңгы дары бөртеге тотылып беткәнгә атнадан артык инде. Получкамны алу белән ресторанга илтеп тапшырам,— диде Жора мактанып.

— Икенче получкага кадәр диңгез җиле белән туенып торасыңмыни? — дидем мин.

— Чын моряк тамак турында кайгыртырга тиеш түгел. Ашау турында кайгырту — буржуй гадәте ул. Врачлар ашауны ашказанына зарарлы дилә р.— Жора учына йомарлаган акчасын пирожки сатучы кызга сузды.— Өч данә борчак пирожкие, синьорина.

— Җиде тиен акчагыз җитми,— диде сатучы кыз.

— Җиде тиен өчен вакланып, сүз көрәштерербезмени инде, синьорина? Швейцария банкысындагы кредитымны алгач, җиде тиен урынына җиде сум җитмеш җиде тиен итеп алтын акча белән түләрмен.

Сатучы кыз, кәгазь тасмага төреп, һәммәбезгә берәр пирожки сузды.

Без Сергей белән сумсаны ике кабуда юк иттек. Жора пирожкиеның яртысын ашады да, калган яртысын сузып, капка төбендә яланып утырган мәче янына бара башлады:

— Пс-пс-пс-пс. Кил, җан кисәгем, мә, борчак пирожкие аша.

— Жора, пижонланма. Үзең аша. Болай да тел очына гына тиеп калырлык бит.

— Кычкырма, мәчене куркытасың,— Жора сумсага алданып янына

[1] Мариман (диңгезчеләр жаргоны) — моряк.
[2] Сармак (диңгезчеләр жаргоны) — акча.

килгән мәченең аякларыннан эләктереп алды да мескеннең гәүдәсе белән ботинкасын чистартырга тотынды.

— Ни эшлисең, фашист! Нигә аны газаплыйсың? — дип, сатучы кыз Жораның кулын борып, мәчене ычкындырып җибәрде.— Хәзер милиция чакырам, хулиган!

— Шаулама, синьорина. Төш вакытында мин бер чибәр леди белән очрашырга тиешмен. Аның каршысына тузанлы ботинкадан барыйммыни? — Жора кулындагы пирожки кисәген мәчегә ташлады.

— Мә, аша. Үзең эшләп алган хәләл ризык.

— Алай булгач, син ул леди белән очраш инде, без Габдрахман белән Лонжеронга су коенырга китәбез,— диде Сергей.

— Минем швартовка сәгать дүрттә. Хәзер мин сезне судка алып керәм. Бүген анда бер аерылышу процессын тыңларга тиешләр. Тамаша инде, чын комедия. Керү бушлай. Андый процессны тыңларга судка көн саен бичтә утыручы мариманнар җыела.

— Юк, минем суд тыңлыйсым килми. Кеше зарын тыңлап күңел ачу начар гадәт ул,— дидем мин.

— Мин дә кермим,— диде Сергей.— Әни белән бертуган апам, «квартирамның ишеге ябылмый, шуны төзәтеп бирмәссеңме?» дигән иде.

— Бакшиш булса, мин төзәтәм,— диде Жора.— Очрашу качмас, судка кергән чак та булыр. Әйдәгез, алайса, ишек төзәтәбез.

— Бакшиш булмас шул,— диде Сергей,— апам пенсия акчасына гына яши.

— Алай булгач, мин сезгә бирәр кызык тамаша күрсәтәм. Эш качмас әле. Ул карчыкка ярдәм иткән чак та булыр. Хәзер Дерибас урамына менәбез. Кичә шулай бичләр белән Дерибастан Собор мәйданына таба бара идек, каршыбызга бер төркем турист килеп чыкты. Тиз генә тротуардан төштем дә пассаж каршындагы йортның түбәсенә карап каттым. Бичләр дә миңа ияреп түбәгә бактылар. Бер хатын түзмәде:

— Нәрсә бар анда? — дип сорады.

— Түбә читенә басып лунатик йөри. Япь-яшь кыз, үзе эчке күлмәктән генә,— мин әйтәм.

Хатыннар мине чолгап алдылар.

— Кая ул? Кая? Без күрмибез! — диләр.

— Әнә теге моржа каплый. Хәзер килеп чыга,— мин әйтәм.

Без бераз көтеп торган булдык та китеп бардык. Собор мәйданы яныннан әйләнеп, кире пассаж янына төшсәк, урамга җыелган халыкны милиционер куып азаплана. Халык юлга бөялеп троллейбусларны туктаткан икән.

— Бераз арттырасың шикелле,— диде Сергей,— минем бер дә андый хәлгә очраганым юк.

— Сез кызык ясый белмисез. Ансыз яшәү — күңелсез. Эш тә эш. Көне-төне эш. Сөйләшү дә эш турында, киносы-театры да. Күңелле итеп яшәп каласы килә. Әйдәгез, Лонжеронга барып кояшта кызынабыз. Кызларның иң чибәрләре шунда җыела. Ял итәргә килгән хатыннар белән танышасыгыз килсә, Аркадиягә, я булмаса Фонтанның Унынчы станциясенә алып барам. Киттекме?

— Юк, китмәдек,— диде Сергей, кырт кисеп.— Без Габдрахман белән ишек төзәтергә барабыз.

Карл Маркс урамына җиткәч, без Сергей белән унга борылып, Сабанеев күперенә таба юл тоттык. Жора кит аулау флотилиясе идарәсе алдында туктап калды.

— Жора тәҗрибәле диңгезче булса кирәк, белмәгән нәрсәсе юк,— дидем мин Гоголь урамындагы йортның баскычында җир шары күтәреп торган атлантлар яныннан узганда.

— Чын бич. Андый дингезчеләр көннәр салкынайгач пароходка утырып, берничә мәртәбә рейска барып кайталар да калган вакытларын резервта уздыралар,— диде Сергей.— Йөзү турында сөйләшергә генә ярата ул. Жора ишеләрне беләм инде мин. Ул синең белән танышты. Күңел кылыңа чиртеп, синең нәрсә ятратканлыгыңны чамалап алды. Пароходка эләгеп эшли башласаң, рейстан кайтканда ул сине каршы алачак. Одесса яңалыклары, дусларың турында бераз ләчтит сатып алгач, ресторанга чакырачак. Саран булып күренмәс өчен сыйлыйсың инде шул соры кортларны. Дингезчеләрнең традицияләре шундый. Саранлык дингезчеләрдә иң начар гадәт санала.

Сергей артына борылып карады.

— Ишек төзәтү турында Жорадан котылу өчен генә сүз кузгаттым. Одессада берниндидә апам юк минем...

— Болай булгач, кая барабыз соң?

— Белмим. Эшсез йөрү — дөньяда иң газаплы эш. Мондый чакларда мин муеныма таш бәйләп дингезгә чумарга риза. Шушы атнада суднога билгеләмәсәләр, валлаһи, авылыма кайтып китәм. Туйдырды. Түзәр хәлем калмады.

Минем дә эшсез йөргән чакларда төшенкелеккә бирелгән вакытларым була иде. Бушлык шул килеш тормый. Бушлык эченә нәрсә булса да тула. Ни эшләргә белми йөргән кеше бервакыт начар шөгыльгә юлыга.

Табигать безгә Геркулес көчен, Әбугалисина акылын биргән. Эшкә җикмәгәч, көч тә, акыл да бөре эчендә калып кипкән яфрак шикелле юкка чыга. Яшәүдә тукталыш юк. Теләк тә хәрәкәтсез булырга тиеш түгел.

— Одессаның атаклы китапханәсе бар дип ишеткән идем. Әйдә, шуны барып карыйк әле,— дидем мин.

Сергей каршы килмәде.

## 50

Китапханәдә утырган чакларымда мин үземне морадына ирешкән бәхетле бер кеше итеп сизәм. Китап — үзе бер дөнья. Эчендә фикере булган китапны укыганда син берьюлы ике дөньяда яшисең. Китап битләрендә яңа дуслар, яңа дошманнар очратасың. Фани дөнья ыгы-зыгысына кул селтәп, шул китап дөньясына кереп китә алсаң, син бәхетле кеше. Китап битендәге дусларың шатланганда син дә шатланасың, алар кайгырганда син дә кайгырасың. Хәтта начар китапны уку да файдалы. Эчтәлексез, башка китапларга имитация ясап кына язылган әсәрләрне укыганда авторның ни сәбәпле тормыш дөреслегеннән тайпылганын, ни өчен чын тормыш урынына ясалма бер схема гына биргәнлеген аңлый алсаң, вакытың бушка үтмәячәк.

— Бүген нишләптер укыйсым килми. Әллә су коенырга гына барабызмы? — дип, Сергей туктап миңа карады.

— Укыйсың килмәсә, рәсем-сурәтләр карап утырырсың.

— Китапханәдә сурәтле китаплар буламыни?

— Булмыйча, зур китапханәләрдә битләре бозау тиресеннән ясалган борынгы фолиантлар да бар. Сәнгать бүлегендә барлык музейларның каталогларын табарга була.

— Дингездә йөзгәндә мин күп укыйм. Коры җирдә чакта китап белән мавыгырга вакыт табып булмый. Дингездә сагынуны басар, юаныр өчен укыйсың, монда китапсыз да юанырга була.

— Китап уку бервакытта да зыян итми. Әдәбият кешенең тойгыларын тәрбияли, диләр. Әйбәт китап яхшыны начардан аера белергә өйрәтә ди торган иде безнең укытучыбыз.

— Тойгыларың тәмам тәрбияләнеп җитсен өчен ничә китап укырга кирәк соң?

— Бер даһи кеше утыз-кырык китап җитә дигән.

— Шулай әзмени?

— Әйе. Ләкин шул утыз-кырык китапның исемнәрен белү өчен гомер буе туктаусыз укып торырга кирәк дигән шул ук кеше.

— Элек яратып укыган китапларымның күбесен хәзер күрәсем дә килми,— диде Сергей. Мин аңа кайбер китапны унар мәртәбә укый алганлыгымны әйттем.

— Юк, мин алай булдыра алмыйм. Кабатланып торган фикернең мәгънәсе тиздән юкка чыга.

— Бер урында таптанып торуны диалектика кабул итми, шунлыктандыр,— дидем мин.

Колонналы зур йортның фасадына элгән белдерүне укыгач, эчкә кердек. Регистрациядә эшләүче кыз безгә билет язып бирде.

Китапханәнең залларын карап чыккач, Генрих Бёльнең «Хуҗасыз йорт» исемле романын сорап алдым да икенче каттагы кечкенә бүлмәгә кереп, почмактагы аулак урынга барып утырдым.

Ачык тәрәзәдән ишегалдындагы бакча күренә. Хәзер мин чын-чыннан бәхетле кеше. Каршымда — шаулап үсеп утырган каштан агачлары. Яшәвем Кельн шәһәрендә торучы бер кеше төзегән хыялый чынбарлыкта. Габдрахман атлы Караяр малаенның тыныч тормыштан качып, һавадагы торнаны тотарга йөрү дуамаллыгы да бар миндә, шул ук вакытта мин китаптагы кешеләр тормышы белән дә яшим. Әсәрдәге кешеләрнең шатлыгы мине сөендерә, аларның кайгысы минем йөрәгемне ачыттыра. Мин хәзер гаделсезлек, начарлык дошманы, хакыйкатьнең, кешелекнең дусты. Шушы тойгылар аша мин үземнең адәм баласы икәнлегемне аңлыйм. Шушы хисләрне кичерү мине кешеләр сафына бастыра.

Бу дөньяда бер ялгызым яши алмаганлыгымны аңлаган минутларда мин тизрәк дусларым янына йөгерәм. Әгәр аларны очрата алмасам, тизрәк кулыма китап алам.

Урамга чыкканда дөньяны йомшак август төне каплап өлгергән иде. Шәһәр өстендә йолдызлар җемелдәшә. Шәһәр бакчасында басынкы гына тавыш белән оркестр Штраус вальсын уйный. Зур кала ишетелеришетелмәс кенә гөжли, мондагы сигез йөз мең кеше яшәү дигән татлы газап кичерәләр. Аларга кушылып мин дә яшим.

— Китапханәдә утыру ошадымы соң? — дип сорадым мин Сергейдан, янәшә атлап бара башлагач.

— Миңа андагы кызлар ошады. Гаҗәп, ничә ел Одессада яшәп, минем андый кызлар очратканым юк иде әле. Диңгезчеләр йөргән җирдә гел тәти киенеп, сине каратырга, тизрәк кияү итәргә теләүчеләр йөри. Мондагылар бөтенләй икенче төрле.

— Монда, билгеле, интеллигентрак кешеләр йөри,— дидем мин.

— Иртәгә дә килсәк, каршымда утырган кыз белән танышам. Көне буе аның күзе миңа укырга ирек бирмәде. Китапка карасам да, күземне йомсам да, шул күзләрне генә күрәм,— дип, Сергей, дулкынланып, китапханәдә очраткан кыз турында сөйләргә тотынды.

— Ул бит кызлар белән таныша торган җир түгел. Үзеңне уңайсыз хәлгә куюың бар.

— Мин аның китапханәдән чыкканын көтеп торачакмын,— диде Сергей.

Без Диңгез буе бульварына кадәр бардык та ярга якынрак эскәмияне сайлап, тышкы рейдтагы пароходларның утларына карап, төн уртасына кадәр сөйләшеп утырдык.

Шушы көннән башлап, эштән кайткач, без Сергей белән китапханәгә йөри торган булдык.

Иртән теркәлүгә килгәч, инспектор миннән:
— Күнегеп буламы соң? — дип сорады.
— Башыңа төшкәч күнегәсең икән, — дидем мин.
Чыннан да соңгы көннәрдә пароход палубасын тутыктан чистарту эшенә күнегә башлаган идем инде. Башта бу эш искиткеч авыр тоелган иде.
— Син кичә кайда эшләдең? — диде инспектор.
Мин бераз шикләнә калдым.
— «Орел» пароходын тутыктан чистарттык, — дидем мин.
— Бүген дә шунда барасың.
Урынымнан кузгалып, ишеккә таба юнәлгән идем, инспектор мине кире туктатты:
— Ашыкма. Башта менә бу исемлеккә кул куй.
Мин шикләнә калдым:
— Нинди исемлек ул?
— Анда язылган. Бүген төштән соң сәгать дүрттә политбүлек начальнигы белән очрашу булачак. Сезнең арагыздан кемдер жалоба язган. Кем язганын белмисеңме?
— Юк, белмим.
— Беләсең, әйтәсең генә килми. Ул кешене мин барыбер фаш итәчәкмен.
Инспектор биргән кәгазьдән фамилиямне табып кул куйдым да коридорга чыктым.
Унбиш кешелек бригада җыелгач, пароход ремонтлау заводына киттек.
Безнең һәрберебезгә озын саплы чүкеч, кыргыч-рошкетка тоттырдылар. Үлчәп, һәммәбезгә тимер палуба бүлеп бирделәр. Без палубаны тутыктан чистартырга тотындык.
Кемдер егерменче еллардагы мәшһүр бер җырны башлап җибәрде:

Мы кузнецы и дух наш молод...

Сәгатьтән артык эшләп, тәмәке тартырга утыргач, соңгы көннәрдә генә эшкә чыга башлаган Җора безне үгетләргә керешге:
— Политбүлек начальнигы алдында авызыгызны йомып утырмагыз. Кадрлар бүлегендәге барлык законсыз эшләрне аңа сөйләп бирергә кирәк.
— Алай булгач, син үзең сөйлә. Син сөйләргә оста кеше, — диде Сергей.
— Сөйлим, нигә сөйләмәскә! Өченче ай резервта тоталар дип әйтәчәкмен. Кадрлар бүлегендә махинация, ришвәтчелек диячәкмен. Куреенкога кадәр бер мәртәбә дә эшсез утырганым юк иде дип әйтәчәкмен. Вот шулай.
— Очрашуга баргач күрербез әле, — диде Игорь Матвеев. — Кесә эченнән генә йодрык күрсәтергә без барыбыз да батыр. Начальство алдында без үзебезне башкачарак тотабыз.
— Җора, шулай әйтергә вөжданың җитәрме соң? — диде Сергей. — Син бит күп дигәндә елына өч айга диңгезгә чыгып керәсең. Политбүлек начальнигы бу турыда белми дип уйлыйсыңмыни?
— Ул мине белә, — диде Җора мактанып. — Моннан биш-алты ел элек ул да безнең шикелле палуба чистартып йөри иде. Мин аның нинди юл белән ул урынга күтәрелгәненә кадәр беләм.
— Һәй, лыгырдык! — Игорь тәмәке төпчеген таптап изде дә чүкеч белән суккалап тутык чистартырга кереште.
Төш житү белән безне кайтарып җибәрделәр. Тулай торакка кайтып өстебезне алыштык та Диңгез буе бульварына мендек. Диңгезчеләрнең

культура сарае атаклы Потемкин баскычы каршысындагы элекке генерал-губернатор особнягына урнашкан иде. Эчкә кергәч, очрашуның бакчадагы җәйге кинотеатрда булачагын әйттеләр.

Сәгать дүртенче яртыда ачык һавадагы кинозалның барлык эскәмияләренә резервта торучылар утырышкан иде инде.

Сәгать дүрт тулгач, сәхнә артыннан биш кеше чыгып, кызыл җәймә җәйгән өстәл артына килеп утырдылар. Залда тынычлык урнашты. Кадрлар бүлеге начальнигыннан башка җитәкчеләрнең берсе дә миңа таныш түгел иде.

— Син боларның барысын да танысыңмы? — дидем Сергейга.

— Уртада утырганы — политбүлек начальнигы Матузко, аның уң ягында — профсоюз председателе, сул ягында — Курененко, аңа янәшә—комсомол комитеты секретаре. Бишенчесенең кем икәнлеген белмим.

Сергей танымаган кеше урыныннан күтәрелеп сөйләргә кереште:

— Резервта торучы диңгезчеләр таләбе буенча, политбүлек начальнигы безнең белән очрашырга килде. Сүз кадрлар бүлеге начальнигы иптәш Курененкога бирелә.

Курененко резервта торучылар алдындагы бурычларны санап китте. Ул бүгенге көндә Кара диңгез пароходчылыгында эшләүче кадрлар алдына алтынчы бишьеллык планы нинди бурычлар куйганлыгын аңлатты.

Уңышлыклар чыннан да күп иде. Диңгез флоты көннән-көн үсә. Техника һаман камилләшә, автоматика һаман өстәлеп тора. Техник революция диңгезчеләрнең белемен күтәрүне, тәртип ныгытуны катгый рәвештә куйган инде. Курененко кәгазьгә язылган сүзен болай дип йомгаклады:

— Резервта торучыларның күбесе шушы мәсьәләне дөрес аңлап, тырышалар, укыйлар, квалификацияләрен күтәрү өстендә зур эш алып баралар. Андыйлар эштә дә үзләрен уңай яктан гына күрсәтәләр. Ләкин шушы уңай сыйфатлы диңгезчеләр арасында тырышып эшләргә, белемнәрен күтәрергә теләмәүчеләр дә юк түгел, мәсәлән...

Мисалга әләккәннәр исемлеген безнең бүлмәдәшебез Җора Багменко башлап җибәрде. Аның исеме иң беренче урында иде. Мин Җорага күз салып алдым — гадәттәге масаюы, мин-минлеге юкка чыккан иде инде.

Курененкодан соң баскомфлот председателе сөйләде. Ул бассейн комитетының диңгезчеләр интересын яклауда нинди эшләр башкарганлыгын санап чыкты: «Без һәр вакыт кадрлар бүлегенең эшен тикшереп торабыз. Ялны дөрес, вакытында бирү, эш хакын дөрес, законлы түләү, эшкә алу һәм эштән чыгаруның закон буенча эшләнүе безнең тарафтан даими контрольдә», — диде профсоюз председателе.

Комсомол секретаре сөйләп туктагач, политбүлек начальнигы урыныннан күтәрелде:

— Кадрлар белән эш итү турында күп сөйләнелде инде, минем сезнең фикерне беләсем килә. Кемнең нинди соравы бар? — Ул сөйли башлау белән залда тирән тынлык урнашкан иде. Шушы тынлыкны бозып, күрше бинада өйрәнчек пианистның гамма алган тавышы ишетелеп китте. — Бәлки кем дә булса чыгып сөйләр? Без бит резервта торучыларның сүзен ишетмәдек әле. Я, кем башлый?

Җитәкчеләр күренер алдыннан гына резервта торучыларның һәммәсе диярлек гөж килеп, кыю-кыю фикерләр әйтеп, Курененконы урыннан төшерүне дауларга хәзерләнеп утыралар иде. «Орел» пароходында эшләгәндә дә, тулай торакта чакта да сүз гел шушы очрашу турында гына барды. Ул чакта диңгезчеләрнең һәрберсе кадрлар бүлегенең начар эшләве, инспекторларның тупаслыгы, әйбәт пароходта эшләргә үзләренең танышларын гына җибәрүләре турында сөйли иде. Шул ук кешеләр, монда җыелгач, авызларын йомып тик утыралар.

Политбүлек начальнигы тагын бераз көтте дә, чыгып сөйләүче табылмагач, өстәл артында утыручыларга нәрсәдер әйтте. Алар урыннарыннан күтәрелеп, сәхнәдән төшә башладылар. Политбүлек начальнигы да аларга ияриде. Аска төшкәч, ул үзен көтеп торучы Куренeнко һәм профсоюз председателе белән саубуллашты. Алар залдан чыгып киттеләр. Политбүлек начальнигы арткы эскәмияләр янына килде:

— Син дә резервтамыни, Багменко? — диде ул Жорага.

— Шулай шул, Алексей Васильевич, — диде Жора юхаланып. — Унбиш ел эшләп, унбиш көн дә резервта утырганым юк иде. Нишлисең, шулай туры килде инде.

— Тукта әле, иптәш Багменко. Отпуска бирмиләр, арыдым, түзәр хәлем калмады дип, моннан өч ай әле кем миңа килгән иде?

— Зарланганмындыр инде, Алексей Васильевич, булгандыр. Хәзер диңгезгә чыгасым килә. Без бит өйдә чакта диңгезне сагынабыз, диңгезгә чыккач — өйне. Нишлисең бит. — Жора хәзер мескенләнеп, акыллы булып сөйләшә иде.

Якын-тирәдә утыручы диңгезчеләр көлешә башладылар. Игорь Матвеев сүз кыстырды:

— Анысы дөрес, диңгездә чакта без өйне сагынабыз, ә Жора Багменко резервны сагына. Ким дигәндә унбиш елның ун елын ул бич булып үткәргән.

Диңгезчеләр, урыннарыннан торып, политбүлек начальнигы янына җыела башладылар. Матузко папирос савытын чыгарып егетләргә сузды. Тәмәке кабызгач, мөнәсәбәт тагын да гадиләнеп китте. Тел ачылды. Әкренләп сораулар да туа башлады.

— Бүгенге көндә алты йөздән артык резерв тупланган, диләр, дөресме? — диде Одессага килгән көнне очраган күксел курткалы егет. — Без бу эшне Куренeнкодан күрәбез.

— Резервның үсүенә Куренeнко гаепле түгел, — диде политбүлек начальнигы. — Беренче кварталда без өч яңа пароход алырга тиеш идек — алдык. Икенче, өченче кварталлардагы сигез яңа пароходның берсе дә алынмады. НАТО вәкилләре Франциядә, Голландиядә, Италиядә төзелгән судноларны стратегик корал категориясенә кертеп, вето салганнар. Шунлыктан өч квартал эчендә уникe пароход алынмыйча калды. Кадрлар бүлеге шуларга билгеләнәсе диңгезчеләрне җыеп өлгергән иде. Санап карагыз: кырык бишәр кешедән дә уникe пароходка биш йөзгә якын кеше бит.

— Пароходлары булмагач, җыйган кешеләрне өметләндереп тотмаска кирәк иде аны, — диде күксел куртка кигән егет. — Диңгезченең эшсез ятуыннан ни файда?

— Әгәр быел аласы уникe пароходны ел азагына кадәр кайтартырга ниятләмәгән булсак, бу фикер дөрес булыр иде. Аларның тоннажлары алтынчы бишьеллык планына кертелеп дәүләт законына әйләнгән. Шунлыктан пароходлар ничек тә алынырга тиеш. Судо-импорт вәкилләре шул проблеманы хәл итү өстендә көне-төне эшлиләр. Нәтиҗәдә, пароходларның бер өлеше өстәмә рәвештә үзебезнең верфьләрдә төзеләчәк, калганнарын Польша, ГДР, Югославия, Финляндия бирәчәк. Ул пароходларга бүгенге резерв җитмәячәк әле. Шул чакта инде без Куренeнконы, нигә резерв хәзерләмәдең, яңа пароходларга билгелисе кешеләрең кайда? дип җилтерәтәчәкбез.

— Монысы аңлашылды, Алексей Васильевич, империализм политикасы безне резервта утырта икән, — диде Игорь Матвеев. — Минем тагын бер соравым бар. Ни өчен без тулай торакның идәнендә йоклыйбыз? Бендюжниклар заманы үтте бит инде. Безнең турыда кем дә булса кайгыртырга тиештер бит?

— Профсоюз председателе докладын бик матур итеп сөйләде, —

диде күксел курткалы диңгезче.— «Тикшерәбез, контрольдә тотабыз». Торак мәсьәләсен кем контрольдә тота икән?

Иптәш Матузко үзен төрле яктан урап алган диңгезчеләрне карап чыкты:

— Кунарга урыннары булмаган резервчылар бармы монда?

— Бар! — Дистәдән артык диңгезче, урыннарыннан кузгалып, начальник янына килделәр.

— Урыннары булмаган резервчылар иртәгә үк кадрлар бүлегеннән направление алып, «Петродворец» пароходына урнашырга тиешләр. Пароходчылык начальнигы «Петродворец»ның каюталарын вакытлыча тулай торакка әйләндерергә приказ бирде. Ул пароходны заводтан бишенче причалга күчерделәр.

Диңгезчеләр өчен Аркадиядә салына башлаган йортны күргәнегез бармы? Анда ике кешелек иркен бүлмәләр, һәр номерда душ, санблок. Этаж саен салон, кухня. Һәр бүлмәдә телевизор, радио. Тулай торакның спортзалы, кинотеатры, библиотекасы булачак. Аңа тотыласы фондны резервта торучыларга түләргә мәҗбүр булмасак, торак комплексы күптән салынып беткән була иде. Сезнең идәндә кунып йөрүегезнең дә сәбәбе — шул ук аласы пароходларга вето салудан. — Шулай дигәч, политбүлек начальнигы елмаеп куйды.— Без «Эшләмәгән кеше ашамый» дигән лозунг нигезендә яшибез. Ә диңгезчеләрнең резервта торучылары да тук булырга тиеш. Шунлыктан торак төзү өчен тотасы акчаны резервта торучыларга түләргә туры килде.

Политбүлек начальнигы тагын берничә сорауга җавап бирде. Үзе дә сораштырды. Пароходчылыктагы яңалыклар турында сөйләде.

Әңгәмә төн уртасына кадәр барды. Без пароходчылык алдында нинди йөкләмәләр торганлыгын белдек, аның киләчәге белән таныштык.

Тулай торакка кайткач, мин тагын бер мәртәбә очрашу хатирәләрен күз алдымнан үткәрдем.

Политбүлек начальнигының шушы катлаулы мәсьәләләрне гади генә итеп аңлатуы миңа ошый иде. Аның диңгезчеләр психологиясен тирән аңлавы да сокланырлык иде. Өстәл артында утырып сөйләшкәндә биргән сораулар җавапсыз калачагын ул тиз аңлады. Безнең янга төшеп аралашкач, әңгәмә үзеннән-үзе башланып китте.

Диңгезчеләр үзләренең катлаулы сорауларына җавап алып канәгатьләнделәр. Политбүлек начальнигы диңгезчеләрнең кәефләрен, теләкләрен белә алды.

Шушы көннән соң резерв тоту турындагы шомлы фикерләр акренләп юкка чыкты. Гайбәткә урын калмады.

## 52

Акча бирәсе көнне эштән иртәрәк җибәрделәр. Сергей чират алу өчен туры кассага китте. Без Игорь белән тулай торакка кайтып юындык, өстебезне алыштырдык.

Соңгы көннәрдә Жора тулай торакка кайтмый башлаган иде.

— «Комендант» кайтмый башлагач, бүлмәбез тынычланып китте,— дидем мин Игорьга.

— Хәзер туйганчы сөйләшергә була. Ул барында гел аның сөйләгәнен генә тыңлап утырырга туры килә иде.

— Ул чыннан да шулай тәҗрибәле диңгезчеме соң?

— Диңгездә йөзмәгән кешеләр алдында тәҗрибәле. Ул күбрәк кешедән ишеткәнне сөйли. Очрашуда әйттеләр бит: Жора күп вакытын резервта чуалып үткәрә, дип.

Касса янына кеше күп җыелган иде. Сәгатьтән артык чират торганнан соң без акча алдык.

— Кесәмә акча керсә, җаным кыбырсый башлый, — диде Игорь. —

Дөньяда булган бар нәрсәне берьюлы сатып аласым килә. Акчамны тотып бетергәнче тынычлана алмыйм.

— Мин, киресенчә, акча юк чакта борчылам. Кесәм буш булса, кеше арасында кимсенәм мин. Акча таба белү үзенә күрә егетлек санала бит ул, — диде Сергей.

— Әйдәгез, ресторанга кереп чыгабыз. Күптәннән юньле аш ашаган юк. Киттекме, егетләр? — дип, Игорь безне култыклап Диңгез буе бульварына таба алып китте.

— Анда кергәндә генә «юньле аш ашыйсым килә» дигән булып хәйләлисең. Кергәч, ашавы онытыла, — диде Сергей. — Минем быел җимеш ашаганым юк. Привозга барып җиләк-җимеш алып кайтыйк әле. Бу юлы акчаны киләсе получкага кадәр житкерәсе иде.

— Син, Сергей, саран хатыннар шикелле кыланасың. Әллә акча җыеп йорт алырга уйладыңмы? — диде Игорь.

— Шул Привоз турында ничә мәртәбә ишеттем, үземнең әле аны барып күргәнем юк, — дидем мин, Сергейның тәкъдименә кушылып.

— Базар ябылыр алдыннан әйбернең хакы төшә. Барсак, хәзер китәргә кирәк, — диде Сергей.

— Сез, егетләр, мине авантюрага өндисез, — диде Игорь. — Ашамлык ташуның мәшәкате турында уйладыгызмы соң? Сатып алган нәрсәне күтәреп йөрүе генә дә мең мәшәкать. Алып кайткач, савыт-саба табып, юарга кирәк. Ресторанга керден — мәшәкатьсез-нисез генә ашап чыктың. Ярый инде, икегез дә теләгәч, мин каршы килә алмыйм.

— Ул мәшәкатьләрне үз өстемә алам, — диде Сергей. — Киттекме?

Вокзал яныннан ук Привозның балык сата торган урыны күзгә ташланды. Тротуарга тезеп куйган кәрзиннәрдә яңа тоткан балыклар ялтырап ята иде. Кипмәсен өчен сатучы хатыннар балыкларына су сибеп торалар:

— Скумбрия! Яңа гына диңгездән чыккан симез, тәмле скумбрия!.. Гражданка, алмыйсыңмыни?

— Шушы Привозга килсәм, тарихтагы НЭП чоры искә төшә, — диде Игорь. — Сата беләләр, шайтаннар. Товарларын ничек мактыйлар!..

Балык рәтеннән соң кош-корт сата торган прилавкалар башланды. Канатлары бәйләнгән тавыклар, куркудан миңгерәүләнеп, кешеләргә күзләрен яртылаш ачып карап яталар.

Бизәкле эшләпә кигән чибәр генә бер хатын тавыкның койрык астына өреп, аның симезлеген тикшерде:

— Бу көзге чебеш күпме тора?

— Кая өрәсең, син менә монда өр!..— диде тавык хуҗасы, кызып китеп. — Чебеш дигән була! Ат хәтле тавыкны чебеш дип мыскыл итә бит!..

Базар кайный, гөж килә. Җылы якка очар алдыннан сыерчыклар көтүе шулай гөжли. Товар хуҗасына сатыласы нәрсә кыйммәт күренә. Сатып алучыга, киресенчә, түләнәсе акча зур, аласы әйбер кечкенә кебек тоела. Сатучы белән сатып алучының урыннарын алыштырып куйсаң, сатулашу ничек барыр иде икән?

Яңгыравыклы сүз, эч бушаганчы әрләшү, көлү тавышлары базар өстендә туктаусыз яңгырап тора. Монда кайнашып йөрүчеләрнең күбесе сату-алудан бигрәк тамаша карарга килгәннәр.

Гәрәбә төсе керә башлаган виноградын прилавкага өйгәч, төреккә охшашлы бер молдаван кырпу бүреген салып куенына тыкты да капчыгыннан кепка алып киде.

— Сергей, күрдеңме? Ул нигә алай эшләде?

— Кепка кисәм, тизрәк сатып бетерермен дип уйлый торгандыр, — диде Сергей.

Игорь әлеге молдаванның баш киемен алыштыруын башкача аңлатты:

— Юк, ул, кырпу бүрек киеп сатсам, молдаван иканлегемне белерләр дә озак сатулашырлар, дип курка.

— Чибәр егет, менә бу помидорларга күз сал әле: сөйгән кызың да сиңа болай елмаеп карамый торгандыр,— дип, помидор сатучы хатын прилавка яныннан узучыларны үгетли иде.

— «Кызлар бармагы»! «Кызлар бармагы!» Тышы әчкелтем-төчкелтем, эче шыр бал! «Кызлар бармагы!» «Кызлар бармагы» винограды.

Километрдан артыкка сузылган такта прилавкаларда помидор, йөзем җимешләре, кыяр-кавын, алма, шәмәхә тамчыга охшашлы бадымҗаннар, миңа таныш булмаган әллә нинди ят җимешләр тау-тау өелеп яталар.

Белмим, нилектәндер, ул елларны яшелчә-җимеш Одесса базарында гаҗәп арзан иде. Базар ябылыр алдыннан сатылып бетмичә калган җимешләр тагын да арзанлана төшә иде.

Хуҗалар җимешләрен никадәр кыйммәт сатарга тырышсалар да, күңелләренә охшаган кешеләргә арзанрак та бирәләр иде. Без бу кагыйдәне бик тиз аңлап алдык.

Базар ябыла башлаганчы сатучылар белән сатып алучылар арасындагы әңгәмәне тыңлап, кино караган шикелле күзәтеп йөрдек тә җиңнәренә кызыл бәйләгән кешеләр товарларны җыярга өнди башлау белән «җәтмә»гә яшелчә-җимеш тутырырга тотындык.

Сатулашу урынына шаян сүзләр әйткән булып, сатучының күңелен йомшартырга тырышабыз. Сатучының йөзе ачылып китү белән җимешнең хакы да төшә. Йомшак мөгамәлә акчадан кыйммәтрәк тора бит ул. Сатучылар безгә җимешнең әйбәтләрен генә сайлап бирәләр...

Без троллейбуска утырып тулай торакка кайтып киттек.

Дусларым җимешләрне юып калдылар. Мин икмәк магазинына барып кайнар шишаралар сатып алдым.

Игорь җимешне кайнар булка белән ашарга тотынды.

— Патшалар ашы, Сергей, ашап кара әле.

— Син бит виноград үсә торган җирдә яшәмәгәнсең, моның серен каян беләсең? — диде Игорь.

— Фирма сере, — дидем мин көлеп.

Йөзем җимешенең кайнар шишара белән ашалуын мин Рабленың «Гаргантюа белән Пантагрюэль» дигән китабыннан укып белгән идем.

Игорь, урыныннан торып, эчен сыпырып карады:

— Артыграк та тутырдык булса кирәк. Бераз селеккәләп басылдырасы иде. Әллә танцыга барып кайтабызмы?

— Мин кая барырга да риза, — диде Сергей. — Тамак туйгач, күңел ачасы килә башлады.

— Танцыга да барырга була. Опера театрына баруга сез ничек карыйсыз? — дидем мин.

Игорьның чырае сытылды:

— Опера? Син шаярып әйтмәгәнсеңдер бит? Ул опера дигән нәрсәне аңламыйм мин. Анда нигәдер җырлап сөйләшәләр. Әллә ничек ясалма чыга. Бер кызны әллә ничә мәртәбә опера карарга алып бардым. Барам да, музыка белгечләренә охшарга тырышып, күземне йомып утырам. Күземне ачып җибәргәндә опера беткән була.

— Операны карамыйлар, тыңлыйлар, — диде Сергей, — ул кыз сиңа шуны әйтмәдемени?

— Атаклы опера театры янында яшәп, аның программасы белән танышмау әллә ничегрәк була бит инде, — дидем мин.

— Минем анда барасым килми, — диде Игорь. Сергей да аңа кушылды. Минем алардан аерыласым килмәде.

Без тиз генә чалбар-күлмәкләрне үтүкләп кидек тә Шевченко паркына танцыга киттек.

Мин теркәлергә кергәндә инспектор диңгезчеләр формасы кигән бер кеше белән сөйләшеп утыра иде. Җиңендәге тасмаларын санагач, бу кешенең капитан икәнлеген чамалап алдым.

Кеше сөйләшкәндә бүлмә уртасында басып тору ничектер уңайсыз иде. Берничә мәртәбә тамак кырып караганнан соң стена буендагы урындыкка барып утырдым.

— Радиограмманы мин дүшәмбедә бирдем. Дүрт көн эчендә ике матрос әзерләп була торгандыр бит? — Капитан, канәгатьсезлеген сиздермәскә тырышып, юри басынкы тавыш белән сөйләшә иде.

— Эш анда түгел, Василий Степанович, матрослар бар. Эш башкада. Сезнең партоешманы ныгыту өчен партияле кеше җибәрү турында сөйләшенгән иде. Оешмагызда бер генә рядовой коммунист та юк. Оешма чыгарган карарда эшчеләр сыйныфының тавышы булырга тиеш-тер бит, аңлашыламы?

Капитан сәгатенә карап алды:

— Диңгезгә чыгарга ике сәгать вакыт калды. Алай булгач, андый боерык биргән кешегә әйтегез. Бәлки ул үзе килеп швартовка бауларын сөйрәргә булышыр. Көзге штормнар башланырга да күп калмады. Диңгез инспекциясенә рапорт язып илтсәм, пароходны диңгезгә чыгармаячаклар.

— Шул штат белән эшләргә тырышыгыз инде, Василий Степанович. Киләсе кайтуыгызга мин обязательно әзерләп куярмын, — диде инспектор юхаланып.

— Узган китүдә дүрт ай ярым Одессага керелмәде. Тагын шулай йөзсәк, яңа елга кадәр матроссыз эшләргә туры киләчәк.

Мондый әңгәмә вакытында сүзгә катнашырга ярамаганлыкны белә идем, шулай да түзмәдем:

— Рөхсәт итсәгез, мин барыр идем, иптәш инспектор. Резервта утыруыма киләсе дүшәмбедә ай тула, — дидем.

Капитан тиз генә миңа күз төшереп алды. Мин никадәр тырышып капитанның күзләренә карап торсам да, аның миңа нинди бәя биргәнлеген чамалый алмадым.

— Миңа ни, риза булсагыз, мин Рахманкуловны билгели алам. Бары тик политотделдан рөхсәт алырга кирәк. Аннан рөхсәт алмыйча партиясез кешене җибәрә алмыйм мин, — дип, Зеленовский телефон трубкасын алып, номер җыйды: — Зеленовский сәламли сезне, иптәш Горюнов! Иван Михайлович, «Чолман» пароходына матрос итеп бер комсомолецны җибәрергә ярыймы? Әйе, резервта. Стажы? Зеленовский өстәл тартмасыннан минем карточканы алып укып чыкты. — Стажсыз. Диңгезгә беренче мәртәбә чыгуы. Офицер. Авиациядә хезмәт иткән. Тәмамланмаган югары белем. Читтән торып диңгез училищесында укый. Әйе, әйе, так. Болай ничего күренә. Булды, алайса, булды. Добро. Есть! Шулай эшләрмен, Иван Михайлович.

Инспектор, телефон трубкасын куйгач, зур бер эш башкарган кеше сыман, җиңе белән маңгаен сыпырып алды:

— Сез, иптәш капитан, тавыш куптарып йөрмәгез. Булды. Мин сезгә менә дигән матрос бирдем. Политбүлектән комсорг итеп сайларлык булсын, диделәр. Мин нәкъ шундыйны таптым.

Капитан инспекторның сүзләренә әһәмият бирмәде. Ул мине кабат тикшерергә кереште:

— Синең, егет, диңгез тозын татып караганың бармы соң? Нишләптер кыяфәтең диңгезченекенә охшамаган.

Шул вакыт инспектор ярдәмгә ашыкты:

— Булды, Василий Степанович. Мин сезне канәгатьләндердем. Эшли башлагач, шушы егетне биргән өчен рәхмәт әйтерсез әле. Почти югары

белемле,офицер, заочник. Үзенә карап кына торырлык. Армия тәрбиясе алган егет, тәртип бозмас. Булды.

Инспекторның сүзләре эчемне ачыттырып җибәрде. Аның сөйләшүе сатасы атын мактаган маклерны хәтерләтә иде.

— Туктагыз әле, — диде капитан, инспекторга таба борылып. — Минем ризалыкны сорау кирәк түгел идеме икән? Уставта: «Команданы капитан лично үзе сайлап җыя», дип әйтелгән бит. Матрослыкка читтән торып уку да, офицер булу да кирәк түгел. Миңа штурвал тота, палуба юа белгән гади генә бер диңгезче кирәк. Егетнең хәтерен калдырасым килми, шулай да кисәтеп куям: чайкала башлау белән сузылып ятса, мин аны сезгә кире кайтарам.

— Теләмәсәгез алмагыз, Василий Степанович, политотдел билгеләргә кушты. Алай булгач, политотдел каршында үзегез җавап бирерсез. — Шулай дигәч, инспектор өстәлдәге кәгазьләрне актарырга кереште.

— Без җавап бирергә өйрәнгән кешеләр. Әле узган айны гына сез таккан эчкече кочегар траптан егылып кулын сындыргач, профсоюз каршында җавап бирдем. Ярый. Пока! — Капитан фуражкасын киде. Горур атлап ишектән чыгып китте.

Инспектор, бу кеше кире әйләнеп кермәсме дигәндәй, бер тын ишеккә карап торды да мине тиргәргә тотынды:

— Үз колагың белән ишеттең, Рахманкулов. Мин сине закон бозып кына тага алдым. Сезнең шикелле экзотика эзләп йөрүче романтикларны яратмыйлар монда. Бер капитанның да коры җир кешесе белән диңгезгә чыгасы килми. Айга якын резервта утырдым дисең, монда бишәр ай утырган матрослар да бар, — дигәч, инспектор миңа пароходка билгеләнү приказын сузды. — Начальникка кереп кул куйдырткач, секретарьдан печать бастыр. Беренче копия миндә кала, калганнарын пароходка баргач бирерсең.

Приказ кәгазенә «Рахманкулов Габдрахман «Чолман» пароходына икенче классны матрос итеп билгеләнә» дип язылган иде. Бүлек начальнигы кул кую белән, юридик яктан мин диңгезчегә әйләндем. Ләкин чын диңгезче булу өчен бик күп эшлисе, бик күп сынаулар узасы бар икән әле.

Пароходка эләккәнче нинди авырлыклар аша үтәчәгемне белгән булсам, мин бәлки соңгы сынавымны тапшырып, туры авылыма кайтып киткән булыр идем. Кем белгән, бәлки киресенчәдер...

## 54

Порт краны пароход трюмыннан ташкүмер бушата. Кран трюм төбенә төшеп бәрелүгә пароход калтыранып китә.

Мин грейферның күмер өеменә таба узып киткәнен көтеп тордым да бушатыла торган трюм яныннан узып, трапка мендем. Трап саклаучы матрос палубада швартов бауларын ныгытып йөри иде. Мине беркем дә туктатмады, нинди эш белән килүемне дә сораучы булмады.

Бераз көтеп торганнан соң коридорга кердем. Каршы яктан япь-яшь бер диңгезче малай килә иде. Якынлашкач, туктатып сорадым:

— Мине шушы пароходка билгеләделәр. Кадрлар бүлеге биргән кәгазьне кемгә тапшырырга?

— Кем булып эшлисең?

— Матрослыкка билгеләделәр.

— Матрослар приказны чифка[1] тапшыралар. Тартырга бармы?

— Юк, мин тартмыйм.

— Кара әле, кореш, әллә кызлар да сөймисеңме?

---

[1] Чиф (инглиз.) — капитанның өлкән ярдәмчесе.

— Кызлар да сөймим.
— Алайса, монда ялгыш элэккэнсең. Тэмэке тартмый, кызлар сөйми торган егетлэрне Херсонга текстиль комбинатына озаталар. Анда гел яшь кызлар гына эшли. — Егетнең шаяруы үзенэ ошады булса кирэк, ул рэхэтлэнеп көлде.
— Ул «чиф» дигэн кешене ничек табарга соң? — дип сорадым мин.
— «Чиф» дигэн кешенең фамилиясе — Бригас. Аның каютасы спардекта[1].— Егет коридордагы тимер ишекне ачып эчкэ керде. Ачык ишектэн машина гөжлэгэн тавыш ишетелеп калды.
Бераз аптырап торганнан соң, коридор буйлап алга таба киттем.
Әле яңа гына ишеткэн ике ят сүз мине тынгысызлый иде. Мин үземне чит телдэ сөйлэшүчелэр арасына элэккэн кеше шикелле сизэ башладым.
«Спардек» та яшэгэн ул «чиф» дигэннэре эллэ нинди гаҗэп бер кеше булып күз алдыма килэ иде.
Уратып йөртэ торгач, коридор кире таныш ишек янына китереп чыгарды. Мин, «спардек»ны табудан өметемне өзеп, ишек янагына сөялдем.
Кран эшлэүдэн туктады. Пароходта тынлык урнашты. Шушы тынлыкта кайдадыр пошкырып пар чыккан тавыш ишетелеп китэ. Стена аша кычкырып сөйлэшкэн тавышлар яңгырап куя. Сөйлэшүчелэрнең үзлэре күренми. Ят урын, күнегелмэгэн хэл күңелгэ шом салды. Аяк тавышы ишетелү белэн тизрэк тышкы якка чыктым.
Траптан менеп килгэн бер егет мине күреп алды:
— Әй, кореш, ни эшлэп йөрисең монда?
— Шушы пароходта эшлэргэ килдем.
— Нинди эшкэ? Матрослыкка түгелдер бит?
— Әйе, матрослыкка.
— Кореш, нигэ моңа кадэр эйтми тордың? Мин сине кичэдэн бирле көтэм. Әйдэ, өлкэн штурманга приказыңны тапшыр да минем урынга вахтага бас.
Матросның белэгенэ бэйлэнгэн кызыл чүпрэккэ карап, мин аның вахтада икэнлеген аңлаган идем инде. Армиядэ дежур торганда да нэкъ шушындый киң кызыл тасма тагалар иде.
Матрос бу хэлгэ бик сөенде, сөйлэнүендэ дэвам итте:
— Бик вакытлы килдең, дус кеше. Урыныма кеше җибэрмэсэлэр, чемоданымны күтэреп, рөхсэтсез китэргэ җыена идем.
Без коридор очындагы траптан өскэ күтэрелдек тэ, сулга борылып, ачык ишек янына килеп туктадык. Матрос муенын сузып каюта эченэ карады:
— Карл Янович, миңа алмашка кеше килде. Сез миңа, зинһар, расчет эзерлэгез.
Карл Янович каюта түрендэге өстэл артында кэгазь актарып утыра иде. Мине күргэч, кэгазьлэрен җиздэн ясаган кара савыты белэн бастырып куйды да матроска эйтте:
— Вахтадан алышынгач хэл итэрбез. Бу егетне сезгэ алмашка килгэн дип юкка өметлэнмэгез. Штат буенча безгэ ике матрос җитми.
— Чиф, сез минем хэлне белэсез, зинһар җибэрегез инде.
Өлкэн штурман матрос белэн сүз беткэнлеген белгертеп, миңа стена буендагы кэнэфигэ утырырга ымлады:
— Утырыгыз.Хэзер эшемне бетерэм. Кэгазьлэремне укып чыккач, ул телефон трубкасын алып, кемгэдер шалтыратты:
— Василий Степанович, теге сез эйткэн «кадр» килде. Сөйлэшэсезме? Әйе. Мин аңа бернэрсэ дэ эйтмэдем эле.
Капитанның каютасы без утырган җиргэ якын иде булса кирэк. Ул эйткэн сүзлэр коридор аша ишетелеп торды.

[1] **Спардек** — өстэн санаганда өченче палуба.

Өлкән штурман трубкасын куюга, капитан килеп тә керде.

— Килдеңмени, лачын? Пароход ошадымы соң?

— Бик ошады, — дидем мин ашыгып. — Мин шушындый зур океан пароходында эшләү турында күптән хыяллана идем.

Өлкән штурман капитанга карап күз кысты:

— Рахманкулов океан пароходында эшләргә килгән. Пароходның Гданьскидагы верфьтән чыккач, Кара диңгезгә килгәндә нибары бер мәртәбә генә океан белән очрашканын әйтсәк, егетнең күңеле сүрелмәсме икән, ә? Иптәш Рахманкулов, син бер генә минутка коридорга чыгып тор әле, яме.

Минем артымнан ишек иңләп ябылды. Зарыктыргыч көтү минутлары йөрәк аша үткәрелгән озын җеп шикелле сузылдылар: менә, тәмам урнашып җиттем дип кенә торганда, тагын ниндидер киңәшү, хәл итү кирәк булды...

Ниһаять, ак ишек ачылып китте:

— Керегез, Рахманкулов. Утырыгыз. — Бала чакта әбием сөйләгән Нәнкир-Мөнкирләр менә шушындый була торгандыр инде дип уйлап алдым.

— Сезнең матрос булып эшләп караганыгыз юк идеме? — диде сорау алучыларның беренчесе. Мин аның сүзен раслап баш кактым.

— Тәҗрибәсез килеш, пароход белән танышмыйча матрос булып эшләве бик җаваплы эш ул, иптәш Рахманкулов. Риза булсагыз, дневальныйлыкка билгели алабыз. Көчләп түгел, үзегез теләсәгез генә, — диде икенче сөальчы.

«Дневальный» сүзе миңа таныш иде. Хәрби хезмәттә дежур торучыны дневальный дип атыйлар. Әйтелүгә караганда, пароходтагы дневальныйның вазифасы башкачарак иде булса кирәк. Диңгез эшен белмәгәнлегемне күрсәтмәс өчен, дневальныйның нинди эш башкаруы турында сорашмаска булдым. Минем дневальный булып та эшләгәнем юк иде. Шуңа карамастан, алар, булдыра алуымнан шикләнмичә, турыдан-туры бу эшне миңа тапшырмакчы булалар. Бу вазифаның матрослыктан түбән икәнлеген мин баштан ук аңлап алган идем.

Риза булмыйча, матрослыкны дауларга хакым барлыгын аңласам да:

— Мине матрос итеп җибәрделәр бит. Башка эшкә билгеләү дөрес булырмы соң? — дидем.

— Белмим шул. Синең булдыра алуыңа ышанып, кулыңа штурвал тоттыру дөрес булырмы икән? Йөзүчелекне мин гальюн тазартучы булып эшләүдән башлаган идем. Эшли торгач, менә капитанлыкка кадәр күтәрелдем. Кулыннан эш килгән тырыш егет гомер буе дневальныйлыкта тормас. Әйдә, чиф, бу риза, приказ яз, — диде капитан һәм чыгып китәр алдыннан болай дип өстәде: — Аврал белдерергә вакыт. Йөк документларына кул куйгач, кузгалабыз.

— Аңлатып торырга вакыт калмады. Койкагыз дүрт урынлы кубрикта. Нәрсә эшләргә кирәклеген дневальный егет Стовбуненко сөйләр. Ашханә җиһазларын барлап акт төзегәч, миңа доложить итәрсез. — Шулай дигәч, өлкән штурман фуражкасын киде дә коридорга чыгып китте. Мин кая барырга да белмичә туктап калдым.

— Барсуков, трапны җый! — Минем янымнан ашыгып капитан үтеп китте. Якында шыгырдап ишек ачылып ябылды. Кемдер миңа эндәште:

— Ни эшләп йөрисең монда, студиозус?

Артыма борылып карасам, шатлыгымнан кычкырып җибәрдем:

— Феликс, син мондамыни? Кайчан килдең? Син Мәскәүдә калган идең бит. Ничек ычкына алдың? Шушы пароходта эшлисеңмени?

— Юк, монда эшләмим. Шушы судно белән бер сериядәге пароходта эшлим. Монда үземнең коллегам — өченче штурман янына килгән идем.

— Мине шушы пароходка дневальный итеп билгеләделәр, — дидем мин шатланып.

— Дневальный итеп? Дневальныйның нинди эш эшләгәнен беләсеңме соң? — Феликс сәер генә елмаеп куйды.

— Белеп өлгермәдем әле. Берәр төрле дежур тору булса кирәк.

— Дневальный, дустым, табак-савыт юып, матросларга аш биреп тора. Көн саен иртән комсоставның каютасын җыештыра. Кстати, минем каютамны да дневальный җыештыра. Безнең пароходта ул эшне бер яшь кыз эшли. Билгеләүгә үзең риза булдыңмы?

— Үзем.

— Риза булмаска кирәк иде. Ни әйтсәң дә, син запастагы офицер, университетта укыган кеше. Өстәвенә, бу пароходка, штрафнойга озаткан шикелле, гаебе булган диңгезчеләрне генә билгелиләр. «Чолман»— безнең пароход белән бер линиядә, күмер-руда ташый. Эш авыр, акча төшми. Син ялгышкансың, дус кеше.

Феликсның һәр сүзе ыргытылган таш шикелле минем пыяла җепләрдән тукылган хыялымны челпәрәмә китереп, ватып тора иде.

— Мәскәүдә чакта диңгездә йөзү эшен башкачарак тасвирлаган идең бит. Нигә хурлыйсың? Үзең нигә ирекле көннән штрафнойга керден?

— Минем башка мөмкинлегем юк иде. Укырга китәр алдыннан мин бераз характеристикамны бозган идем. Эшкә алганда кисәттеләр: «Күмер-руда линиясендә эшләп, характеристикаңны төзәтә алсаң гына оформлять итәбез. Башкача чит илгә йөри торган пароходка эләгермен дип өметләнмә», диделәр. Ярый, мин ашыгам. Очрашкач, иркенләп сөйләшербез әле, — дип, Феликс күтәрелә башлаган траптан йөгереп төшеп китте.

Мин сукыр кеше шикелле кая барырга белмичә, кармаланып йөри торгач, койрыктагы дүрт урынлы каютаны эзләп таптым.

Каютада чигәләрен бала йоны баскан үсмер бер малай эшкә кия торган чалбарына сәдәп тагып утыра иде. Мин ишектән керүгә, ул энәсендәге җебен тешләп өзде дә ашыгып киенә башлады.

— Стовбуненко дигән кешенең кайда икәнлеген белмисезме?

— Стовбуненко мин булам. Авралга чакырырга килдеңмени? Хәзер чыгам. Чалбарымның сәдәбе өзелде.

— Мине сезнең урыныгызга билгеләделәр, — дидем мин. Бу егетнең әле яңа гына парта арасыннан чыгып, монда эшли башлаганлыгын сизгәч, дневальный вазифасының ниндирәк икәнлеге миңа тагын да ачыклана төште.

— Мин ашыгам. Авралдан соң сөйләшербез, — дип, егет кабаланып чыгып китте.

Мин дә палубага чыктым.

Вахтада торучы матрос трапны күтәреп бетергән иде инде. Трап палуба белән тигезләнгәч, матрос аны пароходның бортына беркетеп бәйләде дә йөгереп өске палубага менеп китте.

Башка матрослар трюм капкачларын су кермәслек итеп ныгытып яптылар. Йөк күтәрү укларын урыннарына беркеттеләр. Шуннан соң гына алар ике төркемгә бүленеп, пароходның борынына һәм койрыгына таба юнәлделәр.

Алар киткәч, бер өлкәнрәк кеше матрослар башкарган эшне тикшереп узды. Эшнең җиренә җиткерелеп эшләнүенә ышангач, ул, әре-әре атлап, якорь күтәрә торган чыгыр янына барып басты.

Юлга чыгар алдыннан эти, мәрхүм, арба көпчәкләрен, күчәрне, тимер кендекне, ат сбруен шушылай дикъкать белән җентекләп тикшереп чыга иде. Безне һавага озатыр алдыннан Рәдиф Агишев та самолетның һәр детален нәкъ шушы өлкән диңгезче шикелле итеп карый иде. Димәк, диңгез эшендә дә җаваплылык беренче урында.

Капитан күперчекнең сулъяк канатына чыгып, пароходны тотып торган бауларга күз салды. Читтәрәк туктаган буксирга пароход янына килергә боерды. Өлкән штурман рубка ишегеннән башын тыгып капитанга нәрсәдер әйтте. Капитан команда бирде:

— Отдать кормовые!

Команда тавышы мачтадагы репродуктордан чәчрәп чыгып, тирәякка таралды.

Шушы команданы көтеп торучы швартовщиклар швартов бауларының элмәкләрен пушкалардан ычкындыра башладылар. Матрослар аларны палубага сөйрәп алып җыярга тотындылар.

Озын трубалы шөкәтсез буксир безнең пароходтан биргән арканны эләктереп алды да, көчәнеп, койрыкны акваториягә [1] таба сөйрәргә тотынды.

Пароход авыр йөк тарткан ат шикелле калтырана. Трубадан ургылып-ургылып кара төтен чыга.

Дөбер-шатыр килеп чыгыр эшли башлады. Якорь чылбыры бөгеләсыгыла палубага шуышып менә дә чылбыр тартмасына чумып югала. Ниһаять, ләмгә баткан зур ике тырнаклы якорь да өскә күтәрелде.

Акваториягә чыккач, пароход ашыкмыйча гына маякка таба борылды да ачык диңгез ягына бара башлады.

Маяк пароход яныннан узды. Порттан чыктык. Пароход курска ятты.

— Полный ход! Якоря по походному! Конец аврала!

Команда тавышы тышкы рейдта йоклап яткан зур океан корабларын йокыдан уятты. Аларның күперчекләрендә вахтада торучы диңгезчеләр безгә таба бинокльләрен төзәделәр.

Башта шул пароходлар күздән югалды. Аннан соң порт краннары офык артында калды. Соргылт йортлар арасында яшел атау булып күренгән бакчалар әкренләп тоныклана-тоныклана юкка чыктылар.

Яр сызыгы офык эченә кереп эрегәч, безне озата чыккан акчарлаклар җиргә таба очып киттеләр.

Мин шлюпка палубасына мендем. Корылма ышыгындагы ком ящигы өстенә барып утырдым.

Әйләнә-тирәдә очсыз-кырыйсыз су, кояш һәм зәңгәр күк. Тирә-якта бер генә нокта да, бер генә җан иясе дә күренми. Үткән гомер, узган вакыйгалар да офык артында калган җир шикелле каядыр китеп югалдылар. Хәзер алар турында уйлау күңелдә ямансулык кына уята иде.

Туган авылымны, туганнарымны сагыну тойгысы кинәт йөрәгемне ачыттырып алды.

— Әй, дневальный, нишләп утырасың монда? — Каршымда кулына бер уч яшел үлән тотып капитан басып тора иде.

— Диңгезнең матурлыгына сокланам.

— Безнең штатта Чайльд-Гарольд [1] юк. Кичке аш вакыты җитте. Матросларны ашатырга кирәк. Тизрәк өстәл әзерлә. Тырыш, егет, сынатма!..

Мин, урынымнан торып, ашханәгә йөгердем.

Мәскәү,
1969—1973 еллар.

*Беренче китап тәмам*

[1] Акватория — порт эчендәге ачык су.
[1] Чайльд-Гарольд — Байрон поэмасының герое.

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

## АВГУСТ, 1973 ЕЛ

«Күптән түгел генә җәйге җылы кичләрнең берсендә безнең әдипләрнең А. А. Фадеев исемендәге Үзәк йорты үзенә күрә төзелеш штабына әверелде. Кече зал стеналарына төрле сызымнар, схемалар, графиклар эленгән иде, ә сәхнәдә — завод корпуслары һәм торак йортлар макетлары. Төзүчеләр, инженерлар, партия хезмәткәрләре башкала язучылары белән очрашуда КПССның XXIV съезды Директиваларын ничек гамәлгә ашырулары, Татарстан АССРда йөк автомобильләре заводлары комплексын төзүнең барышы турында сөйләделәр.

Ватаныбыздагы гигант төзелешләрнең, планетабызныкы кебек үк, көчле магнит кырлары бар. Ул төзелешләр кешеләрнең тынычлыгын югалталар, аларны үзләренә тарталар. Бер язучы әйткәнчә, КамАЗ пространство һәм вакыт төшенчәсенә төзәтмә кертте, яшь йөрәкләрне буйсындырды. Һәм менә анда әдипләр бригадасын җибәрергә, алар белән бергә Чаллыга бүләк итеп китапханә җибәрергә хәл ителде».

«Литературная газета». Мәскәү.

«Йорт төзү комбинатының СМУ-61 дән Рәис Сәлахов бригадасы членнары Чаллы шәһәрен төзүдә үз-үзләрен аямый эшлиләр. Бригаданың девизы: «Һәр көнне, һәр атнада, һәр айда заданиене арттырып үтәргә!» Кама буендагы каланың меңнәрчә төзүчеләре бу инициативаны күтәреп алдылар. Р. Сәлахов бригадасы һәр айда планны 162 процентка арттырып үти».

«Советская Россия». Мәскәү.

«Советская культура» газетасының КамАЗдагы эшче-хәбәрчеләр посты хәбәр итә:

Чаллы шәһәрендә татар халкының традицион бәйрәме — сабан туе булды. Ул КамАЗ төзүче ударниклар парады белән ачылды. Ә аннары еракларга җәелгән болыннарда җыр яңгырады: «Камгэсэнергострой, автозавод, шәһәр учреждениеләре һәм предприятиеләре каршындагы үзешчән сәнгать коллективларының берләштерелгән мең кешелек хоры совет композиторларының җырларын башкардылар. Сабан туенда Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Габдулла Тукай премиясе лауреаты Әнвәр Бакировның КамАЗ төзүчеләргә бүләк иткән җыры беренче тапкыр башкарылды.

Гадәттәгечә сабан туенда ат чабышлары, спорт ярышлары, күңелле уеннар үткәрелде, концертлар куелды.

*
* *

...Ереваннан Чаллыга килгән рәссам Петрос Малаян аталы-уллы шоферлар Трофимовлар, бригадир Николай Усов, бетончы Федор Прокофьев белән дуслашты. Аларның эшләре, ял итү шартлары белән танышты һәм портретларын ясады...

«Узган елда ук КамАЗ төзү һәм монтаж оешмалары һәр көнне миллион сумлык күләмдә эш башкару темпына ирешкәннәр иде.

Төзелешне материаль-техник тәэмин итү системасының уңышлы эшчәнлегеннән башка бу темпка ирешү мөмкин булмас иде. КамАЗның тылы — үзенә уннарча тәэминат, транспорт оешмаларын, производство предприятиеләрен, инженерлык хезмәтләрен берләштергән бик зур хуҗалык ул. Соңгы елларда гына илебездәге бу гигант төзелешкә хезмәт күрсәтү өчен ике йөз километрдан артык тимер юл, йөзләрчә километр автомобиль юллары салынды, уннарча склад мәйданчыклары һәм биналары, пароходлар өчен причаллар, механизация һәм транспорт базалары, елга ике миллион кубометр продукция җитештерә алырлык бетон, эре панельле йортлар төзү, металл конструкция заводлары булдырылды. Асылда КамАЗда төзелеш индустриясе һәм төзелеш материаллары җитештерү буенча эре промышленность үзәге барлыкка килде».

«Строительная газета». Мәскәү.

Туфан Миңнуллин

# ТАУ БАШЫНДА БАРДЫР БЕР РАЙОН



Үткән ел пароходка утырып Уфага барганда бер кеше белән танышкан идем. Чаллы районының кайсыдыр колхозыннан иде ул. Танышуга ук ул горурланып, хәтта мактаныбрак, үзенең районын күккә чөеп зурларга тотынды. Нинди генә эшләр майтарылмый, янәсе, аларда. Чаллы ягының нинди як икәнен бик яхшы белгәнгә, яңа танышымның сүзләрен хуплап, куәтләп тордым.

Сөйләп арыгач юлдашым:

— Ә сез үзегез кайсы якныкы? — дип сорады.

— Кама тамагы районыннан,— дидем.

— Андый район бармыни? Кайда соң ул?

Бу вакыт пароход нәкъ Кама тамагы яныннан үтеп бара иде.

— Әнә,— дип, Иделнең уңъяк ярына күрсәттем.

Юлдашым исе китмичә генә яр өстендә сибелеп утырган йортларга карады да:

— Ә-ә...— дип куйды.

Туган районым турында «Ә-ә»... дип кенә әйтеп ачуны китерсә дә, мин юлдашымны аңладым. Белми ул. Кама тамагының кайда икәнен белмәгәне өчен нигә кешегә бәйләнергә.

Димәк, районымның дәрәҗәсе кечкенә, өйрәсе сыек. Аның нефте дә, КамАЗы да юк, иген уңышының югарылыгы белән дә кайбер районнар сыман күкрәк сугып сөйләшә алмый.

Шуңа күрә туган ягым турында аны белмәүчеләргә сөйлисе килә. Нинди район соң ул Кама тамагы?

Җәй аеның матур бер көнендә акчарлактай ап-ак «Ракета»га утырып, Кама тамагы пристанена килеп төшәсең. Дөнья мәшәкатьләреннән арынып торган чагың була. Чөнки син сабан туенда бәйрәм итәргә — кунак булырга, күңел ачарга кайткансың. Ашыкмыйча гына тауга күтәреләсең дә борылып Иделгә карыйсың. Гаҗәеп күренеш! Тел белән сөйләп аңлатырлык, каләм белән язып тасвирларлык түгел. Җырлап җибәрәсе килә.

Әй, матур туган ягым,
Әй, гүзәл туган ягым...

Кыскасы, син оҗмахның түрендә басып торасың. Күкрәкне киереп бер сулыйсың да башлаган җырыңны көйли-көйли сабан туе мәйда-

ына юнәләсең. Ә анда!.. Битләре алсуланып янып торган көләч кызлар, алар тирәсендә бөтерелүче яшь-җилкенчәк, чәчен шомартып тарап, толымнарын билгә кадәр сузып салган яшь киленнәр. Янна-рында — ирләре. Ирләр, билгеле, ирлекләрен итәләр: тирә-якка горур гына каранып таныш-белешләрен эзлиләр. Эзләп табалар да вәкарь белән генә исәнләшәләр, тамак төбе белән сөйләшәләр. Дөньялары түгәрәк — хатыннары яннарында, сабыр гына басып тора. Чөй сакаллы картлар көрәш буласы мәйдан тирәсеннән урын алып калырга ашыкканнар. Аларга көрәш кирәк. Бар микән, янәсе, мәйдан тотарлык егетләр хәзергесе көндә, хәзергесе яшьләрнең билләре сыек түгел микән?

Башлана бер заман бәйрәм! Анда көлеш, монда җыр, тегендә бию. Карап-карап торасың да бер генә мыскал кайгы-хәсрәтләре юктыр бу кешеләрнең дип уйлап куясың. Әйтерсең лә алар гомер буе җырлап-биеп кенә яшәгәннәр. Район җитәкчеләренең дә, колхоз башлыкла-рының да авызлары колакта.

Менә нинди ул Кама тамагы районы!

Көз аеның яңгырлы бер көнендә пароходтан ашык-пошык төшәсең дә ышыкланыр урын эзләп тау өстенә үрмәлисең. Аяк тая, сүгенәсең. Вокзалга кереп сыенасың. Яңгыр туктаганны көтәсең. Көн бераз ачылгач, шаулап дулаган Иделгә сырт белән борылып туган авылыңа кайтырга юлга чыгасың. Җәяүләп атларга туры килә. Мондый чакта машиналар Кама тамагы — Апас юлыннан гына йөри ала. Телгә алып сөйләрлек адәм рәтле бердәнбер юл.

Ярты чакрым үтүгә эт булып арыйсың. Үзле балчык аяккаябышса, төшереп калдырырмын димә. Бер таудан төшәсең, икенчесе каршыда тора. Тау, ермак, тау, ермак. Әнә бер тау астында «Беларусь» тракторы үкерә. Арбасына бәрәңге төягән. Үкерүен үкерә трактор, көпчәкләре дә әйләнә, ләкин урыныннан кузгала алмый. Тракторист моторын сүндереп, кабинасыннан җиргә сикереп төшә. Бертуган абыең булса да танырлык түгел — битенә, кулына, киеменә балчык сыланган. Менә ул ни өчендер трактор көпчәгенә тибеп ала да күккә карап сүгенергә тотына.

— Иманын, фәләнен-төгәнен... Туктамаса туктамый бит,— ди.— Ичмасам, җире җир түгел, алла каргаган районда яшибез,— ди.

Шул чакта район үзәгеннән колхоз идарәсенә шалтыраталар.

— Ничек анда сезнең бәрәңге белән? — диләр.

— Булыр,— ди председатель, үзе тәрәзәдән тышка карый да тракторист әйткән сүзләрне кабатлый. Райондагылар председательнең хәлен аңлыйлар. Ничәнче көн тоташтан коя. Ә бу — кайбер бүтән районнар өчен бәла булса, Кама тамагы өчен афәт. Чөнки ул таучокыр эчендә утыра.

Менә нинди ул Кама тамагы районы. Туган районым турында язарга җыенгач, мин җәйге Иделгә карамыйчарак, аңа сырт беләнрәк борылып язарга булдым. Монда яшәгән, монда иген иккән, мал үстергән кешеләрнең Идел ярына басып табигать белән сокланырга вакытлары әзрәк. «Әй, минем туган ягым» дип җырларга да сирәгрәк туры килә аларга. Идел ярыннан ярты чакрым читкә авышу белән үк шактый авыр хезмәт башлана. Тау сыртларына — «алла каргаган» җиргә иген чәчеп, аннан уңыш алырга кирәк. Район диңгез сыман Идел ярында утырса да, суга сусый. Идел яры биек, ә Иделдән читтә елгалар-күлләр юк.

Җир бик саран. Сай сөрсәң дә ярамый, тирәнрәк итеп алдырсаң, өскә кызыл әрләнә балчык, я таш әйләнеп чыга. Өстәвенә, көтеп алынган җәйге яңгырлар җиргә сеңәргә өлгермичә таудан шуып кына төшеп китәләр. Сөргәндә, чәчкәндә, урганда тракторларга, комбайннарга «кәҗә сукмакларыннан» йөрергә кирәк.

«Кәҗә сукмагы» дигәч, «1 Май» колхозы бригадиры Хәсип абыйның сүзләре искә төште. Бервакыт ул газетадан Краснодар краендагы комбайнчыларны мактаган мәкаләне укыгач, шактый ук кызып киткән иде.

— Алар безгә килеп урдырып карасыннар шул хәтле, аннан сөйләшербез,— дигән иде.— Алар монда йөз метр да китә алмыйлар, хәзер комбайннары белән таудан тәгәрәп төшәләр, дигән иде.

Арттыруын арттыргандыр Хәсип абый, әмма ләкин сүзләрендә хаклык та бар. Безнең басуларда комбайнны йөртер өчен зур осталык кирәк. Ә мактау мәсьәләсенә килгәндә, быел Кама тамагы кешеләренең макталырлык эшләре шактый булды. Республикабызның орден һәм медальләр белән бүләкләнгән колхозчылары арасында Кама тамагы районыннан дигән сүзләр еш кабатлана. Ни өчен, нәрсә өчен?

КПСС район комитетының беренче секретаре Миннемөхәммәт Борһанов бу сорауларга саннар белән җавап бирде. Саннар күп күрсәтелгән кәгазь, гадәттә, «корырак» чыга. Әмма нишләтәсең, еллар буе түгелгән хезмәтнең нәтиҗәсе матур сүзләрдә түгел, коры саннарда ачыграк күренә.

Әйтик, менә 20,1 центнер. Нәрсә бу? 1973 елда район буенча һәр гектардан алынган иген уңышы. Бер караганда әллә ни дә түгел сыман. Әгәр инде шул сан телгә килеп сөйләргә тотынса, бик күп хикмәтләр ачыла. Безнең якта шул галәмәт иген үстереп була дисәң, моннан ун-унбиш ел элек һичкем дә ышанмас иде. Ә инде Кама тамагы совхозында көзге бодай 34,3 центнер уңыш бирәчәк диючегә тилемиле дигән кушамат тагарлар иде. Тагын бер сан — 60. Моның серен мин озак аңлый алмый тордым. Райком секретаре Рәшит Даутов белән Миннемөхәммәт Борһанов минем бу мәсьәләдәге наданлыгымны гафу итеп төшендереп бирделәр. Һәм тәки аңладым, хәзер кайберәүләрне үзем өйрәтә алам. 60 саны ул Кама тамагы районындагы туфракның уңдырыш куәтен билгеләүче сан икән. Банитет — 60 балл дигән сүз. Ягъни, мәсәлән, әйбәт, менә дигән туфракның уңдырыш куәте 100 балл булса, безнең районның бары тик 60 кына балл. Шуннан китеп, бер мәсьәләне чишеп алыйк: Буа районы узган ел һәр гектардан 28,2 центнер уңыш җыйган, безнеке — 20,1 центнер. Буа районы җиренең уңдырыш куәте 92 балл, безнеке — 60. Кайсы район алда? Гап-гади арифметиканы эшкә җигеп санасаң-чутласаң, Кама тамагы алда булып чыга. Чөнки буалылар яхшы җирдән югары уңыш алганнар, безнекеләр начар җирдән яхшы уңыш алганнар.

Болай дип Буа районы кешеләренең эшен киметеп күрсәтергә җыенмыйм, безнең район кешеләре дә эшкә уңганнар дип кенә әйтәм. Һәм иң куанычлысы, быелгы уңыш очраклы гына хәл түгел — берничә ел рәттән район тотрыклы уңыш алып килә.

Терлекчелек тармагына күз салып андагы саннарга карасак та, күңел сөенерлек үзгәрешләр күренә. Һәр сыердан 3000 литр сөт савып алучы уңганнарны йөзләп санасалар, фермаларны дистәләп саныйлар.

— Район буенча һәр сыердан 3000 литр сөт алыр чак җитте,— ди Рәшит Даутов.

Кара инде! Кама тамагының да шундый көннәрне күрер чагы җиткән икән. Әле кайчан гына 2 мең литр сөт савып алды фәлән сыер савучы дип мактап язалар иде.

Менә нинди эшләр кубарып яталар безнең як кешеләре. Бактың исә, моның сере дә әллә ни еракта ятмаган икән. «Алла каргаган җир» эшкәртү өчен тракторлар кирәк булган, хәзер алар җитәрлек, комбайннарга да кытлык юк; уңдырышсыз, саран җирне ашлап, аңа сортлы орлыклар чәчсәң, ул юмартлана да белә икән. Искитәрлек

берни дә юк. Ләкин боларның барысын да кемнәрдер эшләргә тиеш бит. Кемнәрдер дигәнем — җирнең хуҗалары. Район, колхоз җитәкчеләре, колхозчылар җирне үз итеп, яратып, аңа чын хуҗаларча карарга өйрәнә башлаганнар.

Җир хуҗалары дигәч, бик күп исем-фамилияләрне санап чыгып булыр иде дә, язма озынга китә. Шулай да, үзем яхшы белгән берничә кеше турында әйтмичә ярамас. «1 Май» колхозы тракторчысы Вәлиәхмәт абый Талиповның сөргән, тырмалаган, культивацияләгән гектарларын бергә җыйсаң күпме була икән, шуны санап карыйсым килә минем. Сугышка хәтле үк тракторга утырган кеше һаман әле төшкәне юк. Сугыш чагында гына аерылып торган, Советлар Союзында эшләнгән трактор маркаларының бөтенесе дә Вәлиәхмәт абый кулында сынау үткән. Вәлиәхмәт абыйның энеләренә, малаена да машина җене кагылган. Җенне әйтәм, кайдан эзләп таба торгандыр шундый уңган кешеләрне.

«Яңа юл» колхозы председателе Фатих абый Саттаров хакында аерым бер китап язып булыр иде. Әкәмәт кеше, карап торсаң, кулыннан бер эш килмәс кебек. Мин аның ашыккан, кабаланган чагын күргәнем юк. Сөйләшүе дә бүтәннәрнеке сыман түгел — үзенчә.

— Фатих абый, пекарня салгансыз икән,— дисең.

— Салынды шул,— ди.

— Фатих абый, бик шәп таш клуб салгансыз икән.

— Салынган шул.

Әйтерсең пекарня да, клуб та үзләреннән-үзләре дөньяга килгәннәр, әйтерсең Фатих абыйның аларга бер катнашы да юк.

Кайберәүләр әйтәләр, Фатих Саттаров кирәк чакта каты куллы да була белә, диләр. Мин ышанмыйм. Хәер, дөрес булуы да ихтимал, җир җебегән куллы кешеләрне яратмый.

«Яңа юл»ның күршесе «Искра» колхозы. Анда Фоат абый Вәлиев. Анысы инде табигате белән Фатих абыйга капма-каршы. Һәр чак чабып йөрер. Әмма ләкин бушка чапмас. Фоат абый йөри икән, димәк, нидер юллап, нидер җайлап йөри.

Район газетасындагы сводкаларны карасаң, Мичурин исемендәге колхоз һәр вакыт алда булыр. Авыл хуҗалыгының бөтен тармаклары буенча ничә ел рәттән инде ул беркемгә дә баш бирми. Бу хуҗалык белән күптәннән исеме республикада танылган председатель, Социалистик Хезмәт Герое Николай Викторович Лисин җитәкчелек итә. Бик аз сүзле кеше. «Одним словом» дип әйтеп куя да эшкә керешә.

Ринат Гатин, Гайса Җәләлов — яшь председательләр. Яшьләргә хас куәт белән алга ашкыналар. Әлегә тәҗрибәләре җитеп бетмидер бетүен, ләкин биюче бии-бии остара диләр бит.

Исем-фамилияләрне күп санамыйм дигән идем дә, мөмкин түгел икән.

«Красный маяк», «Кама тамагы» совхозлары күзгә кергән чүп кебекләр иде,— ди Миннемөхәммәт Борһанов,— хәзер күз тимәсен үзләренә, «Красный маяк» республика совхозлары арасында алдынгыларның берсе. Директоры — Виталий Степанович Толовенков, яшь булуына карамастан, уңган җитәкче булып җитеште. Ә «Кама тамагы» совхозы директоры Виктор Перфильев җирне биш бармагы кебек белә. Башта тракторчы булып эшләде, читтән торып укып агроном дипломы алды, һәм без аңа зур ышаныч баглыйбыз».

Район җитәкчеләрен яхшы беләм дип мактана алмыйм мин. Җәелеп гәп корып утырырга вакыт тими. Аларның һәр минуты санаулы. Ара-тирә очрашып сөйләшкәндә дә эшләнгән эшләр турында түгел, башкарыласы эшләр хакында сөйлиләр алар. Иген үстерү, терлекче-

лек продуктлары җитештерү буенча күп эшләнсә дә, үзкыймммәт мәсьәләсен хәл итәсе бар икән. Җитештерелгән продукциянең үзкыйммәте районда ярыйсы ук югары икән. Юллар салу да проблема булып тора. Проблемаларның иң зурысы — сугару, культуралы көтүлекләр булдыру. Аның өчен кипкән, файдасыз ермакларны су белән тутырып, буалар ясарга кирәк. Ләкин суны кайдан алырга? Иделдән. Ничек? Менә шул турыда уйлыйлар. Хәер, уйланган да бугай инде, Иделдән суны күтәреп, ермаклар буенча агызу корылмасының проекты әзерләнеп ята.

Безнең як алмалары элек-электән тирә-юньдә дан тотканнар. Сугыштан соңгы елларда бакчачылык эше районда сүнебрәк киткән иде. Хәзер яңадан аны тергезү, авыл хуҗалыгының файдалы бер тармагы итү мәсьәләсен дә район җитәкчеләре истән чыгармыйлар...

Яза торгач, мавыгыбрак киттем, ахрысы, гел мактау да гел мактану гына килеп чыккан бугай. Район кадәр районда җитешмәгән, тәнкыйть ителергә тиешле нәрсәләр дә бардыр инде. Ләкин бу очракта минем максатым тәнкыйть белән шөгыльләнү түгел. Былтыргы таныш юлдашым сыман андый район бармыни диючеләргә, бар ул Кама тамагы, менә шундыйрак район ул дип аз-маз таныштыру гына иде максатым. Тик күңелне кытыклап торган тагын бер нәрсә бар, шуны әйтмичә калдырасы килми. Белмәгәннәр белсеннәр: безнең районда исеме илгә билгеле гипс руднигы бар. Шул рудникның продукциясен чит илләр сатып ала башлаган икән. Монысы инде, җәмәгать, «токмач ашау» гына түгел. Әгәр, әйтик, Кама тамагының кайда икәнен белә башлаганнар икән, нигә бераз «тамак кырып» алмаска.

Озын сүзнең кыскасы, Казаннан Идел буйлап түбән төшкәндә Камага җитәрәк уң якка борылып карагыз. Тау башында Кама тамагы районы булыр. Яр өстендә пароходка кул болгап калучыларны күрсәгез, аптырамагыз,— безнең як гадәте ул — эшләп арыгач, яр читенә ял итәргә утыралар да үткән-сүткән пароходларны кул болгап озатып калалар, хәерле юл телиләр. Сез дә аларга җавап итеп кул болгагыз, хөрмәтле пассажирлар. «Армый эшләгез»,— дип әйтергә дә онытмагыз!..

## Мирхәт Хөснимәрдәнов,

киностудия редакторы.

# СИҢА ТАРТЫЛА КҮҢЕЛ



Һәр көн иртән сәгать сигездә безнең гадәти эш көне башлана. Башлану белән куллар телефонга үрелә һәм уналты саннан торган номер җыя башлый. КОД буенча. Унбиш секундтан тоташтыралар.

— Ни хәлләр Чаллыда, яңалыклар...

— Көн саен яңалык, өлгер генә.

Бу безнең зур төзелештәге «Күзебез һәм колагыбыз» — кинохәбәрчеләр пункты. Анда студиянең кинооператоры утыра. «Утыра» дип әйтү болай гына. Ул иртән генә анда. Хәбәрләшкәнче генә. Без белеп торабыз: сөйләшү, яңа задание алу белән ул үзенең «УАЗ» машинасы белән автозавод төзелешләре буйлап чабачак. Аңа аеруча зур бурыч йөкләнгән: КамАЗ төзелешендәге иң әһәмиятле вакыйгаларны, хезмәт батырларын кинолентага төшереп барырга...

Кинохроника вахтада. Мактаулы вахтада.

Кинооператор бүгенге күренешләрне киләчәк буыннар да үз күзләре белән карый алсыннар өчен хезмәт итә. Аның кулында камера, аңа меңнәрчә метр пленка тапшырылган. Һәр метры файдага китәргә тиеш. Без, редакция работниклары да, иртәнге эшебезне Чаллы, КамАЗ сүзләре белән башлыйбыз.

Хәзер инде барысы да җайга салынган дияргә була. Турыдан-туры элемтә дә бар. Оперативлык та җитәрлек. Үз кешебез — махсус кинооператор — даими рәвештә шунда яши, тормышның казанында кайный. Ә баштарак... Баштарак бик мәшәкатьле иде. Кешеләр, белгечләр, транспорт җитми иде. Шулай да без беренче көннән үк җиң сызганып тотындык. Шуны раслау өчен студиянең фильмотекасына, архив материалларына сәяхәт кылыйк.

## Беренче ташны салганда

1969 ел. Җәй уртасы. Иң төгәле — 21 июль. Кулына камера тоткан белгечләр өчен кызу «урак өсте». Бөтенесе юлда, командировкаларда. Кайсысы фильм, кайсысы чираттагы журнал өчен сюжетлар төшерә. Нәкъ менә шундый, бер кешене биш итәрдәй, киеренке чакта гадәттән тыш ашыгыч һәм мөһим задание килеп төшмәсенме! Иртәгә иртүк бер кинооператор Чаллыга очарга тиеш. Булачак автозаводның нигезенә

беренче таш салыначак. Шушы вакыйганы тарих өчен кинога төшереп калырга кирәк.

Кирәк икән, димәк, ничек тә булса вакытында барып җитәргә! Ләкин студиядә бер генә кинооператор да калмаган чак. Җитмәсә, эш көне бетеп килә. Камераны теләсә кемгә тоттырып булмый бит. Кинога төшерү эше кулга кәгазь-каләм алып, ялгызың утырып язу гына түгел. Оператор янына булышчысы — ассистенты кирәк. Аппаратлар салып йөртү өчен аерым машина булсын. Ә монда җиде кирәкнең берсе юк. Бәхетебезгә каршы, бер кинооператорның ассистенты — Виталий Меркулов өйдә булып чыкты. Мондый җаваплы эшне ассистентка йөкләү редакция ягыннан артык тәвәккәллек иде, билгеле. Ләкин бүтән чара юк.

Җәйге чорда алай тиз генә самолетка билет табу кыенлыгы турында әйтеп тә торасы юк инде. Һәркемгә билгеле. Кинохроникада эшлисең икән, кыенлыктан үз инициативаң белән чыгарга омтыл, җаен тап, кирәкле рейска өлгереп кал, вакытында барып җитеп, бирелгән заданиене үтә. Вакыйганы синең өчен генә яңадан кабатлый алмыйлар. Җыену өчен бер кич: камераны көйлә, пленкага сынау үткәр, билет турында кайгырт... Ә югарыдан, әледән-әле шалтыратып, безнең хәзерлекне тикшереп торалар.

Кама буенда гаять тә зур автозавод салыначак икән, дигән хәбәр инде телгә кергән иде. Ләкин аның күләмен дә, куәтен дә, әһәмиятен дә ул вакытта күз алдына китерүчеләр аз булгандыр. Китерсәләр дә, төзелешләргә инде күнегеп беткән бу чорда артык искитмичә генә фикер алышалар иде. Салыначак икән, димәк, салына инде. Завод икән, димәк, завод инде. КамАЗ икән, димәк, КамАЗ... Шаккаттыргыч нәрсә юк кебек.

...Җибәргән ассистентыбыз киткән көнне үк әйләнеп тә кайтты.

— Я, ничек, булдымы? — дип шикләнеп сорыйбыз аннан.

— Булган шикелле булды, — дип, артык һаваланмыйча гына җавап кайтарды Виталий, пленка ничек күрсәтер бит әле, аны караңгыда эшкәртәләр.

Пленканың эшкәртү цехыннан кайтканын көтәсе калды. Башта негатив пленка эшкәртелә. Аннан соң аны позитивка күчерәләр... Икенче көнне позитив пленка әзер иде инде. Карадык, күрдек: шактый күп кеше җыелган Чаллыга. Казаннан да, Мәскәүдән дә... Буп-буш басу уртасы. Кранлы машина, кран элмәгенә «Биредә Кама батыры төзеләчәк» дигән язулы озынчык формасында эшләнгән зур нигез ташы эленгән. Салмак кына итеп аны траншеяга төшерәләр. Җыелган кешеләрнең йөзләре җитди. Шулай да алар канәгать. Бер-берсен тәбриклиләр...

Бу вакыттан соң инде дүрт ел вакыт үтте. Чаллыда, автозавод төзелешендә хәзер ул язулы беренче ташның кайда икәнен дә белмиләр. Аның белән кызыксынучылар еллар үткән саен күбәя генә бара. Ә белүчеләр бөтенләй юк. Имеш, КамАЗның кайсыдыр заводы астына (алар барысы — алты) нигез казыганда экскаватор чүмеченә җир астыннан ниндидер зур тимер-бетон таш эләккән һәм экскаваторчы эшкә комачаулаган бу ташны, кемнедер әрли-әрли, күтәртеп бер читкә бәргән һәм эшен дәвам иттергән. Бәлки нәкъ әнә шул булгандыр, дөрестән дә. Игътибар гына итмәгәндер.

Ә кинокамера үз бурычын үтәде. Хәзер инде уникаль-кадрлы булып әверелгән бу киноленталар студия фильмотекасында алтын фонд булып саклана. Аны әллә ничә тапкыр яңадан ясатып (аны «контратиплаштыру» диләр), күпме режиссерлар КамАЗ турында ясаган журналларында, фильмнарында файдаландылар. Ә редакция архивында Виталий Меркуловның — КамАЗ төзелеше киноархивын башлап җибәргән ассистентның — бу вакыйга турында кыска гына информация язган беренче монтаж кәгазе саклана. Без КамАЗ батырының куәте турында беренче тапкыр шушы кәгазьдән укып белдек.

## Күңелләр КамАЗга тартыла

Тиздән инде без автогигант төзелешенең колачы, күләме турында көн саен киңрәк һәм тулырак мәгълүматлар ала башладык. Бу бездән — документаль кинохроника хезмәткәрләреннән дә — иҗатта яңа адымнар ясауны, заман агышыннан соңга калмауны таләп итә иде. Мәскәү аша эш йөртеп (чөнки студия турыдан-туры РСФСР Министрлар Советының Кинематография комитетына буйсына) Чаллыда яңа кинохәбәрчесе пункты алуга ирештек. Аңа булачак завод идарәсе урнашкан бинаның бишенче катыннан кечерәк кенә бүлмә бирделәр. Кино институтын тәмамлап кайткан һәм киносюжетлар, репортажлар төшерү буенча шактый тәҗрибә туплаган оператор Вил Алабердин даими эшләү өчен Чаллы шәһәренә күчеп килергә теләк белдерде. Аңа махсус машина беркетелде.

Бөек төзелешне башлап җибәрүче энтузиастлар турындагы киносюжетларны без дүрт күз белән көтә башладык. Тамашачыга КамАЗ турында тизрәк һәм мөмкин кадәр күбрәк хәбәр итәсе килә иде. Илебезнең төрле почмакларыннан анда төзүчеләр җыела. КамАЗны бөтен ил төзергә керешә. Моны язу җиңел, бу турыда сөйләү ансат. КамАЗдагы халыклар дуслыгының мәңгә дигән үрнәге булган төзелешне ничек итеп документаль экранда тулы образлы итеп күрсәтергә? КамАЗга аерым кинооператор беркетелүгә карамастан, студиянең башка кинооператорлары да (алар барысы унга якын) күңелләре белән КамАЗга тартыла башладылар. Бөтен ил төзегәндә бер операторга гына ышанып яту яки ваемсыз булып читтә калу «гөнаһ» иде алар өчен. КамАЗ төзелеше колачы инде кыска-кыска гына киносюжетлар түгел, күләмлерәк кино әсәрләре: махсус журналлар, фильмнар таләп итә иде.

Бу юнәлештә беренче адымны кинооператор Анатолий Стрельков ясады. Сәләтле документаль киночы буларак, аның камерасы белән төшерелгән мордва скульпторы турындагы фильм «Эрзя», «Туган йортым», «Кама-66», «Иделдә фестиваль» дигән фильмнар студиянең алтын фондына керде. Һәр вакыт иҗади яңалыкка омтылучы, эзләнүче Анатолий бу юлы да аягын башкаларга караганда алданрак киенде һәм Чаллыга — КамАЗга юл тотты.

Җитмешенче елның беренче салкын буранлы көннәрендә ул үзенә тапшырылган группа белән шактый вакыт төзелештә булып кайтты. Үзе төшергән материалны үзе монтажлады һәм без январь аенда ук инде «Идел киңлекләрендә» киножурналының КамАЗ төзелешенә багышланган махсус санын кабул итеп, Идел буендагы дүрт автономияле республика экраннарына озаттык. Журнал шулай ук татар һәм чуваш телләренә дә тәрҗемә ителде.

Бурыч — КамАЗ төзелешен башлаучыларның беренче батырлыкларын, аларның уй-хисләрен, омтылышларын экранда чагылдыру иде. Экранлаштыру өчен материал әлегә азрак булуга да карамастан, Анатолий төзелешнең шул чорын тамашачыга дөрес житкерү өчен үзенчәлекле алым тапкан иде. Кышкы газаплы юллар, туктаусыз буран себерә. Буранны кисеп үткәндәй, юллардан төрле маркадагы машиналар агыла. Кайдадыр бөек төзелеш башланган. Кешеләр кырыс табигать белән йөзгә-йөз килеп көрәшкә чыкканнар. Кайдадыр... Әмма автор-оператор безне анда алып бармый әле. Инде төзелеп өлгергән беренче уңай ашханәләр, беренче торак йортлар... Кадрлар бүлекләрендә (һәр заводның, һәр төзелеш идарәсенең үзенеке) кайнап торган эшләр экранда бер-бер артлы узып торалар. Көн саен агылып торган хатлар... Хатлар артыннан җанлы кешеләр үзләре... Автор автозаводның ни өчен биредә — Кама буенда салына башлавы турындагы сорауны да онытмый: нефть

якын, Түбән Кама химия комбинаты — каучук рәттән генә, энергия кирәк икән, Зәй ГРЭСы кул сузымында, житмәсә, Түбән Кама ГЭСы чиратта тора. Ерак та түгел шин заводы... Төзү материаллары ташу өчен уңай булган мул сулы Кама үзе генә ни тора... Шулар турында бик үтемле итеп сөйләгәч һәм экранда аларны шактый оста кинокадрлар белән күрсәтеп биргәч, журнал төзелешкә килергә чакыру белән тәмамлана.

Житмешенче елның җаендә без махсус программа әзерләп Чаллы шәһәрендә документаль фильмнар фестивале оештырдык. Беренче фестиваль, беренче танышу... Үзләренә күрсәтергә дип, КамАЗ төзүчеләр турында төшерелгән сюжетлардан кинороли́к ясап һәм шуңа Анатолий Стрельковның беренче киножурналын да өстәп алып барган идек. Бик игътибар белән карадылар, тәнкыйть фикерләре, эшлекле тәкъдимнәр әйттеләр. Бер эшченең залдан торып әйткән сүзләре аеруча истә калды:

— Болар бөтенесе дә бик әйбәт. Ләкин төп игътибар төзелешнең үзенә булырга тиеш. Биек корпуслар күтәрелә башлагач, сезгә — киночыларга киң панорамалы итеп күрсәтер нәрсәләр күп булыр, билгеле. Менә хәзер без — төзүчеләр җир астыннан баш калкытып килгәндә кинолентага алсагыз иде. Чөнки иң авыры әнә шул җир астыннан күтәрелгәнче булды. Күп тә үтмәс, котлованнар күмелер, алар өстендә биек-биек йортлар, завод корпуслары калкып чыгар. Аска, заводның нигезен салуга, нинди хезмәт түгелүе турында аз уйларлар. Соңыннан кинода булса да күрәсе иде бит шуларны.

Сүз уңаеннан гына әйтелгән бу реплика безне соңыннан нык уйланырга, үз эшебезгә тәнкыйть күзе белән карарга мәҗбүр итте. Ә операторлар зарланалар иде: күрсәтер нәрсә юк, тип-тигез басу уртасында чокыр да чокыр әле. Чыннан да, безнең кинооператорлар тирәнрәк карый белмәгәннәр. Юллар, тулай тораклар, кадрлар бүлеге, уку бүлмәләре, ашханәләр тирәсендә генә әйләнгәннәр. Төзелешнең эченә үтеп керергә, аны киң колач белән җәеп җибәргән бүгенге көн батырларының хезмәтен киң итеп, үтемле итеп бирергә кинооператорларның кулы, оперативлыгы җитмәгән. Күрәсең, нәрсәдер һаман комачаулый иде. Әллә инде масштабны күрә белмәвебезме?

Хикмәт нәрсәдә икән соң? Бурычны да аңлыйбыз шикелле, оста операторларыбыз да бар. Күңелләре КамАЗга омтылып торган тәҗрибәле режиссерларыбыз да җитәрлек. Ләкин КамАЗдан төшерелеп җибәргән һәр сюжетны караган саен күңелдә канәгатьсезлек тойгысы кала килә. Инде төзелеш объектларын, балкаларны, җыелма тимер каркасларны, озын-озын торбаларны киң панорамалы итеп төшерергә дә өйрәнделәр. Һаман-һаман эзләнәбез, операторларга үгет-нәсихәт биреп, бурычны аңлатып хатлар да язабыз. Төп төзүчеләрне, бүгенге көн геройларын яңачарак төшерергә кинәш бирәбез. Ә ничек яңачарак? Монда төгәл рецепт бирүе дә читен бит әле. Һәр иҗат кешесенең, һәр операторның үз күз карашы бар, үз алымы бар. Камераның объектив пыяласы аша төзелешкә ул карый, төшерү теймәсенә ул баса.

Художество советының чираттагы бер утырышында КамАЗда төшерелгән сюжетларның сыйфатын тикшерү бара иде. Шунда совет члены— иң өлкән операторларның берсе — гомер буе нефтьчеләр тормышын экранда яктырткан Леонид Васильевич Барышев (хәзер ул пенсиядә), безне борчыган сорауларга җавап биреп, менә нәрсәләр сөйләде:

— Караган сюжетларның күбесе КамАЗ колачын күрсәтә алмый. Сез әнә шул максатка омтылып, озын балкаларны, цехларны, каркасларны төшерәсез. Ә төзүчеләр — чын геройлар — алар арасында кырмыскалар кебек кысылып калалар. Ни өчен камера аларга якын килми? Хезмәт кешеләренең киң портретлары, эре планнары ни өчен тамашачыга якын итеп бирелми? Тамашачы аның йөз сызыкларына кадәр

күрсен, аның йөзендәге киеренкелекне, хисләрен экрандагы кадрлардан тоеп торсын! Алай итсәгез, киң колачлы төзелеш панорамасы югала, сезнеңчә. Шулаймы? Шуннан куркумы? Урынсызга. ҚамАЗ шундый үзенчәлекле төзелеш ул. Анда сез кешеләрнең күпләп бер урында эшләгәнен күрә алмассыз. Техника заманасы. Шуңа күрә камера аерым кешегә — төзүчегә якын килергә омтылырга тиеш. Аның рухи байлыгын, хезмәткә булган мөнәсәбәтен экранда образлы итеп күрсәтү максаты белән эшләсәгез, калганы: автогигантның колачы да, киң панорамасы да — һәммәсе дә күз алдына килеп басар. Алгы планда кеше, аның янып торган күзләре булсын. Утыз метр биеклектә эшләүче монтажчының хезмәтен җирдән торып кына кинога төшерү әле аның эшен күрсәтә алу дигән сүз түгел.

Шуннан соң күпләрнең күзе ачыла төште. ҚамАЗ төзелешен экранда яктыртуны яхшырту чаралары турында дирекциянең аерым приказы чыкты. Бу мәсьәлә партия җыелышында, иҗади киңәшмәдә каралды. ҚамАЗга барып кайткан операторлар, режиссерлар инде төзелеш эченә керүдән, эзләнүдән тартынмыйлар, беренче тапкыр күргәндәге кебек техника күплегеннән каушап, умарта оясыдай гөжләп, ыгы-зыгы килеп торган Чаллы шәһәрен буталчык бер объект итеп сөйләмиләр.

Шуңа да карамастан, яшь оператор Валерий Севостьянов җитәкчелегендә «Без ҚамАЗ төзибез» дигән репортаж формасында төшерелгән киножурнал шактый каты тәнкыйтькә очрады. Биредә кешеләр дә, колач та күрсәтелгән, ә сюжетлар таркау, бер-берсе белән бәйләнешләре җитәрлек түгел иде. Ә синхронлы сөйләшү өлешен яраксыз, төзелеш рухын күрсәтә алырлык түгел, дип журналдан бөтенләй алып ташларга туры килде. Тик шунысы куанычлы иде: боз кузгалды, иҗади эзләнү дөрес юнәлештән юл алды, режиссерлар, кинооператорлар баштагы каушап калу шаукымыннан котылдылар һәм «Чаллы», «ҚамАЗ» сүзләре инде аларны калтыратмый.

Хәзер инде студия фильмотекасында ҚамАЗ төзелешеннән төшерелгән 100 гә якын киносюжет, алты махсус киножурнал, бөтенсоюз экранына чыккан ике документаль фильм, Мәскәүдә чыга торган «Көн яңалыклары» журналына җибәрелгән унга якын сюжет һ. б. лар тупланган елъязма материалы бар. Автогигант салучылар турында төшерелгән кино әсәрләренә конкурс игълан ителгәч, кинооператорлар, режиссерларның һәммәсе үз сәләтләрен тагын да киңрәк күрсәтү мөмкинлеген алдылар. Режиссер Харис Фәхретдиновның («Тукай» документаль фильмы режиссеры) ҚамАЗ төзүчеләренә багышланган «Бүген һәм көн саен», «100 көн калганда» исеме белән чыккан махсус киножурналлары иҗат работниклары арасында зур сөйләшү кузгатты. «100 көн калганда» киножурналы беренче булып сафка баскан ремонт-инструмент заводын төзүчеләргә багышлана. ҚамАЗ турында гомумән генә сөйләмичә, әнә шулай аерым заводларны, аерым бригадаларны, транспортчыларны, монтажчыларны экранда тулы итеп күрсәтү максатка ярашлы, дип табылды. Соңгы ике журнал бу юнәлештә яңа адым булды. Ләкин режиссерның әле һаман таркаулыктан котыла алмавы сизелеп тора, кешеләр конкрет алынмаган, тамашачының күңеленә хуш килә торган яңа кызыклы хәбәр бирәсе урынга экранда адрессыз кадрлар, буш картиналар... РИЗ түбәсендә мотороллерчы кызларның кырмыскалардай тызбыз килеп материал ташып йөрүләре генә (дөрес, алар карарга кызык кадрлар) киножурналның гомуми эчтәлеген баета алмаган.

Икенче бер оператор Валентин Кузьминның карлы-бозлы ноябрь аенда төшереп алып кайткан бер мең ярым метрдан артык кинолентасын иҗади яктан шулай ук яңа адым дип бәяләргә мөмкин. Студия өчен дә, авторның үзе өчен дә... Әмма бу турыда алда киңрәк тукталырга булыр.

Башта ул бик озак дәшми йөрде. «Дәшми» дип әйтүем шул: башка кинооператорлар КамАЗ белән «җенләнгәндә» Валентин бөтенләй башка сюжетлар төшерде, командировкаларда йөрде, КамАЗ төзелеше турындагы сюжетларны тикшергәндә дә читтәрәк утыра торган булды, искитмәгәндәй кыланды.

Әйе, бу үзенә күрә бер «кылану» гына иде. Валентин күптән инде КамАЗга кызыгып йөри. Башкалар сизмәгәндә берничә тапкыр Чаллыда да булып кайтты. Мәскәүдә Үзәк документаль фильмнар студиясендә чыга торган «Көн яңалыклары» киножурналы редакциясеннән Валентин Кузьмин төшереп җибәргән сюжетларны мактап телеграммалар килгәч кенә без Валентинның һич кенә дә тик ятмаганын, гигант төзелеш тормышы белән чын күңелдән кызыксынуын белдек.

Ләкин болар барысы да әле репетиция, көч сынап карау гына булган. Зур эшкә тотынганда Валентинның орылып-бәрелеп йөри торган гадәте юк, һәр вакыт сабыр холыклы, аз сүзле, эшчән кыяфәттә ул. Үткән елның җәендә, режиссер Харис Фәхретдинов белән иҗат планнары турында бик озаклап фикер алышканнан соң, икәүләп КамАЗга юл тоттылар. ... Әйдә, алар бара торсыннар, кирәкле метрларны төшерә торсыннар.

Валентин Казан кинохроника студиясенә Фрунзе шәһәреннән «Кыргызфильм» студиясеннән килде. Килеп сюжетлар төшерә башлау белән үткер күзләр экранда Валентинның үз «почеркын» бик тиз күреп алдылар. Кайберәүләр аның уңышлы сюжетларына шикләнебрәк карадылар, «җае туры килгән» дип кенә бәяләделәр, икенче берәүләр студиягә сәләтле кинооператор килүенә сөенделәр. Күп тә үтмәде, режиссерлар үз фильмнарын төшерергә кинооператор Валентин Кузьминны сорый башладылар. Аның төп осталыгы — гади генә күренешләрне, вакыйгаларны да гомумиләштереп, экранда үтемле итеп күрсәтә белүендә иде. Бер үк эпизодны төрлечә төшерергә, акны кара итәргә, караны акка әйләндерергә, аңа төрлечә аңлатма бирергә була. Бу операторның политик фикерләү сәләтенә, аның бүгенге тормышка, кешеләргә, аларның хезмәтенә партиячел, дөрес мөнәсәбәттә булуына бәйле. Валентин төшергән күп сюжетлар әнә шул ягы белән аерылып тора иде. Шушы елларда ул берничә заказ-фильм төшерде. «Салих Сәйдәшев», «Туган як моңнары» фильмнарында ул үзенең осталыгын тагын да күрсәтә төште. Төсле пленка белән эшләүдә дә сынатмады. Республикабыз колхозларында төшерелгән «Сугарулы гектарлар» төсле фильмын да ул башлады. Ләкин биредә режиссер белән оператор арасында иҗади бәхәс кузгалды. Булачак фильмны режиссер үзенчә, оператор үзенчә күрә иде. Иҗади бердәмлек булмаганда уңышсызлыкка очравы көн кебек ачык. Кино коллектив иҗаты белән туа. Редакция, дирекция бу ике киночының үзара бәхәсен килешү юлы белән чишәргә уйласа да, Валентин кире какты.

— Фильмга карата минем үз фикерем бар. Әгәр дә режиссер аны аңламый икән, димәк, без икебез ике юлдан барабыз. Башка оператор табыгыз...

...Һәм читенде, юл бирде Валентин. Дөрес, «Сугарулы гектарлар» фильмы вакытында экраннарга чыкты. Бөтен Союз экранына алдылар. Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсенең бронза медаленә лаек булды ул. Ләкин Валентин бер дә офтанмады. Чын иҗат кешесе өчен тема җитәрлек бит.

Унбиш көннән Чаллыдагы киногруппа әйләнеп тә кайтты. Режиссер Харис Фәхретдинов яңа төшерелгән материалдан «Бүген һәм көн саен» дигән махсус киножурнал монтажлады. Кинорепортаж буларак уңышлы

иде. Валентин «почеркы» сизелеп тора иде. Ләкин ул моның белән канәгать түгел иде, редакциягә яңа бер тәкъдим белән мөрәҗәгать итте:

— Минем үземә генә КамАЗ төзелешеннән ун минутлык фильм төшерергә рөхсәт итегез. Менә шушы сценарий планы белән...

Баш редактор Роберт Копосов ике бит кәгазьгә язылган планны укып чыгуга андагы яңача алымны тиз тотып алды. Яңа төзелеш операторга яңача юл табарга ярдәм иткән булып чыкты.

— Әгәр дә барып чыкмаса?..

— Башымны «кисәргә» бирәм, — дип шаяртып алды Валентин, — тәвәккәллим әле. Рөхсәт сорыйм. Үтенәм. Үзем төшерермен, үзем монтажлармын. Чыгым да аз тотыла. Срогы 15—20 көн. Фильм быел экранга чыгар.

Дирекция каршы килмәде. Мондый мисаллар элек тә булган иде. Автор—оператор... Мәскәүдән дә уңай җавап алынды.

Инде ел бетеп килә. Ноябрьның карлы-яңгырлы көннәре... Киногруппа юлга чыга. Чаллыдагы корпунктка «булышлык күрсәтегез» дигән телеграммалар оча.

Валентин тәкъдим иткән план беренче карашка бик гади иде. Фильмны да ул «Монтажчылар» дип атарга тәкъдим итә. Биектә эшләүче бер бригада монтажчылары коллективына яшь бер эшче килә. Яңа кешене кабул итү моменты биредә үзенә күрә бер ритуал булып әверелгән. Яңа монтажчылар киеме киендерәләр. Башына каска, ә кулына брезент бияләйләр. Бияләй эченә зур шөреп тыгып җиргә ташлыйлар. Яшь эшче бер нәрсә дә уйламыйча аларны җирдән алып кулына кия һәм, анда тимер кисәге тоеп, аптырап кала. Ә тирә-якта бригада членнары. Ул аларның җитди йөзләренә карый. Яңа кеше шөрепне йөзек итеп бармагына кияргә тиеш. Шуннан соң аңа беренче булып баскычтан югары үрмәләргә, балкалар буйлап барырга кушалар. Аның артыннан бригаданың башка членнары менәләр. Яшь эшченең куллары калтырый, балкалар буйлап басып уза алмый ул, мүкәйләп кенә шуыша. Ә башкалар, тәҗрибәле монтажчылар атлап кына йөриләр. Әнә шул өйрәнчекнең ничек итеп бердәм коллективта аякка басуы, чын монтажчы булып өлгерүе турында сүз бара. Утыз ике метр биеклектә эшләү, чытырдаган суыкларда, уттай кызу июль көннәрендә чыныгу... Менә нәрсәгә омтыла монтажчы. Һәр алган биеклек саен алар флаг эләләр. Бу бригададан качучы юк, бирeдән бары тик башка коллективка җитәкче — бригадир булып кына китәләр. Алар урынын яшьләр алыштыра тора. Дөрес, бригада тарихында өч кеше түзә алмаган. Башкалар сизмәгәндә генә алар бригадир кесәсенә гариза салып калдырганнар да шылганнар. Ә каскалары калган. Каскаларга тимиләр. Гыйбрәт өчен. Яңа килгән кешегә яңа каска бирәләр.

Бөтен эчтәлеге менә шул. Ләкин аны кинооператор ничек төшерер? Осталыгы җитәрме? Бердәм коллектив образын ничек итеп документаль кино теленә күчерергә? Җитмәсә, тышта ноябрь... көнелсез чак.

Валентин төшергән киноленталар цехтан эшкәртелеп чыга торган саен аларны карарга барлык иҗат работниклары җыела. Сүзсез-нисез генә карыйлар да таралалар. «Телсез» вариант диләр аны кино телендә. Ә режиссер аңа «җан» өрергә, тамашачыга илтеп җиткерергә тиеш. Менә, ниһаять, ике мең метрга якын пленка эшкәртелеп бетә. Карыйбыз. Һәммәсе язган пландагыча. Тик кинооператорның экранда үзе булуы гына планда күрсәтелмәгән иде. Әнә шул яшь эшче артыннан кинооператор да монтажчылар эшләгән биеклеккә менә. Ул да биленнән чылбыр белән балкаларга эләктереп куелган. Менә алмаган урыннарда монтажчылар аңа кул бирәләр, тартып менгезәләр. «Сәнгать КамАЗдан калышмаска, үз югарылыгында булырга тиеш», — дип шаярталар алар. Бу сүзләрдә тирән мәгънә барлыгын үзләре бәлки уйлап та карамый торганнардыр.

Бер айга якын монтаж өстәленнән баш күтәрмәде Валентин. Көндез дә, кичен дә эшләде, зур экранга куеп та, кече экранда да карады, артып калган позитив пленкалар белән корзиннар тулды, калганнары сыдырылып-тузып бетте. Болары берни түгел. Негатив пленка, алтын кебек, бикле шкафта саклана. Аңа кагылырга беркемнең хакы юк. Ике мең метр позитив пленка кискәли-кискәли бер мең метрга кала. Аны да яртылаш кисеп ташлыйлар. Һәм, менә фильм үзенең нормасына төшә — 300 метр. Бер тартмага сыя. Режиссер хезмәтен бу чакта балта остасы хезмәте белән чагыштырырга була. Ул да башта агачны ботаклардан арындыра, аннан соң балта белән юына һәм соңыннан ышкы белән тигезли, шомарта һәм үзенә кирәкле әйберне ясый.

...Фильмны «Югары нота» дип атадык. Чөнки монтажчылар үзләре шулай диләр. Җырчы иң югары нотаны алган кебек, бирелә дә хезмәтнең югары нотасына ирешеп, һаман да биеклеккә үрмәлиләр. Бераүләр китә тора, икенчеләр килә тора. Югары нота өзелми... Алар монтажлаган түбәләрдә инде күгәрченнәр оя корып өлгергәннәр. Алар тынычлыкны яраталар. Ә монтажчылар, кошлар кебек, башка төзелешләргә очарлар. КамАЗ әле соңгысы түгел.

РСФСР Министрлар Советының кинематография комитеты «Югары нота» фильмына уңай бәя бирде һәм бөтен Союз экранына тәкъдим итте. Валентинның тәвәккәллеге бушка китмәде... «Тәвәккәл таш ярган», — диләр бит. Операторлыктан режиссерлыкка омтылу Валентинга яңа иҗади уңыш алып килде. Аңа хәзер үзлегеннән фильм эшләүне икеләнмичә ышанып тапшырырга мөмкин инде.

*

* *

Казан киностудиясе документаль киночыларының КамАЗ төзелешендәге иҗади адымнары көннән-көн ныгый бара. Гигант төзелештәге кайнап торган тормыш, күтәренке хезмәт сәнгать кешеләрен осталыкка өйрәтә. Студия коммунистлары КПСС Үзәк Комитетының «Совет кинематографиясен тагын да үстерү чаралары» турындагы карары уңае белән алда торган бурычлар хакында уртага салып сөйләштеләр. Анда КамАЗ төзелешен экранда яктырту мәсьәләсенә аеруча тукталып үтелде. Бигрәк тә сценарий авторларына таләпчәнлекне көчәйтү кирәклеге әйтелде.

КамАЗдан төшерелгән киноленталарның сыйфаты турында сөйләшү әледән-әле булып тора. Даими эшләүче иҗади-производство киңәшмәсенең чираттагы утырышында рецензент итеп билгеләнгән операторлар һәм режиссерлар беренче таш салудан башлап бүгенге көнгә кадәр тупланган киноматериалларга җентекләп анализ ясадылар, уңай һәм кимчелек якларны күрсәттеләр, тәҗрибә уртаклаштылар. Ачык партия җыелышында иҗади эш мәсьәләсе аерым көн тәртибе итеп тикшерелде.

Хәзер КамАЗ төзелешендә өч группа тупланган. Ленинград документаль фильмнар студиясе белән берлектә тулы метражлы фильм эшләнә. Режиссер Харис Фәхретдинов тагын җиңен сызганып Чаллыга омтылды. Максаты — тагын бер фильм эшләү. Чаллыдагы корреспондентлык пункты иҗади штабка әверелде.

Завод конвейерыннан «КамАЗ» маркалы беренче автомобиль төшкәндә Казан киностудиясе цехларыннан автогигант төзүчеләрнең биш еллык батыр эшен яктырткан зур күләмле фильм чыгаруга безнең бөтен тырышлыгыбыз юнәлгән. Шуңа күрә автозавод төзелеше юллары буйлап көне-төне чапкан зур-зур машиналар артыннан кабыргасына «Кинохроника» дип язылган кечкенә «УАЗ»лар да калышмыйлар.

Калыша торган чак түгел...

## Мәгъфүр Ханнанов

# СИН КЕМ, САМАТОВ?..

Габдулла Хаҗиев, эштән кайткач, гадәттәгечә, яңа килгән газета битләрен актарырга кереште. Яшьләр газетасының соңгы битендә бер хәбәрдәге Гобәйдуллин фамилиясе аның игътибарын җәлеп итте. Исеме дә туры килә — Радик.

— Хәер, исеме дә, фамилиясе дә туры килгән кешеләр азмыни? — Ул шулай уйлады да газетаны өстәлгә куйды. Урыныннан торып, арлы-бирле йөрде һәм моннан өч ел элек булып үткән вакыйганы кабат хәтереннән кичерде. Аннан газетаны тагын кулына алды. «Радик Гобәйдуллин студентларның төзелеш отрядында...» Әйе, шул егет булуы да мөмкин, ул көннәрдән соң шактый вакыт үтеп китте бит инде...

...Хаҗиев тикшерү изоляторының сорау алу камерасында кесә карагы Мәхмүтовның җинаять эшен тәмамлап, соңгы протокол язып утыра иде. Шул вакыт ул кинәт күрше камерадагы кычкыру тавышына сискәнеп китте. Ни булды тагын, дип анда йөгереп керде һәм гадәттән тыш күренешкә аптырап калды. Пөхтә генә киенгән, чандыр гәүдәле егет шөрепләр белән идәнгә беркетелгән урындыкта тыныч кына елмаеп утыра, ә ачудан ярсып, йөзе агарган тикшерүче шашынып, өстәл янында басып тора иде.

Егетнең куллары тезендә. Ул: «Нигә юкка кызасың, кулыңнан килерлек булмагач, ни пычагыма тотындың бу эшкә?» — дигән кебек мәкерле караш ташлап, тикшерүчене үчекли. Ләкин тегесе аны-моны белми, кызганнан-кыза бара.

— Ниһаять, кем сез? Исем-фамилиягез, туган елыгыз һәм туу урыныгыз?..

Хаҗиев бу тикшерүчене беraз гына белә иде: университетның юридик факультетын тәмамлаганнан соң, прокуратурада эшли башлады. Берничә эшне уңышлы гына тәмамлаган иде. Һәм аны «өметле егет» дип мактарга тотындылар, өлкән тикшерүче дәрәҗәсенә күтәрделәр. Менә хәзер шул мактаулы кеше, йөгереп барганда дистанциядән төшеп калудан куркып төсе киткән спортчы кебек, кызганыч кыяфәттә иде.

Хаҗиев тикшерү изоляторыннан аның белән бергә чыкты, әмма аның эше турында сүз кузгатмады, тын урам буйлап үз хисләренә бирелеп кенә барасы килде. Алар урам буйлап бер-берсенә сүз катмый

шактый бардылар. Шулай дәшми генә бара торгач, яшь тикшерүче Хаҗиевка кинәт кенә сорау бирде:

— Сез машина йөртә беләсезме? — диде.

— Әлбәттә.

— Ә сезнең менә аны-моны уйламый тыныч кына машинада барганда, бөтенләй көтмәгәндә, руль идарәсе эшләми башлау вакыйгасын очратканыгыз булмадымы?

— Андый хәлнең дә булганы бар. Ул гаҗәеп күңелсез хис тудыра. Шундый вакыйгадан соң, бик озак машинага утыру түгел, борылып та карыйсы килми йөри.

— Ә ул вакытта сез бик нык курыккансыздыр?

— Дөресен әйтәм: ул вакытта миндә нинди тойгылар булгандыр, тәгаен әйтә алмыйм — куркумы, әллә сакланумы. Шуннан соң машинаның руль идарәсен ремонтладылар. Әмма озак вакытлар машина каядыр упкынга тәгәрәр кебек тоелды.

Тагын сүзсез калдылар. Тикшерүченең чырае караңгы иде. Кинәт ул тукталып калды һәм Хаҗиевның җиңеннән тотты.

— Бәлки бу эшне миңа башка кешегә бирергә кирәктер? Сез ничек уйлыйсыз? Әгәр мин үз холкымны бер тапкыр йөгәнләргә көчем җитмәгән икән, аның икенче тапкыр ычкынмавына кем гарантия бирә алсын. Юк, ул кире бәндә белән хәтта сөйләшә дә алмыйм. Ни кыйлана бит, үләрсең, билләһи, — дип кызу-кызу сөйләп китте ул.

— Бәлки чыннан да, — диде Хаҗиев, уйчан гына. — Үзегезгә карагыз тагын...

Эшне, әлеге яшь тикшерүчедән алып, Хаҗиевка тапшырдылар. Ул башта бик җентекләп җыйналган материалларны өйрәнеп чыкты. Эштәге материалларга караганда, ул кеше Саматов Сәлим Рәис улы. Ләкин кулга алганда аның үзе белән бер төрле дә документы булмаган. Шуңа күрә әлеге җинаятьченең исеме, фамилиясе, атасы исеме һәм туган елы белән туу урыны шартлы рәвештә теркәп куелган иде. Хәер, аның җинаяте дә гадәти түгел: Мансуров дигән кешенең машинасын туктаткан, акчасын талаган. Хаҗиев зыян күрүче Мансуровның гаризасын укыгач, Саматовны күз алдына китереп, аз гына елмаеп куйды. Ул Мансуровка, чын мәгънәсе белән әйткәндә, ачыктан-ачык янамаган да, турыдан-туры көч тә кулланмаган. Көпә-көндез, урамда, выжылдап килгән машина каршына килеп баскан һәм аны туктарга, ә машина хуҗасын машинадан чыгарга мәҗбүр иткән. Аннан тыныч кына Мансуровтан әҗәткә йөз сум акча сораган. Шул ук вакытта елмаеп кына, янамый-нитми һәм Мансуровка бөтенләй әһәмият бирмәгәндәй, ялтырап торган пычагын бер кесәсеннән икенче кесәсенә күчергән. Моны күргән Мансуров калтырап төшкән һәм кесәсеннән акчасын чыгарып, сүзсез генә Саматовка сузган.

Шуннан соң Саматов машина хуҗасына:

— Инде, туган, бер унбиш кенә минутка машинагызны да биреп торырга туры килер, — ди икән.

— Юк инде, анысын булдыра алмыйм.

Әмма тегесе, елмаюын дәвам итеп, тыныч кына:

— Сез тагын күпме яшәргә уйлыйсыз? — дигән.

— Алла күпме язгандыр бит...

— Ә, сез динле кеше икәнсез. Хәзерге вакытта андыйлар сирәк, бәрәкалла!

— Ә сез минем дингә булган мөнәсәбәтемне белү өчен туктатып сәдака алдыгызмы?..

— Бик дөрес, — дигән егет, — кем белән эш итүеңне белү бер дә начар түгел. Дингә ышанган кешеләрне яратам мин. Алар фани дөньяда өмет белән яшиләр теге дөньяда җәннәт көтә дип. Бу кеч-

кенә генә күңелсез вакыйганы да алла тәгалә шулай кушкандыр дип уйлый торыгыз...

Саматов машина хуҗасын этәреп җибәрә һәм машинага кереп утырып китеп тә бара.

Дүрт йөз метрлап киткәннән соң, Саматов «Жигули»ны юл читендә калдырып күздән югала. Машина аңа качу өчен генә кирәк булган икән.

Йөз сум акча өчен Мансуров жалоба бирен тә тормаган булыр иде. Чөнки ул, гомумән, милиция органнары белән элемтәгә керергә атлыгып торучылардан түгел. Әгәр көтелмәгән бер хәл килеп чыкмаса, бәлки бу вакыйганы берәү дә белми калган булыр иде. Машинасын тапкан шатлыгыннан Мансуров берәр кружка сыра эчмәкче булып бер-ике урынга туктала. Әмма бар киоскаларда сыра беткән вакытка туры килә. Булмаса, берәр стакан сок эчим дип, яшелчә-җимеш магазинына килеп керә.

Башта ул бер стакан виноград суы эчә. Аннан тагын бер стакан салдырып ала һәм сатучы хатын белән сөйләшеп китә, сүз ара сүз чыгып, аңа, үзе дә сизмәстән, башыннан кичергән вакыйганы сөйләп тә бирә.

Сатучы хатын кинәт җанланып китә.

— Ничек дидегез? Ябык кына, сызылып киткән нечкә мыеклы, ә үзе елмаеп кына тора, дидегезме?..

— Әйе.

— Чалбар балагының очлары чачакланып тора, ә үзе кызларга охшаганракмы?

— Нәкъ үзе.

— Шул, шул үзе. Кичә менә шушы магазинда минем дә йөз илле сум акчамны алып чыгып китте. — Сатучы хатын тиз генә акчаларын җыештыра да чыгып та югала. Мансуров согын эчеп бетергәндә сатучы хатын милиционер ияртеп килеп тә керә...

Җыйналган материалларны укыганнан соң, Хаҗиев бу кешене коры кул белән алырга мөмкин булмасына төшенде. Тыныч кына теләсә кемне чыгырыннан чыгара аладыр сыман тоелды ул аңа.

Тикшерүче камерасына кергәндә үк Саматов Хаҗиевка күптәнге танышын очраткан кебек елмаеп карады:

— О, исәнмесез! — диде. — Мин сезнең белән очрашуга бик шатмын.

— Ә мин алай димәс идем.

— Шулай да серләребез килешер, дип уйлыйм.

— Белмим! Сез үзегезне бик акыллы һәм булдыклы дип санлйсызмы?

— Һәрхәлдә, үземне ахмаклар санына кертәсем килми әле.

— Алай булгач, ничек монда килеп эләктегез соң?

— Кызганычка каршы. Әмма бу очракта мин түгел, ә башка кеше ахмаклыгы гаепле. Менә сез, әйтик, акылга бик үк тулы булмаган начальнигыгызның фикере белән килешмәдегез, ди. Бу нәрсәгә илтә? Әлбәттә, яхшыга түгел. Я шелтә аласыз, я урынсыз каласыз. Мин күргәннәр янында бу чүп кенә әле. Менә мин дә акылгы сайрак кешеләр аркасында менә монда килеп эләктем.

Хаҗиев каршында үз «платформасы» белән эш итүче хәйләкәр һәм уйлана белә торган җинаятьче утыра иде. Кайбер тикшерүче мондый кеше белән очрашканда аптырап кала. Җинаятьче шунда инициативаны үз кулына ала да аны тупикка китереп бастыра. Хаҗиев ул хәтлесен яхшы аңлады һәм ул аңа «һөҗүм» итә башлады.

— Без юкка сүз боткасы белән бер-беребезнең башын әйләнде-

рәбез. Минемчә, иң яхшысы дәлилләр һәм фактлар турында сөйләшү.

— Бик дөрес. Ләкин фактларга һәм дәлилләргә бәяне төрлечә бирергә мөмкин. Менә мине, мәсәлән, кеше талауда гаепләп кулга алдылар. Һәм шуның белән коточкыч ялгышлыкка юл куйдылар. Бу уйлап чыгарылган уйдырма, хәтта алай гына да түгел, бу миңа бәла ягу. Минем берәүгә дә физик яки психологик көч кулланып әйберләрен яки акчаларын алганым юк. Мин бары кайбер кешеләрнең байлыклары кирәгеннән ашканга, минем белән бик аз гына өлешен бүлешүне таләп иттем. Ә алар миңа яхшылык эшләүдән баш тартмадылар. Кеше кешегә бүре түгел. Бер-берең белән артык байлыкны бүлешү яхшы күренеш. Безнең әхлак аны мактый. Менә андыйлар арасында кайвакытта комсызлар килеп чыккан икән, монда минем бер гаебем дә юк. Менә шул комсыз-сараннарга дөньяда алардан башка кешеләр дә барлыгын аңлатырга туры килә. Тирә-яктагы кешеләрне онытып, һәр вакыт үзләре турында гына кайгыртмасыннар...

Әллә ул бу сүзләрне чын күңелдән инанып сөйлиме, әллә каршысында утыручы тикшерүчене үчеклиме — аңлавы кыен иде. «Юк, бу кәмит уйный, мине дә чыгырдан чыгармакчы була»,— дип уйлап куйды. Чыннан да аның җене чыкты, әмма аны җинаятьчегә сиздермәде, үзен сабыр тотарга тырышты. Шул вакыт бүлмәгә җинаятьчеләрне эзләү инспекторы Хәсәнов килеп керде. Ул Хаҗиевка нидер әйтмәкче булган иде, Саматов аны бүлдерде.

— Исәнмесез! — диде һәм аның үзенә генә хас булган теге елмаю белән йөзе балкып китте. — Эшләрегез барамы?

— Син кем соң? Минем сине гомеремдә дә күргәнем юк.

— Беренчедән, «сине» түгел, ә «сезне». Хәер, сезнең тәрбиясезлегегез мине бер дә гаҗәпләндерми. Андыйлар, кызганычка каршы, бар шул әле. Шулай да сез язмышыгызга рәхмәт әйтегез. Әгәр теге вакытта мин булмасам...

Хәсәнов:

— Кайчан? — дигәнен сизми дә калды.

— Займище станциясендә. Әгәр шул вакытта андагы малайларны борып алып китмәсәм, икенче көнне местком сезгә венок алырга дип, милиционерлардан берәр сум акча җыйнаган булыр иде. Мин ул малайлар белән агачлар күләгәсендә идем. Станциягә төшү белән сезнең кем икәнегезне дә, кемне эзләвегезне дә алар бик яхшы аңладылар. Аны мин дә аңладым һәм...

— Шуннан?

— Нәрсә шуннан булсын...

— Шуннан ни булды? — диде Хәсәнов.

— Без урманга таба киттек. Ә сезнең безнең арттан барырга батырчылыгыгыз җитмәде. Анда акыл белән эш иткәндә безне кулга алырга күп тә кирәкми иде. Сезнең икеләнү безгә ярап куйды.

— Минем икеләнүне каян беләсез?

— Белмәскә, безнең профессиябез шундый инде, — диде Саматов, авыр сулап.

— Ә менә хәзер шактый вакыт сезгә үз профессиягезне калдырып торырга туры киләчәк, — диде Хәсәнов, көлемсерәп.

Саматов нечкә бармаклы ябык кулларын җәеп җибәрде.

— Кызганычка каршы! Ләкин мине кулга алу операциясе гадел эшләнмәде. Йоклаган кешене кулга алу өчен әллә ни кирәк түгел,— диде һәм Хаҗиевка борылып өстәде: — Кайвакыт минем дә туйганчы бер йоклыйсым килә.

Саматов тикшерүченең дикъкатен җәлеп итүдән канәгатьләнеп, үзенең яхшы якларын күрсәтергә ашыкты. Һәрхәлдә, Хәсәновның

язмышы кыл өстендә торганда, үзе белән булган нindидер шикле кешеләрне урманга таба алып китеп, зур җинаятьне булдырмый калу һәм үзенең көпә-көндез ике кешене талавы турында ачыктан-ачык сөйләве, ә вакыты белән әрсез һәм оятсыз кылануы, кинәт сүзеннән туктап, уйчан кара күзләрен бер ноктага текәп уйланып калуы Хаҗиевны чын-чынлап гаҗәпләндерде. Ул, тәҗрибәле тикшерүче буларак, шуңа да төшенде: Саматов үзен гади тоткан булып сөйләшә-сөйләшә, тикшерүче аркылы үзенә кирәкле информацияне дә җыйный иде.

«Кем соң бу егет? Ни өчен ул җинаять юлына баскан? Үзе шактый сәләтле күренә. Нилектән ул бу сәләтен кирәкле якка юнәлтмәгән?» — бу сорауларга җавап тапмый торып, эшне дәвам итү мөмкин түгел иде. Тикшерүче һәрбер эшне тәмамлаганда җинаять ясауның сәбәбен ачарга тиеш. Аңа моны эшләргә закон куша, закон гына түгел, вөҗданы куша.

Шунысы ачык: Хаҗиев каршында әлеге яшь тикшерүче сөйләгәнчә кире беткән яшь-җилкенчәк түгел, ә бәлки тормышында килеп чыккан нindидер вакыйгага үзенчә бәя биреп, үзенчә «хөл иткән» кеше утыра. Бәлки чыннан да ул үзенең иптәшләре белән Займищеда Хәсәновны очраткандыр. Бәлки аларның аңа һөҗүм итәргә исәпләре дә булгандыр. Бәлки Саматов Хәсәновка аларның һөҗүм итүенә комачаулагандыр. Алай икән, тегеләре нинди җинаятьләр ясаганнар һәм Саматовның ул җинаятьләрдәге катнашу дәрәҗәсе нидән гыйбарәт. Бәлки Саматов сөйләгән «ахмаклар» җинаять ясарга өлгермәгәннәрдер. Һәм алар моңа хәзерләнәләр генәдер. Алай икән, моны тизрәк белергә һәм аңа юл куймаска кирәк...

Саматов яшелчә кибетендә эшләүче хатынны һәм Мансуровны талавы турында үз гаебен таныган һәм бу турыда берни яшермичә сөйләп биргән. Ләкин әлеге яшь тикшерүче, ул сөйләгән сүзләрне протоколга язып, аның астына: «Протокол мин сөйләгәннәрдән чыгып дөрес язылган һәм ул миңа укылды», — дип язуны таләп иткәч, Саматов: «Мин укый-яза белмим шул», — дип, әнә шул бер юл язуны язудан һәм аңа кул куюдан баш тарткан. Тикшерүче исә моны үзен мәсхәрәләүгә санап кызып китә. Тиктомалга тикшерүчене үчекләп утырырга Саматовка нигә кирәк булган? Моның белән аңа ни файда? Хаҗиев ул турыда уйлап алды да:

— Саматов, бәлки безгә ачыктан-ачык сөйләшергә вакыттыр? Тегеннән-моннан төрттерел, читләштереп сөйләшкәнче ир кеше ир кеше белән сөйләшкән кебек сөйләшсәк, сезнең эш бераз җиңеләер.

— Анысы сездән тора. Әгәр сез теләсәгез, мин һәр вакыт әзер.

— Менә сез рәшәткәләр артына башка бер кеше ахмаклыгы аркасында эләктем, дисез. Ләкин бу хәтлесен әйтүе кыен. Шунысын истә тотыгыз: сез үзегезнең җиңел уйлавыгыз аркасында җитди җәзага тартылуыгыз мөмкин. Сезнең кебек фикер йөртә белә торган кешенең нindидер кәгазь язып үзен фаш иттерүне ничек аңларга?

— Аңламыйм, сез ни әйтергә телисез?

— Хәзер аңлатам. Моннан ике атна чамасы элек, сезне кулга алган көнне сезнең камерадан утыручы Сәүбанов иреккә чыгарылды. Хәтерегездәме? Ул Түбән Камадан килгән төзүче иде. Менә шул кеше кесәсеннән менә бу язу табылды. Тикшерү изоляторы администрациясе бу язуга әллә ни әһәмият бирмәгән, чөнки өстән карагандa бу язуда шикле нәрсә юк сыман иде. Сәүбанов: «Мин ул язуны кесәмә кем салганын да, кемгә тапшырырга кирәклеген дә белмим», — дип аңлатты. Камерада утыручы биш кеше калды, шуларның дүртесе, язуны без язмадык дип, аңлатма яздылар. Аларның язуларын график экспертизы белән тикшергәннән соң, чыннан да шулай булып чыкты. Ә сез шул көнне генә кулга алындыгыз. Сезгә

башта шик төшмәде һәм ул язу турында оныткан да идек инде. Асылда язуны сез язган булгансыз икән. Хәер, бу турыда минем сөйләүнең кирәге шул кадәр генә. Боларны сез үзегез барын да беләсез.

Боларны сөйләгәндә Хаҗиев бу хәбәрнең тәэсирен күрергә тырышты. Ул бер генә секунд та Саматовтан күзен алмады. Әмма Саматов дәшмәде. Хаҗиевны күбрәк сөйләндереп, аның сүзләреннән үзенә кирәк мәгълүматлар җыя иде булса кирәк.

Тикшерүче белән җинаятьче арасында һәр вакыт кискен көрәш бара. Ул көрәшнең һәрберсендә нindидер үзенә генә хас булган үзенчәлеге була. Аны кайберәүләр «кагыйдәсез уен» дип атамакчы булдылар. Бу бөтенләй үк дөрес түгел. Чөнки аның кагыйдәсе — җинаять процессы кодексы бар. Ничек кенә булмасын, берәүнең дә бу көрәштә закон бозарга хакы юк. Әле менә хәзер генә Хәсәновның «син» дигәненә дә Саматов ничек керпесен кабартты.

Хаҗиев Саматов белән әңгәмәсен дәвам итте.

— Шулай итеп, Саматов, биредә сез ике төрле ялгыш ясадыгыз. Беренчесе: язуны ирекә чыга торган кешегә тапшыруда. Икенчесе, монысы мөһимрәге: сез әгәр кул куйсам, язуымны танып, фаш итәрләр дип уйладыгыз һәм протоколга берничә сүз язудан баш тарттыгыз. Бу ике факт бер-берсе белән котылгысыз бәйле.

— Чыннан да сез логик фикер йөртәсез. Ләкин сезгә берничә сорау бирергә мөмкинме?

Башка тикшерүче булса, сорауны мин бирәм, сез түгел, дияр иде. Мин андый формальлеккә бармыйм.

— Рәхим итегез.

— Минем аңлавымча, сезнең кулда нindидер язу бар. Әмма аны кем язганын бик үк белеп бетермисез. Протокол мәсьәләсенә килсәк, чыннан да минем грамотамның рәте юк. Шуңа күрә, әгәр сез ул язуны мин язган дигән нәтиҗәгә килсәгез, моны бик яхшылап тикшереп, котылгысыз дәлилләр китерүегез яхшырак түгелме?

— Сез, бездә сезнең язу үрнәкләрегез юк, дәлилләр җитәрлек түгел димәкче буласыз. Әмма аны бик яхшылап тикшерергә була. Сезнең язу үрнәкләрегезне сезне тәрбияләп үстергән балалар йортыннан соратып алырга мөмкин бит. Аңлатуыгызга караганда, сез Бакалы балалар йортында үскәнсез? Шулаймы? Ләкин бу бик күп вакытны алыр иде...

— Әллә сез минем Бакалы балалар йортында тәрбияләнүемә ышанмыйсызмы?

— Дөрес, легенда начар уйланмаган. Ул балалар йортында биш ел элек янгын чыга һәм барлык документлар янып бетә. Ата-анам бәхетсезлеккә очрап һәлак булдылар, урта мәктәпне тәмамлагач, балалар йортыннан киттем һәм шуннан соң бер җирдә дә эшләмәдем, дисез. Гаҗәп, ул гомердән бирле нинди средствога яшәдегез соң?

— Турыдан-туры җавап бирү миңа җиңел түгел. Джентельмен буларак, кайбер нәрсәләрне әйтүне кирәк санамыйм.

— Сез бай хатыннар «мәхәббәте» хисабына яшәдем димәкче буласызмы?

— Әйе, мин акчалы хатыннарны сөям, алар да мине...

— Фамилияләрне санап торуның кирәге булмастыр дип уйлыйм, — диде Хаҗиев, киная белән. — Тик андый мәхәббәт яшелчә магазинындагы сары чәчле хатынга төшкән мәхәббәткә охшашлы булса, ул хатыннарның язмышы көнләшерлек түгел.

— Сез яңадан төрттерергә тотындыгыз. Алай булганда, закон нигезендә, минем сезгә, гомумән, җавап бирмәскә хакым бар. Ул вакытта сезгә минем эшне җыйналган материаллар нигезендә генә

хәл итәргә туры килер. Бусы сезнең файдага түгел. Кыскасы шул, әгәр сезнең минем узган тормышым турында шигегез туса, аны ачыкларга ярдәм итү яки итмәү минем иректә. Сез аны тулысы белән үзегез ачыкларга бурычлы.

Саматовның тормыш юлы белән Хаҗиев тикмәгә генә кызыксынмады, әлбәттә. Бу аның җинаять юлына басу сәбәпләрен ачачак. Саматов үзе узган тормышы турында тикшерүченең исенә төшерде. Әмма җинаятьче моны тикшерүчегә ярдәм итү йөзеннән түгел, ә аның ялгышуына кинаяләп, мәсхәрәләп әйтте. Хаҗиев моны бик яхшы аңлады.

Тикшерүче белән җинаятьче арасындагы көрәш һәр вакыт диярлек тикшерүче файдасына тәмамлана. Бирелә тикшерүчегә фән, тәҗрибә, кешеләр, хакыйкать үзе ярдәмгә килә.

Саматов Хаҗиевка дәлилләр белән эш итәргә һәм шулар белән операция ясап нәтиҗә ясарга тәкъдим итте. Хаҗиев та бу эшкә буш кул белән керешмәде. Саматовны тентегәндә, аның кесәсеннән Бигештән Казанга самолет билеты табылган. Ләкин ни өчендер билет Саматовка түгел, ә Гобәйдуллинга язылган булган.

— Сез сентябрь аенда Чаллыда нишләдегез?

— Мин анда яшәдем. Ләкин аңлап җиткермим. Моны гына белү өчен өч сәгать буена сөйләшүнең нигә кирәге булды соң? Әгәр сорасагыз, мин аңа әллә кайчан, шундук җавап биргән булыр идем.

— Анда кайда тордыгыз?

— Хакасс урамы, 72 йорт, 12 квартира. Вәлиәхметовларда. Билгеле, пропискага кереп-нитеп тормадым. Үзегез беләсез, Чаллыга һәр көнне меңләгән кеше килеп тора. Нигәдер аларның һәммәсенең дә тизрәк пропискага керәселәре килә. Әмма миндә андый теләк тумады. Аннан соң минем милиция работникларын бик борчып йөрисем дә килмәде. Минем монда эләгүемне белсә, Вәлиәхметов та аларда торуым турында бик әйтәсе килмәс. Аның да милиция органнары белән дуслыгы бик чамалы...

Чаллыдан җавапны озак көтәргә туры килмәде. Андагы хәбәргә караганда, Чаллы шәһәрендә Хакасс урамында андый кешенең яшәмәве генә түгел, хәтта ул урамда андый йортның булмавы да ачыкланды. Бүтән шәһәрләрдән дә андый кешенең пропискада булмавы турында җаваплар алынды. Мәсьәлә ачыкланган, аның ике кешене талавы тиешенчә дәлилләр белән ныгытылган, Саматов кылган җинаятьләрен таный һәм эш судта җиңел генә үтәчәк, аның тормыш юлын ачыклап торуның кирәге юк, — дип, прокурор эшне «түгәрәкләргә» ашыктырды.

Әмма Хаҗиев моның белән килешергә теләмәде. Саматовның, керпе кебек инәләре әченә яшеренеп, чәнечкеләрен һаман саен тырпайтуы теңкәсенә тиде. Ни өчен җинаять юлына басуының бөтен сәбәпләрен ачкач кына аны суд каршына бастырырга үз-үзенә сүз бирде ул. Бәлки аның болардан да яманрак җинаяте бардыр?.. Ул шуны яшерер өчен шулай кыланадыр? Боларны ачу гадел хөкем өчен дә, Саматовның үзе өчен дә кирәк дип санады Хаҗиев. Болардан тыш кешедә мин-минлек дигән нәрсә дә бар бит әле: югары белемле, тәҗрибәле юрист була торып, Хаҗиев Саматов каршында, җинаятьче каршында көчсез булып, җиңелүче булып калсынмыни?!

Саматов исә тикшерүченең максатын бик яхшы аңлады. Шулай да үз дигәненнән кайтмады, төпченер-төпченер дә кул селтәр, дип өметләнде.

Саматовның бу өметен юкка чыгарырга кирәк иде. Хаҗиев аның белән тагын бер тапкыр очрашты. Чаллыда андый адресның юклыгын һәм андый кешенең яшәмәвен әйткәч, Саматов хәйләкәр генә:

— Гаеп миндә, — диде. — Гафу итегез, мин белә торып алдаш-

тым. Мин бала чагында тикшерүче булырга хыяллана идем. Хәер, ул хыялдан хәзер дә арынып беткәнем юк. Менә шулай, уңайлы вакыт килеп чыккан саен, үземнең тормышка ашмаган хыялымны канәгатьләндереп калырга телим. Мин шулай бик күп нәрсәләрне ачыктан-ачык яшерми сөйлим. Сезне бәлки минем болай ачыктан-ачык сөйләвем гаҗәпләндерер. Ә бит, принципка китсә, минем бөтенләй дәшмәскә хакым бар. Ләкин күрәсез, мин сезнең белән очрашканнан бирле гел сөйләшәм, чөнки сезнең белән сөйләшүдә мәгънә бар. Сез тиң әңгәмәдәш. Үз тиңең белән сөйләшү күңелле. Әгәр теләсәгез, мин тагын да ачыграк сөйләшә алам. Башваткыч мәсьәләнең ничек чишелүен күзәтү минем өчен һәр вакыт кызык. Хәтта бу детектив романнарны укуга караганда да кызыграк.

— Бәлки, — диде Хаҗиев. — Ләкин, миңа калса, сез бик югарыга үрелмәкче буласыз түгелме? Сезнең белән мин генә түгел, ә закон сөйләшә... Шуны истә тотыгыз. Хәзер соңгы вакытта кайларда яшәвегез турында үзегез сөйләп бирерсез дип ышанам.

— Ник сөйләмәскә, бик рәхәтләнеп. Ни өчендер башта бу турыда бик сөйлисе килмәгән иде. Ә хәзер менә сөйлисем килә. Газеталардан һәм башка информация чыганакларыннан күп кенә безнең якташларның чит илләрдә яшәве турында ишеткәнегез бардыр. Менә шуларның берсе мин инде.

— Менә ничек? Кайсы илдән һәм кайсы шәһәрдән килеп чыктыгыз соң бу якларга?

— Нью-Йорктан.

— Алай! Бусы инде сезнең моңарчы булган ялгышларның иң зуры, иң төп һәм иң мөһимнәренең берсе.

— Аңлап бетермәдем. Ни өчен?

— Сезнең һөнәр вәкилләренә анда инде чын иркенлек.

— Ләкин мин андагылар арасында иң вагы булып саналыр идем. Вак бернәрсә булып койрыкта чуалуны җенем сөйми...

Бу сөйләшүләрдән соң берничә көн үтеп китте. Хаҗиев һаман эзләнде. Бер көнне, һич тә көтмәгәндә, тикшерүчегә доцент Гобәйдуллинның үзенең югалган улы Гобәйдуллин Радикны эзләве турында милиция органнарына мөрәҗәгать итүен әйттеләр. Ул хәбәрдә доцент малаена гына хас булган билгеләре барлыгын һәм шулардан берсе — кулының терсәктән югары өлешендә «Радик» дигән татуировка булырга тиешлеге әйтелгән иде. Радик Алабуга урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан медицина институтына керергә дип, документларын җибәргән. Керү имтиханнарыннан соң ата-анасына: «Имтиханнар уңышлы үтте, сентябрьдән укый башладым», — дип телеграмма биргән. Шуннан югалган, хат та язмаган, телеграмма да җибәрмәгән. Улларыннан хәбәр килмәгәч, эти кеше Казанга киткән. Шунда улының конкурстан үтмәвен һәм институтка керә алмавын белгән. Малайны аннан-моннан эзләп караган, таба алмагач, милициягә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булган.

Бу көннәрдә Саматов эшен тикшерүне сузган өчен Хаҗиевка берсе артыннан икенче күңелсезлекләр килеп торды.

— Сезне цейтнот куркынычы көтә, иптәш Хаҗиев, — диде прокурор аңа чираттагы оператив киңәшмәдә.— Законда каралган сроклар узып китте. Аны озайтуны сорап республика прокурорына барырга урын тапмыйм. Аннан соң ул аны бу хәлендә озайтмаячак та.

Чыннан да законда каралган сроклар узып китте. Әмма Саматовның шәхесе һаман билгеле түгел иде әле. Бәлки бу егет, чыннан да, бөтенләй Саматов түгел, ә... Әлбәттә, аның кулындагы «Радик» дигән татуировканы тикшерү берни түгел. Ләкин моны тупаслык белән чишендереп карарга ярамый. Хәтта ул булса да, ул шунда берәр хәйлә табачак. Иң мөһиме: аны үзе турында үзе сөйләргә мәҗбүр-

итү. Әмма моның өчен көчле дәлилләр кирәк. Яңа дәлилләр эзләү инде болай да озакка сузылган тикшерүне тагын да сузу дигән сүз. Шунысы да бар: эгоист егетнең җинаять кылу сәбәпләре, аның нигезләре ачылмый калынуы мөмкин. Ә моны ачу зарури. Бик зарури. Һәрбер җинаятьнең тамырына төшеп, аның сәбәпләрен ачсаң гына, тикшерүче буларак, син үз вазифаңны үтәдем диярга хакың бар...

Хаҗиев тикшерү изоляторына гадәттәге вакытында килде. Дежурныйга Саматовны китерергә кушып, үзе каравылчы будкасында калды. Менә авыр тимер ишекләр чыгырдап ачылды, аннан дежурный белән Саматов күренде. Нәкъ шул вакыт ишегалдында эшләүче тоткыннардан кемдер «Радик» дип кычкырды. Саматов исә көтелмәгән тавышка тетрәп китте. Аның ябык озын муены тавыш иясен эзләп төрле якка борылды һәм шунда Саматовның күзләре Хаҗиев күзләре белән очрашты. Аның күзләрендә каушау күбрәк идеме, әллә куркумы — билгеләү кыен иде. Ләкин бу озакка бармады. Алар шунда ук үзгәрделәр һәм аның йөзендә һәм күзләрендә Хаҗиевка таныш елмаю хасил булды. Ул берни булмагандай:

— Хәерле көн, — дип, Хаҗиев белән исәнләште.

Тикшерүче камерасына кереп утыргач, Хаҗиев тагын бер Саматовка карады һәм шунда ул ирешәчәк максатының якынлыгын аңлады. Тыштан караганда ул, элеккечә, бармаклары белән тезләрен тоткан килеш, тыныч кына утыра сымак иде. Ләкин аның күзләре!.. Ә менә күзләре, упкын читенә куып китергәч, бөтен көчен куеп соңгы сикерешкә омтылган яраланган ерткычныкы кебек ялтырыйлар иде.

— Гражданин тикшерүче, — диде ул, кичерешләрен яшерергә тырышып, — кайчан да булса сезнең берәр кешедән курыкканыгыз булдымы?

— Кешеләрдән? Башларында акыллары булганнарыннан, әлбәттә, курыкканым юк. Ә менә җүләрләреннән мин куркам. Шуңа күрә җүләрне читләтеп үтәргә тырышам.

— Минем турыда сезгә фикерләрегезне үзгәртергә туры килер, — диде ул, бераз уйга калып. — Минем белән мөгамәлә шундый урынга җитте ки, аны дәвам итү сезнең тормышыгызга куркыныч китерүе мөмкин. Сез башта ук дөрес юлда булдыгыз. Минем биографиям шактый кызык. Әмма үзегезнең тыныслыгыгызны юкка чыгару бәясенә аның белән кызыксыну, нигәдер, акылга сыеп бетми.

— Минем тынычлыгымны бозу мөмкинлеге булырмы? Шикләнәм!

— Мин булмасам... Башкалар табылыр.

Ниһаять, ул сарык тиресен салып ыргытты да «ерткыч» тешләрен күрсәтте. Ләкин кай арада бу кеше «ерткычка» әйләнгән. Әллә шулай, «уйнап» Хаҗиевның нервлары ныклыгын сыныймы? Ничек кенә булмасын, Хаҗиев арадагы соңгы пәрдәне ертып, аның кем икәнлеген ачыкларга булды.

— Сез мине хөрмәт итәм, дидегез,— диде Хаҗиев,— әмма сез үзегезнең хисләрегезне бик сәер күрсәтәсез — мине куркытмакчы булып яныйсыз. Кем икәнлегегезне яшермәкче буласыз. Асылда сез Саматов түгел, ә Радик Гобәйдуллин. Теләсәгез, мин сезгә биографиягезнең кайбер детальләрен күрсәтеп китәм. Мәсәлән, сез Казанга институтка кермәкче булып килдегез. Мәктәптә укыганда сезне булдыклы укучы дип телгә алганнар. Чыгарыш имтиханнарын да «бишле»гә генә бирдегез. Бу кечкенә уңышлар башыгызны әйләндергән. Җәй буе ныклап имтиханнарга әзерләнмәгәнсез. Шуның аркасында институтта имтиханнарны уңышлы бирә алмагансыз. Шуннан туганнарыгыз янына кире кайтырга хурлангансыз. Монысы күп яшьләр башыннан үтә торган хәл. Ләкин алар шунда ук берәр урынга эшкә керәләр

дә яңадан имтиханнарга хәзерләнә башлыйлар. Сез моны эшләмәдегез. Сез җинаять юлына бастыгыз һәм күпә-көндез бер гөнаһсыз кешеләрне талый башладыгыз.

— Дөрес түгел. Минем бер вакытта да гадел кешеләргә һөҗүм иткәнем булмады...

Радик Гобәйдуллин җиңелдә. Әйе, җинаятьче кайчан да булса бер җиңелергә тиеш. Бу тикшерүченең нинди көч куеп эшләвенә бәйледер дип уйлады Хаҗиев. Ә моңа ирешү өчен аңа ни хәтле көч, ни хәтле түземлелек кирәк.

Радик тикшерүчегә үзенең кыска тормышындагы иң вак детальләрен сөйләп бирде. Ул аларны сөйли һәм, кылган эшләрен анализлап, аңа нәтиҗә ясамакчы кебек иде. Тик ул кылган җинаятьләренә үкенми, акланырга да тырышмый, үзе өчен аларны котылгысыз бер нәрсә дип аңлый булса кирәк: сөйләвендә җинаять кылган өчен түгел, ә «җеп очларын» җыйный белмәве, милициягә эләгүе өчен генә үкенүе сизелеп тора.

— Гражданин тикшерүче, сезгә бер үтенечем бар.

— Тыңлыйм.

— Минем эшемне «Саматов» итеп тәмамлагыз.

— Ни өчен?

— Минем ике абыем бар. Алар менә дигән егетләр. Әнием бар, аның эш урыны да сезгә билгеле. Бер абыем врач, озакламый галим булыр дип торалар. Талантлы егет, диләр үзен. Икенчесе бер институтның махсус факультетында укый — инженер булырга җыена. Гобәйдуллиннар семьясында хөкем ителгән кеше булу алар язмышына нинди йогынты ясавын әйтеп торуның бер кемгә дә кирәге юк...

Бу егетнең ата-анасына һәм туганнарына ни хәтле кайгы һәм авырлыклар китерүен күз алдына китерүе кыен түгел. Өч туган һәммәсе дә бер үк шартларда тәрбияләнгәннәр, өчесе дә сәләтле. Шуларның икесе яхшы юлда, ә менә аларның берсе — Радик кеше талаучы, җинаятьче булып чыга. Ни өчен? Бәлки бу сорауга җавапны Радикның ата-анасы бирер? Юк, алар: «Малайлар бер үк шартларда үстеләр. Аның җинаять кылуына бер төрле дә сәбәп юк», — диярләр. Ә бит җинаять кылынган. Сәбәпсез бернәрсә дә эшләнми. Бәлки безнең гаебебез балаларның һәрберсен бертөрле тәрбияләргә тырышуыбыздадыр. Күп вакытта үзебез үк кешеләргә индивидуаль тәрбия бирергә кирәк дип сөйлибез бит, әмма ул индивидуаль тәрбия бирүнең нечкәлекләрен белмибез. Менә хәзерге шартларда, мең төрле информация средстволары эшләп торганда, алар белән кайбер шикле малай-шалайлар очрашканда, төрле йогынтыларга тиз бирелүче аумакай малайларны ничек тәрбияләргә? Балаларны мәктәп классларында бер төрле ысул белән тәрбияләүче укытучыларны кичерергә мөмкин. Ә менә ата-ананы биредә кичерү мөмкин түгел, — дип уйлады Хаҗиев.

Бу үзенчәлекле егет эшен судта караганда, Хаҗиев хөкем залына кереп чыгарга булды. Радикны хөкем залына алып кергәндә, залдагылар, гаҗәпләнеп, нидер пышылдаштылар. Күпләргә гаҗәпләнергә урын бар иде. Читтән караганда ябык гәүдәле, пөхтәлеге белән башкалардан аерылып торган бу яшь егет бөтенләй кеше талаучыга охшамаган иде.

Хөкем алып баручы судьяларга да, прокурорга да, адвокатка да эшне карау берьяклап уйлаганда авыр һәм катлаулы түгел иде. Радик судта, тикшерү вакытындагы кебек, боргаланмады, зыян күрүчеләр сүзендә аз гына төгәлсезлек килеп чыкса да, аларга тиешле төзәтмәләр кертте, алдаша башласалар, бөтен көче белән аларга ташланды. Ул үзен-үзе тотышы белән педант тәрбиячегә охшый иде.

Хаҗиевка аның мондый төгәллек сере бик ачык иде. Хөкем каршында дөреслекне тулысынча сөйләп биру җиңел җәза алу дигән сүз. Бу кеше, күрәсең, монысын да бик яхшы үзләштергән булса кирәк. Тик залда суд барышын тыңлап утыручыларның күбесе аның үз-үзен якламавын бик үк аңлап җиткермәделәр, ачыктан-ачык сөйләвен үзен-үзе «батыра» дип уйладылар. Кызганычка каршы, аларга җинаять кодексының 38 статьясындагы 9 пунктында язылган «чын күңелдән тәүбә иту яки, килеп, гаебен икърар иту, шулай ук җинаятьне ачуга актив ярдәм иту» җәза билгеләгәндә җаваплылыкны җиңеләйтә торган шартларның берсе икәнен белмиләр иде... Ниһаять, Радикка соңгы сүз бирелде.

— Гражданин судьялар! Мин менә ике айдан артык тикшерү изоляторында утырдым. Шул гомер эчендә уйланырга да, үзем кылган җинаятькә тиешенчә бәя бирергә дә вакыт җитәрлек булды. Зарар күрүчеләрдән гафу үтенергә теләмим. Алар үзләренә тиешлесен иртәме-соңмы барыбер алырлар әле. Мин бары алар белән көрәшү юлында ялгышуыма гына үкенәм. Миңа монда законлы юл табарга кирәк булган икән. «Законны хөрмәт иту һәркемнең ихтыяҗына әйләнергә тиеш», — диләр. Бу бик дөрес. Ләкин, гражданин судьялар, аңларга теләсәгез биредә гаеп миндә генә түгел бит. Мин азмы-күпме гомеремдә нихәтле детектив романнар, повестьлар һәм китаплар укыдым. Күпме чит ил кинолары карадым. Радиодан чит илләр тапшыруларын тыңладым. Һәм... Һичшиксез, минем нindидер, искиткеч бер эш эшлисем килә иде. Минем институтка кергәндә уңышсызлыкка очравым менә шундый ялгыш юлга керүгә бер сәбәп булды да. Гаебем бар. Тиешле җәзаны биру сезнең эш. Һәрхәлдә, хәзер мин гаебемне таныйм... Закон бозу юлы белән яхшылык эшләү мөмкин түгеллеген дә менә хәзер генә аңладым...

— Шайтан, аның сүзләрендә нindидер дөреслек бар сыман, — диде кемдер.

— Ярый ла аның бу тәүбәсе чын күңелдән булса, — дип уйлады Хаҗиев һәм ишеккә юнәлде...

...Бу вакыйгага өч ел үтеп тә киткән. Бу гомер эчендә Радик хөкем җәзасын үтәргә дә, югары уку йортына керергә дә өлгергәндер, мөгаен.

Марсель Зарипов

# БИЕКЛЕКЛӘР

*Нәҗип Җиһанов һәм аның иҗаты турында эскизлар*

## 1



Бервакыт миңа төшке ашны Нәҗип ага Җиһанов белән бергә ашарга туры килде. Композиторның ашханәгә һәр вакыт иң соңгы кеше булып керүе һәм унбиш-егерме минут эчендә тамак туйдырып чыгып китүе турында ишеткәнем бар иде. Сүз җае чыккач, мин аннан моның сәбәбен сорадым.

— Шулай күнегелгән, — диде ул, искитмәгән кыяфәт белән. — Аш өстәле янында иркенләп утырыйм дисәң, тамак ялгап алу өчен генә дә кимендә ярты сәгать вакыт кирәк. Ә болай унбиш минут вакыт янга кала.

— Унбиш минут вакыт күпмени ул?

— Беләсезме, — дип җавап кайтарды Нәҗип ага, — безнең заманда минутларның кадерен белергә туры килә. Бүген унбиш минут, иртәгә унбиш... Ун көнгә йөз илле, йөз көнгә мең биш йөз минутка җыела... Ә бит кешенең уртача гомере нибары утыз миллион минут. Ул аның өчтән бер өлешен йоклап үткәрә, икенче өлеше исә көндәлек мәшәкатьләргә, ял итүгә китә. Шулай итеп, эшләргә күпме вакыт кала? Аз, бик аз!

Әйе, ифрат дөрес сүзләр! Иҗат эше, телисеңме-юкмы, сине вакытның кадерен белергә өйрәтә, бөтен тормышыңны кырыс бер тәртипкә салырга мәҗбүр итә.

Нәҗип Җиһанов кебек, берьюлы күп төрле эшләр башкара торган иҗат кешесе өчен вакытның кадерен белү бигрәк тә зарури. Менә чирек гасырдан артык инде ул консерваториягә җитәкчелек итә. Ул — Россия һәм СССР Композиторлар союзы идарәләре секретаре, партиянең Татарстан өлкә комитеты члены, Татарстан композиторлар союзы идарәсенең председателе, Ленин премияләре комитеты члены, республикабыз Верховный Советы депутаты.

Композиторга иҗат эшчәнлеген җәмәгать, дәүләт, партия оешмаларында эшләү белән бергә бәйләргә туры килә. Җәмәгать, административ, хуҗалык эшләре кайбер көннәрдә аңа хәтта пианино янына килерлек тә ара калдырмый.

Төзүче йортлар салырга, шагыйрь шигырь язарга, пианист уйнарга, композитор музыка иҗат итәргә тиеш, дисәм, минем белән беркем дә бәхәсләшмәс дип уйлыйм. Нәҗип ага Җиһановның да вакытын бары тик музыкага гына багышларга тулы хакы бар. Күнекнә күпмедер вакыт язып утыру, аның өстенә консерваториядә лекцияләр уку, үзенең коллегалары белән очрашып, бүгенге музыка сәнгате мәсьәләләре хакында кызып-кызып бәхәсләшү — боларның барысы да композитордан ифрат зур киеренкелек таләп итә. Үз әсәрләре уйнала торган концертларга, спектакльләргә йөрү, тамашачы чакырганда сәхнәгә күтәрелү, танылган балеринага яки гастрольгә килгән солисткага ихтирамны белдерү, республикабызның симфоник оркестры җитәкчесе дирижер Натан Рахлинны дусларча кочып алу белән чикләнергә мөмкин ич, югыйсә. Юк, Җиһановны болары гына канәгатьләндерми. Беренче карашка, нindидер сәер кеше! Ул бернинди эштән дә баш тартмый, көндәм, тыңлаучан йөк аты шикелле, теләсә нинди авыр йөкне карусыз сөйри бирә.

Нәҗип Җиһановның музыкаль әсәрләрен бик яхшы беләм дип әйтә алмыйм. Аның әсәрләрен җентекләп тикшерү — белгечләр эше. Композиторга карата булган фикеремне башкаларга көчләп тагуның да кирәге юк. Ә менә бер нәрсәгә махсус тукталмыйча булдыра алмыйм. Нәҗип Җиһановның һәр әсәре, моннан дүрт дистә ел элек иҗат ителгәнме ул, яки беренче тапкыр кичә генә башкарылганмы, безне бай хисле, профессиональ югарылыкта язылган булуы белән әсир итә. Ул әсәрләрдә художникның шатлык-кайгылары, борчылу-кичерешләре калку булып чагыла. Композитор турында, аның иҗаты, тормышы турында сөйләгәндә мин үземә башка бурычны — үз халкының музыка культурасын үстерүгә зур өлеш керткән кеше турында сөйләү бурычын куям.

Музыка — тормышның бөтенләй үзгә бер өлкәсе. Һәр милләтнең музыкаль байлыгы гасырлар буена туплана килә, күпмедер вакыттан соң югары биеклеккә күтәрелү өчен бер буыннан икенче буынга түкми-чәчми тапшырыла бара. Әмма татар халкы бу биеклеккә бер кеше гомере эчендә — Бөек Октябрьдан соң узган ярты гасыр вакыт эчендә күтәрелде. Сигез опера, өч балет, дүрт зур симфония, күп санлы маршлар, җырлар, композиторның татар профессиональ музыкасының иң уңышлы дип саналган әсәрләренә бирелгән өч Дәүләт премиясе — Нәҗип ага Җиһановның үз халкына бүләге әнә шуннан гыйбарәт.

## 2

Күпләргә билгеле: бөек Моцарт үзенең беренче әсәрен бала чагында ук язган. Бу яшьтә башка сабыйлар әле гади алфавитны да рәсемнәргә карап кына танырга өйрәнәләр.

Италия тамашачыларын үзенә табындырган Нино Рота, «музыкадан тукылган» кеше, иҗат эше белән тугыз яшендә шөгыльләнә башлаган.

Рус музыкасының бөек тылсымчысы Петр Ильич Чайковский унсигез яшьлек Сергей Рахманиновның «Чегәннәр»гә нигезләнеп язылган үлемсез «Алеко»сын тыңлаганнан соң ук аңа бөек киләчәк юраган.

Татар композиторының сәнгатькә килү юлы боларның берсенекенә дә охшамаган. Нәҗип Җиһанов, әнисез калып, балалар йортында үсә. Кече яшьтән кешенең кайгы һәм шатлыклары, мәхәббәте һәм газапларына, иң нечкә кичерешләре турында сөйли торган сәнгатьне ярата, гармун тарта, бармаклары белән пианино клавишларына суккалап карый. Ниһаять түзми, шул илаһи сәнгатьнең серләренә төшенергә теләп, укырга дип Казанга юл тота. Җиде-сигез яшьлек сабыйлар

музыкага өйрәнә башлаган мәктәптә укырга аның инде яше узган була. Аңа бердәнбер юл кала — техникумга керү.

Егетнең документларын кабул итәләр, чыннан да музыкага укырга телисеңме, авырлыклардан курыкмыйсыңмы, дип сорашалар. Әйе, Нәҗип укырга бик тели, авырлыклардан курыкмый, барлык кыенлыкларны җиңеп чыгачагына ышандыра. Аңа үзе теләгән белгечлек буенча беренче имтиханга керергә рөхсәт итәләр.

Ә белгечлек дигән нәрсә — әллә нинди нокталар, вак кына сызыклар, бернәрсә дә аңлап булмый торган билгеләр белән чуарланган һәм кем өчендер кара урман, ә кем өчендер гап-гади әлифба саналган кәгазь битеннән гыйбарәт икән. Бу кәгазь бишенче класс укучысы өчен тапкырлау таблицасы, студент өчен интеграл, инженер-конструктор өчен сопромат кебек үк иң элементар бер нәрсә булса да, Нәҗипнең әле аны беркайчан да күргәне, беркайчан да кулына тотып караганы булмый.

Шуның белән имтихан тәмам, егеткә өенә кайтып китәргә дә мөмкин. Музыканың әлифбасын да белмәгән, кулына бер генә тапкыр да нота тотып карамаган кешене кем студент итеп алсын? Махсус программа буенча аны кем укытсын?

Егетнең күзләрендә кайгы билгеләре чагылгандыр, күрәсең: сизгер күңелле педагог Нина Александровна Шевелина аңа балалар музыка мәктәбенең бөтен курсын бер ел эчендә үзләштерергә тәкъдим итә. Бәлки бу аның: «Риза булырмы, юкмы?» дип сынап каравы булгандыр...

Балалар йортында үскән һәм пианиноны бары тик чама белән, үзенчә суккалап маташкан егет бу тәкъдимгә риза булудан нәрсә югалта соң? Нина Александровнаның тәкъдименә ул, әлбәттә, шатланып риза була. Музыканың элементар нигезләрен өйрәнеп, бер елдан соң техникумга укырга керә. Аннан Мәскәүдә махсус училищеда укый, консерватория тәмамлый. Аны тәмамлагач Казанга кайта һәм татар милли опера театрын ачып җибәргән беренче әсәрен — «Качкын» операсын иҗат итә.

Моцарт... Нино Рота... Рахманинов... Җиһанов...

Игътибар иткәнсездер: бу дүрт художникның биографияләре бер-берсенә һич тә охшаш түгел. «Ни өчен?» дип сорасагыз, җавабы ачык: һәр талантның үз юлы, үз сукмагы була. Хәтта бер үк иҗтимагый, социаль һәм политик ситуацияләрдә дә һәр художник сәнгатькә үз юлы белән килә.

Халык теләндә акыллы бер сүз бар: «Һәрбер кеше — үз токымының, үз ыруының тузан бөртеге, һәр кешедә шул халыкның кичәге тарихын һәм киләчәк язмышын күрергә мөмкин».

Профессиональ музыка Казан өчен элек-электән шаккаттыргыч нәрсә булмаган. Чиксез киң Россия империясенең экономик һәм культура үзәкләреннән берсе саналган Казанның күп заманнар элек үк үз театры булган. Монда Рахманинов концертлар биргән, Нежданова һәм Шаляпиннар җырлаган...

Мин читтән килгән күренекле артистлар куйган концертларның әһәмиятен һич тә инкарь итәргә җыенмыйм. Андый концертлар куелган һәм киләчәктә дә куелачак, шулай булмаганда, сәнгать аерым бер шәһәрнең, илнең, материкның тар географик чикләре эчендә бикләнеп калыр иде. Әмма ризалашыгыз: башкалар язган музыканы тыңлау бер нәрсә, ә үз музыкаңны иҗат итү бөтенләй икенче нәрсә.

Бу яктан караганда, татар халкының язмышы бик гыйбрәтле. Кеше күңеленең иң нечкә, иң тирән кичерешләрен чагылдырган Бах, Лист, Шопен, Глинка, Чайковский һәм башкаларның даһилыгына дөнья таң калганда, татарларның, Россия империясендәге рус булма-

ган күп кенә башка милләтләрнеке кебек үк, үзләренең профессиональ музыкасы булмый.

Моның сәбәпләре күп. Урта гасырлардан бирле сакланып килгән иске йолалар һәм гореф-гадәтләр, ислам дине, аның тормыштагы һәр төрле яңалыкка дошман политикасы, милли һәм колониаль изүнең рәхимсезлеге һәм башкалар, һәм башкалар...

Архивларда Казан духовный семинариясе профессоры Н. И. Ильминскийның изге синод обер-прокуроры А. Г. Победоносцев белән ике арада алып барган шәхси язмалары сакланган. Мин шул язмаларны актарам һәм аларның авторларының чуалчык фикерләрен аңларга, ул фикерләрнең асылына төшенергә тырышам.

«Грамотага өйрәнү мәктәпләрендә,— дип белдерә Н. И. Ильминский,— барлык дөньяви гыйлемнәр икенче планда торырга тиеш... Ике еллык чиркәү мәктәпләре өчен рус орфографиясен һәм грамматикасын мин бөтенләй артык дип, ә чит милләтләр укый торган мәктәпләр өчен (турысын әйтим) зарарлы һәм куркыныч дип санар идем».

Бу сүзләргә аңлатма биреп торуның кирәге бармы икән? Һәммәсе ачык һәм конкрет әйтелгән: иң кирәклесе — гыйбадәт кылу, дини догалар. Ә «дөньяви гыйлемнәр — икенче планда», «артык» һәм, ниһаять «зарарлы һәм куркыныч».

Шулай булгач, Идел һәм Урал арасындагы чиксез киңлекләргә сибелеп утырган авылларда яшәүчеләрнең революциягә кадәр биштән дүрт өлешенең укый-яза белмәвенә, грамотасыз булуына гаҗәпләнергә урын калмый.

Беренче татар операсының ни өчен Октябрьдан соң гына дөнья күрүе үзеннән-үзе аңлашылса кирәк. Башкаларның талантлары инде чәчәк атканда Нәҗип Җиһановның һәм аның яшьтәшләренең нота укырга ни өчен олыгаеп беткәч кенә өйрәнүләрен аңлавы бер дә кыен түгел.

«Качкын»нан соң Нәҗип Җиһанов икенче операсын — «Алтынчәч»не яза башлый. Аны Муса Җәлил белән бергә иҗат итә. Әсәр сугыш башланыр алдыннан языла. Мәскәүдә инде биш китабын чыгарып өлгергән танылган шагыйрь һәм иҗат юлына әле яңа аяк баскан яшь-яшь композитор татар авылларында олысыннан кечесенә кадәр билгеле булган борынгы легенданы музыкага салалар. Бу легендада чибәр кыз Алтынчәчнең һәм көчле, батыр егет Җикнең олы мәхәббәте, аларның туган җиргә тугрылыклылыгы, чит ил баскыннарына каршы көрәшкә күтәрелгән халыкның батырлыгы турында сөйләнә. Шагыйрь һәм композитор әсәрне илһамланып эшлиләр, аның һәр кисәген каткат язалар, кызып-кызып бәхәсләшәләр, аерым бүлекләрен, партитураның язылган битләрен өр-яңадан эшкәртәләр.

Зур художниклар үзләренең киләчәкләрен алдан күрә торган булганнар. Мисал өчен Пушкинның «Исемем җәелер бөек Русь иленә» дигән сүзләрен хәтерлик. Үпкә авыруы белән газап җиккән бөек Тукай болай дип язган:

Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарың? [1]
Качан китәр кичең, килер нәһарың? [2]
Килермәллә, кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч...

Инде хәзер Муса Җәлилнең шигъри юлларын искә төшереп үтик:

Мин яшәргә телим бирер өчен
Илгә соңгы йөрәк тибешен.
Үлгәндә дә әйтә алсам иде,
Үлдем, диеп, туган ил өчен!

---

[1] Бәһарың — язың.
[2] Нәһарың — көндезең.

Планета өстендә шомлы кара болытлар куера... Бюргерлар Нюренбергы фашист башкисәрләренең сафларын куркынып күзәтә... Караңгы мәйданнарда, тар урамнарда «Һайль Гитлер!» сүзләре ишетелә, репродукторлардан коңгырт күлмәклеләрнең маршлары яңгырый. Күп тә үтми, Прага басып алына һәм талана. Танклар Варшава урамнары һәм мәйданнары буйлап үтә. Әле кичә генә Польшаны, Чехословакияне Гитлерга саткан Лондон һәм Париж тынып кала.

Алда дөньяны нәрсә көтә? Планета өстенә ябырылган үләт чирен кем туктатыр?

«Алтынчәч» операсының уңышка ирешәсен һәм Дәүләт премиясенә лаек буласын, либретто авторы Муса Җәлилнең фашистлар тоткынлыгында көрәш алып барасын ул вакытта, мөгаен, беркем дә башына китермәгәндер. Ике дус, ике фикердәш — шагыйрь һәм композитор — бүгенле-иртәгәле һәркемнең өлешенә туры киләчәк бөек сынауны алдан сизенгәндәй героик опера иҗат итәләр.

Кырлар яна. Котырынган ялкын болытларга кадәр үрли. Чиксез күп михнәтләр күргән җир-ананың сулышы кысыла, аны әйтеп бетергесез зур кайгы чолгап ала. Инде җирдә үлем хакимлек итә башлар, бөтен нәрсә ерткыч хан иркенә буйсыныр шикелле һәм менә шул чагында Тугзак, тугыз малай үстергән, кайгылар алдында баш имәгән һәм рухи көчен югалтмаган горур ана, баскынчының йөзенә бәреп әйтә:

— Үтерегез...
Мин аягүрә басып үләргә телим,
Кол булып түгел...

Әсәрне сәхнәгә сугыш башлангач куялар. Спектакльгә Муса хәрби формадан килә. Операны караганда ул уйчан һәм моңсу утыра... Җиһанов дусты белән саубуллаша, аның тиз көннән җиңеп, яу кырыннан исән-сау әйләнеп кайтуын тели. Алар әле киләчәктә бергәләп эшләү турында хыялланалар. Кабат бер-берләрен күрә алмаячаклары ул чакта ике дусның уена да килми.

Фашистлар тоткыны Муса Җәлил, өч елдан соң, палач балтасы астына башын куяр алдыннан горур һәм батыр ана Тугзакның сүзләрен кабатлый:

Мин тез чүкмәм, катыйль, синең алда,
Кол итсәң дә, тоткын итсәң дә.
Кирәк икән, үләм аягүрә,
Балта белән башым киссәң дә.

Муса Җәлил зур шагыйрьләрнең поэзиядә үзләре күтәргән идеалларга һәр вакыт туры булып калуларын героик үлеме белән раслады.

### 3

Сугыштан соң, урау юллар үтеп, шагыйрь һәм солдат Мусаның шигырьләре туган җиргә әйләнеп кайта. Озак та үтми, Нәҗип Җиһанов, шагыйрьгә багышлап, «Җәлил» операсын язарга керешә. Аның алдында изге сугыш кырында һәлак булган дусты турында, поэзиянең, кешелек өстенә килгән иң зур афәтне җиңеп чыккан халыкның гражданлык батырлыгы турында сөйләү бурычы тора. Ул мөмкин кадәр тизрәк, мөмкин кадәр яхшырак язу теләге белән янып эшли.

Опера башта Казанда, аннан Мәскәүдә бара. Соңыннан аны Прагада куялар.

Чехословакиягә премьерага барырга җыенганда Җиһанов чиксез зур дулкынлану кичерә. Югыйсә бит инде зур-зур шәһәрләрдә һәм кечкенә авылларда меңнәрчә концертлар, музыка сөючеләр белән меңнәрчә очрашулар уздырган ул. Бактың исә, үзен тыныч тотарга һаман күнегеп, өйрәнеп җитмәгән икән. Үз әсәрләре белән тамашачы алдына чыкканда ул һәр вакыт шулай дулкынлана, каушый, кыенсына.

Әйе, әсәрең Прага сәхнәсендә уйнала икән, моның бит әле икенче ягы да бар. Сүз монда аның турында, ягъни операсы ерак ил сәхнәсендә уйналачак татар композиторы Нәҗип Җиһанов турында гына бармаячак.

Заманында Бетховен, Лист, Шуман, Берлиоз, Вагнер кебек титаннар белән очрашкан Европаның музыкаль Мәккәсе үзеннән ерак торган башка милләтнең музыкаль культурасын ничек бәяләр? Ян Гус, Юлиус Фучикның ватандашлары рухы һәм эше белән шушы легендар затларга якын булган шагыйрь һәм солдат Муса Җәлилнең үлемсез батырлыгын ничек кабул итәр?

Шунысы кызык, Прагага барганда чиктән тыш дулкынланган Җиһанов анда барып җиткәч кинәт тынычлана. Вацлав мәйданында, опера театрының зур залында ул музыкантларга карата һәр вакыт ихтирамлы шәһәрнең сизгер музыкаль зәвыгына ышана. Аның дөнья күләм дан казанган гигантларга карата да, ирешелмәслек биеклекләр турында әле яңа хыялланучы яшьләргә карата да бер үк дәрәҗәдә игътибарлы булуын күрә.

Эмоцияләрен, хисләрен вакытыннан алда түгеп бетерергә ашыкмагандай, зал дирижерны чамасын белеп кенә, артык юмартланмыйча гына, гадәти алкышлар белән каршылый. Җиһанов тамашачының мондый халәтен яхшы аңлый. Бу — нинди дә булса бәйрәм көткәндә генә була торган сизелер-сизелмәс эчке бер дулкынлану, кешеләрнең әнә шул халәте аның үзенә дә — операның һәр күренешен белгән генә түгел, андагы һәрбер авазны аермачык ишетеп торган авторга да күчә. Спектакльнең тамашачыда нинди тәэсир калдырасын алдан беркем дә анык кына әйтә алмый. Залдагыларның ихлас күңелдән белдергән рәхмәте белән тәмамланырмы ул, әллә аның җанны өшеткеч салкын ваемсызлыгы беләнме?..

Менә залда ут сүнә. Дирижер бераз вакыт музыкантларның инструментларын көйләүләрен көтеп тора һәм кулларын алга суза: «Игътибар, хәзерләндек!»

Беренче аккорд көтмәгәндә яңгырый һәм көчле дулкын булып тамаша залы буйлап уза. Аннан, тукталыш-мазар ясап тормастан, оркестр тавышы акрыная, иртәнге җиләс җил искәнен, каен яфракларының салмак лепелдәүләрен хәтерләтеп, сизелер-сизелмәс кенә ишетелә башлый. Шушы сихри моң астында акрын гына пәрдә күтәрелә.

Операны карарга ифрат күп халык килгән, хәтта залдагы өстәмә урыннар да буш калмаган. Театрның зур залында утырган һәр тамашачы бу минутларда сәхнәдәге тормыш белән яши. Музыкаль образларның куәтле көче кешеләр күңелендә шатлык, нәфрәт һәм игелекле теләкләр уята. Алар үзләренең хис-тойгыларын композитор уйлары, композитор кичерешләре белән чагыштыралар, үлемгә үч итеп тормышка ышанырга телиләр. Кояшны караңгылык белән капларга, таң атуын төн белән тоткарларга мөмкин түгел!

Күп михнәтләр кичергән, фашизмның тимер дагалы итекләре табаны астында ыңгырашкан бу борынгы җирнең кешеләре композиторга, аның музыкасына ышаналар, чөнки әсәрдә аларның шатлык һәм нәфрәте, теләк һәм хыяллары да гәүдәләнгән.

Дирижерны, оркестрантларны, төп партияләрне башкаручыларны һәм тамашачыларны сәламләү өчен сәхнәгә чыккан Җиһанов кулла-

рың өскә күтәрүгә, тамашачыларның бөтен игътибары аңа юнәлә, зал эче дулкын-дулкын булып җәелгән көчле алкышлар белән тула. Тамашачылар үзләренә бәйрәм китергән өчен, композиторга кат-кат рәхмәт әйтәләр.

Моннан соң тагын унөч ел вакыт узды. Һәм менә Казан Прага консерваториясе профессоры Йозеф Паленичекны кабул итте. Башкалабызга ул үзенең «Кеше турында поэма» исемле ораториясен беренче тапкыр сәхнәгә кую өчен килгән иде.

Бу чор эчендә музыкабыз өлкәсендә нинди үзгәрешләр һәм яңалыклар булып узды соң? Фактларга игътибарсыз кеше өчен телгә алырлык бернинди дә әһәмиятле яңалыклар булмагандыр кебек тоелуы мөмкин. Чынлыкта исә алай түгел. Консерваториябезнең тагын унөч чыгарылышы булды. Тамашачылар күптән көткән концерт залы ачылды. Казанда беренче тапкыр орган пәйда булды. Яңа оештырылган симфоник оркестр концертлар бирә башлады.

Беренче карашка, гадәти фактлар, ә игътибар итсәк, шактый эш эшләнгәнен күрербез. Башкалабыз, үзебез дә сизмәстән, музыкаль интеллектын үстергән, иҗади җитлеккән, планетабызның теләсә кайсы почмагында иҗат ителгән иң катлаулы әсәрләрне сәхнәгә беренче булып куярга алынырлык биеклеккә күтәрелгән икән.

Концертлар Казан консерваториясенең Актлар залында өч көн дәвам итте. Дүрт йөз музыкант составындагы искиткеч зур хор, симфоник оркестр өч көн буена кешенең батырлыгына, көченә гимн башкардылар. Бу уңайдан әлеге концертлар турында безнең тормышыбызның иң сизгер, иң төгәл барометры — газеталарның нәрсә язганлыкларына күз төшереп үтәсе килә.

«Бу көн турында мин моннан уналты ел элек, дирижер Натан Рахлинга әле тәмамланып бетмәгән партитурамны күрсәткәндә үк хыялланган идем. Бүген менә шул көн килде һәм минем тормышымда иң бәхетле көн булды. Рәхмәт татар музыкантларына!» Күренекле чех композиторы, атаклы пианист Йозеф Паленичек Казанда үзенең «Кеше турында поэма» исемле ораториясе премьерасы уздырылгач әнә шулай дип язды.

Нәҗип Җиһанов концертларга Йозеф Паленичек белән бергә йөрде. Бөтен игътибарын биреп, аның музыкасын тыңлады, башкалар белән аягүрә басып, авторны һәм аның әсәрен башкаручыларны алкышладылар.

Әле дә хәтеремдә: беренче концерттан соң, Җиһанов янына барып, үзебезнең туган җиребездә кешеләрнең бөек Дворжак, Сметана илендә иҗат ителгән музыканы беренче тапкыр башкарылуына шат-канәгатьме дип сорау теләге туды. Ләкин бу уемнан шунда ук кире кайттым. Чөнки һәрбер кешене бары тик аның үз кичерешләре, үз уйлары белән генә калдырырга кирәк мизгелләр була.

## 4

Бервакыт мин композитор Мирсәет Яруллин белән сөйләшеп утырдым. Мирсәетнең әтисе Заһидулла Яруллин үз халкының рухи җанын музыкада башка беркем дә чагылдыра алмаганча искиткеч зур осталык белән гәүдәләндергән Салих Сәйдәшевнең беренче остазы булган. Заһидулла агайның өлкән улы Фәрит Яруллин — беренче татар балеты «Шүрәле»не иҗат иткән композитор. Бу балет җир шарының барлык почмакларында куелды һәм зур уңыш белән барды. Әмма авторның үзенә аны бер генә тапкыр да карарга туры килми. Взвод командиры лейтенант Фәрит Яруллин 1943 елда фронтта һәлак була.

Татар халкына әнә шундый күренекле композиторны биргән гаиләдә туып үскән Мирсәет белән без бүгенге музыкабызның торышы, аның аерым вәкилләренең иҗатлары турында шактый озак әңгәмә алып бардык. Шул нәүбәттән Нәҗип Җиһанов иҗат иткән әсәрләрне санап уздык, татар профессиональ музыкасының беренче карлыгачлары булган композиторларның, шулай ук бүгенге көндә бу өлкәдә эшләүчеләрнең иҗат эшчәнлегенә тукталдык. Салих Сәйдәшев, Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров, Рөстәм Яхин, Хөснул Вәлиуллин, Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарев, Ринат Еникеев, Луиза Хәйретдинова... Шактый зур байлык тупланган.



Аннан соң без Нәҗип Җиһанов белән очраштык. Аның шәхси «өлешен» күз алдында тотып, мин Нәҗип Гаязовичтан үзе язган әсәрләрнең кайсысын иң мөһиме дип санавы турында сорадым.

Җиһанов әйтерсең лә минем бу соравымны алдан ук көткән, ул миңа шунда ук җавап бирде.

— Минем өчен иң мөһиме — махсус балалар музыка мәктәбе,— диде ул һәм әйтергә теләгән фикерен тагын да ачыклый төшеп, болай дип дәвам итте:

— Әйе, әйе, балалар музыка мәктәбе. Мин язганнарның бөтенесе, иҗат юлын инде тәмамлаган, я булмаса әле дә исән булган композиторларның бүгенге эшләре — болар инде безнең узганыбыз. Бөтен Идел буеннан җыелган балаларны кабул итә торган музыка мәктәбе — туган ягыбызның, димәк, илебезнең дә музыкаль киләчәге ул.

Менә хәзер инде Җиһанов холкының икенче ягы турында да сөйләргә мөмкиндер кебек. Кайберәүләр уйлаганча, аның музыкага бәйләнеше булмаган эшчәнлеге турында алда әйтеп узган идек инде. Теләсә кемне Верховный Совет депутаты итеп сайламыйлар, һәртөрле комитетларга чакырмыйлар. Моның өчен кешенең эшләргә теләве, эшли белүе һәм, ниһаять, эшләве кирәк.

Әлбәттә, теләсә кайсы художник шикелле үк Җиһанов та һәр буш сәгатен, һәр буш көнен үзенең музыкасына багышларга тели. Ләкин бер генә чын художник та үз бүлмәсенә бикләнеп кенә иҗат итә алмый, үзен чолгап алган мохитка игътибарсыз кала алмый, үзе турында гына кайгыртып яши алмый.

Җиһанов үзен чолгап алган музыкаль тормыштан ничек инде читтә кала алсын? Ул бөтен гомерен биргән консерваториягә утыз ел тулып килә. Махсус балалар музыка мәктәбенә унөч ел!

Кемнеңдер фикерен кабатлыйм: һәрбер талант табигать-ана тарафыннан тудырыла торган могҗиза ул. Музыка язу сәләтенә ия булуны шундый могҗиза дисәк, безнең белән беркем дә бәхәсләшмәс. Ә акыллы, төпле администратор була алу шулай ук бәхет түгелмени? Хуҗалык эшләрен белеп, тәртип белән алып баручылар да бездә әле тулып ятмый. Әгәр бер үк кеше шушы өч төрле сәләтнең һәркайсына ия була икән, бу инде өчләтә уңыш дигән сүз.

Республикабыздагы бердәнбер югары музыка уку йорты ректорының тынгысыз эшчәнлеге, Верховный Совет депутатының, республика, Россия һәм СССР Композиторлары союзлары җитәкчесенең гражданлык, партия һәм җәмәгать активлыгы зур художникка карата булган ихтирамны тагын да арттыра.

Ышаныгыз, иҗат эше өчен кирәкле кыйммәтле минутларны үз-үзеннән тартып алу, кемнәрдер уйлаганча, Җиһановка да җиңел түгел. Ләкин көндәлек җәмәгать эшләренә киткән һәм беренче карашка бөтенләйгә югалган, әрәмгә тотылган дип исәпләнгән мизгелләр һәм сәгатьләрдән дә файда алырга мөмкин. Әлбәттә, үзе өчен түгел, консерватория өчен, үз халкының, үз милләтенең музыкаль культурасы үсеше өчен.

Алдан сизеп торам, миңа тәнкыйтьчеләр әйтүләре мөмкин: Җиһанов та Җиһанов... Республикабыз музыкаль культурасының барлык уңышларын бер Җиһановка гына кайтарып калдырырга минем һичбер нинди исәбем юк. Һәм бу дөрес тә булмас иде. Әмма бернәрсәне онытырга ярамый: аның музыкаль талантының уянуы, формалашуы, җитлегүе нинди чорга туры килде соң? Әйдәгез, «Кремль хыялчысы» Владимир Ильич Ленинның илдә моңарчы булмаган җимереклек, ачлык, ялангачлык хөкем сөргән бер вакытта Клара Цеткин белән үзенең киләчәккә юнәлтелгән уйларын уртаклашуын искә төшерик, юлбашчының фикеренә ныклабрак игътибар итик.

«Бүген, әйтик, Мәскәүдә ун мең, ә иртәгә тагын йөз мең кеше театрда куелган гүзәл спектакль белән ләззәтләнгән бервакытта миллионнарча кешеләр үзләренең исемнәрен хәрефләп язарга һәм санарга өйрәнергә омтылалар, үзләрен җирнең яссы түгел, ә шар формасында икәнлегенә, дөнья белән тәңре, күз бууччылар һәм сихерчеләр түгел, ә табигать законнары идарә итә икәнлегенә өйрәтүче культурага якын килергә омтылалар».

Икенче бер язмасында Клара Цеткин В. И. Ленинның революция һәм социализм җиңүе нәтиҗәсендә киләчәктә кешеләр алдында ачылачак чиксез зур мөмкинлекләр хакында аеруча басым ясап әйтүе турында сөйли:

«Массаларның гомуми культура дәрәҗәсе күтәрелүе сәнгатьнең, фәннең, техниканың үсеше өчен кирәк булган куәтле, иксез-чиксез көчләр үсеп чыгачак ныклы, сәламәт җирлек тудыра».

Нәҗип Җиһанов музыкага нәкъ әнә шул «сәламәт җирлек» булдырылган бәхетле чорда килә, эшли, иҗат итә. Аңа кадәр инде беренче татар милли операсы «Эшче» язылган иде. Халык арасыннан үсеп чыккан күренекле композитор Салих Сәйдәшев татар милләтенең профессиональ музыкаль культурасына нигез салды. Татарстанның сәнгатькә әле яңа аяк басучы яшь җырчыларына, музыкантларына Мәскәү һәм Ленинградның иң яхшы, иң тәҗрибәле педагоглары белем бирделәр. Элек беркайчан да булмаган шундый куанычлы хәл: совет халыкларының зур гаиләсе составына керә торган кечкенә милләтләрнең музыкаль культурасын үстерү турында кайгырту гомум дәүләт эше булып әверелде.

Җиһановка менә шушы җирлеккә ныклап аяк басарга, музыкага әзерне кулланучы кеше булып түгел, ә бәлки ару-талуны белмәс эшче, төзүче, иҗат итүче булып килергә, анда үз буразнасын сызарга, үз эзен калдырырга кирәк иде. Һәм ул шулай эшләде дә. Әйтергә кирәк, тырышып, үз-үзен аямыйча, һәр язган әйберен кат-кат эшкәртеп, тикшереп, энә күзе аша үткәреп, һәр адымы өчен үзендә чиксез зур җаваплылык тоеп эшләде.

Җиһанов, мәсәлән, музыкаль әлифбаны башка композиторга караганда да соңрак күргән, соңрак аңлаган композитор буларак, кешегә музыка белән мөмкин кадәр иртәрәк шөгыльләнә башлауның ничаклы әһәмиятле икәнлеген бөтен йөрәге белән аңлый. Билгеле, мәктәптә, консерваториядә укып кына Моцарт һәм башка гигантларны тулы тирәнлеге белән өйрәнеп бетәргә мөмкин дип уйлау беркатлылык булыр иде. Ләкин үз әсәрләрен язу өчен бөек композиторларга да башта иң гади ноталарны белергә кирәк булган ич. Шулай булмаганда үзләренең үлемсез әсәрләрен алар кешеләргә ничек җиткерә алыр иде?!

Талант һәр вакыт көтмәгәндә ачыла. Монда күп төрле очраклы хәлләрнең булуы мөмкин. Әнә шул очраклы моментларны дөрес тотып ала белергә кирәк. Әмма ничек? Талантларны эзләү, табу, музыка мәктәпләренә кабул итү, озак еллар дәвамында тәрбияләү,

аларга табигать-ана тарафыннан бирелгән алмазны, шомартып, сирәк очрый торган, камиллектә тиңе булмаган хәзинәгә әверелдерү юлы белән. Нишлисең бит, авыр эш, күп вакыт һәм көч сарыф итүне сорый торган эш, ләкин шуннан башка бүтән чара юк. Һәр яз саен Җиһанов чуваш, мордва, татар, башкорт авылларына курайда, гармунда уйнаучы балаларны эзләү, әти-әниләрен аларны ун елга Казанга, музыка мәктәбенә укырга җибәрергә үгетләү өчен махсус укытучы-белгечләр җибәрә.

Кайчандыр Җиһановның укучылары булган күп кенә яшь композиторлар — аның бүгенге коллегалары, тарафдарлары, фикердәшләре, танылган башкаручылар, көй чыгаручылар әнә шулай очраклы рәвештә табылган талантлар. Шунысын да әйтергә кирәк, Җиһановның хәзерге урынбасары Мирсәет Яруллинны исәпләмәгәндә, үзенең нәсел-нәсәбендә кемнең дә булса берәүнең музыка белән чын-чынлап шөгыльләнүен бу яшьләрнең берсе дә хәтерләми. Үзенчәлекле композитор Фасил Әхмәтов, мәсәлән, Казан арты лесхозларының берсендә үскән. Аның әти-әниләре гомер буена урманчылык эше белән шөгыльләнгәннәр. Биш яшендә гармун тарткаларга өйрәнгән сабыйның бирегә килеп чыккан укытучы-белгечләр тирәсендә бөтерелеп йөриячәге, аннан музыкага өйрәнү өчен Казанга китәчәге, соңыннан консерватория тәмамлап, шунда ук укытырга калачагы һәм матур-матур көйләр иҗат итәчәге турында алар, мөгаен, уйларына да китермәгәннәрдер.

Мин әле безнең көннәрдә дә сирәк саналган әлеге музыка мәктәбенә сугылып чыктым. Хәзергә әле гармун телләрен бер генә бармак белән чыңгылдатучы беренче класс укучылары янында булдым. Гомуми белем бирү дәресләре беткән, махсус белем дәресләре әле башланмаган. Мин балаларның кайберләре белән аерым-аерым сөйләштем, алардан ишеткәннәремне кыскача гына итеп куен дәфтәремә язып куйдым. Кем белә, бәлки еллар үткәч, әнә шул язмаларны актарып, моңарчы үзләренә әле бөтенләй таныш булмаган ерактагы зур шәһәргә килгән шук малайларның кем булып чыгулары белән кызыксынырга, алар белән кабат очрашырга туры килер.

Менә Аксубай районының Яңа Дума авылыннан килгән Илһам Хәбибуллин. Ул скрипка уйный. Әти-әнисе пенсионерлар. Радик Шәйдуллин Минзәлә районының Иске Абдул авылында туган. Бәләкәй чагында ук абыйсының гармунында уйнаган Радик та районга килгән укытучы-белгечләр игътибарыннан читтә калмый. Хәзер ул фортепьянода уйнарга өйрәнә. Мидхәт Шакировны укытучылар Балтач районының Киров өлкәсе белән чиктәш Янгул авылыннан табалар. Мидхәтнең әтисе колхоз гаражында эшли, машиналар төзәтә, ә әнисе төрле эшкә йөри. Малай скрипка белән ихлас күңелдән кызыксына.

Мәктәптә ике йөздән артык бала укый. Аларны чиксез киң Идел буеның төрле якларыннан — Чувашстан, Башкортстан, Татарстан, Мари республикаларыннан җыйганнар. Уку, әлбәттә, түләүсез. Читтән килгәннәр интернатта, тулысынча дәүләт исәбенә яшиләр.

Монда тәрбияләнгән һәр баланың киләчәк язмышы ничек булачагын алдан әйтү кыен, билгеле. Аларның кайберләре бәлки укып бетергәнче үк китеп барырлар. Беркемгә дә сер түгел, ун ел буе икеләтә-өчләтә нагрузка белән уку баладан зур түземлелек һәм физик ныклык, тазалык таләп итә. Кайберләре исә музыканы гомерлеккә үзләренә юлдаш итәрләр, консерваторияне уңышлы тәмамлап, аспирантурага керерләр, көйләр тудырырлар. Юра Егоров кебек оста башкаручы булып җитешерләр һәм үзләре укыган мәктәпнең данын тагын да үстерерләр. Әйе, бу хакта әле хәзергә бары тик күрәзәлек

кенә итәргә мөмкин. Ләкин шунысы ачык: монда һәр укучы баланың киләчәк язмышы аның үз кулында, дөресрәге, бүгенгә әле алар белән көнен-төнен шөгыльләнүче педагоглар, укытучылар, тәрбиячеләр кулында.

Юра Егоров музыка мәктәбен 1970 елда тәмамлаган. Укуының соңгы елларына кадәр яшьтәшләреннән бер ягы белән дә аерылып тормаган. Бабасы чуваш шәһәре Алатырьда паровозлар депосында эшләгән, колакка сак әтисе гомер буе география укыткан, бу малайның зур талантка ия булуын башта бик үк күреп тә бетермиләр. Унынчы класста укыганда Юра Парижга, күренекле пианистка Маргарита Лонг васыяте буенча башкаручыларның һәр ел саен уздырыла торган бөтен дөнья конкурсына бара. Иң катлаулы әйберләрне: Сен-Санс, Бетховен, Шопен, Дюбси, Лист әсәрләрен башкарып, өч турны да триумф белән үтә һәм Казанга лауреат булып кайта.

Былтыр Октябрь бәйрәме алдыннан башкала консерваториясенең өченче курс студенты Юра Егоров үзен тәрбияләгән һәм музыкага өйрәткән туган шәһәребездә концерт бирде. Турысын әйтергә кирәк, Казан музыкага ифрат бай шәһәр. Анда Маргарита Лонг исемендәге конкурсның почетлы призына лаек булган башкаручыга караганда да популяррак музыкантларның чыгыш ясаганнары бар. Әмма Юра Егоров чыгыш ясаганда залда сүз белән аңлатып бирә алмаслык тантана хөкем сөрде. Юра үз-үзен тыйнак тотты, дулкынланды, кичерешләр эчендә калды. Ләкин аның уйнавында һәр останың башкаруын бүтәннәрдән аермалы итә торган ихласлык, гадилек бар иде. Концерт залын тутырган йөзләрчә тамашачылар аңа ихлас күңелдән инандылар, үзләрен аның белән бергә хис иттеләр, музыкантка үз тойгыларын, теләкләрен, омтылышларын ышанып тапшырдылар. Бу минутта алар каян да булса килгән күренекле бер музыкант түгел, ә үзләре арасында үскән, үзләре арасыннан күтәрелгән талант концерт биргәнлеген ачык аңлыйлар иде.

## 5

Юра Егоров концертларыннан соң Нәҗип Гаязович белән без тагын бер тапкыр очраштык. Алтмыш дүрт яшьне иңнән алып ташлап булмый, ә ул һаман шул ук җитез, ашыгучан, әйтерсең еллар аңа комарлык өстенә комарлык, кайнарлык өстенә кайнарлык өсти торалар.

Мин аның Юра Егоровның пианино уйнавы турындагы фикере белән кызыксындым. Халкыбызның профессиональ музыкасы чыганаклары башында торган аксакалдан Дворжак, Сметана ватандашларының үз әйберләрен башкаруны сорап Казанга килүләреннән, Юра Егоров кебек шәкертләренең Халыкара конкурсларда призлар алуыннан канәгатьме, дип сорадым.

Җиһанов башын селекте, гадәтенчә, дипломатларча булмаган турылык белән җавап кайтарды:

— Азрак мактанырлык берәр төрле сәбәп килеп чыкса, «ах» итәргә яратабыз без. Юк, анысы дөрес, шактый нәрсәләр эшләнгән. Ләкин, әйдәгез, эшләнгән эшләр белән әле ирешелергә, тормышка ашырылырга тиешле нәрсәләр арасындагы аерманы чагыштырып карыйк. Соңгы ике съезд арасында, әйтик, республикабыз композиторлары тарафыннан 2 балет, 4 музыкаль комедия, 17 зур симфоник әсәр, 2 оратория, 9 камера әсәре, 260 җыр иҗат ителде. Әмма эш санда-

мыни? Бездә күпме пьесалар языла, чутына чыгарлык түгел. Ләкин бик сирәге генә бер сезоннан артык бара. Ә Грибоедовның «Акыллылык бәласе»н һаман куялар. Спектакльгә ничә тапкыр барсаң да беренче тапкыр карагандагы шикелле карыйсың. Зур уңышка ирешкән саен тагын да зуррагына өметләнәсең. Безгә һәр минутның кадерен өчләтә, бишләтә артыграк белергә кирәк. Ә без акрын кыймылдыйбыз, акрын һәм озак эшлибез.

Утыз биш яше тулганда (ә безнең композиторларыбызның күпчелеге хәзер шул яшьтә) Шостакович җиде симфония, ике опера, өч балет, күп санлы камерный әсәрләр иҗат итте. Монда әле аның төрле спектакльләргә, кинофильмнарга язган җырлары керми. Профессиональ музыканың әлифбасына унтугыз яшендә генә төшенә башлаган Арам Ильич Хачатурян уналты елдан соң инде биш зур симфоник әсәр, балет, исәпсез-хисапсыз романслар, җырлар, тынлы оркестр өчен бик күп әсәрләр язды. Безнең яшь композиторларыбызның яшьтәше ленинградлы Борис Тищенко хәзер инде дүрт симфония, дүрт концерт, квартетлар, вокаль цикллар һәм балет авторы... Ә безнекеләр тыйнаграк...

Нәҗип Гаязович Җиһанов үзенең сүзен болай дип тәмамлады:

— Әгәр профессиональ музыкабызның үсешен аның беренче адымнарыннан, ягъни нульдән алып карасак, уңышларыбыз, әлбәттә, бар. Ләкин шуны онытырга ярамый: без моннан ярты гасыр элеккегә караганда бөтенләй башка шартларда яшибез һәм иҗат итәбез. Кешелек җәмгыяте тарафыннан күпме нәрсә иҗат ителүен күздән кичерсәң, исең-акылың китәрлек. Буй җитмәслек биеклек! Безгә әле алга карап атларга да атларга, әнә шул биеклеккә күтәрелергә, революциягә кадәрге йөз еллар эчендә ирешелергә тиеш булган нәрсәләрне яулап алырга һәм үстерергә кирәк. Биеклек ул елларга гына буйсынмый, ул алга карап атлаучыларны ярата, бары тик аларга гына баш ия.

Ильтани Илялова

# АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ— ТАТАР КЛАССИКАСЫ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры репертуарында классик драматургларыбызның әсәрләре елдан-ел күбрәк урын ала бара. «Зәңгәр шәл» (К. Тинчурин), «Галиябану» (М. Фәйзи), «Хуҗа Насретдин» (Н. Исәнбәт) кебек, һәр сезонда уйналып килгән атаклы әсәрләр белән бергә, коллектив соңгы елларда күренекле татар драматургларының моңарчы игътибардан читтәрәк калып килгән пьесаларын да сәхнәгә куя башлады. Әйтик, К. Тинчуринның «Американ» комедиясе белән «Сүнгән йолдызлар» мелодрамасы 1924 елдан бирле, Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу» драмасы 1936 елдан бирле, Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар»ы 1939 елдан бирле сәхнәдә куелмаган булган. 30—40 еллар тукталып торганнан соң, әлеге әсәрләр кабат сәхнәгә кайтты. Бу спектакльләрнең беришеләре, мәсәлән, «Миркәй белән Айсылу», «Американ», «Сүнгән йолдызлар» һәм өлешчә «Кыю кызлар» бүгенге театрның җитлеккәнлек дәрәҗәсен, үсешен күрсәтә торган әсәрләр буларак кабул ителсә, икенче берләре (мәсәлән, «Зәңгәр шәл») нигездә тышкы яңалыгы белән генә игътибарны җәлеп итте, өченчеләре исә (әйтик, «Галиябану») бөтенләй уңышсыз булып чыкты. Әлбәттә, уңышка ирешүнең дә, уңышсызлыкка очрауның да үз сәбәпләре бар.

Күптән язылып, озак еллар буе уйналмый йөргән ул әсәрләрне сәхнәләштергәндә, театр коллективы бүгенге сәхнә таләпләреннән чыгып, бүгенге тамашачыны истә тотып эш иткән. Башкача әйткәндә, ул заман рухы, заман сулышы белән сугарылган спектакльләр куярга омтылган. Фикеребез аңлашыла төшсен өчен, беркадәр арткарак кайтып карыйк.

Югарыда телгә алынган әсәрләр кайчандыр сәхнәгә куелган булган, шуңа күрә элекке спектакльләр белән бүгенгеләрен чагыштырып багыйк. Сүз дә юк, 20 нче һәм 30 нчы елларда куелган спектакльләр бүгенге спектакльләр төсле булмаган һәм алай була да алмаган. Хикмәт аларның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләрендә генә дә түгел. Бу хәлнең төп сәбәбен шул чорның үзенчәлекләреннән, шул замандагы әдәби-эстетик карашлардан эзләргә кирәк. Тормыш үзгәрү белән кешеләр дә үзгәрә һәм аларның матурлыкны тою, шул исәптән, сәнгатьне аңлау дәрәҗәләре дә үзгәрә. Шуңа күрә 20—30 нчы еллардагы тамашачылар тарафыннан сокланып каралган спектакльләр бүгенге кешеләргә охшамаска, иске бер нәрсә булып тоелырга мөмкин. Без яратып карый торган постановкаларга да, ихтимал, егерме беренче йөздә яшәячәк кешеләр әллә ни сокланмаслар. Бу — диалектиканың бәхәссез законы.

Бу кадәресе аңлашыла торган нәрсә. Безне, моннан да бигрәк, мәсьәләнең башка яклары кызыксындыра. Мәгълүм ки, татар театры барлыкка килгән чагында ук реалистик театр була. Шуңа күрә без 1910 елда сәхнәгә куелган әсәрләрне дә, 1930 һәм 1970 елларда куелганнарын да реалистик спектакльләр дип саныйбыз. Әмма, алда әйткәнебезчә, заманнар үтү белән реализм төшенчәсе үзе дә үзгәрә бара икән. Әгәр элекке елларда реализмны тормышның натуралистик дөреслеген сурәтләү дип аңласалар, бүгенге көндә инде безнең өчен барыннан да бигрәк әсәрнең идея юнәлеше,

яндагы социаль фикер әһәмиятле. Бу хакта һәр спектакльне аерым-аерым тикшергәндә конкретрак әйтербез.

Моннан тыш, тагы шуны да истән чыгармыйк: утызынчы елларга хәтле театрлар, шул исәптән татар театры да, сезон саен дистәләрчә яңа спектакль куйганнар, икенче төрле әйткәндә, һәр яңа пьесага күп дигәндә дүрт-биш репетиция туры килгән. Билгеле, бу рәвешчә эшләгәндә спектакльне иң сәләтле берничә артист кына «коткарып» килгән. Ул заманда әле бүгенге мәгънәдәге режиссура да булмаган...

Яңадан куелган спектакльләр арасында 1966 елда М. Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәләштерелгән «Миркәй белән Айсылу» беренче урында тора. Бу постановка турында матбугатта күп язылды. Шуңа күрә аның хакында җентекләп сөйләп тормыйбыз. Шулай да, Г. Камал исемендәге академия театрында куелган классик пьесалар хакында сүз барганда, бу спектакль турында да берничә сүз әйтми китеп булмый. Чөнки бу постановкада элекке әсәрләрне ничек итеп заманча куярга кирәклекнең төп принциплары чагыла. Режиссер бу әсәрне сәхнәләштерүнең заманга кулай төп принципларын таба, соңга таба аларны тагы да үстерә төшә. Сүз, беренче чиратта, хосусый, тар конфликтлар белән мавыкмыйча, әсәрнең төп, социаль фикерен калку итеп ачу турында бара.

Пьесаларның артык озын урыннары кыскартыла. Концерт тамашасына охшап китә торган җыр-бию номерлары нык кыскартыла, ә калган җырлар геройларның эш-хәрәкәт логикасына туры китереп бирелә. Әгәр элек актерлар, төрле сәбәпләр аркасында, геройның эчке дөньясын ачу, үз-үзен тотыш логикасына төшенү урынына, рольгә иярүне, ипләшүне эзләсәләр, хәзер инде режиссер артистларга таныш образларның дистәләрчә еллар буена ничек уйналганын онытып торырга куша, актерлардан геройларның эчке логикасын тирәнрәк төшенүне таләп итә һәм геройларның эчке дөньясын, эчке халәтен ачу аша драманың төп фикерен ачык яңгырашлы итүгә ирешә.

...Көнкүреш планында язылган татар пьесаларын сәхнәгә куюдагы иске традиция илленче еллар азагына хәтле яшәп килде. Бу турыда «Театр» журналы 1967 елда мәнә болай дип язган иде:

«...Түбән зәвыклы тамашачыга ярарга тырышу милли үзенчәлек итеп карала. Андый тамашачы әсәрнең фабуласы белән генә кызыксына һәм, өстәвенә, спектакльдә җыр-биюләр дә булса, моңа бик күңеле була. Г. Камал исемендәге театрның кайбер спектакльләре әнә шундый тамашачыга исәп тотып эшләнгән. Бу спектакльләрдә һәрбер хәрәкәт җәеп-җентекләп күрсәтелә, ә аның эчке сәбәпләре бер-ике сүз белән әйтелә; тышкы хәрәкәт эчке торгынлыкны көчәйтә генә төшә; характерлар беренче күренүдә үк ачылып бетә, шуннан ары алар үстерелми дә, ачылмый да, кыскасы, тамашачының игътибарын сәхнәдәге төп вакыйгадан башка нәрсә җәлеп итми. Мондый спектакльләрдә персонажлар бары тик бер генә төрле буяу белән — күбесенчә ак яки кара буяу белән генә сурәтләнә, «чуарлык» комик персонажларда гына булырга мөмкин, төрле полутоннар куллану исә бөтенләй юк» [1].

Яңа режиссурага сәхнә әсәрләрен куюда дистәләрчә еллар буена урнашып килгән бу традицион принципны җимерергә туры килә. «Миркәй белән Айсылу» спектаклен алыйк. «Миркәй белән «Айсылу»ны беренче тапкыр сәхнәгә 1935—36 елгы театр сезонында М. Мәһдиев куя. Шул елларда язылган рецензияләр буенча фикер йөрткәндә, спектакльдә алданган халыкның трагедиясе ачылмый кала, актерлар образларның асылына төшенеп җитмиләр. Айсылу ролен уйнаучы Ильская артык күп йөгерә, артык күп хәрәкәтләнә [2]. Әсәрне сәхнәгә куючы режиссер да, артистлар да тулы канлы, тормышчан образлар тудыра алмаганнар дигән сүз бу. Спектакльнең оформлениесе натуралистик планда эшләнгән була. Әсәрнең соңгы пәрдәсендә зират, зират эчендә берничә кабер күрсәтелә. Кемнәрдер, ашыгып балчык ыргыта-ыргыта, Айсылуга чын кабер казыйлар. Персонажларның берсе — Гариф — ат ярата. Үзенең ат яратуын күрсәтү өчен ул кулына ат аягы тотып йөри. Дәүли, үзенең явызлыгын күрсәтү өчен, һәр вакыт кашын-йөзен җимереп йөри.

Шуңа күрә, драманы яңадан сәхнәгә куйганда, М. Сәлимҗанов, беренче эш итеп, аны натуралистик детальләрдән арындыруны күздә тота. Халык, аның фаҗигале язмышы спектакльнең төп героена әверелә.

---

[1] «Театр» журналы. 1967 ел. 9 сан.
[2] «Красная Татария» газетасы. 1936 ел. 24 май.

«...Соңгы спектакльдә массовый күренешләргә катнашучы һәр кешегә әсәрнең төп фикерен ачыкларга ярдәм итә торган ачык бер бурыч куела. Алар мәгънәле итеп, хис-тойгы белән уйныйлар. Артистларга үз персонажлары өчен характер уйлап табарга, иҗади эзләнергә туры килә... «Миркәй белән Айсылу»да халык тәшенчәсен аерым шәхесләр тудыра»... [1]

Спектакльнең төп үзенчәлегеннән туа торган икенче бер сыйфат — геройны һәм халыкны күрсәтү. Биредә халыктан өстен торган, үзенә бер төрле романтик герой юк, мондагы герой халыкның үз эченнән чыккан. Бу спектакльдә массовый күренешләр дә татар театрында беренче тапкыр яңача хәл ителә. М. Сәлимҗановның бу юнәлештәге тырышлыгы, «Миркәй белән Айсылу»да да, аннан соңгы эшләрендә дә, бөтен совет театры үсешенең уртак бер сызыгына туры килә. Тулы канлы массовый күренешләр тудырып, аерым персонажларны психологик яктан конкрет, төгәл гәүдәләндереп, ул кеше язмышы аша халык язмышын ачуга ирешә.

Массовый күренешләрне кую осталыгына ирешү белән бергә, Академия театры милли театр культурасына тирән тамыр җибәргән төп традицияләрнең берсен — татар артистларының психологик драманы ачудагы традицияләрен тагы да үстерә һәм тирәнәйтә төшә. «Миркәй белән Айсылу»да режиссер да, артистлар да фаҗиганең киеренкелеген тышкы патетика белән түгел, бәлки кешеләрнең күңел дөньясын төрле яктан күрсәтү юлы белән ачалар. Спектакльнең куелышындагы кайбер нәрсәләрне үзгәртү нәтиҗәсендә артистлар геройларның эчке халәтенә аеруча игътибар итәргә тиеш булалар. Мәсәлән, җен-пәриләрне куу күренеше әнә шундый. Акылдан язган Айсылу яткан өйгә, укып-өшкереп җен-пәриләрне куу өчен, муллалар килә. Элек бу күренеш иске тормышка хас гадәти бер хәл итеп уйналган булса, хәзер төп игътибар аның социаль асылын ачуга юнәлдерелгән.

Сәхнә уртасында өч яктан чуар чаршау белән корып алынган, киң генә агач сәке тора. Сәкедә авыру Айсылу ята. Өй эче ярым караңгы. Муллалар сәкегә менеп утыралар, авыруның коты алынып кычкырынуына карамастан, аны көчләп урынга яткыралар, әфсен-төфсеннәрен укырга керешәләр. Айсылу кычкыра, чабалана, торырга талпына, ә муллалар кызны ныгытып тотканнар, урыннан торгызмыйлар. Чаршау белән корып алынган тар, караңгы сәке бөтен эпизодка куркыныч, шомлы бер төс бирә. Авыру кешене чаршау белән аерып кую бу очракта кешенең рухи тоткынлыгы, аның иркенең богауланган булуы, тормышта нык сакланып килгән иске кануннарга колларча буйсыну символына әверелә. Айсылу бу тар бүлмә эчендә читлектәге кош кебек чабалана, чыгарга талпына.

Соңгы ун елда милли классиканы шушы рәвешчә яңача аңларга омтылу һәр театрда диярлек күзгә ташлана. Ягъни, бүгенге һәр совет театры әсәрнең социаль сызыгын беренче планга куя, бу хәл исә төрле төбәкләрдә куелган спектакльләрнең гомуми кешелек өчен уртак булган якларын тагы да көчәйтә төшә. Казакъ академия театрының баш режиссеры А. Мамбетовның классиканы яңача кую хакында әйткән фикерләре бик кызыклы. Ул болай ди: «Театр үзенең беренче елларында этнографик яклар белән мавыга, беренче нәүбәттә милли характер ачарга омтыла иде. Соңга таба без этнографик материалдан читләшә төштек. Хәзер исә безне гомум кешелек темалары, бөтен кеше өчен уртак булган мәсьәләләр һәм тойгы-кичерешләр кызыксындыра. Хәтта борынгы заман тормышын күрсәткәндә дә без үзебезнең заман өчен әһәмиятле булган сыйфатларны, тамашачыга якын, аңлаешлы характерларны табарга тырышабыз. Без теләсә кайсы милләт тамашачысының да безнең спектакльне яратып каравын, безнең геройларны үзебез кебек үк аңлавын, якын итүен телибез» [2].

Татар театрының эзләнүләре дә шушы юнәлештә бара. «Миркәй белән Айсылу», «Американ», «Кыю кызлар» исемле әсәрләрдән соң, ул К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» мелодрамасын сәхнәләштерүгә керешә. Алда әйтелгәнчә, бу әсәр сәхнәгә беренче тапкыр 1924 елда куелган. Ул чагында спектакльдә төп урынны өч гашыйкның мелодраматик, сентименталь рухта сурәтләнгән мәхәббәт хисләре алып торган.

Сәрвәр исемле яшь кызга ярлы егет Исмәгыйль дә, мулла малае, бөкре мәхдүм дә гашыйк. Кыз исә Исмәгыйльне ярата. Сугыш башлана. Сәрвәр, үзенең сөйгән егетен солдаттан коткарып калу өчен, аның колагына им-томчыдан алган ниндидер дару сала.

[1] «Театр» журналы. 1967 ел. 9 сан.
[2] «Советская Татария» газетасы. 1972 ел, 16 июнь.

Дару зарарлы булып чыга. Исмәгыйл үлә. Сәрвәр бу авыр кайгы-хәсрәтне күтәрә алмыйча акылдан шаша. Мәхдүм акылдан язган кыз өчен җанын бирердәй булып йөри. Дөньяда аның бөтен өмете, хыялы — шушы Сәрвәр генә. Әмма кыз сөйгән егетенең кабере өстенә барып җан бирә. Мәхдүм дә кызның үле гәүдәсе янында агачка асылынып үлә.

Спектакльне беренче тапкыр куйганда актерларның бөтен игътибары шушы фаҗигане чын, дөрес итеп күрсәтүгә юнәлдерелгән була. Академия театрының өлкән артистларыннан Хәким ага Сәлимҗанов бу спектакль турында болай сөйли:

«Спектакльнең оформлениесе, костюмнары артык натуралистик иде — авыл йортларына хас бөтен вак-төякләренә хәтле күрсәтелгән бер өй, кабер өсләре калкып торган зират (соңрак, 1936 елда, азакны пәрдәнең оформлениесе бернинди үзгәртүсез диярлек «Миркәй белән Айсылу» спектакленә күчерелде). Артистлар нәкъ авылдагы ярлы крестьяннарча киенәләр. Спектакльдә бер-бер артлы бик күп җыр башкарыла. Диалоглар сүлпән һәм салмак кына алып барыла.

Зират күренеше. Каберләр арасында, кайгы-хәсрәтеннән шашкан хәлдә, Сәрвәр каңгырап йөри (аны Р. Кушловская уйный иде). Җеназа күтәреп узалар. Каберләр арасында хәерчеләр дога кылып утыра. Ягъни, чынлыкта зиратта була торган хәлләр бөтен җиренә җиткереп күрсәтелә.

Шуннан соң Сәрвәр үлә. Аның артыннан кыз янында мәхдүм агачка асылынып үлә. Мәхдүм ролен башкарган артистларны баудан көчкә коткарып калган чаклар була иде...»

Шулай итеп, спектакльдәге хәлләр нәкъ тормыштагыча итеп, тормыштагыча ритм белән, гомумиләштерелмәгән эпизодлары һәм очраклылыклары белән күрсәтелгән.

Билгеле инде, 1971 елда 1924 елдагы постановканы кабатлау мөмкин түгел иде. «Сүнгән йолдызлар» спектаклендә (режиссер М. Сәлимҗанов) «Миркәй белән Айсылу» спектакленә караганда да яңачарак адым сизелә. «Миркәй белән Айсылу»да әле актерлар гадәти көнкүрештәгечә ясалган оформлениедә уйныйлар иде (художник Ә. Тумашев). Монда инде бөтенләй шартлы декорацияләр ясала. Бернинди этнография, бизәк-мазар юк. Бөтенесе җыйнак-тыйнак, аз-саран бирелгән (художник М. Сутюшев). Сәхнә алдында ике, түрдә өч ширма. Ширмаларны борып, сәхнәгә икенче төрле төс һәм яктылык бирү вакыйганың урыны алмашынуын күрсәтә. Моның белән режиссер конкрет вакытка да, билгеле бер урынга да ишарә ясамый. Мондый оформление әсәрнең бөтен кешелек өчен уртак булган мәгънәсен ныграк ача төшәргә булыша. Бу очракта артистларның үз рольләрен психологик яктан дөрес һәм төгәл башкарулары да әсәрнең гомум гуманистик яңгырашын көчәйтә. Оформление шартлы булганга карап, тойгы-кичерешләр абстрактлашмый. Киресенчә, шартлы оформление артистларның уенына тәэсир итә — алар, гадәттәге көнкүреш обстановкасы булмаган буш сәхнәгә чыккач, үзләрен икенче төрлерәк хис итәләр, икенче төрлерәк «яши» башлыйлар. Шуның нәтиҗәсендә К. Тинчуринның бу мелодрамасы социаль яктан көчле яңгырашлы сәхнә әсәренә, искергән әхлак кануннарын, диннең кешелеккә зарарлы булуын фаш итә, сугышка каршы нәфрәт уята торган бер әсәргә әйләнә. Рецензентлар бу хакта бик дөрес яздылар: «Шактый озын, сүзгә артык юмарт пьесаны Марсель Сәлимҗанов бөтенләй яңа күз белән, үзенчә, хәзерге заман таләпләреннән чыгып укыган. Беренчесе һәм иң мөһиме — ул спектакльгә көрәш рухы өргән. Шуның аркасында Надыйр белән Сәрвәрнең кара дөньяга протестлары да, сәхнәдәге дәһшәтле кара ширмалар да, актерлар ансамбленең уены да сугышчан сыйфатлар алганнар» [1].

Спектакльнең уңышлы чыгуы, алда әйткәнебезчә, әсәрдәге идеянең, социаль актив фикернең тирәнтен эшләнгән, психологик яктан дөрес, конкрет кеше характерларына нигезләнгән булуыннан да килә.

«Миркәй белән Айсылу»да режиссер идеяне күп халык катнашкан күренешләр ярдәмендә ачарга тырышкан булса, биредә инде ул һәр образны психологик яктан җентекләп төгәл ачу юлы белән, тамашачыга аерым шәхесләр фаҗигасен җиткерә. Спектакльдә катнашкан артистларның Г. Нигъмәтуллина белән А. Харисовадан

---

[1] А. Гыйләҗев, Р. Батуллин, Сүнмәс йолдызлар кубәя, «Социалистик Татарстан» газетасы, 1971 ел, 21 февраль.

башкалары — яшьләр. Бу хәл режиссерның эшен бераз җиңеләйтә төшкән дияре кила. Чөнки яшьләр бу образларның элек ничек башкарылганын белмиләр, шуңа күрә аларның штамплашкан алымнарга иярү ихтималлары да азрак.

Сәрвәр (Ф. Хәмитова) белән Исмәгыйл (Н. Әюпов) образлары спектакльнең буеннан-буена ачыла киләләр. Башта алар яшьләрчә шат күңелле, шаян-шук, дәртле булсалар, соңыннан фаҗигале хәлдә ни эшләргә, ни чара кылырга белми аптырап калалар. Спектакльнең азагында Ф. Хәмитова психологик яктан бик төгәл, көчле уйный. Әлбәттә, әсәрнең бу куелыштагы финалын беренче куелыштагысы белән чагыштырырлык та түгел — аерма бик зур.

...Буш сәхнәнең һәр ягында — кара ширмалар. Ярым караңгы. Акылыннан язган Сәрвәр арлы-бирле йөгерә. Менә аның күз алдында якын, кадерле кешеләрнең сыннары пәйда була. Сәхнә дөм караңгы. Шушы караңгыда прожекторның сыек яктысы бер ак фигураны гына күрсәтә. Кинәт әле бер ширма, әле икенче, әле өченче ширма янында сүрән, тоныкнур яктысында Сәрвәр өчен якын, газиз булган кешеләрнең йөзләре күренә. Бөтен гәүдәләре түгел, йөзләре генә. Кыз эндәшкән тавышка таба йөгерә... Ләкин әлеге сын шундук юкка чыга. Икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә таба йөгерә, тик алар да төштәге кебек югала баралар. Ниһаять, бу сыннар, әллә нинди куркыныч тавыш-өннәр чыгара-чыгара, кызны бөтен яктан чолгап алалар. Бу хәлгә коты алынып, Сәрвәр үлә. Кыз үлү белән бу җен-пәри туе да юкка чыга. Спектакльнең азагы әнә шулай саран гына детальләр белән бик тәэсирле итеп эшләнгән.

Көчле уйналган образ — Надыйр мәхдүм образы. Аны ике артист: Ә. Шакиров белән Р. Таҗетдинов башкаралар. Артистларның икесе дә бөкре мәхдүмнең рухи халәтен дөрес уйныйлар. Бер яктан, ул үзенең гариплегеннән кимсенеп, көлү-хурлаулардан куркып, сагаеп яшәсә, дөньяга ачулы, бәгыре каткан бер кеше булса, икенче яктан, Сәрвәрне күрсә, ул бөтенләй танымаслык булып үзгәреп китә, аны җаны-тәне белән өзелеп сөя. Кызны очратуга, аның чыраендагы ачу, өметсезлек билгеләре шундук юкка чыга, йөзе ягымлыланып, яктырып китә.

Үзенең гариплегеннән кимсенеп яшәсә дә, ул үз тирәсендәге кешеләрнең күбесеннән зирәгрәк. Характер, психология логикасы эш-хәрәкәт логикасын да тудыра. Шуңа күрә дөньяның гаделсезлеген иң нык күралмаучы, шуңа җәберләнүче кеше — Надыйр мәхдүм. Ул йодрыгын төя-төя «күктәге» аллага каргышлар яудыра. Надыйр мәхдүм, бигрәк тә Р. Таҗетдинов башкаруында, үзенең гариплегеннән бик кимсенүче, шул сәбәпле дөньяның гаделсезлегеннән бик нык җәберләнүче Квазимоданы хәтерләтә.

Татар драматургиясендә берничә пьесада: К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» һәм «Җилкәнсезләр»ендә, Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу»ында бөкре (Надыйр мәхдүм, Рокыя, Гариф) образлары бар. Бу образлар дөньяга ачулы, караңгы чырайлы булулары белән бергә, оригиналь, үзенчәлекле итеп тә бирелгәннәр, бигрәк тә баштагы ике персонаж шундый. Алар акыллы, зирәк. Дөньяда барган социаль көрәшне алар ачыграк аңлыйлар, тирәнтен тоялар. Физик кимчелекле булу сәбәпле, алар үз эчләренә бикләнеп яшиләр, кешеләр белән аз аралашалар. Ләкин әнә шул ялгызлык аларны зирәк күңелле итә. Шуңа күрә дөньядагы гаделсезлеккә нәфрәт белдерүләре очраклы бер хәл түгел. Бу персонажларның шул үзенчәлеге театрның соңгы спектакльләрендә тагы да тулырак ачыла төште.

«Сүнгән йолдызлар»ның яңа вариантында спектакльгә пролог һәм эпилог кертелгән. Пьесадагы ике эпизодик персонаж — карт белән малай — беренче вариантта иң азакта узгынчылар итеп кенә бирелгән булсалар, хәзер алар вакыйгаларның үзенә бер төрле камертоны булып китәләр. Иң элек алар спектакльнең башында күренә. Буш сәхнә. Ике кеше — бер карт (Г. Фәтхуллин) белән бер малай (Н. Ибраһимова) узып бара. Алар «Каз канаты» җырын җырлыйлар. Малай бу җырның каян килеп чыкканлыгын сорый. Карт пьесаның сюжетын сөйләргә керешә. Спектакльнең азагында сәхнәдә тагы шушы ике кеше күренә һәм карт үзенең хикәясен сөйләп бетерә. Шул рәвешчә, спектакльгә үзенә бер төрле баш һәм азак куелган.

Иске традицияләрне яклаучылар күзлегеннән карaганда, «Сүнгән йолдызлар» спектакле уңышсызлыкка очрарга тиеш иде кебек, чөнки анда моңарчы татар тамашачылары күреп гадәтләнгән әйберләрнең күбесе кыскартылган. Баштарак театр үзе

да шулай булмагае дип шикләнә. Ләкин мондый шик-шөбһәләрне тормыш юкка чыгарды. Тамашачылар спектакльне яратып каршы алдылар. Гаҗәпләнүчеләр дә булды. Гадәти генә бер мелодрамадан шундый көчле социаль яңгырашлы сәхнә әсәре чыгарып булыр дип кем уйлаган, янәсе.

Татар классикасының яңача куелган спектакльләрен тамашачы яратып кабул иткән икән, бу да күп нәрсә турында сөйли. Кайчандыр культ дәрәҗәсенә күтәреп киленгән традициячелекнең гомере узды. Татар классикасы әсәрләренең уңышлы куелуы гына түгел, хәзерге һәм тәрҗемә пьесаларның яратып каралуы да шуны ук күрсәтә. Ниһаять, театрга элек һәм хәзер күпме тамашачы йөрүе дә шуны әйтеп тора. Әйтик, 1963 елда, театр иске традицияләр йогынтысында эш иткәндә, тамаша залында халык яртылаш кына яки аннан да кимрәк була иде (театрның финанс отчетлары шуны күрсәтә). Татар академия театрының соңгы еллардагы спектакльләре исә дистәләрчә һәм йөзләрчә тапкыр куела, зал һәр вакыт тулы була. (Моны да шул ук финанс отчетлары күрсәтә.) Тамашачы сан ягыннан арту белән бергә, сыйфат ягыннан да үзгәрде. Тамаша залында хәзер яшьләр, интеллигенция күбрәк күренә башлады. Әлбәттә, театрга аларны заманча куелган әсәрләр тарта.

«Миркәй белән Айсылу»да конфликт күп халык катнашкан күренешләр, «Сүнгән йолдызлар»да образларны социаль планда психологияләштерү аша чишелсә, «Американ»да икенче төрле бурыч куела.

Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар» комедиясен (режиссер М. Сәлимҗанов) «Американ»ны куюга хәзерлек чоры дип карарга кирәк. «Кыю кызлар» комедиясендә ук инде режиссер дин әһелләрен, тәкәббер байларны һәм аларның тиле-миле малайларын рәхәтләнеп көлә-көлә хурлыкка калдыра, искергән кануннардан аяусыз көлә. Ә менә заманына күрә зур кыюлык күрсәткән, егетләр киеме киеп мәдрәсәгә укырга килгән өч кызга зур симпатия белән карый. Бу комедия халыкка хас уенкөлке, батырлык-тапкырлык стихиясе белән сугарылган. Сатирик элементлар исә спектакльнең тукымасына аз-азлап кына салынган. Чын сатирик комедияне театр үзенең шуннан соңгы эшендә — К. Тинчуринның «Американ» комедиясендә күрсәтте.

К. Тинчуринның бу әсәре татар нэпманнарыннан көлеп язылган. Искәндәр исемле бер студент, нэпманнарның чит ил кешеләре алдында баш июләреннән файдаланып, аларны алдый, көлке хәлләргә калдыра. Нэпманнарга ул үзен Америкадагы бер татар галиме итеп таныта. Пьеса геройларыннан Муса дигән кешедә кыйммәтле китаплар, кульязмалар саклана. Бу алдашу әнә шуларны кулга төшерү өчен кирәк була.

Әсәр сәхнәгә фарс итеп, көлке бер тамаша итеп куела. «Сурәтләү чаралары буенча иң төгәле — «Американ» спектакле... Пьеса моннан утыз ел элек язылган булса да, идея максаты анык куелган һәм бүгенге заманга хас сурәтләү чаралары уңышлы табылганлыктан, хәзерге тамашачы аны яратып карый»,— дип язды «Правда» газетасы [1].

«Миркәй белән Айсылу», «Гүзәлем Әсәл», «Сүнгән йолдызлар», «Хуш, Назлыгөл» һәм башка драмалар белән чагыштырганда, бу комедиядә инде режиссер актерлар алдына бөтенләй икенче максатлар куя. Бер яктан, артистлар һәр вакыттагыча тойгыкичерешләрне чын итеп уйнарга тиеш булсалар, икенче яктан, бу чынлык үтә көлке, мәзәк рәвешләрдә бирелергә тиеш. Иң элек артистлар үзләре, Гоголь персонажлары йолкыш бер Хлестаковны усал ревизор дип кабул иткән кебек, «американ»ның чын булуына, үз геройларының гайре табигый кыланышларына ышанырга тиеш. Гоголь әсәрендә дә, бу комедиядә дә болай ышану өчен башлангыч бер нигез булырга тиеш. «Американ»да бу нигез — нэпманнарның совет властеннан ризасызлыгы. Татарстан җирлегендә бу хәлгә тагын милләтчелек мотивлары өстәлә. Шул сәбәпле, Мусаның үзен чын мөселман итеп күрсәтү өчен, башына фәс киеп йөрүе дә очраклы хәл түгел. Ике студенттан кала барлык геройлар «американ» белән очрашканда үз мәнфәгатьләрен кайгырту хакында гына уйлыйлар. Шуңа күрә «азат дөнья»дан килгән кеше күренү белән бу геройлар ялганны, алдашуны чын дип кабул итәләр. Искәндәр, Хлестаков шикелле, ни сөйләсә дә, ни кыланса да, аңа ышаналар.

Искәндәр (артист Р. Шәрәфиев) баштан ук болар белән «уен уйный». Бу образ эчендә ике кеше яши — бер яктан, ул җаваплы эш башкаручы совет студенты

[1] «Правда». 1970 ел. 1 август. О. Кайдалованың «Опираясь на традиции» исемле мәкаләсен карагыз.

(билгеле бер дәрәҗәдә разведчик сыман), икенче яктан, ул — ата-бабалары җиренә кайткан «американ» татары. Ләкин шушы ике кешедән тыш әле тамашачы тагын өченче кешене — артистның үзен дә тоеп тора.

Рольне башкаручының үз шәхесе дә катнашуы образга үзенә бер төрле колорит өсти. Студент ролендәге артистның үзе уйный торган «американ»нан үзе үк көлгәнен тамашачы күреп тора. Рольне шулай уйнау — татар театрында яңа нәрсә. Әнә шулай берьюлы өч кеше булып уйнау артистка теләсә ни кыланырга мөмкинлек бирә һәм болар барысы да табигый килеп чыга.

Р. Шәрәфиев — бүгенге татар театрындагы иң эксцентрик артист дисәк ялгышмабыз. Ул комедиядәге көлке, мәзәк рольләрне оста башкара. Әмма бу көлке-мәзәклек тамашачыны тиктомалга көлдерә торган түгел, сатирик яктан күпертелгән, ирония катыш көлү бу. Шуңа күрә актер Искәндәрне уйнаганда да комсыз, ахмак сәүдәгәрләрдән, надан галимнәрдән рәхәтләнеп көлә.

Ф. Халитов Шәехморза ролен моңарчы башкарган рольләренең берсенә дә охшамаганча уйный. Менә сәхнәдә өстенә курач пиджак, кыска балаклы аксыл чалбар кигән кечкенә генә бер кеше йөри. Иләмсез зур башында як-якка сирәк чәчләре тырпаеп тора. Аның бөтен кыяфәте, килеш-килбәте көлке. Бу «укымышлы ир» йөргән чагында да сикеренгәләп йөриме, чатанлапмы — аерып әйтүе кыен. Сөйләгәндә дә оратор кыяфәтенә кереп, карлыккан чыелдык тавыш белән акыл өйрәткән сыман сөйли. Ф. Халитов үзеннән арттырып уйнамый, рольне бик дөрес башкара. Ләкин шушы дөреслеге белән дә Шәехморза-Халитов карикатурага охшый.

Артистлардан А. Галиева (Дилбәр) белән Ф. Әхтәмова да (Мәйсәрә) үзләренең героиняларын ахмак бер туташлар итеп күрсәтәләр. Алар икесе дә «американ» егеткә ничек кенә итеп булса да ошарга, аны эләктерергә тырышалар. Дилбәр-Галиева 20 еллардагы Европа модасынча әллә ничек сәер һәм ямьсез киенгән карт бер кыз. Ул үзен укымышлы итеп күрсәтергә тырыша, сөйләшкән чакта күзләрен акайтып, тавышын үзгәртеп кыланчыклана, вата-җимерә французча сөйләшкән була, пианинода бер бармак белән генә ниндидер көй уйнаган булып маташа. Мәйсәрә-Әхтәмова исә укымышлы, мәдәниятле туташ түгел. Аны француз «манер»ларына өйрәтмәгәннәр. Өстендәге киеме дә татарча гына. Әмма ахмаклыгы, томаналыгы чиктән ашкан. Әнә шул акылы белән дә ул Америкага китү, бай хатыны булып рәхәттә яшәү турында хыяллана.

«Американ»ның соңгы вариантындагы яңалык шул — актерлар үзләренең геройларын ачыктан-ачык «фаш итеп» уйныйлар. 1924 елда исә аны гадәттәге көнкүреш комедиясе итеп, бөтен көнкүреш ваклыклары белән сәхнәгә куйганнар. Ул спектакльдә вакыйга үз җаена акрын гына, салмак кына барган. Төп мизансцена — күп итеп пәрәмәчләр куелган өстәл тирәсендә самовардан чәй эчә-эчә сөйләшеп утыру. Геройлар тормыштагыча ашыкмыйча, бик озаклап әңгәмә корып, гәпләшеп утыралар. Әлбәттә, ул постановкада пролог та, эпилог та булмаган, хәзергесендәге шикелле Искәндәр комедия геройларын сандыктан да тартып чыгармаган. Ул заманда артистлар «чын» нэпманнарны уйнаганнар. 1924 елларда әле, НЭП заманында, сәхнәдә чын тормышны күрсәтү тарихи яктан кирәк була.

Бу комедияне берничә дистә ел узганнан соң, 1969 елда гына яңача куярга мөмкинлек туа. Бу юлы инде Г. Камал исемендәге академия театры комедияне чын фарс итеп куя, әллә кайчан үлеп, череп беткән геройларны режиссер нафталин исе сеңгән зур сандык эченнән берәм-берәм тартып чыгара. Бу сандык сәхнәнең уң як читенә куелган, һәм геройлар аннан төчкерена-пошкырына килеп чыгалар. Бу — инде күптән узган, онытылып беткән заман. Без рәхәтләнеп көлә-көлә шул заман белән «хушлашабыз».

Шуңа күрә актерлар да, бүгенге заманча уйнау логикасыннан чыгып, үз геройларын ачыктан-ачык фаш итәләр. Аларның һәркайсы, бүгенге заман актеры булган бер хәлдә, әсәрдә билгеле бер образны уйный һәм шул ук вакытта бу образга карата ачыктан-ачык үз мөнәсәбәтен дә күрсәтә. Алар образны дөрес башкаралар, ләкин шул ук вакытта эчләреннән генә үз персонажларыннан рәхәтләнеп көләләр, аларның ахмаклыгын, мәгънәсезлеген ачалар.

«К. Тинчуринның «Американ» комедиясен М. Сәлимҗанов, оста, тапкыр алымнар кулланып, чын фарс итеп куйган... «Гомерләрен яшәгән» бу геройларның бер тиенгә

тормаслык кешеләр икәнлеген, нэпманнарның тарих сәхнәсеннән төшеп калуы законлы бер хәл булуын актерлар бик шәп уйнап күрсәтәләр»[1],— дип язды «Советская Россия» газетасы.

Уңышлы куелган әлеге спектакльләр арасында «Зәңгәр шәл» пьесасы үзенә бер аерым урын алып тора. «Зәңгәр шәл» гаҗәп кызык язмышлы бер әсәр булды. 1926 елда беренче тапкыр сәхнәгә куелганнан бирле ул театр репертуарында даими сакланып килә диярга була. «Зәңгәр шәл» легенда сыман бер әсәргә әйләнде. Ул кайда гына, кайчан гына һәм ничек кенә куелмасын, татар тамашачысы аны һәр вакыт яратып карый. Күпчелек кеше пьесаның кимчелекләре барлыгын да белә. 1930 елда ук әле «Эшче» газетасында Муса Җәлил: «Пьесада бернинди социаль көрәш күренми, ә Булатның шахтерлык эшенә бернинди мөнәсәбәте юк», дип яза. Шуңа да карамастан, «Зәңгәр шәл»нең популярлыгы кимеми. Драматург Д. Вәлиев хәтта «Зәңгәр шәл»нең сере» дигән махсус мәкалә дә язды. Үз-үзенә сорау куе рәвешендә ул болай ди: «Шулай да бу кай ягы беләндер беркатлы, гади бер мелодраманың тамашачыга ошавының сере нәрсәдә? Әсәргә энҗе бөртекләре шикелле сибелгән халык юморындамы? Спектакльнең аерылгысыз бер кисәге булып киткән, халык рухы белән сугарылган Сәйдәшев көйләрендәме? Спектакльне караганда безгә үзебезнең онытыла язган бала чак, үсмер чак елларын хәтерләтә, күңелдә туган илгә, туган җиргә тирән тойгылар уята торган татар халык биюләрендә, халык җырларындамы?».

Язучы үзенең бу сорауларына турыдан-туры җавап бирми, шулай ук яңа редакциясенең әһәмияте, бу әсәрнең яңадан сәхнәгә куелган татар классик пьесалары арасындагы урыны хакында да әйтми. Авторның уңай рухта әйткән фикерләрен мәкаләдәге сорауларга җавап итеп аңларга кирәктер, күрәсең. Әсәрдәге халык юморы да, Сәйдәшев җырлары да, биюләр, халык бәйрәме күренешләре дә һәм, ниһаять, кабатланмас бер үзенчәлекле халык рухы да — шулар барысы бергә К. Тинчурин мелодрамасының гаҗәп дәрәҗәдә популяр булуына сәбәп.

Шуның белән бергә, тагы бер нәрсәне онытмыйк. Тамашачы әсәрнең беренче куелуыннан бирле кабатланып килгән вариантын күреп гадәтләнгән. Милли үзенчәлекле бай кием, бизәүле җиһаз, озын колгага тагылган чигүле сөлгеләр. Үткен телле, тапкыр сүзле егетләр, кызлар. Бию, җыр, музыка — болар барысы халык бәйрәме рухын тудыра. Шушы бәйрәм фонында бер-берсе белән кавыша алмаган ике сөйгән яр язмышы да бар. Тамашачы алар өчен борчылып, аларны кызганып утыра.

Пьесада персонажларның эш-хәрәкәтләрен социаль яктан мотивлаштыру урынына, беренче планга аны сәхнә тамашасы буларак кочле итеп бирү бурычы куела. Актерларның эше дә бер-ике сызык белән билгеләнгән тышкы алымнарга гына кайтып кала. Шуңа күрә М. Сәлимҗанов, спектакльне яңача куярга керешкәч, шактый кыен хәлдә кала. Бер яктан, бүгенге академия театрында инде спектакльләрне үткән чор эстетикасы буенча куеп булмаса (бигрәк тә «Миркәй белән Айсылу», «Кыю кызлар» һәм «Американ»нан соң), икенчедән, тамашачының афишадан төшми торган спектакльгә ияләшүе, гадәтләнүе дә бар. Бу яктан караганда, әлбәттә, дистәләрчә еллар буе уйналмаган, бары тик картлар хәтерендә генә сакланган пьесаларның трактовкасын тамырыннан үзгәртү күп өлеш җиңелрәк. Ә болар белән эш итү катлаулырак. Чайковскийның атаклы «Аккош күле»н куйганда элекке традициядән бөтенләй читләшеп булмаган кебек, биредә дә традицияне бозган режиссерның уңышсызлыкка очравы ихтимал. Шуңа күрә, турысын әйтик, режиссер яңалык мәсьәләсендә артык ерак китә алмаган. «Зәңгәр шәл»нең яңадан эшләнгән варианты театр тарафыннан аңарчы куелган милли классик әсәрләребез кебек үк ачыш була алмады.

М. Сәлимҗанов эш-хәрәкәтләрне логик яктан нигезли, аклый төшкән (беренче вариантларында моңа аз игътибар ителгән). Пьеса «Зәңгәр шәл» дип аталса да, бу шәл анда бер генә тапкыр күренә иде. Шуның белән шәлнең роле дә бетә. Шуңа күрә, әсәрнең исеменә кергән бу нәрсәне ничек тә аклау өчен, М. Сәлимҗанов аны оформлениенең бер элементы итеп файдалана, сәхнәнең сул ягына өскә зәңгәр шәл элеп куела һәм асылда бөтен спектакль шул шәл фонында уйнала. Беренче пәрдәнең оформлениесе үзгәртелә. Мәйсәрәнең абзасы саран, кансыз кулак Җиһаншаның

[1] «Советская Россия», 1970 ел. 30 июль. К. Березинның «Секрет успеха» исемле мәкаләсен карагыз.

ишегалды элек колгалар белән генә киртәләп алынган, ямь-яшел чирәм үскән якты бер урын итеп бирелгән булса, хәзер зур капкалы, биек коймалы ишегалды күрсәтелә. Мондый оформление актерларга да билгеле бер дәрәҗәдә тәэсир итми калмый. Бәйрәм итүче яшьләр шау-гөр итеп Җиһанша йортына килеп керсәләр дә, биредә үзләрен уңайсыз хис итәләр. Биек койма, эре-эре бүрәнәләрдән салынган таза каралты-кура аларның иреген чикли кебек. Җиһаншаның күренеп торган байлыгы, ә крестьяннарның бәйрәмдә дә артык гади, ярлы киенүе кулак белән бөтен авыл арасында зур каршылык барлыгын сиздерә. Пьесадагы вакыйгалар ике капма-каршы сыйныфның социаль көрәше юнәлешендә бармаса да, режиссер театр сәнгатенә хас чаралар белән әсәргә шушы көрәш элементларын кертә. Спектакльдә өлешчә кайбер образлар да үзгәртелә. Мәсәлән, элек тәмле аш яратучы бер карт итеп кенә уйналган ишан Ш. Биктимеров башкаруында хәйләкәр, комсыз, намуссыз итеп күрсәтелә, ягъни актер бу образга яңа сыйфатлар өсти. Шулай да, кайбер үзгәртүләр булуга карамастан, тулаем спектакль үзенең элекке традициясендә кала.

Шунысы кызыклы, Мәскәү тамашачылары (театр спектакльнең бу вариантын 1970 елда Мәскәүгә гастрольгә баргач күрсәтә) пьесаның куелышындагы үзгәрешләрне яратмый. Казанда исә спектакль андый ризасызлык тудырмый. Күп нәрсә аңлата торган кызыклы факт бу: Казан тамашачыларын театр инде тәрбияләгән, аларга заманча зәвык биргән. Шуңа күрә алар театрны яраталар, спектакльләргә еш йөриләр, яңа постановкаларны карарга хәзерлекле булуларын күрсәтәләр. Мәскәү тамашачылары хакында алай әйтеп булмый.

М. Фәйзинең атаклы «Галиябану» пьесасын әллә ни исе китмичә кабул итүе дә шулай ук очраклы бер хәл түгел. «Зәңгәр шәл»дән кала үзенең популярлыгы ягыннан бу мелодрама, һичшиксез, икенче урында тора. Әсәргә Салих Сәйдәшев музыка язганнан соң халык аны тагы да яратыбрак карый. Шул сәбәпле татар театрының үз гомере дәвамында бу әсәрне кайта-кайта сәхнәгә куюы бик табигый. Спектакльнең соңгы премьерасы 1972 елның башында булды. Пьесаны сәхнәгә Хәким Сәлимҗанов куйды. Тик, кызганычка каршы, «Галиябану»ны яңадан сәхнәгә кую сүздә генә яңа булып чыкты.

Сәхнәдә, «элекке заманнардагы» шикелле, яңадан шул ук билгеле бер заманга һәм җирлеккә бәйләнеше булмаган кешеләр йөри. Тамашачы элеккечә үк рәхәтләнеп С. Сәйдәшевның искиткеч гүзәл музыкасын тыңлый. Артык матур декорацияләр, бәйрәмчә киенгән кешеләр идиллик картина тудыра.

Сәнгатьчә югары дәрәҗәгә җиткереп, бүгенге заман ысулында уйналган берничә әсәрдән соң, искергән манерда: һәр сүзне кирәгеннән артык кычкырып әйтеп, публикага тәэсир итү исәбе белән генә уйнала торган спектакль кую, әлбәттә, бик гаҗәп тоела. Галиябану (М. Хәйруллина) белән Хәлил (Р. Әбелмәмбетов) рольләрен башкаручыларга да режиссер ярдәм итә алмаган: алар «сабый акыллы», кайгы-хәсрәт, газап кичерүче чарасыз-пассив геройлардан ерак китмәгәннәр. Арада тик бер генә актер — Исмәгыйл ролен башкаручы И. Йомагулов кына — үзенең уены белән башкалардан аерылып тора. Бу очракта артистның сәләтле булуы, мөстәкыйль уйлый белүе ярдәм иткәндер. Исмәгыйл образын гадәттәгечә явыз бер кеше итеп кенә уйнаудан бигрәк, И. Йомагулов үзенчә ярата белә, газаплы тойгылар кичерә торган характер тудырырга омтыла. Исмәгыйл-Йомагулов акайган күзле, әшәке тавышлы, кискен хәрәкәтле трафарет бер явыз бәндә түгел. Аның газаплы кичерешләре, әрнүсыкранулары йөзенә чыккан. Галиябану белән ул бик йомшак итеп сөйләшә, үзенең яратуын кызга аңлатырга тырыша.

Башка классик пьесаларыбыз кебек, «Галиябану»ны да сәхнәгә яңача куярга мөмкин. Ләкин татар академия театрының үсешендә һәм милли классикабызны яңача аңлауда төп урынны «Галиябану» түгел, бәлки 60 нче елларның азагында һәм 70 нче елларның башында сәхнәдә өр-яңадан туган «Миркәй белән Айсылу», «Американ», «Кыю кызлар» һәм «Сүнгән йолдызлар» спектакльләре алып тора. Болар — бүгенге заман театрына хас сәнгать чаралары белән бөтен, төзек бер әсәр итеп эшләнгән, актерлар тарафыннан зур осталык белән башкарыла торган ачык социаль фикерле спектакльләр. Шуңа күрә тамашачы да аларны яратып карый.

Әмир Мәхмүдов

# МУСА ҖӘЛИЛНЕҢ ТӘНКЫЙТЬ ЭШЧӘНЛЕГЕ

Татар әдәбиятын бөтен ил һәм дөнья аренасына башлап Г. Тукай, М. Гафури һәм Г. Ибраһимовлар алып чыкты. К. Нәҗминең «Язгы җилләр» һәм Г. Бәшировның «Намус» романнары дөнья халыкларының күп телләренә тәрҗемә ителде. Шулай да татар әдәбияты белән чын-чыннан кызыксыну Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре» басылып чыккач башланды. Франциянең атаклы язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе Луи Арагонның 1955 елда басылып чыккан «Совет язучылары» дигән китабында татар әдәбиятына аерым бүлек багышланган иде.

«Муса Җәлил... Сез, Франция диварларында эленеп торган зур кызыл афишаларны оныткан кешеләр, кабатлагыз бу исемне... Муса Җәлилнең ялкынлы җыры түгел, салкын тәне туфрак белән күмелде», — ди ул. Һәм аның «уч алырга чакырган ал байрак астында ант иткән» барлык көрәшчеләр өчен үлүенә басым ясый. Италия язучысы Дж. Джерманетто, Бельгия язучысы Р. Бодар, немец язучылары Л. Небенцаль һәм Э. Мюллер аның батырлыгы белән чын күңелдән соклануларын белдерделәр.

«Моабит шигырьләрендә без Муса Җәлилнең кайнар йөрәге тибешен ишетәбез, аларда шагыйрьнең тирән тойгылары һәм фикерләре ачыла, өмете һәм теләкләре чагыла. Бу шигырьләрдә без геройның, коммунистның сугышчан рухын, берни дә какшата алмас ихтыяр көчен, җиңелмәс ышанычын тоябыз. Бу шигырьләрне укыган саен аларны корычтай нык көрәшче, үз Ватанының патриоты, халыкның тугры улы гына яза алуына ышанабыз»[1] — дип язды Леон Небенцаль.

...М. Җәлил ифрат күпкырлы әдип була. Татар халкының мәдәният тарихында ул шагыйрь буларак кына түгел, әдәби тәнкыйтьче буларак та нык-лы урын алды. Бик күп шигырь-поэмалар, либреттолар, балалар өчен пьесалардан тыш, шагыйрь әдәбият-сәнгатьнең төрле тармакларына караган йөздән артык мәкалә яза.

М. Җәлилнең бай әдәби мирасы бик күп галимнәрнең, язучыларның игътибарын үзенә җәлеп итте. Шагыйрьнең иҗаты турында унга якын кандидатлык диссертациясе язылды. Шуңа да карамастан, әдипнең әдәби-тәнкыйть өлкәсендәге мирасы әлегә кадәр тиешенчә тикшерелмәгән. Җәлил иҗатын иң күп өйрәнгән, ул хезмәтләрне туплап укучыларга җиткерүдә зур хезмәт куйган өлкән тәнкыйтьче һәм галим Гази ага Кашшаф бу хакта шагыйрьнең «Сайланма әсәрләр»енә язган кереш сүзендә дә әйтеп уза. Шагыйрь иҗатын өйрәнүче галим һәм тәнкыйтьчеләрдән Р. Бикмөхәммәтов, Р. Мостафин, Н. Юзиев, В. Воздвиженский, К. Барская, Й. Исәнбәт үз хез-

[1] Воспоминания о Мусе Джалиле, Рус телендә. Казан, 1966 ел, 232 бит.

мәтләрендә аның тәнкыйть мәкаләләреннән аерым өзекләр китерсәләр дә, шагыйрьнең тәнкыйть эшчәнлегенә махсус тукталмыйлар. Шуңа күрә бу мәкаләдә игътибарны М. Җәлил иҗатының әнә шул аз өйрәнелгән өлкәсенә, аның тәнкыйть хезмәтләренә юнәлтәсе килә.

М. Җәлилнең әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте өлкәсендә актив эшли башлавы утызынчы елларга туры килә. Ул мәкаләләрнең тематикасы күп төрле. Татар халкының тарихи үткәне, әдәбият, театр, опера сәнгате мәсьәләләре һәм башкалар, һәм башкалар. Бу мәкаләләрнең күбесе Мәскәүдә чыгып килгән «Коммунист» газетасында, «Ударниклар», «Октябрь баласы» журналларында басыла, зуррак күләмлеләре «Совет әдәбияты» журналында урын ала.

Муса Җәлил иң элек әдәбият-сәнгать әсәрләренең сыйнфый асылына һәм халыкчан характерына игътибар итә. Ул буржуаз сәнгать тарафдарларына, халыкның культура тарихын бозып күрсәтүчеләргә кискен каршы чыга, аларның чын йөзен фаш итеп, гыйльми тирәнлек һәм публицистик ялкын белән сугарылган мәкаләләр яза: «Бервакытны кайбер иптәшләр арасында тарихка коммунистик аң өчен ят булган, кире, юкка чыгарып карау хөкем сөрә иде. Бу, әлбәттә, безнең арада сакланырга тиеш түгел. Безнең халыкның тарихы тирән өйрәнүне, гыйльми тирән эшләүне һәм тарихка буржуача ят караш тенденцияләреннән әрчүне сорый. Шунлыктан язучыларның тарихи үткәнебез белән кызыксынулары, конкрет тарихи фактларны үз иҗатлары аша реалистик төстә, дөрес итеп чагылдырырга омтылулары зур әдәби һәм гыйльми кыйммәткә ия булган уңышлы адым һәм ул революцион аңлылыкның, чын патриотизмның чагылышы булып тора». (Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том. 346 бит.)

Театр сәнгатенең үсеш мәсьәләләрен М. Җәлил киң теоретик планда тикшерә. Чорның зур проблемаларын күтәргән, заман таләпләренә тулысынча җавап биргән әсәр генә, М. Җәлил фикеренчә, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүгә ярдәм итә. Әдип үз иҗаты белән кешеләр аңында хезмәткә, социалистик сәнгатькә карата җаваплылык хисе тәрбияләргә тиеш, ди ул. Ул, беренче чиратта, сәнгать әсәрләренең сыйнфый, партияле булуларына басым ясый. Чынбарлыкка булган мөнәсәбәтен тирән эчтәлек һәм үзенчәлекле образлар аша белдергәндә генә язучы үзенең эстетик идеалын укучыга җиткерә ала, ди.

М. Җәлил татар әдәбиятын һәм сәнгатен кешелек җәмгыятенең мәдәни казанышларыннан аерып карамый. Шуңа күрә ул К. Тинчуринның «Кандыр буе», Ш. Камалның «Ут», Зөлкарнәйнең «Өермә», С. Батталның «Язулы яулык» әсәрләренә дөнья сәнгате ирешкән иң югары биеклектән карап бәя бирә. Язучыларның иҗатына анализ ясаганда, ул татар әдәбиятындагы күп кенә җитешсезлекләргә дә тукталa: «Бездәге әсәрләрдә зур җитешсезлекләрнең берсе — бөтен мәсьәләләрне бер әсәргә тыгарга тырышу, бөтен типларны бер әсәрдә бирергә омтылудан гыйбарәт. Бездә нинди генә темага булсын, бер әсәр языла икән, анда вредительлек тә, ярыш та, ударниклык та, икмәк җыю да, техника өчен көрәш тә, интеллигенцияне безгә таба бору да, бар да, бар да керергә тиеш булып чыга». (Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том. 124 бит.)

Совет әдәбияты тарихыннан билгеле булганча, тәҗрибәле язучылар һәр вакыт башлап язучыларның иҗаты белән кызыксынып яшәгәннәр, әдәбиятта яңа талантлар ачканнар, яшь әдипләргә ярдәм кулы сузганнар. Бу яктан бигрәк тә Максим Горький эшчәнлеге игътибарга лаек. Мәшһүр сүз остасы редакцияләгән «Литературная учеба» журналы даими рәвештә яшь язучылар өчен әдәби консультацияләр биреп барган. «Литературная учеба» журналының уңай тәҗрибәсенә таянып, М. Җәлил үзәк татар газета-журналларында әдәбият мәсьәләләре, шигырь теориясе буенча тирән эчтәлекле мәкаләләр белән чыгыш ясый. Шагыйрь илебезнең төрле өлкәләрендә яшәүче яшь татар язучылары белән нык бәйләнеш тота. Ул аларның иҗаты белән махсус рәвештә кызыксынып тора. «Ударниклар» журналының 1931 елгы беренче санында М. Җәлилнең «Яшь шагыйрьләр белән әңгәмә» дигән мәкаләсе басылып чыга. Әлеге мәкаләсендә ул шигырь теориясенең кайбер мөһим мәсьәләләренә тукталa. Җәлил яшь ша-

гыйрьләрне үзләренең фикерләрен шигъри образлар, афоризмнар аша әйтеп бирергә, әдәби әсәрнең эчтәлеге һәм формасы өстендә җиң сызганып эшләргә чакыра. М. Җәлил «Дүртиленең яшь язучылары» дип исемләнгән мәкаләсендә заман сулышын тоеп иҗат итүгә, әдәбият әсәрләрендә чорның мөһим проблемаларын чагылдыруга аеруча нык басым ясый. Иҗатлары кайчандыр Җәлил тарафыннан җентекләп тикшерелгән Ш. Шәһәретдинов, С. Баттал, М. Садри, Г. Әмири кебек татар һәм башкорт язучылары күптән инде әдәбиятта үз урыннарын алдылар.

Шагыйрь әдәбият һәм сәнгать әсәрләренә һәрчак зур таләпчәнлек белән якын килде, каләмдәш дусларының иҗатына карата һәрчак искиткеч игътибарлы булды.

Үзенең күп кенә мәкаләләрендә М. Җәлил яшь буынга әдәби-эстетик тәрбия бирү мәсьәләләрен күтәреп чыга. Бу эшне ул культура революциясенең гомуми бурычлары белән бәйләп карый. Аның фикеренчә, эстетик тәрбия төп максатка — коммунистик тәрбия бирүгә, яңа җәмгыять кешесе формалашуга хезмәт итәргә тиеш. Бу фикер аның «Совет балалар әдәбиятына иң нык игътибар», «Дулкыннар», «Күршеләр», «Яшь театрның үсү юлы», «Сүз башы урынында» дигән мәкаләләрендә ачык чагыла.

М. Җәлилнең күләме ягыннан зур булмаган мәкаләләрендә дә тирән фикерләр әйтелә. Бу яктан бигрәк тә «Сүз башы урынында» дигән мәкаләсе аерылып тора. Балалар өчен язылган җырларның эстетик үзенчәлегенә тукталып, ул кызыклы күзәтүләр ясый, җырларны ничек өйрәнү хакында методик күрсәтмәләр бирә: «Без бу беренче җыентыгыбызны эшләгән вакытта башлап мәктәпкә кадәр һәм мәктәпнең беренче группаларында укучы балаларны күздә тоттык. Шуның өчен безнең бу беренче җырларыбызның тематикасы шул балаларга якын булган табигатьтән, кошлар һәм хайваннар тормышыннан алынды». (Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том. 204 бит.)

М. Җәлил яшьтән үк социализм төзү өчен барган көрәш эчендә кайный. Ул туган авылы Мостафада пионер хәрәкәтен оештыручыларның берсе була, соңрак комсомол эшләрендә актив катнаша. Мәскәү дәүләт консерваториясе каршындагы Татар опера студиясенең әдәби бүлек мөдире, «Октябрь баласы» журналының редакторы булып эшли. «Коммунист» газетасының әдәбият һәм сәнгать бүлеге белән җитәкчелек итә. Шундый бай хезмәт юлы аңа әдәбият-сәнгать әсәрләрен тормыш белән бәйләп карарга зур мөмкинлекләр тудыра.

Муса Җәлилнең әдәби тәнкыйть хезмәтләре арасында татар халкының музыка, опера, балет, театр сәнгатен үстерүгә багышланган мәкаләләре аеруча игътибарга лаек. Аның «Татар совет музыкасы һәм композитор Ключарев», «Яшь театрның эш үрнәкләре», «Атаклы гармонь остасының юбилее», «Дулкыннар», «Яшь театрның үсү юлы», «Татар опера театры», «Драматургия-без алдындагы бурычлар», «Шүрәле» балетына язылган либретто турында», «Алтынчәч» һәм «Илдар» опералары турында» дигән тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләре театр сәнгатенә багышланган әсәрләрнең алтын фондына керде. «Татар совет музыкасы һәм композитор Ключарев» исемле мәкаләсендә шагыйрь татар халкының музыка сәнгатенә тирән анализ ясый. Шагыйрь анда Октябрь революциясенә кадәрге музыкабызның артта калу сәбәпләрен ачыклый. М. Җәлил ислам диненең татар музыкаль культурасын үстерүдә киртә булып торуы турында яза, татар сәнгатенә, ислам диненең тискәре йогынтысы белән бергә, музыкаль культура үсешен тоткарлаучы төп киртәне әдип, иң беренче чиратта, тормышның социаль чыганакларында — патша хөкүмәтенең рус булмаган милләтләргә дошманнарча политика үткәрүендә күрә, «буржуазиянең классик мәнфәгатьләре сәнгатьнең үсүенә туры килмәвен» билгеләп үтә. Мәкаләдә Солтан Габәши, Салих Сәйдәшев, Латыйф Хәмиди, Нәҗип Җиһановлар иҗатына югары бәя бирелә. Шагыйрь татар музыкасының төп сыйфатларын ачыклый. Татар музыкаль сәнгатенең актуаль һәм әһәмиятле мәсьәләләрен күтәреп чыга, композиторларның мең еллар буена яшәп килгән халык җырлары традициясен уңышлы дәвам итүенә туктала.

1934 елда Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында Татар опера студия-

се оештырыла. Ләкин аның эше беренче көннән үк җайга салынмый. Бу хәл, әлбәттә, Җәлилне борчымый калмый, һәм ул, әдәби бүлек җитәкчесе буларак, Татар опера театрының киләчәге өчен көрәшкә кушыла. 1939 елда «Татар опера театры» исемле мәкалә язып, ул студия эшендәге кимчелекләргә туктала, укучыларны булачак артистларның ничек укулары белән таныштыра. Опера сәнгатенә караган бер генә мөһим мәсьәлә дә М. Җәлил игътибарыннан читтә калмый. Шагыйрь Татар опера студиясенең төп бурычын югары квалификацияле артистлар әзерләүдә күрә, студиянең җырчылары бөтен дөнья һәм рус музыкаль культурасының алдынгы тәҗрибәсенә таянырга тиешлеген билгеләп үтә.

Күп кенә кыенлыкларга да карамастан, студиянең эше уңышлы тәмамлана. Җәлил бу фактны татар опера сәнгатендә зур әһәмияткә ия булган «тарихи баскычка» тиңли: «Бер яктан, җырчылар, үзләре беркетелгән педагогларның ярдәме белән, классларда тавышларын кую, җыр техникасын үзләштерү, музыка теориясен өйрәнү юлында эшләсәләр, икенче яктан, оригиналь һәм тәрҗемә опера материаллары өстендә, опера партияләрен үзләштерү, булачак опера театрының репертуарын хәзерләү һәм актерлык мастерлыгына ия булу буенча эш алып бардылар... Шулай итеп, Татар опера студиясе уку белән производство эшенең, теория белән иҗат эшенең ныклы бәйләнеше нигезенә корылды. Ул бер үк вакытта яшь кадрларга белемнәрен арттыру өчен мәктәп хезмәтен дә үтәде. Һәм беренче Татар опера театрының төзелүенә хәзерлек баскычы да булып торды». (Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том. 250 бит.)

Татар опера театрының үсү, формалашу юлын М. Җәлил интернациональ процесс дип атый һәм театрның үсүендә аның җитәкчесе С. Бергольц һәм дирижер Пазовскийларның ролен аеруча билгеләп үтә.

Мәкалә М. Җәлилнең дөнья сәнгате казанышларын тирән үзләштергән зур эрудицияле әдип булуын күрсәтә. Хәер, моңа әллә ни гаҗәпләнергә дә кирәкми. М. Җәлилнең шагыйрь һәм җәмгыять эшлеклесе булып формалашуында, халкыбызның эстетик культурасы белән беррәттән, рус һәм бөтен дөнья эстетик культурасының да роле бик зур. Ул Пушкин, Белинский, Чернышевский, Добролюбов, Луначарский, Г. Тукай, М. Гафури әсәрләрен зур дикъкать белән өйрәнгән. Җәлил әдәби осталыкка күренекле язучылардан өйрәнүне максат итеп куйган, бигрәк тә Владимир Маяковский һәм Һади Такташ әсәрләрен тирән үзләштергән. Шагыйрьнең Татарстан язучылар союзында 1940 елда уздырылган җыелышта ясаган чыгышы әнә шул хакта сөйли: «Без В. Маяковский һәм Һ. Такташ кебек чорыбызның зур шагыйрьләрен бик яратабыз. Ләкин алардан үз чорыбызның рупоры булырга ныклап өйрәнмибез. Маяковский көннең җылы, актуаль лозунгларын поэзияләштергән чын сугышчан партиячел поэзияне тудырды. Ул үзенең үткен, сугышчан поэзиясе белән массаны партия лозунгларын үтәүгә туплады. Бездә менә бу тармак күп артта калды. Бу өлкәдә Н. Баян, Ә. Исхак, Ш. Маннур кебек шагыйрьләр уңышлы гына эш күрсәтсәләр дә, күп шагыйрьләребез читтә торалар. Политик темадагы лирик шигырьләребездә Маяковскийга хас көчле образлылык, югары художество сыйфаты, оригинальлек һәм үткенлек җитешми». (Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том. 366 бит.)

Шагыйрь А. Барбюс, Э. Потье, Р. Роллан, М. Лермонтов, В. Маяковский иҗатларына очраклы рәвештә генә мөрәҗәгать итми. Чын мәгънәсендә интернационалист буларак, М. Җәлил әдәбиятларның тыгыз бәйләнеше өчен көрәшә, төрле халыкларның яңа әдәби алымнары аларны баетуы турында яза: «Поэзиядә яңа художество алымының — ягъни халык җыры һәм эпосы стилен үзләштереп, халык иҗатындагы образлылык системасыннан, форма, сурәтләү чаралары байлыгыннан файдаланып, әсәр тудыру үрнәгенең урын алганын күрәбез... Безгә бу тип әсәрнең классик үрнәге булган «Русьта кем өчен тормыш яхшы» (Некрасов) поэмасы бар һәм мин шул юнәлештә иҗат эзләнүләрен үстерү уңай нәтиҗәләр бирер, дип уйлыйм». (Муса Җәлил. Сайланма әсәрләр. III том. 351 бит.)

Тагын шундый факт та бик кызыклы. «Коммунист» газетасының 1933 елгы 18 март санында М. Җәлил «Инте-

национал»ның татарча тәрҗемәсенә тирән анализ ясый. Шагыйрь «Интернационал»ны ирекле тәрҗемә итүне тәнкыйтьләп, аны татарчага төгәл тәрҗемә итү кирәклегенә, ул әсәрнең татар пролетариатын интернациональ тәрбияләүдә роле зур булуга туктала.

М. Җәлилнең әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренә караган мәкаләләренең стиле дә бик үзенчәлекле. Алар укучыны җәлеп итәрлек җиңел тел белән язылганнар. Үз фикерен ачык итеп аңлатып бирү өчен, шагыйрь үткен фразеологик алынмаларга, мәкальләргә һәм халык әйтемнәренә мөрәҗәгать итә.

Француз язучысы Анри Барбюс турында язамы, В. Маяковский яки Э. Потье иҗатын тикшерәме, ул, беренче чиратта, алар иҗатының төп үзенчәлеген ачып бирергә омтыла: «Бөтен дөнья пролетариатының сугышчан көрәш гимны булган «Интернационал»ның авторы — Эжен Потьеның иҗаты Франция һәм бөтен дөнья пролетариатының революцион көрәше белән тыгыз бәйләнгән. Ул 1848 елгы революцион пролетариат белән бер сафта булып, эшчеләрне килешүсез көрәшкә чакырган шигырьләрен язды. Бу шигырьләр тирән революцион содержание белән сугарылганнар һәм аерым бер үткенлек, дәрт һәм ялкын белән капитализм дөньясының черек нигезен ачып күрсәтеләр. Бу шигырьләр, һәрбер эшчегә аңлашырга җиңел, простой булу белән бергә, һәрбер көрәш кешесен дулкынландырырлык көчле ялкынлы һәм нәфисләр. Ул шигырьләр революцион сыйныфның бөтен хәрәкәте, тормышы һәм көрәше белән сугарылганнар». (Муса Җәлил, Сайланма әсәрләр. III том, 130 бит.)

Муса Җәлилнең тәнкыйть материаллары бүген дә актуаль һәм әһәмиятле, алар әдәбият теориясенә кагылышлы мәсьәләләрне ачыклауда ярдәм итәләр. Чөнки шагыйрь тәнкыйть мәкаләләрен бер татар әдәбиятын гына түгел, ә бөтен совет әдәбиятының киләчәген күз алдында тотып язган һәм шул югары таләпләрдән чыгып, милли язучылар алдында зур бурычлар куйган. Мәсәлән, М. Җәлил «Ударниклар» журналының 1931 елгы 5—6 саннарында басылган «Ике шагыйрь турында» дигән мәкаләсендә Һади Такташ иҗатына уңай бәя биреп, шагыйрьнең кайбер әсәрләрен принципиаль рәвештә тәнкыйтьли. Такташ иҗатындагы җитешсезлекләрне ул аның кайбер шигырьләрендә идея һәм теоретик юнәлешләрнең даими булмавында, әдәби форма мәсьәләләренә җиңелрәк каравында, әдәби фронтта барган көрәшне бәяләп җиткермәвендә күрә.

Муса Җәлилнең әдәби тәнкыйть өлкәсендәге мирасы бүген дә зур әһәмияткә ия. Сугыштан соңгы елларда әдәбият мәйданына баскан шагыйрьләр бүген әдипнең эстетик карашларын өйрәнәләр. Алар, Муса Җәлил кебек үк, халык шигърияте́нә, бүгенге чор кешесенең аңына мөрәҗәгать итәләр, космик эраның үзенчәлеген ачып бирергә омтылалар. Бүгенге чор шагыйрьләре Муса Җәлилнең әдәби-эстетик принципларына таянып, аларны дәвам итеп, әдәби тәнкыйть буенча да актив эшләп киләләр, татар шигърияте турында эчтәлекле мәкаләләр белән чыгыш ясыйлар.

Мәдәниятебез тарихында Муса Җәлилнең иҗаты зур урын алып тора. Совет әдәбиятына дан китергән шигырьләр иҗат итү, балалар өчен кызыклы пьесалар язу, опера һәм театр сәнгатен үстерүдә зур эш башкару, татар совет язучыларының яңа буыны формалашуы өчен көрәш алып бару — бөек әдипнең татар эстетик культурасына кертkән өлеше турында кыскача шулай әйтеп була.

Рафаэль Мостафин

# ҮСЕШТӘГЕ, ХӘРӘКӘТТӘГЕ ТӘГЪЛИМАТ

*Социалистик реализм методы хакындагы бәхәсләр уңае белән*

Матбугат битләрендә берничә ел буе социалистик реализм методы хакында кызу бәхәсләр барды. Төрле-төрле фикерләр әйтелде, бик күп мәсьәләләр кузгатылды. Ниһаять, «Правда» газетасының 1973 елгы 25 апрель санында СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты Д. Марковның «Социалистик реализмның эстетик байлыгы» дигән мәкаләсе басылып чыкты. Бу мәкаләдән соң озакка сузылган бәхәсне түгәрәкли башларга да вакыт шикелле.

Дөресен әйтергә кирәк, социалистик реализм методы хакындагы бәхәс кызыклы һәм нәтиҗәле булды. Фикер алышу барышында методның эчтәлеге һәм эстетик куәте тагын да ачыклана төште, социалистик реализм сәнгатенең чикләнмәгән мөмкинлекләргә ия булуы расланды. Шуның белән бергә, әдәбият белеме өлкәсендә яшәп килгән берьяклырак карашлар да ныграк ачыла төште. Әдәбият галимнәре арасында социалистик реализм методының мөмкинлекләренә шикләнеп караучы аерым кешеләр бар иде. Алар совет сәнгатенең нигезен какшатуга китерә торган фикерләр белән чыктылар, безнең сәнгатьтә, социалистик реализм методы белән бергә, башка иҗат методлары да «янәшә тыныч яшәргә» мөмкин, дигән хата теорияне алга сөрделәр. Мондый караш, бик хаклы рәвештә, кире кагылды.

Яшерен-батырын түгел, әлеге теориянең шаукымы күпмедер дәрәҗәдә безгә дә килеп җиткән иде. Матбугат битләрендә үк булмаса да, Язучылар союзында уздырылган кайсыдыр җыелышта танылган тәнкыйтьчеләребезнең берсе, хәзерге татар әдәбиятында критик реализм әсәрләре дә яшәргә хаклы, дип белдерде. Н. Фәттахның «Артта калган юллар» һәм А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повестьларын шундый әсәрләр рәтенә кертте. Татар совет әдәбиятында романтизм методы белән иҗат ителгән әсәрләрнең яшәргә тиешлеге турындагы фикер исә тагын да активрак һәм әзлеклерәк төстә үткәрелде. Аерым алганда, мондый караш В. Воздвиженскийның «Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәре» турында» [1] исемле китабында ачык чагылды.

Мондый теорияләрнең төп кимчелеге һәм зарары шунда, алар, тегеләйме-болаймы, социалистик реализм методын какшатуга хезмәт итәләр. Әгәр

[1] В. Воздвиженский. «Моабитские тетради» Мусы Джалиля. Рус телендә. Мәскәү. «Наука» нәшрияты. 1970 ел.

социалистик реализм методы белән янәшә тагын ниндидер методлар яши ала икән, ул чагында социалистик реализмның зарурлыгы, кирәклеге дә калмый булып чыга. Ахыр чиктә мондый карашлар безнең әдәбиятның идея көчен йомшартуга китерәләр.

Фикеребезне дәлилләү өчен Н. Фәттахның «Артта калган юллары» повестен карап узыйк. Безнең тәнкыйтьтә: язучы үзенең бу әсәрендә төп, хәлиткеч мәсьәләләрдә социалистик гуманизм позицияләрендә тора: сугыш елларында гади авыл кызы җилкәсенә төшкән кыенлыкларны һәм авырлыкларны ихлас кызгану һәм кайгыртучанлык белән сурәтли, дигән фикерләр әйтелгән иде инде. Шуның белән бергә, тәнкыйть әсәрнең җитди генә кимчелекләрен дә күрсәтте. Чыннан да, автор сугыш елларындагы җитешсез һәм кимчелекле якларны күрсәтү белән артыграк мавыга, геройларын үтә пассив, хәтта мескен кешеләр итеп тасвирлый. Чынбарлыкны бизәп, матурлап сурәтләгән аерым әсәрләр белән бәхәскә керәм дип, язучы урыны-урыны белән перспективаны югалтып җибәрә. Совет халкының нинди сыйфатлары аңа узган сугышта көч биргән, кыенлыкларны җиңәргә һәм мәкерле дошманны тар-мар итәргә булышкан — бу әсәр буенча әнә шуларны күз алдына китереп булмый.

Әгәр «Артта калган юллар»ны критик реализм методы белән язылган әсәр дип саныйбыз икән, ул чагында авторны гаепләргә урын да калмый. Чөнки аның әсәрендә очрый торган кимчелекләр критик реализм методының табигатеннән үк килеп чыгалар. Билгеле булганча, критик реализм методы нәкъ менә кимчелекле якларны сурәтләү, чынбарлыкны тәнкыйть итү пафосы белән көчле. Шул ук вакытта тормыштагы уңай якларны, матур башлангычларны күрсәтүдә, кешелек җәмгыятенең киләчәген яктыртуда ул социалистик реализм методыннан нык калыша. Минемчә, Н. Фәттах повестен социалистик реализмнан аерырга ярамый. Шул ук вакытта авторга туп-туры әйтергә кирәк: ул социалистик реализмның мөмкинлекләреннән ахырга кадәр файдалана алмаган, шуңа күрә аның әсәре бу хәлендә безне канәгатьләндереп җиткерми.

А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир» повесте турында да чама белән шул ук сүзләрне кабатларга мөмкин. Ул — кызыклы, үзенчәлекле һәм, һичшиксез, социалистик реализм методы белән язылган әсәр. Ләкин идея-сәнгатьчә эшләнеше ягыннан аның да кимчелекләре шактый әле.

Никадәр генә абстракт төстә бармасыннар, романтизм турындагы бәхәсле фикерләрнең дә иҗат практикасына турыдан-туры мөнәсәбәте бар. Әйтик, аерым әсәрләрдә очрый торган купшы урыннар, ясалмалык, һәр төрле тартып-сузып китерүләр һәм чынбарлыкны бозып сурәтләүләр еш кына романтизмга хас үзенчәлекле сыйфатлар дип аңлатылып киленде.

Билгеле, фәннең бүгенге казанышлары белән коралланган хәзерге галимнәргә социалистик реализм методын аңлау һәм аңлату өлкәсендә моңарчы яшәп килгән төрле кимчелекләрне һәм ялгышларны фаш итү кыен эш түгел. Мәсьәләнең кыен ягы ул хаталарның ни өчен барлыкка килгәнлекләрен ачыклауга кайтып кала. Элеккерәк елларда аерым очракларда без социалистик реализм методын шактый тар һәм догматик төстә, алдан уйлап куелган мәгълүм бер кагыйдәләр җыелмасы төсендәрәк аңлатып килдек шикелле. Болай аңлатканда, совет язучыларының барлык әсәрләрен алдан билгеләнгән әлеге кысалар эченә сыйдырып бетерү кыен эш булып чыкты. Һәм белгечләр, шул кыен хәлдән чыгу өчен, критик реализмны, романтизмны һәм башка иҗат методларын ярдәмгә чакырырга мәҗбүр булдылар. Тәнкыйтьче һәм әдәбият галимнәренең башка иҗат методларына мөрәҗәгать итүе, миңа калса, шуның белән дә аңлатыла.

Әйтик, бер заман социалистик реализм әсәренең үзәгендә һәр вакыт уңай герой торырга тиеш дигән караш киң таралган иде. Бөтен совет әдәбиятын тулаем күз алдында тотканда, бу, һичшиксез, дөрес караш. Социалистик реализм методы яңа геройны — социализм җәмгыятен төзүче хезмәт кешесенең, актив көрәшченең тулы канлы образын иҗат итәргә киң мөмкинлек бирде. Ләкин һәр конкрет әсәрнең үзәгендә, һичшиксез, уңай герой торырга тиеш, дигән таләпне кую мәсьәләне

артык гадиләштереп аңлатудан башка нәрсә түгел.

В. Липатовның «Соры тычкан» исемле повестен алыгыз. Әсәрдә берничә исерекнең мораль йөзе һәм тормышы тасвирлана. Алар ничек итеп беренче яртыга акча җыялар, аннан ничек итеп түземсезлек белән кибет ачылганны көтәләр, тагын эчү өчен нинди юллар белән акча юнәтәләр — әсәрдә шуларның һәммәсе хакында озак итеп һәм тәфсилләп сөйләнә. Күз алдында шактый ямьсез һәм күңелсез картина туа. Кайбер эпизодлар хәтта җирәнгеч тәэсир ясый. Социалистик реализмны тар догмалар җыелмасы төсендә күз алдына китергәндә, авторны без «чынбарлыкны бозып сурәтләүдә», безнең тормыштагы уңай һәм тискәре күренешләрнең пропорциясен бозып күрсәтүдә, хәтта совет кешеләренә яла ягуда гаепләргә тиеш булыр идек. Ләкин бөтен хикмәт тә шунда, автор безнең тормыштагы бары бер генә күренешне — совет кешеләренең матур тормышын ямьсезләп торган әчкечелекне, аның бөтен әшәкелеген, гаять зур социаль зыян китерүен ачып бирергә тели. Тәмам эштән чыккан исерекләрне бу повесть кына әчүдән туктата алмас, билгеле. Әмма шул юлга аяк кына баскан кешеләрне әсәрнең җитди төстә уйландыруы бик мөмкин. Менә шуңа күрә В. Липатовның «Соры тычкан» повесте социалистик мораль нормаларын яклый, таза тормыш өчен көрәшә һәм бернинди бәхәссез социалистик реализм кысалары эченә керә торган әсәр булып санала.

Үз вакытында бездә Ә. Еникинең «Саз чәчәге» повесте да кызу бәхәсләр уяткан иде. Кайбер тәнкыйтьчеләр авторны тискәре райком секретаре образына каршы торырлык уңай райком секретарен күрсәтмәгән өчен гаепләгәннәр иде. Ләкин бит Ә. Еники повесте бер үзәк мәсьәләгә багышланган. Язучы кайчандыр яхшы гына булган партия эшчесенең ничек итеп принципиальлеген югалтуын, халыктан аерыла һәм мещанлык сазына бата баруын күрсәтергә уйлаган. Һәм ул үз алдына куйган бу бурычны начар башкармый. Инде уңай секретарь образын бөтен тулылыгында күрсәтү өчен бөтенләй башка әсәр, әйтик, Б. Камаловның «Ялыкмаслар» повесте тибындагы әсәр иҗат итәргә кирәк булыр иде.

Танылган прозаикларыбыздан Мирсәй Әмир — күп еллык иҗат эшчәнлеге дәверендә уңай образларның бөтен бер галереясен иҗат иткән кеше. Аның «Агыйдел» повестенда һәм «Саф күңел» романында, шулай ук «Миңлекамал» һәм «Тормыш җыры» кебек пьесаларында тискәре персонажлар булса да, аларга һәр вакытта да калку итеп эшләнгән уңай образлар каршы куела килде. Заманында «идеаль герой» теориясен дә нәкъ менә М. Әмир күтәреп чыккан иде.

Соңгы елларда язган «Җан көеге» дигән повестенда М. Әмир бу кагыйдәдән читкә китте. Һәм әсәренең үзәгенә мораль гарип, сугыштан качып идән астында яткан куркак дезертир образын чыгарды. Бу шул кадәр көтелмәгән хәл булды, әсәрне аңлый һәм бәяли алмыйча аптырап беттек. Кайбер кешеләр хәтта язучы элекке принципларыннан ваз кичкән икән дип уйлауга кадәр барып җиттеләр. Бу хәлне ничек аңлатырга соң? Гаилә гарипсез булмый, диләр. Бик аз булса да, куркаклар һәм дезертирлар безнең халык арасыннан да чыккан. Төбендә М. Әмир повесте дезертирлар турында да түгел, ә халыкның шундый кешеләргә мөнәсәбәте турында. Игътибар иттегезме икән, дезертирга хәтта үз әнисе белән хатыны да никадәр чиркану һәм җирәнү белән карыйлар. Ул, карак кебек, бөтен кешедән качып яшәргә мәҗбүр. Караңгы идән астында ятып, ул шәхес буларак таркала, юкка чыга бара... М. Әмир повесте тормыштагы тискәре күренешне тикшерә, әмма үзенең идея яңгырашы ягыннан ул уңай әсәр.

50 елларда язылган кайбер хезмәтләрдә социалистик реализмның чынбарлыкны революцион үсештә сурәтләү, перспективаны күрү кирәклеге турындагы икенче бер положениесе дә шактый догматик төстә аңлатылды. Яңалыкның искелекне җиңүе безнең тормышның төп законы булудан чыгып, кайбер теоретиклар һәр әсәрдә явызлыкның җиңелүен, гаделлекнең тантана итүен күрсәтүне таләп иттеләр. Ул чагында Ч. Айтматовның «Хуш, Сарыгөл» яки «Ак пароход»ы кебек әсәрләрне кая куябыз? Миңа Г. Сигитиның («Вопросы литературы» журналы. 1973

ел. 4 сан.) Берлинда социалистик реализм мәсьәләләренә багышлап уздырылган киңәшмәдә әйткән бер фикере бик ошады. Күп кенә әсәрләрнең бәхетле тәмамлануы (җинаятьчеләр тотыла, караклар фаш ителә, консерваторлар эштән куыла һ. б.), диде ул, укучының аңын томалый, аны тынычландыра, хәлбуки, социалистик реализм әдәбиятының һәр күренекле әсәре укучы аңын активлаштыра төшәргә тиеш. Чыннан да, беренче карашка, Ч. Айтматовның «Ак пароход» исемле әсәренең ахыры артык караңгы булып күренергә мөмкин. Ләкин бит автор нәкъ шуның белән укучыларны кисәтергә тели дә: сак булыгыз, Орозкул кебек типлар безнең арада очрый әле, ди. Повесть безнең игътибарны зур социаль явызлыкка юнәлтә, ул табигатькә вәхшиләрчә мөнәсәбәтне фаш итә, бездә гражданлык намусы тәрбияли, укучыны Орозкул кебек типларга актив төстә отпор бирергә өйрәтә. Әсәрнең төп кыйммәте әнә шунда.

Г. Ахуновның «Хәзинә» романы да миңа барыннан бигрәк әнә шул сыйфаты белән ошады. Автор нефтьче хезмәтенең моңарчы кеше кулы тимәгән яңа якларын тотып алган. Бу, беренче чиратта, Кәрим Тимбиков язмышында ачык күренә. Зур саннар, шаушулы рекордлар артыннан куа торгач, романның төп герое һәлак була. Мораль яктан гына түгел, физик яктан да. Шуның белән автор җәмәгатьчелекнең игътибарын коры рекордлар артыннан куу, аерым алдынгы бригадалар тирәсендә кирәкмәгән шау-шу оештыру кебек җитди социаль мәсьәләгә юнәлтә.

Әле генә тикшереп узган әсәре кебек үк, язучының «Чикләвек төше» дә котелмәгәнчә төгәлләнә. Төп геройны, партия эшенә ахырга кадәр бирелгән кристаллдай саф коммунистны әсәр ахырында колхоз председательлегеннән алалар. Саматовның андый зур җәзага тартырлык гаебе дә юк. Ул бары райком секретаренең тормышка ашмаслык таләпләрен үтәүдән генә баш тарта... Инде төптәнрәк уйлап карасак, мондый бетем төп геройның характерыннан ук килеп чыга. Ул бит аерым шәхесләргә түгел, ә партиягә, халыкка хезмәт итә. Һәм шундый кешеләрнең булуы үзе үк безнең җәмгыятьнең көче, бездәге сәламәт атмосфера турында сөйли. Шушы әсәре өчен язучы республикабызның Г. Тукай исемендәге премиясенә лаек булган икән, бу үзе үк күп нәрсә турында сөйли.

Билгеле, мин нәкъ шундый бетемне генә закон төсенә кертергә кирәк димим. Социалистик реализм методының көче дә шунда, ул чынбарлыкны сәнгатьчә чагылдыру алымнары, материалны бирү формалары ягыннан язучыны бернинди кануннар белән чикләми. «Социалистик реализм, — дип яза Д. Марков, — эстетик платформасының ифрат киңлеге, сәнгатьчә сурәтләү байлыгының практик яктан чикләнмәгән булуы белән аерылып торган алдынгы юнәлеш буларак, XX йөздәге дөнья сәнгатенең алдынгы сафына чыкты». Бу тезис бүгенге татар әдәбиятының җанлы практикасы белән дә раслана. Х. Туфан һәм С. Хәким, Ф. Хөсни һәм М. Әмир, Ш. Галиев һәм И. Юзеев, Т. Миңнуллин һәм Д. Вәлиев, Ә. Баянов һәм М. Мәһдиев, Р. Фәйзуллин һәм Р. Харис һәм башка бик күп язучыларның иҗаты бер-берләреннән алымнар төрлелеге, сәнгатьчә тасвир формаларының байлыгы белән аерылып тора.

Социалистик реализм методын аның чыганакларыннан, ул формалашып һәм үсеп чыккан базадан башка тулысынча аңлау да, бәяләү дә кыен эш. Хәзер бу мәсьәләне аңлауда да мәгълүм бер алга китеш сизелә. Күптән түгел генә кайбер галимнәр социалистик реализмның чыганакларын пролетариат сәнгатенең аерым үрнәкләренә һәм чагылышларына гына кайтарып калдыралар иде. Бүген күпчелек әдәбият галимнәре яңа методның барлыкка килүендә критик реализмның да, шулай ук мәгърифәтчелек реализмының да мәгълүм бер өлеше булуын таныйлар. Традиция төсендә генә түгел (ул кадәресе элек тә инкарь ителми иде), ә хәлиткеч фактор буларак. Эш шунда ки, пролетариатның дөньяга карашы булган фәнни социализм бер сыйныф рамкалары белән генә чикләнми — ул киң халык массаларының социаль идеаллары белән дә тәңгәл килә. Шуңа күрә социализм чорында пролетариатның сыйнфый интереслары белән гомуми халык интереслары бер бөтенне тәшкил итәләр. Гомум халык интересларын яклаган һәм яклый торган язучылар ахыр чиктә бары-

бер революцион идеяләрне, социалистик гуманизмны раслауга килделәр (Р. Роллан, Т. Драйзер, Б. Шоу, М. Пуйманова һ. б.).

Әгәр татар әдәбиятына мөрәҗәгать итсәк, бу фикерләр җитди уйланулар һәм кайбер карашларны яңадан карап тикшеру өчен җитди азык бирәләр. Әйтик, нигә без пролетар язучысы Гафур Коләхметовның исемен телгә алабыз да, яңа методның ныгуында Г. Ибраһимов, М. Гафури, Г. Камал, ахыр килеп, Г. Тукай кебек язучылар иҗатының ролен бәяләп җиткермибез? Гомуми халык интересларын җырлаган Г. Тукайның эстетик идеалы безнең бүгенге көннәргә авазданг булуын тарих безгә исбат итте. Димәк, Г. Тукай поэзиясе, бәрәкәтле традиция буларак кына түгел, бәлки тере фактор буларак та социалистик реализмга килеп кушыла. Моннан берничә ел элек «Социалистик Татарстан» газетасы битләрендә барган бәхәс бер дә юкка гына «Бүгенге татар поэзиясендә Тукай һәм Җәлил традицияләре» дигән исем астында узмады. Төрле чорда яшәгән ике зур шагыйрьнең исеме хаклы рәвештә янәшә куелды, чөнки алар арасында узып булмаслык киртә юк. Төп, хәлиткеч мәсьәләләрдә алар иҗатының пафосы ифрат тәңгәл килә.

Ләкин мондый караш метод мәсьәләсен артык киңәйтеп җибәрүгә, «ярлары булмаган реализм»га (мин Р. Гародиның мәгълүм концепциясен күздә тотам) алып килмиме? Юк, алып килми. Дискуссиядә катнашучыларның иң зур күпчелеге, социалистик реализм ул — тарлыктан, эстетик платформасының вульгар нормативлыгыннан, шуның белән бергә, тигезләүдән, социалистик сәнгатьнең идея нигезләрен җимерүдән азат, принципаль яңа эстетик система, дигән уртак фикергә килде.

Социалистик реализм методында төп, хәлиткеч нәрсә — дөньяга яңача караш, методның нигезен шул билгели. Марксизм тәгълиматы сәнгатьне чынбарлыкны танып-белүнең үзенчәлекле бер формасы дип саный. Нәкъ менә фәнни социализм, кешелек җәмгыяте тарихын марксистик-ленинчыл аңлау чынбарлыкны танып-белүгә, шул исәптән сәнгать юлы белән танып-белүгә дә, киң юллар ачты. Башка бер генә философик система да моны булдыра алмаган иде. Яңа методның асылы, җаны шунда. Марксистик философия күренешләрнең асылына тирәнтен үтеп керергә мөмкинлек бирә, ә бу, үз чиратында, методның эстетик новаторлыгын да билгели. Чөнки, билгеле булганча, форманы эчтәлек билгели, форма яңалыгы тормышны танып-белүнең тирәнлегенә таяна.

Шул кадәресен искәртеп үтәргә кирәк, сүз методның потенциаль мөмкинлекләре хакында гына бара. Күп нәрсә язучының талантына, сәләтенә, эрудициясенә һәм фикерләү тирәнлегенә бәйләнгән. Ләкин шуның белән бергә, Көнбатыштагы күп кенә талантлы художникларның нәкъ менә экзистенциализм, сюрреализм һәм бүгенге модернизмның башка агымнарына ияргән өчен иҗатларында кризис кичерүләрен дә истән чыгарырга ярамый.

Яңа методның философик нигезеннән әдәбиятның партиялелек принцибы килеп чыга. Бу принцип, чит илләрдәге безгә дошман кешеләр расларга маташканча, иҗади шәхеснe тигезләүне дә, өстән кушылган буенча гына язуны да күздә тотмый. Партиялелек принцибы, барыннан да элек, социалистик идеалларны аңлы һәм актив рәвештә яклауны, аңлы һәм актив рәвештә халыкка хезмәт итүне күздә тота.

Көнбатыштагы белгечләр «иҗат ирекe» дип шапырыналар, партиялелек принцибы художникны шул иректән мәхрүм итә, дип лаф оралар. Ләкин уйлап карыйк, дөньяны сәнгатьчә танып-белүдән «азат булу», халыкка хезмәт итүдән «азат булу» нәрсә дигән сүз соң? Көнбатыштагы күп кенә художникларның иҗат практикасына күз салсак, әлеге «азатлыкның» иллюзияләр, уйлап чыгарылган символлар дөньясында әсир булып яшәүдән башка нәрсә булмавын күрербез.

Миңа Америкада басыла торган «массовый» сәнгать үрнәкләре белән танышырга, көчләү, секс, табыш артыннан куу рухы белән сугарылган әдәбият әсәрләрен укырга туры килде. Бездә Америка сәнгате хакында шактый языла. Шулай да, анда чыккан китапларны үзең укый башлагач, форма кытлыгыннан да бигрәк, ул әсәрләрнең гуманизмнан, халык мәнфәгатьләреннән никадәр ерак булуын күреп шаккатасың.

Мин укыган китапларның берсендә Америка колледжларында укучы кызлар турында сүз бара. Өлкән классларда укучы кызлар «гыйффәтлеккә каршы» клуб төзиләр. Исеменнән үк күренгәнчә, бу клубка гыйффәтләрен югалткан кызлар гына кабул ителә. Клубның яшерен җыелышларында аның членнары — 15—16 яшьлек кызлар һәм егетләр — анадан тума хәлдә йөриләр. Повестьның эчтәлеген тәфсилләп язылган сексуаль процесслар тәшкил итә.

Дөрес, әсәр социаль мәсьәләләрне дә бөтенләй читләтеп узмый. Бик саф һәм инсафлы бер кызны иптәшләре әлеге клубка керергә өнди башлыйлар. Кыз моңа бик нык нәфрәтләнә. Һәм шул хакта сөйләү өчен ул әнисе янына йөгереп кайта. Кайтса, әнисе йокы бүлмәсендә сөяркәсе белән ята. Шуннан ул әтисенең эшләгән җиренә китә. Ләкин аның янына да керә алмый, әтисе секретарь кыз белән бикләнгән булып чыга. Сөйләп тә торасы юк, бу хәлләрдән соң кыз үзе генә клубка кереп калмый, күптән үзенә бәйләнеп йөргән бер егетне дә алып килә. Күрәсез, бу әсәрдә Америка яшьләренең мораль бозыклыгы сурәтләнә. Ләкин әсәрнең пафосы әлеге күренешне фаш итүгә түгел, киресенчә, аны тагын да тирәнәйтүгә, яшь укучының аңын агулауга юнәлдерелгән.

Массовый сериядә чыккан тагын бер китапның эчтәлеге менә мондый. Бәләкәй генә провинция шәһәренә яшь укытучы килеп төшә. Тиздән аның каршына җитди бер педагогик мәсьәлә килеп баса: класстагы иң яхшы укучы, иң сәләтле кыз кинәт бик начар укый башлый. Укытучы аның белән өстәмә дәресләр уздыра, бер үк материалны кат-кат аңлата — берсенең дә файдасы тими. Аптырагач, ул кызның әнисе белән сөйләшеп карарга була. Шәһәрнең иң матур урынында зиннәтләп салынган бай йортка килә. Кызның әнисе — кырыкларны узган тол хатын — педагогик темаларга сөйләшеп утыруга караганда, күңеллерәк шөгыль таба: үзенә ошаган яшь укытучыга килә-килешкә тәнен тәкъдим итә. Моның белән генә дә калмый, бөтенләй сатып ала: аның өчен шәп квартира таба, аны кыйммәтле мебельләр белән җиһазлый, сөяркәсенә иң соңгы модадагы машина бүләк итә. Яшь укытучы боларның һәммәсен бик табигый кабул итә.

Алга таба шул нәрсә ачыклана, бай хатынның кызы да укытучыга кызыгып йөри, аны үзенә карату өчен юри начар укый башлаган икән. Кыз укытучысының квартирасына килә һәм аңа үзенең тәнен тәкъдим итә. Дөрес, укытучы каршылык күрсәтеп маташа, чөнки кызның әнисеннән курка. Шулай да ахыр чиктә яшь кыз алдында җиңелергә мәҗбүр була. Шул көннән башлап яшь укытучы әнисе белән дә, кызы белән дә яши башлый. Алай гына да түгел, ул колледжда укучы тагын бер яшь кызны кочли...

Алга таба вакыйгалар түбәндәгечә үстерелә. Алданган кызның әти-әниләре укытучыга каршы эш кузгаталар. Аны суд һәм төрмә көтә. Билгеле, әлеге бай хатын аны бу бәлаләрдән йолып кала алыр иде, ләкин ул сөяркәсенең хыянәтен гафу итә алмый, шуңа күрә аңа сырты белән борыла. Шул чак тол хатынның укучы кызы актив эшкә керешә. Ул укытучы тарафыннан көчләнгән дип саналган кызның ирләр белән ялангач ятканда төшерелгән фотоларын таба. Баксаң, кыз күптән алданган икән. Димәк, укытучы гаепсез. Шуңа бүләк төсендә тол хатынның кызы бер шарт куя: укытучы аңа өйләнергә тиеш. Шулай эшлиләр дә. Укытучыга квартирасы һәм машина кала, шулар янына бай хатын кызының бирнәсе өстәлә. Хатынның кызы үз максатына ирешкәнгә шат, хатын исә кызымның төрмышын рәтли алдым дип күңелен юата.

Эчтәлеген сөйләгәндә үк күргәнсездер, әлеге әсәр буржуаз җәмгыять өчен характерлы кайбер якларны ачып салса да, ул җәмгыятьнең нигезләрен җимерергә һич тә дәгъва кылмый. Киресенчә, мондый тәртипләр мәңгелек, үзгәрә торган түгел, максатка ирешүдә барлык чаралар да яхшы, дөньядагы бөтен нәрсә, шул исәптән мәхәббәт, турылык, гаилә бәхете дә сатыла һәм сатып алына, дигән ышанычны ныгытуга хезмәт итә. Күрәсез, иҗат иреге турында күпме генә лаф ормасыннар, буржуаз әдипләр барыбер партияле булып кала, чөнки алар буржуазиянең, гомумиләштереп алганда, бөтен буржуаз җәмгыятьнең тар сыйнфый интересларына хезмәт итәләр.

Социалистик реализм язучысының иҗатында исә партиялелек һәм халык-

чанлык принциплары нигездә тәңгәл киләләр. Коммунистлар партиясе әзлекле төстә халык мәнфәгатьләрен кайгыртып килгәнгә, совет язучыларының иҗатында да партиялелек һәм халыкчанлык принциплары бер-берсеннән аерылгысыз.

Яңа методның идея нигезен марксистик-ленинчыл философия тәшкил иткәнлеге алда әйтелгән иде. Ләкин социалистик реализм белән аның төп дошманы — бүгенге буржуаз модернизм арасындагы чик идеология өлкәсенә генә кайтып калмый, ул әдәби форма өлкәсенә дә карый. Социалистик реализм, барыннан да элек, форма эчтәлек каршында икенчел, аны эчтәлек билгели, дигән караштан чыгып эш йөртә. Безнең аңлавыбызча, форма ул — эчтәлекнең чагылышы. Буржуаз идеологлар теге яки бу төстә форманың беренчеллеген яклыйлар, форманы абсолютлаштыралар. Һәр төрле формаль экспериментлар һәм күп төрле «изм»нар шуннан килеп чыга.

Марксистик эстетика: сәнгать чынбарлыкны образлы формада танып-белү чарасы, дигән караштан чыгып эш итә. Бүгенге модернизм исә сәнгатьнең нигезе булган образны инкарь итә, аны символлар һәм билгеләр, я булмаса чынбарлыкның натуралистик сурәтләре белән алмаштыра. Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, социалистик реализм шартлылыктан качмый. В. Маяковскийның «Кандала» һәм «Мунча» кебек әсәрләрен, Һ. Такташның «Җир уллары» трагедиясен искә төшерү дә җитә. Ләкин бу чынбарлыкның аерым якларын тирәнрәк ачарга ярдәм итә торган шартлылык, модернизм сәнгатендә исә ул үзмаксатка әйләнеп китә.

Шулай итеп, сәнгатьчә платформасы никадәр генә киң булмасын, социалистик реализмның бик анык эстетик принциплары бар. Менә шуңа күрә дә социалистик реализм сәнгатенең күп төрлелеге белән «ярлары булмаган реализм» теориясенең, практикада политик һәм эстетик талымсызлык теориясенең берничә уртаклыгы юк.

Берлинда үткәрелгән сөйләшү вакытында Б. Ничев (Болгария Халык Республикасыннан) болай дигән иде: «Социалистик реализмның асылы шунда, ул — дөньяга яңа, коммунистик караш, тормышка коммунистик мөнәсәбәт сәнгате. Социалистик реализм абстракт теория түгел, ә бәлки җанлы сәнгать реальлеге: аның төрле милли вариантлары бар, шул ук вакытта аңа күп әдәбиятлар өчен уртак гомуми закончалыклар хас». («Вопросы литературы» журналы. 1973 ел. 4 сан.)

Әгәр социалистик реализм теориясе елдан-ел тирәнәя, ачыклана бара, аның кайбер положениеләре яңара бара икән, монда гаҗәпләнерлек бернәрсә дә юк. Чөнки социалистик реализм катып калган, бер дә үзгәрми торган тәгълимат түгел. Совет сәнгате үсү белән бергә, мәңге тере агачның мәһабәт, шаулап торган кәүсәсе кебек, социалистик реализм турындагы фән дә гел үсә, байый бара.

# «ГАЛИЯБАНУ» НИЧЕК ЯЗЫЛГАН...

Казан дәүләт университетының фәнни китапханәсендә күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзинең шәхси архивы саклана. Анда әдипнең көндәлекләре, байтак әсәрләренең төп нөсхәләре бар. Китапханә хезмәткәрләре, университетның татар әдәбияты кафедрасы белән берлектә, бу кадерле мирасны тагын да тулыландыру уе белән яшиләр. Шушы максат белән язучы туып-үскән һәм яшәгән якларга махсус командировкалар оештырыла.

Үткән җәй миңа Уфа, Сибай, Баймак шәһәрләрендә һәм М. Фәйзи китапханә мөдире булып эшләгән Юлык авылында булырга туры килде. Анда драматургны якыннан белүчеләр байтак икән әле. Берәүләре М. Фәйзи җитәкчелегендә авылда тәүге яшьләр түгәрәге оештыруда катнашкан, икенчеләре аның белән спектакльләр куйган, кичке уеннарга йөргән. Чәчләренә күптән кырау төшсә дә, аларның йөрәкләрендә М. Фәйзи калдырган ялкын бүген дә сүнмәгән.

«Галиябану» әсәренең язылу тарихы белән кызыксынуымны белгәч, драматургның якын дуслары Әдһәм Чанышев, Мостафа Зәйнигабдинов, Гомәр Әбүбәкеров, Фәрхебану Әдһәмова һәм башкалар кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә булдылар: истәлекләр белән уртаклаштылар, адреслар юлладылар. Гомумән, үзләренең яшьлек символы булган бу драманың тарихы аларда зур кызыксыну тудырды.

* * *

Мәшһүр «Галиябану» әсәрен иҗат итәргә нинди вакыйгалар, нинди хәлләр сәбәп булган соң? Кайбер әдәбиятчылар әсәрнең язылу тарихын Татарстан белән генә бәйләү ягында торалар. Мәсәлән, әдәбият галиме Мөхәммәт Гайнуллин драматургның юбилее уңае белән язылган мәкаләсендә болай ди: «Мирхәйдәр Фәйзи 1914—16 еллар арасында авыл китапханәсендә эшли. 1916 елның җәендә Татарстанның Балтач районы авылларында да була. Шул вакытларда авыл яшьләренең тормышын, авылның этнографиясен һәм халык иҗатын да тулырак өйрәнә. Нәтиҗәдә, «Галиябану» пьесасында яшьләрнең саф мәхәббәт, ирекле тормыш өчен көрәшүләрен тагын да реальрәк шартларда алып, типик характерларда гәүдәләндереп бирүгә ирешә»[1].

«М. Фәйзинең иҗат лабораториясеннән» дигән мәкаләдә Б. Камалов та әсәрдәге «вакыйгалар хәзерге Балтач һәм Чепья районнарындагы татар авылларында булган»[2], дип яза. Башка чыганакларда да нигездә шушы ук фикер кабатлана. Драматургның 1957 елда С. Фәйзуллин редакциясендә чыгарылган ике томлык сайланмасындагы искәрмәдә дә: «Язучының көндәлек дәфтәрендәге язмалар, геройларның исемнәре Чепья районы Шода авылында шул елларда яшәгән кешеләрнең исемнәренә туры килү авторның әсәр өчен шул як авыллары тормышыннан материал алганлыгын раслый», диген юлларны очратабыз.

Бер уйлаганда, бу фикерләрдә дөреслек тә бар кебек. Чөнки драматург

[1] М. Гайнуллин. Мирхәйдәр Фәйзи, «Совет әдәбияты» журналы, 1951 ел, 11 сан, 90 бит. («М. Фәйзи 1914—16 еллар арасында авыл китапханәсендә эшли» дип, мәкалә авторы хаталана. Бу эшкә М. Фәйзи 1919 елның кышында гына керешә.— М. М.)

[2] Б. Камалов. М. Фәйзинең иҗат лабораториясеннән, «Совет әдәбияты» журналы, 1956 ел, 12 сан, 70 бит.

үзе үк көндәлегенә: «1916 ел... Октябрь, 8 ендә. Казан ягы авылларында йөреп кайттым, бу яктагы авылларда күргән матур күренешләрдән файдаланып, «Сәгадәтбану» исемле пьеса язу уе туды»[1],— дип язып куйган.

Күрәсез, дәлилләр җитди. Көндәлектән алынган бу өзек исә икеләнергә урын калдырмый төсле. Ләкин нәкъ менә шул соңгы цитата җитди уйланырга мәҗбүр итә дә инде. Тормыштагы һәр аһ-зарны, һәр тигезсезлекне үтә авыр кичергән М. Фәйзи «Галиябану»дагы нинди урыннарны «матур күренешләр» дип атый соң? Билгеле, акыллы һәм чибәр кызны көчләп кияүгә бирүне яки Хәлилнең һәлакәтен әйтми торгандыр. Димәк, язучы монда әсәрнең үзәк сюжет сызыгын билгеләгән вакыйгага кагылмый. Ул, әлбәттә, чишмә буендагы күңелле уеннарны, анда авыл яшьләренең очрашуларын күздә тота. Шулай булгач, әсәрне әдәби калыпка салырга нинди вакыйга этәреш биргән соң?

Серле йомгакның очы язучының көндәлек дәфтәрләрендәге язмаларга яшеренгән булып чыкты. 1917 елның башында теркәлгән язмаларга мөрәҗәгать итәбез: «Сәгадәтбану»ны тәвәккәлләп Мортазин-Иманскийга җибәрдем. Ул бик күтәреп каршы алды. Мактап күңелне күтәрде. Арабызда озын хатлар язышу китте. Үзе тапкан кимчелекләрне күрсәтте. Кабул ителәрдәен төзәттем. Исемен дә «Галиябану»га алыштырдым. Иң элек көенең тарихы итеп бетерсәм дә, соңыннан, чын тарихына җинаять булыр дип, үзгәрткән идем. Бу инкыйлаб пьесага бер гайре табигыйлек биргән иде. Мортазинның мәслихәте белән куана-куана әүвәлге калыбына салдым...»[2].

Димәк, драма, соңыннан нинди генә үзгәрешләр кичерүенә карамастан, башта көй тарихы буларак туган. Бу — әһәмиятле деталь.

«Сәгадәтбану» көенең тарихы күп нәрсәләрне ачыкларга ярдәм итәчәк. Ләкин аның турында язма документлар әлегә күренгәне юк. Картлар да көйне «Галиябану» буларак кына хәтерлиләр. Шулай да серле «төенне» чишәргә ярдәм итүче табылды. Уфада яшәүче Зәйнәп Зөбәерова күп еллар Баймак ягында укытучы булып эшләгән. Татар һәм башкорт әдәбиятлары укыткан. М. Фәйзи белән дә якыннан таныш булган. Драматург аның альбомына күңелле генә истәлекләр дә язып калдырган. Зәйнап ханым аларны кадерләп саклый.

— Үзем күп тапкырлар Галиябану ролен башкардым. Елый-елый уйный идем. Шуңа да бу әсәр белән бәйләнешле һәр вакыйга хәтеремдә саклана,— ди ул.— Хәзер «Галиябану» дип җырланган татар халык җырын безнең якларда элек «Сәгыйдәбану» диләр иде. Текстында да «Сәгыйдәбану, сылуым иркәм» дип кабатлый идек. Чөнки көй Сәгыйдәбану Каиповага багышлап чыгарылган. Соңга таба «Сәгадәтбану» дип җырлый башладылар. Аны Юлык авылыннан килгән бер гармунчы башлап җырлаган дип ишеткәнем бар.

Зәйнәп ханым йомшак тавыш белән көйне җырлап та күрсәтте. Сүзләре хәзерге текстан әллә ни аерылмый. Ә моңына килгәндә исә, ул хәзерге «Галиябану»га караганда гадирәк, җиңелрәк. Соңыннан Зәйнәп ханым көйнең үзе белгән тарихын сөйләде.

...Верхне-Уральск ягындагы татар авылларының берсендә, бик ярлы гаиләдә Сәгыйдәбану исемле чибәр кыз булган. Ул бер ярлы егетне сөйгән. Егет тә аны өзелеп яраткан. Ләкин алар кавыша алмаганнар. Моталлап Каипов исемле бер карт бай Сәгыйдәбануны сатып алган. Кыз йортында туй үткәрерлек булмагач, шәһәргә барып, кунакханәдә мәҗлес уздырганнар, никах укытканнар. Шуннан Моталлап Баймактан ерак түгел Темәс дигән зур авылга йорт салдырган. Яшь хатынга яхшы киемнәр алган, аның өчен махсус тройка атлар тоткан. Ә үзе Орск ягында сал агызу эше белән мәшгуль булган...

— Без, яшь егетләр, сокланып туя алмый идек аның чибәрлегенә. Тал чыбыгыдай зифа буйлы, кыйгач кара кашлы, ягымлы бер ханым иде ул,— ди шул авылда туып үскән Гайфулла ага Зөбәеров.— Бай үлгәч, Сәгыйдәбану Уфага күчте. Анда ул китап кибетендә эшләде. Бик культуралы, үзалдына укып, шактый белем алган кеше иде...

---

[1] Мирхәйдәр Фәйзи, Сайланма әсәрләр 1957 ел. 2 том. 391 бит,
[2] Шунда ук, 392 бит,

«Сагыйдәбану» көенең тарихын картлар әнә шулай аңлата. Ләкин Верхне-Уральскидан драматург яшәгән Орск якларына барып җиткәнче җырның нинди үзгәрешләр кичергәнлеге, М. Фәйзи ишеткәндә ул тарихның ни дәрәҗәдә үзгәргән булуы хәзергә билгесез. Ләкин шул ачык: Темәс авылында шундый язмышка дучар булган кыз чыннан да яшәгән. Яңа җыр да нәкъ шул чорда (1915—16 елларда), башлап шул якларда таралган. М. Фәйзи исә, әлеге көй тарихыннан файдаланып, «Галиябану» драмасының беренче вариантын язган.

Шунысы кызыклы, М. Фәйзи 1921 елда Темәскә килеп, «Кызыл Урал» газетасында эшли башлый. Монда ул сәхнә эшен дә җәелдереп җибәрә. Рәсми труппага режиссер булып, спектакльләр куя. «Галиябану», «Урал суы буенда» һәм башка драмаларны тамашачылар яратып карыйлар. Шул елның февраль аенда язучы үзенең көндәлегенә болай дип язып куйган: «Бүген ике күңелле нәрсә ишеттем бит әле: берсе — бер алтмыш яшьлек карт бер кешегә, үземне күрергә муаффак булмау сәбәпле, үзе өчен кулымны кысарга кушкан. Спектакльдә булган икән. Икенчесе — Сагыйдәбану Каипова дигән бер хатын, «Урал буе» уйналып беткәннән соң, кулымны үбәр өчен сәхнәгә менгән. Ләкин кыючылык итә алмый кире төшкән. Соңыннан икенче берәү аркылы күңеленең серләрен әйттерде... «Мин аның кулын үбәр идем, бүләкләр белән күмәр идем,— дип әйтә»,— ди. Сөйгәненә ирешә алмый, картка бирелгән икән үзе»[1].

Кызганычка каршы, М. Фәйзигә «Галиябану» драмасын иҗат итүгә сәбәп булган вакыйганың иясе белән күрешергә насыйп булмый. Автор бу хатынның кемлеген ныклап белми кала, күрәсең. Белмәве дә гаҗәп түгел. Чөнки җырның исеме Орск якларында «Сәгадәтбану» буларак таралган. Бирелә исә М. Фәйзигә Сагыйдәбану турында: «картка бирелгән яшь кыз» дип кенә аңлатулары, аның язмышы турында җентекләп сөйләп тормаулары бик ихтимал. Сөйгәненә бара алмыйча, карт байга сатылган Сагыйдәбанулар аз булганмыни ул заманда?!.

[1] Язучының көндәлегеннән, 29 нчы дәфтәр.

Сәнгать әсәрен аның тормыштагы вакыйгасы яки прототиплары белән чагыштыру кызык өчен генә эшләнми, әлбәттә. Бу алым әдипнең әдәбияттагы сайлап алу, образлы гомумиләштерү, типиклаштыру кебек закончалыкларны ничек тормышка ашыруын күзәтергә мөмкинлек бирә. Мондый чагыштыру аша әсәрнең формалашу баскычларын һәм язучының иҗади үсешен төсмерләргә була.

Билгеле булуынча, «Галиябану» драмасы җыр тарихыннан шактый үзгәргән. Сюжет корылышында да яңа тармаклар туган, байтак персонаж өстәлгән. Күп явызлыкны үзендә туплаган Исмәгыйл яшь егет итеп бирелгән. Старшина образын кертү, Хәлилнең һәлакәте авылдагы сыйнфый бәрелешне югары ноктага җиткереп күрсәтергә мөмкинлек биргән. Монда инде М. Фәйзинең, драма остасы буларак, зур иҗади хезмәте ярылып ята. Ул тормыштагы вакыйганы турыдан-туры күчереп сөйләп чыгучы гына түгел. Чынбарлыктагы хәл аның көчле фантазиясе эчен «оеткы» хезмәтен генә үтәгән. Калганы язучының хыялы тарафыннан өстәлгән. Ягъни тормыш биргән материал, язучының хыял казанында кайнап, аның уй-хисләре, дөньяга карашы нигезендә туган философиясе белән баетылган. Мәхәббәт дигән мәңгелек тема үзенчәлекле, тормышчан образларда, чорның тирән социаль бәрелешләре аша чишелгән. Нәтиҗәдә буржуаз җәмгыятьтә хезмәт кешесе бәхеткә ирешә алмый дигән идеяне сәнгатьчә гәүдәләндергән «Галиябану» драмасы туган.

Мәгълүм булганча, әсәр җиңел генә язылмаган. М. Фәйзи аны кат-кат эшкәрткән. Әле сәхнәдә куела торган «Галиябану» драманың соңгы варианты түгел. Ул 1922 елда кемнәндер алынган кульязмадан китапка кергән. Бу чорда, Казан белән ныклы бәйләнеше булмаганга, М. Фәйзи моны үзе дә белми кала. Башта ул пьесаның матбугатта чыгуына сөенә. «Ләкин китапны укып чыгу һич мәмнүн итмәде. Иң тәүге нөсхәдән басу, бер бите микән төшеп калулар планымны җимеренкерәде. Тәҗрибәләр белән үзгәртелгәне булып чыкмау елата язды. Куаныч диңгезен-

дә рәхәтләнеп йөзә алмадым...»[1], — ди язучы үзенең көндәлекләрендә.

Язучы исән чакта драма яңадан басылмаган. Ә инде соңгы елларда дөнья күргәннәре, зур булмаган үзгәрешләр белән, нигездә тәүге басма буенча алынганнар. Әсәрнең «тәҗрибәләр белән үзгәртелгәне» әле булса табылганы юк. Язучының дусларында, аның белән аралашкан кешеләрдә һәм, гомумән, шул елларда сәхнәдә уйнаучыларда аның саклануы ихтимал.

Язучының архивында калган тәүге вариантларның берсендә[2] барлыгы алты персонаж алынган. Төп героиня — Сәгадәтбану, аның сөйгән егете Вафа исеме белән аталган. Бу урында язучының көндәлегенә күз ташлау әһәмиятле: «1916 ел... Декабрьдә «Сәгадәтбану» исемле биш пәрдәлек пьеса яздым. Баш каһарман Хәлил Юлык егете Вафа Әдһәмовның тибы аркылы сөзелеп чыкты. Пьесаның язылуына да Вафа сәбәп булды. Аның ямьле күренеше вакыйгага «тон» бирде... »[3]

Кем ул Вафа Әдһәмов?

— Безнең Юлыкта элек гармунчылар күп иде, — дип сөйли язучының якын дусларыннан Вәкил ага Зәйнигабдинов (ул хәзер Сибай шәһәрендә яши). — Бик матур уйнаучылар бар иде. Тик аларның берсе дә Вафа кебек уйный алмады. Күңелләрнең иң нечкә кылларын кузгатырлык итеп, үзенчәлекле бер моң белән уйный иде ул тальянны.

Матурлыкны, моңны һәм, гомумән, авылның самими тормышын үзенең «күңел кәгъбәсе» иткән романтик язучы бу тыйнак егетнең гармунда уйнавына беренче очрашуда ук чын-чыннан гашыйк була. Алар 1915 елда, Вафа Орскидан никрут булып каралудан кайтып килгәндә, Җүнәйдә танышалар. Аның «матур көйләр уйнавы күңелемдә матур типлар, матур уйлар тудырды; гармунны матур уйнаучы матур халык егете белән дусланырга кызыгып калулар үз уңаенда иркенрәк урын алып кала алмаганнар...»[4] — дип язып куйган М. Фәйзи көндәлегенә.

Билгеле булуынча, бу очрашу эзсез калмый. Башта Вафа Әдһәмов персонаж буларак әсәргә керә. Аннан бу егеткә булган ихтирам 1919 елда драматургны Юлык авылына алып килә.

Юлык Башкортстанның Баймак районында табигатьнең гүзәл урынына, Магаш һәм Төгән дигән кечкенә елгаларның кушылган җиренә урнашкан. Тирә-якта яшел урман белән капланган таулар. Авыл зур. Ул хәзер «Сакмар» колхозының бер бригадасы. Биредә сигезьеллык мәктәп, клуб, китапханә бар.

Революциягә кадәр биредә ике мәчет булган. Авылның бай катламы нигездә сәүдәгәрләр булган. Алар утызга якын кибет, күн эшкәртү мастерскойлары тотканнар. Малайлар һәм кызлар мәктәбе ачылган. Даими рәвештә булмаса да, китапханә эшләгән. Биредә үткәрелә торган ярминкәгә Урта Азиядән дә сәүдәгәрләр килгән. Шулай итеп, Юлык бу төбәктәге башка авылларга караганда культура ягыннан шактый алда торган. Яшьләрнең байтагы Орск, Оренбург мәдрәсәләрендә һәм хәтта рус мәктәпләрендә дә укыган.

Драматург буларак даны Казанга кадәр барып җиткән М. Фәйзи ике ел ярым шушы авылда гади китапханәче булып эшли. Соңыннан Юлыкта үткәргән вакытын ул гомеренең иң якты чоры итеп искә ала. Биредә ул үзенә яңа дуслар таба. Билгеле, оста гармунчы Вафа Әдһәмов аның иң якын сердәшенә һәм киңәшчесенә әйләнә.

— Ут белән дә, су белән дә аерырлык түгел, шул кадәр дуслар иде, — дип сөйли Вафаның сеңелесе Мәрьямбикә. — Бервакыт шулай, абый белән икесенә кытай ефәгеннән бер төсле күлмәк тектереп киделәр. Мирхәйдәрнең әнисе дә якын күрә иде абыйны. Бүләк итеп аңа ике чиккән сөлге җибәрде. Без аны бик озак сакладык.

Вафа яшьли Рәмиевләрнең алтын приискаларында эшли башлый. Шахталар ерак булмаганга, байтак кеше килеп эшләгән анда Юлыктан. Егет башта алтын юган. Соңрак, тәҗрибә туплагач, аны руда разведкалауга куйганннар. Әмма шулай да Вафа авыл тормышын ташламаган. Яшьләр белән кичке уеннарга йөргән, туйлар, каз өмәләре аңардан башка үтмәгән. Ә инде никрутлар, каралырга киткәндә, еш кына Вафаны

[1] Мирхәйдәр Фәйзи, Сайланма әсәрләр, 1957, 2 том, 424 бит.
[2] Бу вариантның тулы булмаган ике генә пәрдәсе сакланган.
[3] Мирхәйдәр Фәйзи, Сайланма әсәрләр, 1957, 2 том, 392 бит.
[4] Шунда ук, 385 бит.

үзләре белән алганнар. Мондый вакытта гармунчы нинди көйләр уйнарга кирәклекне сорап тормаган.

Вафа дип тә, Хәлил дип тә дәшкәннәр аңа. Ләкин егет моның белән беркайчан да масаймаган. Аның йомшак табигате, тыйнаклыгы һәркемдә ихтирам уяткан. Күпләр хәтта Вафаның Юлык кызы Хәдичәгә булган мәхәббәтен «Галиябану» драмасының сюжеты итеп карыйлар. Моңа нигез дә бар кебек. Чөнки Хәдичә дә гаиләдә бердәнбер кыз була. Төскә чибәр, эшкә уңган бу кызга күп егетләрнең күзе төшеп йөри. Хәдичәнең әтисе һәм агалары аның Вафага булган мәхәббәтен суындырырга тырышып караганнар.

— Су сөлегедәй кызыбызны бер зимагурга бирер хәлебез юк әле, — дип, бай малаена димләгәннәр. Ләкин Хәдичә мәхәббәтенә турылыклы калган һәм Вафага ябышып чыккан. Яшьләр бик матур тормыш корганнар, балалар үстергәннәр. Аларның уллары һәм кызлары хәзер Баймак шәһәрендә яши.

Якын дусының мәхәббәт тарихын М. Фәйзи яхшы белгән. Шуңа күрә, драманың соңгы вариантларын эшләгәндә, аңардан файдаланмагандыр дию кыен, әлбәттә.

Шулай итеп, язучының Татарстанга сәяхәте «Галиябану» өчен җыр, уен бизәкләрен бирсә, аның туган ягындагы авылларда булган фаҗигале вакыйгалар, гыйбрәтле хәлләр әсәрнең үзәк сызыкларын билгеләгәнлеге ачыклана. М. Фәйзинең драма башындагы «Вакыйга Оренбург ягы авылларының берсендә» дигән искәрмәсе моны тагын бер кат раслый.

**МУСА МӨЛЕКОВ,**
Казан дәүләт университеты аспиранты.

# ФИКЕР ГАРМОНИЯСЕ

Моңарчы күп еллар буе әдәбият теориясенең эшләнмәгән булуыннан зарланып килдек. Бәхеткә каршы, соңгы елларда бу өлкәдә дә беркадәр җанлану сизелә башлады. Әдәбият тарихына һәм әдәбият теориясенә караган фәнни китаплар, төрле монографияләр елдан-ел күбрәк чыгып килә. Шундыйлардан иң элек Нил Юзиевның «Шигырь гармониясе (татар шигыре поэтикасы)» дигән китабын күрсәтергә кирәк. Ул 1972 елда Казан университеты нәшриятында басылып чыкты.

Авторның бу хезмәте матбугат битләрендә һәр яктан уңай бәя алды. Мин, беренче чиратта, филология фәннәре докторы Г. Рамазановның һәм филология фәннәр кандидатлары М. Бакиров белән Х. Мәхмүтовларның рецензияләрен күздә тотам[1]. Хезмәткә гомуми бәя бирү ягыннан рецензияләр берберләренә бик якын торалар. Аерма тик аларның гомуми яңгырашында гына. Г. Рамазанов рецензиясе эмоциональ пафос белән язылган булса, М. Бакиров фәнни анализга өстенлек бирә. Х. Мәхмүтов рецензиясе исә Н. Юзиев хезмәтләрен Г. Тукай исемендәге премиягә тәкъдим итү уңае белән язылган.

Шигырьдә ритм һәм рифма нинди вазифа башкара, шагыйрьнең иҗат процессында ритм һәм рифма ничек туа, шигъри фикер белән ни рәвешле бәйләнешләргә керә — «Шигырь гармониясе» исемле хезмәтендә Н. Юзиев әнә шул сорауларга җавап бирергә омтыла. Күрәсез, галим алдында торган бурычлар шактый катлаулы һәм четерекле. Автор аларны ничек үтәп чыккан соң?

Ритм һәм рифма шигырьне шигырь иткән төп үзенчәлекләрдән санала. Аларны тәфсилләп өйрәнү өчен еллар буе күзәтүләр алып барырга, бик күп материал тупларга кирәк. Алай гына да түгел, поэзияне тирәнтен аңламый торып, әлеге мәсьәләләрне ныклап өйрәнеп үк булмый. Биредә галим шагыйрьләргә хас шигъри сиземләүгә дә ия булырга тиеш.

Китап «Шагыйрь — ритм иясе», «Шигырь гармониясе һәм рифма» дигән ике бүлектән тора. Беренче бүлектә сүз шигырьнең ритмикасы, поэзия әсәрләренең шигъри аһәңе, үлчәм-ритмның табигате һәм башка мәсьәләләр турында бара. Ул мәсьәләләрне тикшергәндә автор бай конкрет материалга таяна, традицион поэзия әсәрләренә дә, бүгенге шигырь-поэмаларга да еш мөрәҗәгать итә. Шигъри әсәрләргә хас үзенчәлекләр даими хәрәкәттә, диалектик үзгәрешләрдә тикшерелә. Галим шигырьнең тотрыклы хасиятләрен ачыклау белән генә чикләнми, поэзия өлкәсендәге төрле яңалыкларны да күзәтеп бара. «Иске кыса эчендә яңа хасиятләр», «Такташ шигыре» кебек бүлекчәләр нәкъ әнә шул хакта сөйли. Автор, кайбер галимнәр кебек, бүгенге поэзиядә барган эзләнүләрне инкарь итү юлына басмаган. «Шигырьдәге ике тенденция» исемле бүлекчәдә, мәсәлән, ул болай ди: «Шигырьдә ике тенденция яши: берсе аның — идеаль ритмик төгәллеккә, төзеклеккә омтылу, сүзләрне ритм-үлчәм таләбенә буйсынып төркемләү. Икенчесе — ритмның үзен сөйләмгә буйсындыру, шигырьгә сөйләмне «баш» итеп кую, сүзләрне сөйләм таләбенә ияреп

[1] Г. Рамазанов. Шигърият дөньясына сәхәт. «Социалистик Татарстан» газетасы 1972 ел. 30 ноябрь; М. Бакиров. Шигырь гармониясе. «Казан утлары» журналы. 1973 ел. 5 сан; Х. Мәхмүтов. Шигырь теориясенә яңа өлеш. «Социалистик Татарстан» газетасы. 1974 ел. 24 март.

тәркемләү» (92 бит). Беренче тенденция безнең поэзиядә күптән урнашкан. Шул ук вакытта, ди ул, икенче юл белән шигырь язу да яхшы гына нәтиҗәләр бирә...

Китапның икенче бүлегендә сүз рифманың шигъри вазифалары, аваз ярашуындагы яңа өлгеләр, ак шигырь һәм башка мәсьәләләр турында бара. Галимнең тирән анализга нигезләнгән фикерләре ышандыра, дәлилле яңгырый. Автор фикеренчә, поэзия үскән саен рифманың табигате дә үзгәрә, «шигырь тукымасында ул тагы да өлгеррәк, хәрәкәтчәнрәк рәвеш ала, аның күп функцияләлеге тагы да ачыграк күренә» (220 бит).

Н. Юзиевның «Хәзерге татар поэтикасы (поэзия теориясенә кереш)» исемле икенче китабы 1973 елда Татарстан китап нәшриятында басылып чыкты. Ул «Шигырь гармониясе»нең үзенчәлекле дәвамы булып тора. Бу ике китап бер үк фәнни хезмәтнең, бер үк монографиянең аерым бүлекләрен тәшкил итәләр. «Шигырь гармониясе»ндә сүз поэтик әсәрнең шигъри тукымасы, эчке хасиятләре турында барган иде. «Хәзерге татар поэтикасы»нда күтәрелгән мәсьәләләр күп тапкыр киңрәк һәм катлаулырак. Биредә автор тикшерү чикләрен нык киңәйтә һәм шигъри әсәрнең бүгенге тормыш, күркәм традицияләр һәм чорның эстетик концепцияләре белән бәйләнешләрен күзәтә. Анализ өчен алынган материал үзе үк шуны сорый. Чөнки шагыйрь үзе бүгенге тормыш белән никадәр нык бәйләнгән булса, аның әсәренә хас шигъри сыйфатлар да шул кадәр үк заманча, яңача була. Конкрет әсәрләрне тикшергәндә, Н. Юзиев эстетиканың әнә шул объектив закончалыгына таяна.

Фәннең берәр өлкәсендә нинди дә булса яңа сүз әйтү өчен, иң элек бу өлкәдә моңа кадәр нәрсәләр эшләнгәнен ачыклау зарури. Әнә шул принципка тугрылыклы буларак, китапның керешендә автор поэтиканы өйрәнү тарихына туктала. Әдәбият теориясен өйрәнүнең төрле чорларына хас үзенчәлекләрне күзәтеп чыкканнан соң, галим поэтиканы тикшерүнең бүгенге хәлен һәм үзенең төп бурычларын ачыклый.

Китапның беренче бүлекләре әдәби иҗат процессын өйрәнүгә багышланган. Билгеле булганча, иҗат процессы уй-ният туудан башлана. Уй-ниятнең тууы объектив һәм субъектив характердагы төрле сәбәпләргә бәйләнгән. Биредә шагыйрьнең шәхси тәҗрибәсе һәм кичерешләре, аның дөньяга карашы һәм тирә-яктагы тормыш шартлары зур роль уйный. Ләкин уй-ният — ул иҗади процессның беренче адымы гына. Аны тормышка ашыру өчен шагыйрь дәвамлы иҗади эш алып барырга тиеш. Акрынлап шагыйрь күңелендә уй-ният кристаллаша башлый. Әнә шул процессның закончалыкларын ачыклау өчен, галим С. Хәкимнең «Язгы ыз, җир уллары» исемле поэмасының ничек язылуын күзәтә. Галим тарафыннан шагыйрьнең төрле язмалары, планнары, эскизлары өйрәнелә. Тикшерүче аларның һәркайсын иҗади процессның билгеле бер этабы дип бәяли, эскиз-язмаларның отышлы һәм кимчелекле якларын күрсәтеп бара. Ни өчен шагыйрь беренче планнарыннан баш тарта, нигә алдан ук эскизлар, конспектлар төзи? Бу эш әдәби-эстетик яктан ничек аклана? Автор әнә шундый сорауларга фәнни җавап эзли.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, иҗат эше барышында төрле эскизлар, конспектлар, язмалар барлыкка килә, алар уй-ниятнең кристаллашуына, чарлануына ярдәм итәләр. Авторның дәлилле күзәтүләренә һәм хезмәттә китерелгән күп санлы фактларга карагында, чын мәгънәсендәге сәнгать әсәре иҗат итү өчен дәвамлы иҗади эзләнүләр, җитди хезмәт сорала икән. Еш кына әдәби әсәр берничә вариантта языла. Иҗат процессын тулырак күз алдына китерү өчен автор бер үк әсәрнең төрле вариантларын чагыштыра. Бу мәсьәләне ачыклаганда автор кабат С. Хәким иҗатына таяна, аның «Үрләр аша» поэмасын нигез итеп ала.

Әсәрнең сәнгатьчә тукымасын формалаштыруда чорның эстетик концепциясе, милли әдәбиятның, киңрәк алганда, гомумән сәнгатьнең художество дәрәҗәсе зур роль уйный. Чөнки һәрбер әдәби әсәрнең поэтик үзенчәлекләре әлеге шартлар белән бәйләнгән.

Н. Юзиев әдәбият теориясенең әлегә бик аз өйрәнелгән мәсьәләләрен дә читләтеп үтми. Әйтик, символик сурәтләрнең шигъри мөмкинлекләре — шундый мәсьәләләрнең берсе. Әдәби символика — ул бик катлаулы һәм үзенчәлекле

шигъри күренеш. Язма поэзиядә киң таралган символик образларның шигъри тамырлары халык иҗатына барып тоташа. Шуңа күрә «шигырьдәге символиканы дөрес һәм җиңел аңлар өчен, шул халыкның сурәтле фикерләү табигатен, гасырлар буенча үзләшенгән үзенчәлекле символик образларын яхшы белергә кирәк. Шул халык төшенчә белән сурәт арасында тапкан бәйләнешкә игътибар итмәсәк, шигырь табышмакка әйләнәчәк» (159 бит). Бүгенге шигырьләрнең поэтик үзенчәлекләре хакында сүз алып барганда, автор еш кына халык иҗатыннан ук килә торган символларга мөрәҗәгать итә, аларның язма поэзиягә ничек килеп керүен, анда нинди үзгәрешләр кичереп, үзләренә лаек урын яулауларын ачыклый.

Хезмәттә әдәби иҗат процессы, шуның нәтиҗәсе буларак туган сәнгать әсәре, шигырь яки поэманың төп шигъри үзенчәлекләре һәм башка мәсьәләләр төрле яклап, тирәнтен тикшерелә. Бүгенге поэзиянең төп тенденцияләре хакында сүз барганда, Н. Юзиев болай ди: «Хәзерге поэзиядә тыгыз бәйләнешле, күп сыйдырышлы, күп планлы шигырьгә — хисси һәм тасвирый ассоциатив шигырьгә омтылыш көчәеп бара» (102 бит).

Әлегә кадәр сүз поэзиянең үзе турында барган иде. Алга таба автор тикшерү диапазонын тагы да киңәйтә төшә. Һәм поэзияне сәнгатьнең башка төрләре белән бәйләнештә өйрәнә. Билгеле булганча, сәнгатьнең аерым төрләре бер-берләре белән тыгыз бәйләнештә яши. Ләкин бу күренеш сәнгать һәм әдәбият белгечләренең игътибарыннан читтәрәк калып килә иде. Н. Юзиев бу мәсьәләгә дә яңача килә һәм аны җитди фәнни проблема дәрәҗәсенә күтәрә. Дөрес, галим үзенең төп тикшерү объекты булган поэзиядән аерылмый. Ләкин хәзер инде ул аны сәнгатьнең башка төрләре белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә. Үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, мәсьәләне бу рәвешчә киң итеп күтәрү автордан эрудиция, бай тәҗрибә һәм сәнгать төрләренең үсеш процессын яхшы белүне сорый. Бәхеткә каршы, Н. Юзиевта бу сыйфатларның һәркайсы бар. Тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече буларак, ул — әдәбият сөючеләргә күптән таныш. Моңа ышану өчен, галимнең «Муса Җәлил поэмалары» (1960), «Традицияләр яңарганда» (1966), «Сәнгатьчә матурлык һәм осталык» (1969) кебек китапларын искә төшерү дә җитә. Татар поэзиясен өйрәнү өлкәсендә күп еллар дәвамында нәтиҗәле эшләү авторга «Шигырь гармониясе»н һәм «Хәзерге татар поэтикасы»н язу өчен ышанычлы җирлек булган. Моңа кадәр Н. Юзиев күбрәк поэзиянең гомуми мәсьәләләрен күтәреп килә иде. Хәзер инде ул әдәбият белеменең чикләрен киңәйтә, мәсьәләгә киң философик һәм эстетик позиция нигезендә якын килә.

Н. Юзиев хезмәтләреннән күренгәнчә, әдипнең эстетик карашлары формалашуда сәнгатьнең һәр төре билгеле бер роль уйный. Үз чиратында әдәбият әсәрләре дә башка сәнгать төрләренә йогынты ясамый калмый. Әйтик, галим Тукай иҗатына татар, рус һәм шәрык классик әдәбиятының йогынтысын да, халыкның музыкаль-поэтик иҗаты, сынлы сәнгать һәм татар профессиональ театры тәэсирен дә күзәтә. Шул ук вакытта Тукай иҗаты да сәнгатьнең әлеге төрләренә, бигрәк тә профессиональ музыкага, зур йогынты ясаган. Бөек шагыйрь иҗатын төрле яклап өйрәнү аның иҗатының чыганакларын, поэзиясенә хас үзенчәлекләрне һәм милли культураның үсешендәге ролен тулырак итеп күз алдына китерергә ярдәм итә.

Н. Юзиев китапларында тарихилык принцибы эзлекле саклана. Аның фикеренчә, гасыр башында сәнгать төрләре арасындагы бәйләнешләр гадирәк була. Утызынчы-кырыгынчы елларда исә әдәбиятның музыка, рәсем сәнгате, милли балет һәм опера белән бәйләнешләре катлаулана төшә. Театр һәм драматургия тәэсирендә поэзия үзе дә җитди үзгәрешләр кичерә, анда драма әсәрләренә хас үзенчәлекләр үсеп китә. Язучыларның рухи дөньясы катлаулана, иҗади офыгы киңәя бара.

Хезмәттә әдәбиятның кино сәнгате белән булган мөнәсәбәтенә карата да кызыклы фикерләр әйтелә. Кино сәнгатенең үзенчәлекләре әдәби әсәрләрнең художество тукымасына, тел-стиль чараларына тәэсир итә икән. Бу процессны күзәтүе җиңел түгел, билгеле. Чөнки ул кайдандыр тирәннән үтә, әдәби әсәрнең эчке хасиятләрендә чагыла. Әмма шигъри әсәрләрнең тел-

стиль үзенчәлекләрен җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә автор бу мәсьәләгә дә ачыклык кертә, кино сәнгате белән әдәбиятның бер-берсен баетуын конкрет мисаллар китереп дәлилли.

Теоретик хезмәттә нинди дә булса җитди мәсьәлә күтәрелә икән, аны уңышлы хәл итү өчен конкрет мисаллар сайлый белү дә сорала. Н. Юзиев хезмәтенә бу яктан да тел-теш тидерерлек түгел. Мәсәлән, шигъри әсәрләрдә реальлекнең һәм фантастиканың берләшү процессын ачыклаганда, ул М. Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосына тукталa. Бу аңа әлеге мәсьәләгә карата җитди фикерләр әйтергә ярдәм иткән.

Моңа кадәр поэзияне өйрәнүче галимнәр күбрәк лингвистика фәннәренә таянып эш йөрттеләр. Безнең көннәрдә исә галимнәр әдәбият тарихы, әдәби тәнкыйть, музыка теориясе, археология, социология, эстетика мәгълүматларыннан да киң файдаланалар. Н. Юзиев китабы — шуның матур бер мисалы. «Йосыф-Зөләйха» поэмасының шигъри үзенчәлекләрен тикшергәндә, галим археология, тарих, этнография мәгълүматларына таяна.

Моннан тыш, хезмәттә традицион поэтиканың тарихи чагыштыру, типологик чагыштыру, структур өлешләрне таркатып карау кебек алымнары киң кулланыла. Шуның белән бергә, автор яңарак алымнарга да мөрәҗәгать итә. Алдарак әйтелгәнчә, ул шигырь-поэмаларны сәнгатьнең башка төрләрендәге әсәрләр белән чагыштыра, әдипнең иҗат процессын күзәтә, шагыйрьләр белән әңгәмәләргә, анкеталарга киң таяна, бер үк әсәрнең төрле вариантларын чагыштырып карый. Гомумән алганда, әдәбият теориясе өчен бу алымнар бөтенләй үк яңа түгел. Рус һәм чит ил әдәбиятын тикшергәндә алар киң кулланыла. Тик шагыйрьләр белән әңгәмәләргә фәнни чыганак итеп карау гына чагыштырмача яңа алым булса кирәк. Бу алымнарның кайберсен, бигрәк тә соңгысын, аерым галимнәрнең ошатмавы да мөмкин. Моны автор үзе дә сизә һәм хезмәтендә шул хакта махсус әйтеп уза. Чыннан да, документаль характердагы фәнни чыганаклар белән эш итәргә өйрәнгән галимне шәхси әңгәмәләр генә канәгатьләндереп бетермәве дә мөмкин. Ләкин биредә мәсьәләнең икенче бер ягын да истән чыгарырга ярамый. Иҗат психологиясен, мәсәлән, әдипнең үзеннән башка өйрәнеп тә булмас кебек...

Аерым урыннарда, әйтик, «Лириканың үз йөзен, үз сыйдырышлыгын эзләп» дигән бүлекчәнең соңгы битләрендә, җитди фәнни анализны гади тәнкыйть алыштыра (214—217 битләр). Урыны-урыны белән галим тәфсилле анализ белән мавыгып китә. Әмма анализ озынга сузылса, аның ышандыру көче кими. «Шигырь гармониясе»нең кайбер битләрендә бу аеруча нык сизелә иде. «Хәзерге татар поэтикасы»нда да галим бу кимчелектән котылып җитә алмаган. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Юллар, юллар» шигыренә анализ шундыйрак тәэсир калдыра (92—102 битләр).

Кайвакыт автор аерым әсәрләрдән, шагыйрьләрнең куен дәфтәрләрендәге язмалардан өзекләр китерү белән мавыгып китә. Нәтиҗәдә фикер эзлеклелеге югала башлый, хезмәтнең композицион бөтенлегенә зыян килә. «Үрләр аша» поэмасын тикшерүгә багышланган битләр әнә шундый нәтиҗәгә китерә (68—80 битләр). Сирәк кенә булса да, китапта каршылыклы теоретик фикерләр дә очрап куя. Әдәбиятның кино сәнгате белән бәйләнеше турында автор болай ди: «Кино сәнгатен татар халкының җиңел кабул итүе нәрсә белән аңлатыла? Бу күренеш, безнеңчә, татар халкының сурәтле фикерләве кинематографик фикерләүгә бик якын булуы турында сөйли. Чыннан да, халык җырларына гына мөрәҗәгать итеп карыйк. Аларда табигать күренешләре белән лирик геройның рухи халәтен янәшә кую, символлар, метафоралар белән эш итү, яки сөйгәненең портретын «эре планда» сурәтләү аз очраймыни?» (337 бит). Иң элек, шул кадәресен билгеләп үтик: күрсәтелгән сыйфатлар татар халык җырларында гына түгел, ә бәлки башка халыклар фольклорында да киң таралган. Димәк, биредә «татар халкының сурәтле фикерләве» турында гына сөйләү дөреслеккә туры килми. Икенчедән, биредә «кинематографик фикерләү»нең катнашы юк. Әлеге шигъри чараларның килеп чыгышы һәм формалашуы халыкның бик борынгы анимистик карашлары белән бәйләнгән.

Ләкин, тулаем алганда, Н. Юзиев китаплары әдәбият теориясен өйрәнүдә

зур казаныш дип бәяләнергә тиеш. Шундый зур, катлаулы һәм җитди теоретик хезмәтне вак-төяк кимчелекләрдән башка гына язу мөмкин дә түгелдер. Бу китапларның уңай яклары, аларның теоретик мәсьәләләрне өйрәнүдә гаять зур әһәмияткә ия булуы бәхәссез. «Шигырь гармониясе» һәм «Хәзерге татар поэтикасы» белән танышып чыккач, безнең проза һәм драматургиягә карата да шундый ук җитди хезмәтләр булса иде дип уйлап куясың.

Фатих УРМАНЧЕЕВ,
филология фәннәре кандидаты.

# «КАНАТЛАНЫР ЧАК»НЫҢ ЯҢА ВАРИАНТЫ

«Онытылмас еллар» трилогиясенең кайбер бүлекләре матбугатта утызынчы елларның урталарында ук күренә башлаган иде. Әсәрнең «Канатланыр чак» дип аталган соңгы кисәге 1966 елда «Казан утлары» журналында дөнья күрде.

Озакламый яраткан язучыбыз үзе дә безнең арадан китеп барды. Без инде, табигый, трилогия шушы журнал варианты белән тәгәлләнгәндер дип уйлап йөри идек. Һәм менә 1973 елда Татарстан китап нәшриятында «Канатланыр чак»ның китап варианты басылып чыкты. Әсәрнең ахырына «1965—1969 еллар» дип куелган. Димәк, кульязмасын журнал редакциясенә илтеп бирү белән, автор аны кабат эшкәртергә, аның яңа вариантын язарга утырган икән.

«Канатланыр чак»ның китап вариантын кулга алабыз. Үзгәреш кайсы өлкәләргә кагылган соң? Иң әүвәл әсәрнең хикәяләү рәвеше, стиле, формасы үзгәргән. Журнал вариантында автор вакыйгаларның иң ахырына килеп төшә дә аңа хәтле булган хәлләрне Хәлимнең искә төшерүе рәвешендә генә хикәяләп уза иде. Бу форма әсәрнең стиленә эскизлык элементлары кертеп җибәрә, автор телиме-юкмы хәл-вакыйгаларның иң мөһимнәрен, истә калырдайларын һәм кабат хәтердә тергезүгә лаеклыларын гына хәбәр итәргә тиеш була иде.

Китап вариантында И. Гази искә төшерү формасын бөтенләй диярлек кирәксенмәгән, аңа бик аз гына урын биреп, хикәяләүне нигездә вакыт эзлеклегенә, хронология тәртибенә корган. Ягъни трилогиянең беренче, икенче китапларында язучыга бик әйбәт хезмәт иткән хикәяләү стиленә кабат әйләнеп кайткан. Һәм, шулай итеп, бу җәһәттән бөтен трилогиягә стиль бөтенлеге, форма бердәмлеге биргән.

Композицион үзгәреш шактый мөһим һәм кызыклы эстетик нәтиҗәләргә китергән. Иң әүвәл вакыйгалар агышы үзенең табигый үзәненә төшкән, кысан кабыктан, кыршаудан арынгандай, иркен сулыш белән ага башлаган. Икенчедән әсәрдә сурәтләнгән тормыш киңәйгән, андагы вакыйгаларның колачы зурайган, повестька яңа буяулар, яңа төсләр өстәлгән. Шулай икәнлеген китап вариантының күләме дә раслап тора. Журнал варианты 7—8 табактан артмый иде. Китапта ул 14 табакка җиткән, ягъни бермә-бер чамасы арткан дигән сүз. Нәтиҗәдә аерым кисәкләр арасындагы элеккеге аерма беткән. Күләме ягыннан ул «Онытылмас еллар»ның алдагы өлешләренә якынлашкан. Кыскасы, трилогия чын мәгънәсендә композицион төзеклек, тәгәлләнгән төс алган.

Шунысы игътибарга лаек, күләмнең зураюы сюжет сызыкларын арттыру хисабына эшләнмәгән. Киресенчә, беренче, икенче кисәкләр белән чагыштырганда, «Канатланыр чак»та сюжет тармаклары нык кына тарая төшә. Яңа геройлардан бирегә Акчернов белән Айдаров (Броневик) килеп керә. Боларның һәр икесе институтка гражданнар сугышы кырларыннан килгән кешеләр. Китап вариантында болардан тыш, тагын материаль яктан үтә кысынкылыкта яшәп укыган, тик әрсезлеге белән генә җан саклап бара алган, алай да тормышның бормалы юлларына

керел чыгарга мәҗбүр булган студент Осипов образы өстәлә. Ләкин аларның берсе дә сюжетны тармакландыруга хезмәт итми, әсәргә яңа сызыклар алып килми. Чөнки алар студент Хәлимгә бәйле рәвештә генә тасвирланалар. Аның каравы, Хәлим өченче китапта бөтен сюжетка берүзе диярлек хуҗа булып ала. Биредә инде ул, балалык һәм үсмер чак дәверен үтеп, җиткән егет чорына килеп керә. Хәзер Хәлим, өлкә комитеты вәкиле буларак, вакыйгаларның, колхозлаштыру хәрәкәтенең каршылыклы, чәбәләнгән чоңгыллары арасында, кешеләрнең хисләре, өметләре, шикләре уртасында кала, шушы вакыйга-хисләргә билгеле бер юнәлеш бирә яки, киресенчә, иҗтимагый конфликтлар, ситуацияләр үзләре аның язмышын көтелмәгән якка борып җибәрәләр. Трилогиянең баштагы кисәкләреннән аермалы буларак, биредә барлык күренешләр дә диярлек Хәлим карашы аркылы үткәреп яктыртыла. Автор гәрчә Хәлимнең искә төшерүләре формасындагы хикәяләүдән котылса да, хәл-вакыйгаларны Хәлим уйлары, Хәлим бәяләре яктылыгында күрсәтү үзенчәлегеннән арынып җитмәгән һәм арынуны кирәксенмәгән дә. Герой карашы аркылы сурәтләү күренешләрне бер үзәккә җыярга, цементлаштырырга, аларга билгеле бер психологик төсмер бирергә ярдәм иткән.

Ил эчендәге социаль үзгәрешләрне, дөнья күләмендәге мәсьәләләрне Хәлим турыдан-туры үзенә кагыла торган мәсьәләләр кебек кабул итә, революция язмышы аның шәхси язмышына барып тоташа. Кыскасы, чорның кайнар сулышы, каршылыклары Хәлим күңеле аша үтә. Авылларда хуҗалыкны күмәкләштерү мәсьәләләре белән йөргән чакта аңа чорның, крестьян психологиясенең бик күп гыйбрәтле каршылыклары белән күзгә-күз очрашырга туры килә. Шундыйлардан, мәсәлән, Аю Көйдергән авылында ярсудан күзләре акайган халыкның Хәлим белән Ярхәмиевне алагаем кыйнап ташлаулары, мыскыллап чанага җигеп йөртүләре укучыга журнал варианты буенча да таныш иде. Яңа басмада мондый каршылыкларга, колхозлашу хәрәкәтендәге кыенлыкларга тагын җитәкчелектәге кайбер тар карашлы кешеләрнең яраксыз эш методлары, башбаштаклыклары өстәлә. Мәсәлән, Волком бюросы члены прокурор Ташмөхәммәтов ярлы егет белән кулак кызына өйләнешергә фатиха биргән өчен, партия өлкә комитеты вәкиле Хәлимне кулга алырга санкция бирә. Мондый законсыз карар Хәлим күңелендә капма-каршы уйлар кузгата. Буйсынырга мы, юкмы? Ихтыярның кайсыдыр күзәнәкләре буйсыну, аңлашу ягын куәтли. «Күңелнең икенче почмагында капма-каршы фикер талпына иде: һич буйсынырга ярамый! Ул самодурның сине кулга алырга бертөрле хакы юк! Хәлим кесәсеннән обком биргән мандатны чыгарып, тегеләргә күрсәтте:

— Укыгыз, мин теләгән кешемне төрмәдән чыгарта алам, бик теләсәм утырта да алам» [1].

Геройларның рухи дөньясында иҗтимагый мотивлар, социаль проблемалар зур урын ала. Ара-тирә хәтта әдәби персонажның политик вакыйгалар рупоры булып калу куркынычы да туып киткәли. Әмма зур художник Ибраһим Газиның абстракт күренешләргә конкрет сурәт бирү осталыгы сәнгать закончалыкларыннан читкә чыгып китәргә юл куймый.

Китап битләрендә мәхәббәт хисләрен җанлы картиналарда сурәтләргә күп урын бирелгән. Интим мөнәсәбәтләр беренче тапкыр трилогиянең икенче китабында күренә башлаган иде. Биредә үсмерләрнең тәүге саф хисләре тагын да зуррак урын ала.

«Канатланыр чак»ның журнал вариантында Кафия күбрәк футуристлар тирәсендә йөрүче бер кыз булып хәтердә кала иде. Китап вариантында автор аның кылануларын гына күрсәтеп калмый, романтик омтылыш белән яшәвен дә тулы чагылдыра. Кыскасы, әсәр дәвамында баш герой Хәлим аны төрлечә күрә, төрлечә таный. Биредә инде Кафия Хәлим тормышыннан тиз генә төшеп калмый. Әле Хәлим Галимәне яратып йөри башлаганнан соң да, Кафия егеткә бик якын, бик кадерле кеше булып кала.

Мондый мөнәсәбәт әсәргә шактый киеренке, психологик конфликтлы яңа картиналар китереп кертә. Хәлимнең

[1] Ибраһим Гази. Канатланыр чак. Повесть һәм хикәяләр. Татарстан китап нәшрияты. 1973. 216—217 битләр.

аягы авыртып яткан чакта тулай торакта өч кеше — Хәлим, Галимә, Кафия очраша. Өчесендә өч тойгы. Һәрберсе үзенекен уйлый, үзенекен кичерә. Әмма һәркайсыныкы каршылыклы.

«Хәлим ике ут арасында... Кызларны таныштырырга да кирәк, кем дип таныштырырга да белми. Таныштыру вакыты инде үтеп тә китте. Икесе белән берьюлы ничек сөйләшергә? Нәрсә турында сөйләшергә? Хәлим сүз катып карый, тегеләр дәшмиләр... Дәшми генә бер-берсен карашалар, астыртын күзәтәләр...

Галимә үзен Кафия белән чагыштырып өлгерде һәм «мин яшьрәк, матуррак» дигән фикергә килде. Кафия күрсәткән урындыкка юри утырмыйча туп-туры Хәлим янына узды һәм авыруның караватына барып утырды. Кафияне бөтен тәне белән сизеп торса да, юкка санаган сыман, демонстратив рәвештә аны игътибардан төшереп, Хәлим белән генә сөйләшә башлады.

Егет күреп тора: Кафия үзен көчләп, игътибарсыз булырга тырыша, тумбочкадан алган высшая математика китабын укыган булып утыра, ә үзе дүрт колак белән боларны тыңлый иде»... (161 бит).

Күренә ки, автор әсәрнең китап вариантында яңа психологик ситуацияләр иҗат итүгә дә ныклы игътибар биргән. Һәм алар Ибраһим Газиның рухи дөньяны катлаулылыгында, каршылыгында аңлауда сизгер психолог булуын исбатлыйлар. Тагын шунысы да бар: психологик бәрелешләр барышында ул яраткан геройларның берсен дә ямьсез итеп чыгармый, өчесе дә укучыга якын булып кала. Әдип безне кичерешләрнең эчке көче, тойгы-хисләрнең яшендәй ялтырап алуы, күңелдәге процессларның төрле позициядән торып яктыртылуы белән, кыскасы, психологик картинаның мастерларча сурәтләнүе белән җәлеп итә.

Журнал вариантында Кафия образына бөтенләк, эзлеклелек, буяулар тигезлеге җитеп бетми иде. Икенче китапта ул үзенең чибәрлегеннән, бөтенең алсулыгыннан уңайсызланып йөрүче беркатлы сөйкемле кыз итеп бирелә. Казанда исә, бигрәк тә баштагы мәлдә, Хәлимгә бөтенләй башка төстә, «футуристик» кыяфәттә, тойгы-кичерешләрдән мәхрүм калган кыланчык бер кыз кебегрәк күренә. Тора-бара ул иске эзгә төшә төшүен, әмма бу хакта автор үтеп барышлый гына әйтеп китә иде. Укучы күңелендә исә, барыннан да бигрәк, әлеге футуристик шыксызлык кына утырып кала, герой бездән шактый ерагая төшә иде. Китап вариантында автор бу кимчелекне, эзлексезлекне бетерүгә күп көч салган, Кафиянең кешелек сыйфатларын, аның тойгы-хисләрен тасвирлауга күп урын биргән. Яңа вариантта Кафиянең тынгысыз омтылыш белән яшәвенә, хәтәр бәрелешләргә атлыгып торуына, күңеленең бар ярсуын кайнап торган көрәшләр өлкәсенә күчерергә тырышуына, кыскасы, романтик характерына кат-кат басым ясала. Кафиянең батырлыгы һәм һәлакәте очраклы хәл төсен алмый, бәлки романтик натуралы кызның табигый дәвамы буларак бирелә. «Канатланыр чак»ны үзгәртеп эшләү нәтиҗәсендә, барыннан да бигрәк, Кафия образы яктыра төшкән, яңа төсләр белән балкыган.

Шуның белән бергә, Хәлим — Кафия мөнәсәбәтләрен сурәтләүне аклау өчен, автор Галимә образын бераз күләгәгәрәк авыштыруны кирәк тапкан. Журнал вариантында ул тик бер генә яктан — гаҗәп матур, сокландыргыч чибәр булуы белән генә хәтердә кала иде. Китапта исә язучы аның беркадәр тәртәгә тибеп алуларын да өстәгән. Ләкин бу шулай да психологик һәм художество җәһәтеннән акланып җитмәгән. Әгәр китап вариантындагы аерым югалтулар турында сүз чыга икән, башлыча менә шушы моментны күрсәтергә мөмкин булыр иде. Җыеп кына әйткәндә, «Канатланыр чак» китабын без яңа әсәр укыгандай кызыксынып, мавыгып укыйбыз.

Бу китапта, «Канатланыр чак» белән бергә үк, И. Газиның иң соңгы әсәрләреннән берсе — «Малайлыкта кунакта» исемле автобиографик повесте урнаштырылган, Биредә озын гомер юлы кичергән, бай тормыш тәҗрибәсе туплаган өлкән кешенең, акыл иясенең сабый чак хатирәләре тасвирлана, күңелдә ләззәтле истәлекләр тергезелә, йончу елларда ятимлектә үткән көннәрнең ачы газаплары турында күркәм сабырлык, юмор белән сөйләнә.

Автобиографик повестьның икенче яктан да зур әһәмияте бар. Бу әсәр

иҗат юлын йомгаклап барган чорда язылган. Игътибар белән укыган кеше «Малайлыкта кунакта» повесте белән «Онытылмас еллар» трилогиясе арасындагы тыгыз бәйләнешне күрми калмас, дип уйлыйм. Автор болай ди: «Кайда минем иптәшләрем? Хәбир? Касыйм? Шакир? (Синең кушаматың Челән Шакир иде бит, син буйга бик озын идең)» (264 бит.) Бу юллардан трилогиядәге Берьярым Миңнулла прототибын тануы читен түгел. Икенче бер урында түбәндәгечә яза: «Карамал юлларын бик яхшы беләм. Шушы юллар бит инде минем әтине шахталарга алып киткән, алып кайткан. Шушы юллар минем әнине алып китте дә кайтарып куймады. Шушы юллар үземне дә алып китеп балалар йортына илтеп бирде...» (Шунда ук.)

Автобиографик повестьтан күренүенчә, «Онытылмас еллар»ның нигезенә язучының үз башыннан кичкән хәлләр, революция чорына туры килгән индивидуаль һәм шул ук вакытта күпләр өчен типик булган язмыш, замандашларының эш-гамәлләре салынган. Шулай итеп, «Малайлыкта кунакта» повесте, биографик моментларны яктырту белән бергә, укучыларны язучының иҗат лабораториясенә дә алып керә.

Ләкин «Малайлыкта кунакта»ны «Онытылмас еллар»ның кыскартылган конспекты дип кенә карарга да ярамый. Уртак яклар белән беррәттән, без монда «Онытылмас еллар»да бөтенләй телгә алынмаган язмышлар күрәбез. Автобиографик повесть реаль җирлек белән иҗат фантазиясенең ни рәвешле үрелүен аңларга мөмкинлек бирә.

Китапта, ниһаять, И. Газиның берничә хикәясе һәм әдәби парчалары урын алган. Алар нигездә соңгы елларда язылганнар. Тик «Берсе өйгә ташый, берсе өйдән ташый» хикәясе һәм нәсерләре генә илленче еллар азагына туры килә. Сан ягыннан әллә ни күп булмасалар да, характерлары белән хикәяләр бер-берсеннән нык аерылалар. Аларның беришә гражданнар сугышы чоры героикасын, көрәш романтикасын гәүдәләндерә, икенчеләре драматик вакыйга-кичерешләрне чагылдыра. Драматизмны автор бер очракта иҗтимагый тормыштан алса, икенче мәлдә тормыш фәлсәфәсе өлкәсеннән ала. Хикәяләрнең өченче төре лирик хисләрне яктырта. Әдәби парчалар-нәсерләр һәммәсе дә лирик рухта язылганнар. Ләкин шундый тематик төрлелеккә дә карамастан, аларның һәммәсе дә ныклы кул, талантлы каләм белән иҗат ителгән. Соңгы елларда И. Газиның хикәя өлкәсендәге таланты аеруча үсеп китте. Ул кечкенә генә мәйданда ачык характерлар тудыру осталыгына ирешә. Бу китапта әле И. Газиның соңгы елларда иҗат иткән барлык хикәяләре дә кереп бетмәгән. Аларны тиз арада бастырып чыгару китап нәшриятының әһәмиятле бурычы булып кала.

Кыскасы, «Канатланыр чак» олы әдипнең укучыларга калдырган бик кыйммәтле бүләге булып чыккан.

**ФӘРИТ ХАТИПОВ,**
**филология фәннәре кандидаты**

# ОЛЫЛАР ДА ЯРАТЫП УКЫРЛЫК

Татарстан китап нәшрияты Миркасыйм Госмановның «Серле балбал» исемле китабын[1] басып чыгарды. Урта һәм олы яшьтәге балаларга адресланган бу китапка авторның тарихчылар, археологлар турындагы язмалары тупланган. Аларда фән кешеләренең кызыклы һәм авыр хезмәте хакында сөйләнә, кешелек җәмгыятенең борынгы тарихына караган күп төрле мәсьәләләр яктыртыла.

Китапка кергән язмаларның һәркайсы диярлек кызыксынып һәм мавыгып укыла. Бу яктан бигрәк тә «Илче кортка», «Патша курганы» дип исемләнгәннәре аеруча нык аерылып тора. Аларның һәр икесе әдәби хикәя кебек язылган. Шулай да җыентыктагы язмаларның кыйммәтен аларның сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләренә карап түгел, ә бәлки фәннилек дәрәҗәләренә, танып-белү җәһәтеннән булган әһәмиятләренә карап билгеләү дөресрәк булыр. М. Госманов, барыннан да элек, тарих галиме. Һәм аның язмалары да, беренче чиратта, кызыклы фәнни мәсьәләләр күтәрүләре, гыйльми тирәнлекләре белән игътибарны җәлеп итә.

Үзебез рәтләп белмәгән теге яки бу фән, шул өлкәдә эшләүче галимнәр турында без шактый җиңел фикер йөртәбез. Янәсе, өй салуның ние бар — мүклисе дә чутлыйсы. Ихтимал, укучылар арасында халкыбызның борынгы тарихын өйрәнүче археологлар хезмәте турында да шулайрак уйлаучылар шактый булгандыр. Баксаң, археология тикшеренүчедән зур түземлек һәм пөхтәлек, тирән белем һәм эрудиция сорый торган ифрат катлаулы һәм кыен бер фән икән.

Археолог казынулар алып барганда, җирнең һәр катламы, шул катламнардан чыккан бөтен әйберләр төгәл исәпкә алына, кайсы табылдыкның ничек һәм кайсы якка карап ятканлыгына, ни рәвешле сакланганлыгына хәтле тәфсилләп язып барыла икән. Алай гына түгел, гыйльми казынулар алып бару өчен, Фәннәр академиясеннән рөхсәт язуы — «ачык табак» дип атала торган махсус таныклык кирәк икән. Менә шул кагыйдәләрне бозган өчен, практика узучы студентлардан Борис белән Кәбирне фәнни җитәкчеләре Семен Гаврилович археологик экспедициядән куарга мәҗбүр була («Карт археолог нигә ярсыды»).

Ә инде үз эшен чын-чыннан яраткан, түземле һәм белемле тикшеренүчегә «җир китабы» кешелек җәмгыятенең борынгы дәверләренә караган бик күп серләрне ачып бирергә булыша ала. Җир астыннан чыккан борынгы акчаларга таянып, укытучы Кәрам («Чүлмәктәге тәңкәләр») Идел буе шәһәрләренең экономик хәле, культурасы турында күпме мәгълүмат бирә.

Археология белгече Игорь Андреевич, Сарай Бәркә шәһәрен казыганда табылган борынгы остаханә янындагы әйберләргә нигезләнеп, шәһәрнең бөтен тормышын күз алдына бастырырлык кызыклы хикәят сөйли («Җимерек остаханә янында»).

«Аю биргән исем» дигән этюдта Апас районындагы Аюкөйдергән авылының тарихына караган борынгы риваять белән танышабыз. «Аюдан алган оя» этюдында борынгы кешеләрнең авыр

[1] М. Госманов. Серле балбал, Татарстан китап нәшрияты, 1973 ел.

тормышы тасвирлана. Укучы китаптагы «Серле балбал», «Мамонтлар һәм кешеләр», «Йокысыз төн», «Чуен җайдак» исемле язмалардан да бик күп файдалы мәгълүмат таба алачак.

Билгеле, китаптагы язмаларның һәммәсе дә бер дәрәҗәдә язылмаган. Бик матур, җыйнак язмалар белән бергә, сүлпәнрәк язылган, таркаурак чыкканнары да очрый. Аерым язмаларда тиешенчә мотивлаштырылмаган, дәлилләп җиткерелмәгән урыннар калган. «Чаңгы узган озын юл» дигәнендә чаңгы тарихы артык тәфсилләп, кулъязмалардан өзекләр китереп, бик озын итеп язылган. Укый-укый ялыгып бетәсең. Матур гына, җыйнак кына төзелгән җөмләләрне укып барганда, аңлашылмаган яки дөрес кулланылмаган сүзләргә сөртенеп куясың. Кайбер сүзләр тартым яки килеш белән дөрес төрләнмәгән яисә үз урыннарында кулланылмаган. Мәсәлән, **күз алдына күченеп йөргән; чибәр генә шәһәр кызы; әнә теге кирпечтән салынган алка; иртәгә бүген казылган куышта көн уздырачак** һ. б.

Йомгаклап шуны әйтәсе килә: китапта археология, казыну эшләре фәнни яктан никадәр дөрес яктыртылгандыр, анысы галимнәр эше. Әмма гади укучылар аңында археология турында, авторча әйтсәк, «җир китабы» турында тулы бер картина барлыкка килә, һәм китап бездә тарихчы-археологлар хезмәтенә мәхәббәт уята.

«Серле балбал» урта һәм олы яшьтәге балалар өчен чыгарылган булса да, аны олылар да яратып укырлык.

**РЕНАТ ГАЛӘВИН.**

# «ЯШЬ ЛЕНИНЧЫ» БЕЗДӘ КУНАКТА

*Октябрь аенда «Яшь ленинчы» газетасының чыга башлавына 50 ел тула.*

*Илебездә татар укучылары өчен чыгарыла торган бу бердәнбер газетаның тарихы татар совет әдәбияты үсеше белән үрелеп бара. «Яшь ленинчы»да күренекле әдипләр Фатих Кәрим, Галимҗан Мөхәммәтшин, Ләбиб Гыйльми эшләгән. Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Абдулла Алишлар үзләренең әсәрләрен шушы газетада бастырганнар. Әдәбиятыбызның бүгенге аксакаллары да беренче иҗат шатлыкларын «Яшь ленинчы»да татыганнар.*

*Язучылар хәзер дә газетабызның кадерле кунаклары. Бу санда «Яшь ленинчы» безгә кайбер авторларын тәкъдим итә.*

## Зәкия Туфайлова

### Туган ил

Туган ил ул була бер генә.
Туган илнең кадерен бел генә.
Туган ил ул — алтын арышлар,
Туган ил ул — зифа камышлар.
Туган ил ул — иркен болыннар,
Болыннарда нәни колыннар.
Туган ил ул — зәңгәр диңгезләр,
Туган туфрак, үскән нигезләр.
Туган илдә барыбыз бертуган,
Бик кадерле безгә ул шуңа.

1972

## Марс Шабаев

### Ленин

Үстергән аны Иделем,
Иләмән иткән Илем,
Иделгә, Илгә аваздаш
Исемгә ия Ленин.

Бәхетле минем Иделем,
Ирекле минем Илем:
Иделенә һәм Иленә
Игелекле булды Ленин.
Мәңгелек иркен Иделем,
Илем мәңгелек минем.
Иделеңә, Илеңә тиң,
Идеяң мәңгелек, Ленин.
Ягымлы, моңлы, аһәңле
Әй минем туган телем:
Тоташ җыр булып яңгырый —
Иделем, Илем, Ленин.

1971

## Шәүкәт Галиев

### Рәхмәтләр хакында

Җиргә төшкәч
Бияләе,
Гафур алып
Биргән иде.
Динә аңа:
— Рәхмәт! — диде.
Малайның да
Җылы сүзгә
Кәеф килде.
Елмайды да:
— Рәхмәтеңә
Рәхмәт! — диде.
Кыз җавапсыз
Калсын диме?
Җавап бирде:
— Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәт инде!
Малай аңа
Башын иде:
— Рәхмәтемә
Рәхмәт өчен
Рәхмәтеңә
Рәхмәт! — диде.
Динә көлде.
Бик күңелле,
Рәхәт иде.
...Җиргә төшкән
Бияләйгә
Рәхмәт инде!..

1971

## Рәдиф Гатауллин

### Зәңгәр ил—бала чак иле

Туган илем — илләр иле,
Туган җирем — җирләр җире,
Бәхет җире, нур иле.
Мәңге яңгырар җыр җире.
Әйдә җырлыйк яңа бер җыр:
— Илемдә бар — иң матур ил,
Исеме — Бала чак иле.
Ямьле бала чак иле,
Зәңгәр бала чак иле,
Аяз күгең, якты көнең,
Кем генә белми сине!
Җилләрнең иң-иң җылысы
Исә синдә, зәңгәр илем!
Гөлләрнең дә иң гүзәле
Үсә синдә, бәхет иле, —
Хыяллар һәм чынлык җире!
Татулык, Дуслык, Туганлык,
Матурлык, Сафлык, Уңганлык, —
Байрагыңда шулар синең —
Язган шулай туган илем.
Серләр тулы — утрау түгел,
Әкиятләр күп — тормыш үзе.
Бакча кебек — төрле төсле
Матур ил — Бала чак иле!
Шул илдә үткән бала чак,
Җыр булып яңгырап барачак:
Ямьле бала чак иле,
Зәңгәр бала чак иле,
Аяз күгең, якты көнең,
Кем генә сөйми сине!

1971

## Равил Фәйзуллин

### Кошларга

Бездә кыш. Җир-сулар
капланды ак карга.
Әй, кошлар, сезнең хәл
ничек ул якларда?

Җылы як илләре
торганнармы көтеп,
безнең күк сөенеп,
оялар беркетеп?

Бездәге кебекме
ул җирнең таңнары?
Исләргә төшәме
туган як таллары?

Кайчакта шундый уй
шомлата күңелне:
кошкайлар, сез анда
кадерсез түгелме?

Талчыккан канатка
сыеныр җир бармы?
Очарга — тыныч күк,
ашарга — җим бармы?

Картадан карыйбыз
сез киткән якларга.
Бар анда дуслар да,
бар анда ятлар да.

...Бездә кыш. Туңмыйбыз,
Уйныйбыз күңелле.
Кошкайлар, ул якта
күңелсез түгелме?

1972

## Газиз Нәбиуллин

### Чапаевчылар

Әнием теккән
Шлёмны киеп,
Шатланып, көлеп,
Әй йөрим биеп.
Мине һәр малай:
— Чапаев, — дияр.
Кирәк инде ат,
Бик яхшыияр.
Чаптым урамга,
Бу ни эш булган?
Барлык малайлар
Бүген шлёмнан.
— Мин, — дим, — Чапаев!
Ничек күрмисез,
Сәлам бирмисез.
Хәрби тәртипне
Әллә белмисез?
— Йөрмә бер ялгыз
Масаеп,— диләр,—
Без бит үзебез
Чапаев, — диләр.

1973

## Рәшит Гәрәй

### Учакларың дөрли

Барабанчы чая малайларга
Мин кызыгып карыйм һаман да.
Картлыгымны онытып, тагын менә
Иярәсем килә аларга.
Ә аларга кызык... Әйдә, абый,
Пионерга син дә кер, диләр...
Әй үсмер чак, сүнмәс учакларың
Йөрәгемдә гел-гел дөрлиләр.
Юк, картаймый икән җырлы күңел,
Якынлашсаң да син иллегә.
Быргы тавышы серле, ерак юлга
Дәшә әнә, дәшә мине дә.
Күңел сөенә, йөрәк кушылып тибә
Көчле, дәртле поход маршына.
Һәм кабатлыйм:
Мең кат бурычлы мин
Шушы җитез сафлар каршында.
Шушы сафлар малай чакларымның
Хыялларын чынга ашырды!
Юлларыңны матур дәвам ит, дип,
Комсомолга мине чакырды.

1972

## Рөстәм Мингалимов

### Кар коела

Кар коела,
Куна өскә.
Куна кашка,
Куна күзгә.
Кар коела,
Кунак булып
Килә Җиргә,
Килә безгә.
Гаҗәп кунак,
Күпме килеп
Өмет итми
Безнең сыйны.
Бозы белән,
Кары белән,
Уен белән —
Безне сыйлый.
Йортыбыздан
Үзен читкә
Чыгарсак та
Көрәп-көрәп.
Гаҗәп кунак,
Һаман сыйлый,
Һаман килә,
Һаман керә,
Машинага
Төяп-төяп
Озатсак та
Күпме генә! —
Гаҗәп кунак,
Үз вакыты
Җитмичә ул
Китми генә.
Шаярмагыз,
Кумагыз, ди.
Куна кашка,
Куна күзгә.
Кар коела,
Кунак булып
Килә Җиргә,
Килә безгә.

1973

## Гәрәй Рәхим

### Минем тырысым

Кибеттән чиләк сатып ал, диеп,
Борчып тормадым әле әнине.
Каен тузыннан үрдем бер тырыс,
Ярдәмгә дәштем бары әбине.

Матур булсын дип бик тә тырыштым,
Күр, нинди күркәм булды тырысым.

Урманга баргач, алсу җиләкләр
Минем тырысны бик ошаттылар.
Мине өз, диеп, яфрак астыннан
Чыгып калырга ашыкты алар.

Мин җиләкләрне бик тә яратам,
Каен тырыска утыртып кайтам.

Ал җиләкләрне кызыктыруның
Бик ансат юлын уйлап таптым мин.
Каен тузыннан тырыс үрдем дә
Күп итеп җиләк җыеп кайттым мин.

Каен тырыста каен җиләге,
Бер читтә торсын кибет чиләге.

1971

## Мөдәррис Әгъләмов

### Чая малай

Ялан тәпиләрен салындырып,
Атланган да агач коймага,
Чая малай җиргә карап тора,
Өстән карап тора дөньяга.

Аякларын яктан якка гына
Әйләндерим әле дигәндә,
Кинәт кенә башы әйләнде дә
Чая малай очты түбәнгә.

Бармагыннан төшкән эзләр генә
Сызгаланып калды коймада...
Чая малай күккә карап ята,
Исе китеп ята дөньяга.

1973

# ӘДӘБИЯТ һӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ VIII СЪЕЗДЫ

23 май. Татарстан язучыларыннан бер төркем Казан вокзалында съездга килүче кунакларны каршы алды. Бу көнне РСФСР язучылар союзы идарәсе председателе, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое С. В. Михалков житәкчелегендә Мәскәү язучылары делегациясе килде. Делегация составында РСФСР язучылар союзы идарәсе секретарьларыннан берсе Виктор Тельпугов, прозаик Николай Богданов, шагыйрь Вадим Кузнецов, башкаларның газета-журнал редакцияләреннән, китап нәшриятларыннан иптәшләр бар иде. Шулай ук съездга КПСС Үзәк Комитетының Культура бүлеге мөдире урынбасары А. А. Беляев та килде.

Язучыларның икенче төркеме Казан аэропортында Уфа кунаклары — Башкортстан язучылар союзы идарәсе председателе Әсхат Мирзаһитов һәм «Агыйдел» журналының баш редакторы Рәис Низамовны, Минскидан шагыйрь О. Савицкийны, Украинадан Ф. Гаринны, Үзбәкстаннан Б. Байкабуевны, Төркмәнстаннан А. Алиевны, Әзербәйҗаннан И. Арозны, Кыргызстаннан А. Айтбаеваны, Каракалпак АССРдан К. Мамбетовны каршыладылар.

Татарстан язучыларының VIII съездына катнашу өчен күрше Чувашстаннан Н. Дедушкин, Мордовиядән И. Пиняев, Мари АССРдан С. Вишневский, Удмуртиядән Г. Сабитов һ. б. иптәшләр килделәр.

Кунаклар шул ук көнне шәһәребезнең истәлекле урыннары белән танышып йөрделәр. В. И. Ленин, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар.

24 май. Республикабыз Политик-мәгариф йортында язучыларның сигезенче съезды үзенең эшен башлады.

Съездны, кыскача кереш сүз белән, әдәбиятыбызның аксакалы, Тукай премиясе лауреаты Мирсәй Әмир ачты.

Язучылардан, кунаклардан, партия һәм җәмәгать эшлеклеләреннән торган президиум сайланды. КПСС Үзәк Комитеты Генеральный Секретаре Л. И. Брежнев житәкчелегендә КПСС Үзәк Комитеты Политбюро составын почетлы президиумга сайларга дигән тәкъдимне съезд делегатлары алкышлап каршы алдылар.

Көн тәртибендә: Татарстан язучылар союзы идарәсенең 1968—1974 еллардагы оештыру-иҗат эшчәнлеге турында отчеты, ревизия комиссиясенең отчеты, Язучылар союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составын сайлау.

Беренче мәсьәлә буенча доклад өчен сүз идарәнең председателе Зәки Нурига бирелә.

Моннан тыш проза турында Гариф Ахунов, поэзия турында Илдар Юзеев, драматургия буенча Туфан Миңнуллин, тәнкыйть турында Рафаэль Мостафин, балалар әдәбияты буенча Ләбибә Ихсанова, рус язучыларының иҗаты турында Тихон Журавлев докладлары тыңлана.

Ревизия комиссиясенең отчетын комиссия председателе Гариф Гобәй ясый.

Докладлардан соң фикер алышулар башланып, беренче сүзне Фатих Хөсни ала. Ул әдәбиятыбызның соңгы елларагы уңышларына тукталa һәм кайбер язучыларның иҗатларында күренгән кимчелекле якларны тәнкыйтьли. Татарстан журналистлар союзы председателе, «Социалистик Татарстан» газетасының редакторы Шәмси Хамматов үзенең чыгышында язучы белән газета дуслыгын сөйли. Сүз С. В. Михалковка бирелә. Ул РСФСР язучылар союзы идарәсенең Татарстан язучыларына күрсәткән эшлекле ярдәменә тукталa. Татар әдәбиятының күренекле вәкилләре Нәкый Исәнбәт, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Фатих Хөсни, урта буын язучылардан Илдар Юзеев, Шәукәт Галиев, Шамил Бикчурин һ. б. иҗатына карата күп җылы сүзләр әйтә.

25 май. Докладлар буенча фикер алышулар дәвам итте. Чыгыш ясаучылардан драматург Риза Ишморат өлкән буын драматургларның иҗатына туктала, хәзер актив эшләп килгән яшь буын драматурглар алардан өйрәнде, алар традициясен дәвам итеп язалар дигән фикер әйтте.

Әхсән Баян шагыйрьнең үз гражданлыгы турында сөйләде. Сибгат Хәким һәм Хисам Камалларның иҗат биографиясенә тукталып, бу шагыйрьләрдә уйчан лирика ялкынлы публицистика белән аралашып яши, үз вакытында публицистик шигырьләрнең әйбәт үрнәкләрен Әнвәр Давыдов та биргән иде, хәзер аның традициясен Илдар Юзеев, Марс Шабаев дәвам итә, алар ил, халык турында уйланып, әсәрләрендә проблемалар күтәрәләр, дип әйтте.

Татарстан АССР культура министры Әдип Миндубаев драматургларның иҗатына туктала һәм пьесаларда хезмәткә һәм кешенең шәхесенә кагылышлы проблемалар төп урынны алырга тиеш, аталарыбызның сугышчан батырлыгы турындагы пьесалар кирәк, әле бездә сәхнә әсәрләренең сатирик комедия, политик памфлет, романтик трагедия кебек төрләре юк, дигән фикерне әйтә. Аннан соң ул шагыйрь, композитор һәм җырчыларның үзара дуслыгына тукталып, Сибгат Хәкимнең Җәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров белән, Нури Арсланның Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи белән, Мостафа Ногманның Рөстәм Яхин белән, Илдар Юзеевның

Мирсәет Яруллин белән иҗади дуслыкта туган әсәрләренә туктала.

Татнефтьнең Ленин орденлы производство берләшмәсе начальнигы урынбасары Үзбәк Саттаров Татарстан язучыларына республикабыз нефтьчеләреннән сәлам тапшыра. Нефть республикабызның йөзен генә түгел, кешеләрнең психологиясен дә үзгәртте, ди ул. Гариф Ахунов, Рафаэль Төхфәтуллин, Әдип Маликов, Юныс Әминев, Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Әлмәттә яшәүче һ. б. язучыларның шул кешеләр турында талантлы әсәрләр язулары туырнда горурланып сөйли.

Сибгат Хәким үзенең чыгышын буыннар алмашуы белән башлап китә. Әдәбиятны үзенчәлекле шәхесләр билгели, ди ул. Татар әдәбиятының зурлыгын Ибраһимовлар, Мусалар, Әмирханнар билгели. Язучы үз чорының актив гражданины, әдәбиятны үз җилкәсендә күтәрә торган шәхес булырга тиеш. Соңгы елларда әдәбиятыбызга нәкъ менә шундый алмаш килде, әдәбиятыбызга әйбәт буын килә, ди өлкән шагыйрь.

Равил Фәйзуллин да Сибгат Хәкимнең фикерен дәвам итеп, шагыйрьнең шәхесе турында сөйли. Ул чын талантларның иҗатына хөрмәт белдерә һәм талантсызларның әдәбияттагы әрсезлеге, талымсызлыгы турында ачынып әйтә.

Композиторлар союзы идарәсе председателе Нәҗип Җиһанов шагыйрь һәм композиторның дуслыгына кагылышлы мәсьәләләргә туктала, яңа опера һәм балет өчен либреттолар язарга өнди, язучы Гази Кашшаф әдәбиятка килүче яшь көчләр турында сөйли, комсомолның әдәбияттан беркадәр ерак торуын тәнкыйтьли, Нәби Дәүли татар әсәрләрен русчага тәрҗемә итү турында сөйли һәм бу өлкәдәге чатаклыкларны тәнкыйтьли.

Тәнкыйтьче Фәрвәз Миңнуллин партиябезнең әдәбият-сәнгать тәнкыйте турындагы карарыннан соң бу өлкәдә булган күтәрелеш турында сөйли. Әдәбиятның сыйфатын күтәрүдә тәнкыйтьнең роленә туктала.

Фикер алышуларда шулай ук Буа районының «Коминтерн» колхозы механизаторы И. Гәрәев, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре З. Бохараев, Казан дәүләт университеты профессоры Х. Госман, КамАЗ төзүчеләренең комплекслы бригада бригадиры В. Филимонов, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты директоры урынбасары А. Әхмәдуллин, язучыларның Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе Р. Җиһаншина, Татарстан художниклар союзы идарәсе председателе урынбасары Ә. Тумашевлар катнашты.

Съездга килгән кунаклардан Әсхат Мирзаһитов, О. Савицкий, Ф. Гарин, Б. Байкабуев, А. Алиев, А. Айтбаева, К. Мамбетов, И. Ароз, Н. Дедушкин, И. Пиняев, С. Вишневский, Г. Сабитов иптәшләр Татарстан язучыларына сәламнәр тапшырдылар, истәлекле бүләкләр бирделәр, аларның һәркайсы үз республикалары һәм Татарстанның экономик, культура бәйләнешләре турында сөйләделәр.

Съезд тикшерелгән мәсьәлә буенча карар кабул итте. Соныннан республика Язучылары союзы идарәсенең һәм ревизия комиссиясенең яңа составы сайланды.

Съездда КПСС Татарстан өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Табеев, КПСС Үзәк Комитеты Культура бүлегенең мөдире урынбасары А. А. Беляев, КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, КПССның Казан шәһәр комитетының беренче секретаре Р. М. Мусин, ТАССР Министрлар Советы председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Н. И. Демидов, КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев речь белән чыкты.

*

* *

Съезд тикшерелгән мәсьәлә буенча карар кабул итте, идарәнең җитәкче органнарын сайлады. Татарстан язучылар союзының правление составына Мирсәй Әмир, Гариф Ахунов, Азат Әхмәдуллин, Гомәр Бәширов, Әхсән Баянов, Марсель Зарипов, Мәдинә Маликова, Әдип Маликов, Туфан Миңнуллин, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Шамил Рәкыйпов, Гәрәй Рәхим, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Сибгат Хәким, Марс Шабаев, Илдар Юзеев кертелде.

Ревизия комиссиясенә Шамил Бикчурин, Рәис Даутов, Кояш Тимбикова сайланды.

*

* *

Яңа правлениенең беренче утырышында Татарстан язучылар союзы правлениесе председателе итеп Гариф Ахунов, правление председателе урынбасары итеп Илдар Юзеев сайланды.

Утырышта Татарстан язучылар союзы правлениесенең җаваплы секретаре итеп Равил Фәйзуллин, оештыру эшләре буенча секретарь итеп Мөсәгыйть Хәбибуллин расланды.

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп Рәис Даутов сайланды.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕНӘ

Һәр елны үткәрелә торган шигырь бәйрәменә катнашу өчен Казанга быел да күп өлкәләрдән кунаклар килде. Мәскәү язучылары Ю. Кузнецов, В. Шлемский, Ленинградтан С. Макаров, Башкортстаннан Р. Бикбаев, Чуваш АССРдан М. Сеспель, Алма-Атадан Б. Исхаковлар яңа шигырьләрен укыдылар. Кунакларның чыгышы да алкышлап каршы алынды.

Бәйрәмгә килгән кунаклар, татар язучылары белән бергәләп, В. И. Ленин,

А. С. Пушкин, Габдулла Тукай, Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр куйдылар, Г. Тукайның кабере янында булдылар. Казанның тегү фабрикаларында эшчеләр, мәктәпләрдә укытучылар, укучылар белән очраштылар.

*

* *

26 апрельдә Әлмәт район культура йортында да поэзия көненә багышланган зур әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Кичәне КПССның Әлмәт шәһәр комитеты секретаре Сания Хәкимова ачты. Татарстан язучылар союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Әдип Маликов татар поэзиясендә Тукай традицияләре турында сөйләде. Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, Клара Булатова, яшь шагыйрьләрдән Фәһимә Галиева һәм Венера Туктаровалар яңа шигырьләрен укыдылар.

Көндез Әлмәт шәһәре пионерлары Тукай һәйкәленә чәчәкләр китерделәр, язучылар белән очраштылар.

## ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯЛӘР

Тугызынчы бишьеллыкның өченче хәлиткеч елы планнарын үтәү өчен социалистик ярышны җәелдерүгә багышланган мәкаләләр, очерклар, репортажлар, корреспонденцияләрне уңышлы биреп барган өчен Түбән Кама район газетасы «Ленинская правда»ның элекке редакторы Ю. Б. Шелыванов, редактор урынбасары А. Д. Данилов, редактор урынбасары Н. Е. Кузнецов, хатлар бүлеге мөдире Р. И. Гурьянова, «Без КамАЗ төзибез» дигән радио һәм телевизион тапшырулар циклы өчен, ТАССР Министрлар Советы телевидение һәм радиотапшырулар комитетының иҗтимагый-политик тапшырулар баш редакторы Р. В. Гатауллинга, радионың промышленность тапшырулары өлкән редакторы Т. К. Сәгыйтовка, радионың КамАЗдагы үз корреспонденты О. П. Равиловага, телестудиянең промышленность тапшырулар редакторы Э. В. Гужинга 1974 ел өчен Хөсәен Ямашев исемендәге республика журналистлар премияләре бирелде.

## ӘДӘБИЯТ ТУРЫНДА ЗУР СӨЙЛӘШҮЛӘР

*

* *

РСФСР язучылар союзының май аенда уздырылган пленумында «Җитмешенче еллар әдәбиятында яңалык» дигән темага зур сөйләшү булды.

Пленумда татар әдәбияты вәкилләреннән Сибгат Хәким, Гариф Ахунов, Зәки Нури, Равил Фәйзуллин һәм Әдип Маликовлар катнашты. Фикер алышуларда Гариф Ахунов чыгыш ясады. Ул татар прозасының үсеш тенденцияләре турында сөйләде. Татар әдәбиятының олы һәм урта буын вәкилләре дә, яшь көчләре дә баштанаяк уйлап чыгарылган «теория»ләр шаукымына бирелмәде. Күрәсең, ул Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал кебек классикларның традициясен, шулай ук бөек рус язучылары һәм совет классикларының, бөтендөнья әдәбиятының прогрессив язучылары традицияләрен тирәнтен хөрмәт иткәннән киләдер, диде Г. Ахунов. Башкорт язучысы Гыйлемдар Рамазанов һәм Кабардинобалкар язучысы Алим Кешоков та үзләренең чыгышларында татар прозаикларының соңгы елларда язган әсәрләренә тукталдылар. Алим Кешоков Шамил Бикчуринның «Каты токым» романына аеруча зур бәя бирде.

Пленумнан соң язучылар Лихачев исемендәге заводта һәм башкаланың төрле предприятиеләрендә эшчеләр белән очраштылар.

*

* *

Тбилиси шәһәрендә язучыларның һәм тәнкыйтьчеләрнең бөтенсоюз киңәшмәсе үткәрелде. Анда «Әдәбиятта коммунист образының гәүдәләнеше» дигән темага зур сөйләшү булды. Бу киңәшмәдә Татарстан язучылары исеменнән Габдрахман Минский катнашты. Ул Кутаиси шәһәрендәге автозаводта, В. Маяковскийның мемориаль музей йортында, мәшһүр грузин композиторы Палиашвилиның мемориаль музеенда үткәрелгән очрашуларда да булды.

«Урта Азия халыклары әдәбиятында Октябрь революциясе темасы» дигән зур сөйләшү Ашхабад шәһәрендә уздырылды. Бу кызыклы форумга татар язучысы Миркасыйм Госманов катнашты.

## КАЗАН КУНАГЫ

Дөнья халыклары республикабызның экономика һәм культурасы белән торган саен ныграк кызыксына башладылар.

Май ахырларында Казанга Дания Коммунистлар партиясенең Үзәк Комитеты члены язучы Ханс Шерфиг һәм аның хатыны художник Элисабет Шерфиг килделәр.

Дания кунакларын партиянең Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусин, язучылардан Гариф Ахунов һәм Зәки Нурилар каршы алды.

Кунаклар Казан шәһәре һәм КамАЗ белән таныштылар.

## ТАТАР ҖЫРЛАРЫ ТУРЫНДА

Венгр галиме Ласло Викарның татар музыка тарихына караган хезмәтләре барлыгы журналыбыз укучыларына элегрәк тә билгеле иде. Музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗановның «Татар халык җырлары» китабына да ул рецензия язып, «Студия музыкологика» журналында бастырды.

Доктор Ласло Викар үзенең мәкаләсендә бу китапка югары бәя бирде.

## ОЛЫ ЮБИЛЕЙ

М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театры бинасында СССР Фәннәр академиясенең 250 еллыгына багышланган тантаналы кичә уздырылды. Бу тантанага Мәскәүдән космик өйрәнүләр институты директоры, академик Роальд Сәгъдиев житәкчелегендә илебезнең күренекле галимнәре дә килгән иде.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев һәм академик Р. З. Сәгъдиев тантанага килүчеләрне котладылар, илебезнең, республикабызның фәнни казанышлары турында сөйләделәр.

СССР Фәннәр академиясенең 250 еллыгына багышланган докладны Социалистик Хезмәт Герое, академик Б. А. Арбузов сөйләде.

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында 23 майдан башлап 4 июньгә кадәр фәнни сессия эшләде. Химия, физика, биология һәм ижтимагый фәннәр секциясендә төрле темаларга күренекле галимнәр докладлар ясадылар.

«Төрки халыкларның әдәби телләрендә үсеш этаплары» дигән темага профессор Мирфатих Зәкиев, «Лингвистик стилистика һәм поэтиканың системасы һәм төзелеше» дигән темага өлкән фәнни хезмәткәр Хәлиф Курбатов, «Текстология татар тел гыйлеменең бер өлкәсе» дигән темага кече фәнни хезмәткәр И. Абдуллин, «Татар халык лирикасында традицион образлар» дигән темага өлкән фәнни хезмәткәр Илбарис Надиров, «Татарның музыкаль халык ижатын өйрәнүнең торышы һәм аның бурычлары» дигән темага кече фәнни хезмәткәр Мәхмүт Нигъмәтжановларның докладлары тыңланды.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Совет сынлы сәнгатен үстерүдәге уңышлары өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының художнигы **Әнәс Тумашевка Татарстан АССРның халык художнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## КЫЗЫКЛЫ КҮРГӘЗМӘ

Май азакларында Казанның художниклар йортында РСФСР художниклар союзы тарафыннан оештырылган күргәзмә ачылды. Бу күргәзмәгә Мәскәү художниклары Э. Г. Браговский, В. Н. Гаврилов, Ф. П. Глебов, А. М. Грицай, Е. И. Зверьков, Ю. Л. Кatц, М. П. Кончаловский, Е. Л. Леонова, Д. А. Косьмин, А. Н. Макаров, Е. А. Малегина, А. Ю. Никич, П. П. Оссовский, А. С. Папикян, В. Е. Попков, И. А. Попов, В. М. Сидоров, А. Д. Соколов, И. В. Сорокин, Г. А. Сретанский, А. А. Тутунов, С. А. Тутунов, В. А. Чуловнч, И. В. Шевандроновларның эшләре куелган иде. Күргәзмә Казан тамашачыларында зур кызыксыну уятты.

## ЮБИЛЕЙ КИЧӘЛӘРЕ

* * *

Әлмәт шәһәренең Техника йортында язучылар, нефтяниклар, укытучылар һ. б. хезмәт ияләре катнашында язучы Энже Мөэминованың юбилей кичәсе уздырылды. Гомерен балалар укытуга биргән һәм «Ефәк яулык», «Шигырьләр», «Синең өчен язам», «Минем бүләк», «Чәчәкләр китердем» һ. б. шигырь китапларының авторы булган Энжегә күп оешмалардан котлаулар килде, бүләкләр тапшырылды.

СССР Язучылар союзы идарәсеннән килгән телеграммада мондый сүзләр бар иде: «Сезне, кадерле Энже Илалетдиновна, «Өткәм чүкече тавышы» дигән поэманың һәм балалар өчен язган китапларның авторын, юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйбыз. Ныклы сәламәтлек, ижат уңышлары телибез».

Кичәнең икенче бүлегендә укучылар катнашы белән зур концерт бирелде.

Совет әдәбияты өлкәсендә уңышлы эшләве өчен һәм 50 ел тулу уңае белән **Энже Мөэминовага КПСС өлкә комитеты** һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** бирелде.

* * *

Казан шәһәренең Актерлар йортында татар профессиональ театрын оештыручыларның берсе Ильяс Кудашев-Ашказарскийның тууына 90 ел, олы буын артистларның берсе, Хезмәт батыры Мифтах Әбсәләмовның тууына 80 ел тулуга багышланган кичә уздырылды.

* * *

Татар дәүләт республика күчмә театры һәм Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге май аенда Татарстанның атказанган артисты Фәридун Юнысовка 60 яшь, ижади хезмәтенә 40 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе үткәрде.

Актерлар йортында уздырылган бу кичәдә республикабыз җәмәгатьчелеге тарафыннан котлап, юбилярга күп жылы сүзләр әйтелде, бүләкләр бирелде.

Кичәнең икенче бүлегендә Фәридун Юнысов катнашы белән спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде.

## ӘДӘБИ ОЧРАШУЛАР

«Хезмәт кешесе — әдәбиятның төп герое». Буа районында булып үткән әдәбият көннәрендә төп сөйләшү әнә шушы темага багышланган иде.

Очрашуларга катнашкан драматург Риза Ишморат, шагыйрьләрдән Мөхәммәт Садри, Мәхмүт Хәсәен, прозаик Диләрә Зөбәерова, драматург Рәйсә Ишморатова, шагыйрь Мөдәррис Әгъләмов һәм нәфис сүз остасы Фәйзи Юсупов, районның хезмәт ияләре алдында чыгышлар ясап, язучыларның сигезенче съездга хәзерлекләре һәм соңгы елларда ижат ителгән әсәрләр

турында сөйләделәр. Үзләренең иҗатлары белән таныштырдылар, әсәрләрен укыдылар.

* * *

Прозаик Мөхәммәт Мәһдиев һәм шагыйрь Илдар Юзеев Бөгелмә шәһәре медицина училищесы укучылары белән очраштылар. Аларга татар әдәбиятындагы яңалыклар турында сөйләделәр, хикәя һәм шигырьләрен укыдылар.

* * *

«Яшь ленинчы» газетасына 50 ел тулу уңае белән Балтач районы пионерлар слеты булды. Районның Культура сараена җыелган укучылар алдында язучы Габдрахман Минский һәм газетаның әдәби бүлеге мөдире, шагыйрь Хәкимҗан Халиков чыгыш ясады.

* * *

КамАЗ төзүчеләрнең 28/11 тулай торагында «Ләйсән» әдәби берләшмәсе членнары М. Газизов, Р. Юнусов, Х. Хөснуллиннар төзүче кызлар белән очраштылар. Әдәби сөйләшүләрне язучы Эдуард Касыймов алып барды.

* * *

Мытищы машина төзү заводы китапханәсендә Шамил Бикчуринның «Каты токым» романы буенча укучылар конференциясе үткәрелде.

Романның эшчеләр тормышыннан язылуы, кеше шәхесенең коллективта формалашуына багышлануы башкала машина төзүчеләрендә зур кызыксыну уятты.

Конференциядә чыгыш ясаучылар әсәрнең тормышчан булуын, ихлас күңелдән, эчке бер җылылык белән язылуын әйттеләр.

## КОНКУРСКА ЙОМГАК

«Камгэсэнергострой» берләшмәсенең партия һәм профсоюз комитетлары КамАЗ һәм Чаллы шәһәрен төзүчеләр турында иң яхшы әдәби әсәргә конкурс игълан иткән иде.

Май ахырларында конкурска йомгак ясалды.

Төзелешнең башлангыч чорын художество чаралары белән уңышлы ачкан «Ут һәм Су» романы өчен Әхсән Баяновка беренче премия бирелде.

«Кама аръягында» дигән очерклар циклы өчен икенче премия Эдуард Касыймовка бирелде.

# АБДУЛА ГОМӘР



Шушы елның 7 июлендә озакка сузылган каты авырудан соң «Казан утлары» журналының элекке редакторы, СССР язучылар союзы члены, тәрҗемәче Абдулла Гомәр вафат булды.

Абдулла Закир улы Гомәров 1906 елның 15 июлендә Оренбург шәһәрендә туган. Хезмәт юлын ул 1928 елда Казанда, «Яңалиф» китап нәшриятында башлап җибәрә. 1928—1942 елларда «Яңалиф», «Совет әдәбияты» журналларында башта әдәби сотрудник, соңыннан җаваплы секретарь булып эшли. Ә 1954 елда аны журналның баш редакторы итеп билгелиләр.

1942—54 елларда Абдулла Гомәр Татарстан китап нәшриятында матур әдәбият бүлеге мөдире, ә 1958—1963 елларда Язучылар союзында әдәби консультант булып эшли.


1945 елда ул Коммунистлар партиясе сафына керә. Кайда гына эшләмәсен, Абдулла Гомәр үзен туры сүзле, таләпчән, үз эшенә нык бирелгән, тырыш кеше итеп танытты.

Редакторлык вазифасы белән бергә Абдулла Гомәр үзе дә әдәби иҗат эше белән шөгыльләнде. Ул Д. Фурмановның «Мятеж», П. Павленконың «Баррикадалар», М. Шолоховның «Нәфрәт фәне» һәм «Алар Ватан өчен көрәштеләр» дигән әсәрләрен тәрҗемә итте. Нәфис кинофильмнарны татарчалаштыруда да тырышып, уңыш белән эшләде. Аның аерым татар язучыларының иҗатына багышланган мәкаләләре, рецензияләре дә укучыларга таныш.

Абдулла Гомәр әдәби-иҗат эшчәнлегеннән һәрвакыт җәмәгать эшләре белән алып барды: озак вакытлар Татарстан язучылар союзының партия оешмасы секретаре булып эшләде.

Татарстан язучылары, әдәбият сөючеләр, мәрхүмнең хезмәттәшләре язучы һәм тәрҗемәче, принципиаль коммунист Абдулла Закир улы Гомәровның якты истәлеген бик озак хәтердә сакларлар.

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕ.
«КАЗАН УТЛАРЫ» ЖУРНАЛЫ РЕДАКЦИЯСЕ.
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ.



Шагыйрь СИБГАТ ХӘКИМ
Ф. ӘМИНЕВ фотосы.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Язучылар, журналистлар, әдәбият фәне галимнәре, археолог һәм тарихчылар, сәнгать осталары үзләренең яңа хезмәтләрен 1975 ел өчен редакциягә тәкъдим итә башладылар.

Алар арасында:

Узган елларда «Канатлар талмасын» исемле уңышлы повесть бастырган Хәниф Хәйруллинның «Ана улларын барлый» дигән яңа әсәре, Марсель Зариповның «Квартирага ордер алгач», Җәмит Рәхимовның «Өлешемә тигән көмешем» дигән повестьлары бар.

Галимҗан Ибраһимовның тормыш иптәше Гөлсем Мөхәммәдова «Яшьлек еллары» дигән роман китерде. Исеменнән күренгәнчә үк, бу әсәр даһи язучының тормышына багышлана. Гариф Ахунов, Әмирхан Еники, Гомәр Бәшировлар да яңа әсәрләрен тәгәлләп килерләр.

Алдагы елда Хәсән Туфан һәм Әхсән Баян яңа поэмалар тәкъдим итә. Төрле буын шагыйрьләренең яңа шигырьләре дә сезнең игътибарны җәлеп итәчәк.

1975 ел юбилейларга бай. Бу елда республикабыз җәмәгатьчелеге күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның тууына 150 ел тулган көнне билгеләп үтәчәк. Шулай ук күренекле татар драматургы Таҗи Гыйззәтнең тууына 80 ел, беренче татар шагыйрәләреннән берсе Заһидә Бурнашевага 80 яшь, Бөек Ватан сугышында һәлак булган Нур Баянның тууына 70 ел, күренекле татар шагыйрьләре Шәйхи Маннур, Әхмәт Исхак, Салих Баттал, балалар язучысы Абдулла Әхмәт, прозаик Газиз Иделлеләргә 70 яшь, тәнкыйтьче Гали Халитка 60 яшь һ. б. язучыларның туган көннәре дә билгеләп үтеләчәк. Шул уңай белән журнал битләрендә юбилярларның яңа әсәрләре, аларның иҗатлары турында мәкаләләр, истәлекләр урнаштыру күздә тотыла.

Һәр елдагыча республикабызда барган бөек төзелешләр, хезмәт алдынгылары турында очерклар, фән, сәнгать, спорттагы күренекле кешеләрнең иҗат портретлары, республикабызның тарихы буенча фәнни мәкаләләр, истәлекләр, әдәбият фәненә караган гыйльми хезмәтләр, яңа китапларга рецензияләр һ. б. күп кенә материаллар урнаштырылачак.

Журналыбыз 1975 елда да бай эчтәлекле, кызыклы булыр һәм укучыларыбызга күп рухи азык, эстетик ләззәт бирер дип ышанабыз.

Сентябрь аеннан 1975 ел өчен газета-журналларга язылу башлана. Сез дә, хөрмәтле укучыбыз, «Казан утлары» журналына соңармыйча, үз вакытында язылырсыз дип өметләнәбез. Язылган вакытта журналның 73210 номерлы индексын күрсәтү мәҗбүри. Язылу бәясе бер елга 6 сум.


Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210